ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

4.2006



# 2006 ЕЛ — ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ ЕЛЫ














# Казан утлары
# Qazan utları

2006

# 4

**(1002)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Әхмәт Рәшит, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


*Бу санда*

**ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ**


Габдулла ТУКАЙ. Туган тел. *Шигырьләр.* ........ 5
Нурмөхәммәт ХИСАМОВ. Шигърияттә Тукай феномены. ........ 11
Тукай турында шагыйрьләр. ........ 16, 99, 114
Тукай турында олуг шәхесләр. ........ 18, 65, 104, 111
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. "Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь" ........ 59
Резеда ГАНИЕВА. Тукайның "Золым" шигырен укыганда... ........ 68
Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Еракта да якын Тукай. ........ 105
Әдәбият өлкәсендә Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары (1958-2005). ........ 117


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**


Марат ӘМИРХАНОВ. И, кылган догам минем... *Повесть.* ........ 19
Әхсән БАЯН. Җырлы, Тукайлы халык без... *Шигырьләр.* ........ 55
Фәнис ЯРУЛЛИН. Бер нәрсә дә булмый мәңгелек. *Шигырьләр.* ........ 73
Заһид МӘХМҮДИ. Һәркемнең үз юлы. *Роман.* ........ 78
Роза МУЛЛАНУРОВА. Бүре чагасы. *Хикәя.* ........ 122
Нәҗибә САФИНА. Яшерен уйлар. *Шигырьләр.* ........ 133


**ЯҢА ИСЕМНӘР**


Әлфия СИТДЫЙКОВА. Мин – бер инеш... *Шигырьләр.* ........ 137


**ХӘТЕР**


Миркасыйм ГОСМАНОВ. Беренче редакторым. ........ 139
Госман ӘХМӘТҖАНОВ. Әти сагынып сөйли иде. ........ 172


**СӘЯХӘТНАМӘ**


Әхәт МУШИНСКИЙ. Яңгырлы Финляндиядә. ........ 149

"Татар энциклопедиясе" битләреннән. ........ 155


**ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ**


Камил КӘРИМОВ. Татар кайчан көлгән яки Мәкәрҗә синдромы. ........ 157


**ХИСАМ КАМАЛОВКА 80 ЯШЬ**


Шамил МАННАПОВ. Иҗатта табылган бәхет. ........ 165


**ФӘН**


Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ........ 174


**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**


Тәфкил ВАФИН. Әмәйгел әби. ........ 178

"Казан утлары" архивыннан. ........ 184


**ЮМОР ҺӘМ САТИРА**


Радиф СӘГЪДИ. Сихерче Виктория. ........ 186

Берлекнең яңа әгъзалары. ........ 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"К 120-летию Г. Тукая": стихи Г. ТУКАЯ, статьи Н. ХИСАМОВА, Т. ГАЛИУЛЛИНА, Р. ГАНИЕВОЙ, Х. МИННЕГУЛОВА; стихи известных поэтов о Тукае; полный список лауреатов Государственной премии Республики Татарстан имени Г. ТУКАЯ в области литературы (с фото).
"Проза и поэзия": роман З. МАХМУДИ "У каждого своя дорога" (окончание); повесть М. АМИРХАНОВА "Моя молитва" (окончание); рассказы Р. МУЛЛАНУРОВОЙ, Т. ВАФИНА; стихи А. БАЯНА, Ф. ЯРУЛЛИНА, Н. САФИНОЙ.
"Новые имена": стихи А. СИТДИКОВОЙ.
"Память": М. УСМАНОВ. "Мой первый редактор" (о Р. Гайнанове);
Г. АХМЕТЗЯНОВ. "Воспоминания отца" (о Г. Тукае).
"Путешествия": А. МУШИНСКИЙ. "В дождливой Финляндии".
Страницы из "Татарской энциклопедии".
"История литературы": К. КАРИМОВ. "Макарьевский синдром".
"Наши юбиляры": статья Ш. МАННАПОВА к 80-летию Х. Камалова.
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
Из фотоархива журнала.
"Юмор-сатира": Р. САГДИ. "Виктория".
Новые члены Союза писателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Стихи Тукая". Картина А. ФАТХУТДИНОВА.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«To $120^{th}$ anniversary of Tukai»: verses by G. TUKAI, articles by N. HISAMOV, T. GALIULLIN, R. GANIEVA, H. MINNEGULOV; verses by the known poets about Tukai; complete list of winners of State premium of Tatarstan Republic named after TUKAI in the field of literature (from photo).
«Prose and poetry»: novel by Z. MAHMUDI «Everyone has his way» (ending);
story by M. AMIRHANOV «My pray» (ending);
stories by R. MULLANUROVA, T. VAFIN; verses by A. BAYAN, F. YARULLIN, N. SAFINA.
«New names»: verses by A. SITDIKOVA.
«Memory»: M. USMANOV. «My first editor» (about R. Gaynanov);
R. AHMETZYANOV. «Father's memoirs» (about G. Tukai).
«Travels»: A. MUSHINSKI. «In rainy Finland».
Pages from «Tatar encyclopedia».
«History of literature»: K. KARIMOV.
«Makariev syndrome».
«Our jubilee celebrators»: article by Sh. MANNAPOV to $80^{th}$ anniversary of H. Kamalov.
«Science»: A. TIMERGALIN.
«Dictionary of nation».
from photoarchive of magazine. «Humour-satire»: R. SAGDI.
«Victoria». New members of Union of writers.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Verses by Tukai». Picture by A. Fathutdinov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 5.04.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ З–200. Тираж 7100.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2006 ел.

# Габдулла Тукай

## Туган тел

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән
Әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе
Әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта
Ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
Әткәм-әнкәмне, ходам!

## Яшьләр

Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,
Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас.

Кичә якты вә милли бер күңелдән
Бүген тычкан утыдай нур табылмас.

Вә кем бар, йөз чөерми милләтеннән,
Көмеш, алтын санәмнәргә[1] табынмас?

[1] Санәм – статуя, сын (акча).

Тәти тапса сабый барган юлында,
Йомыш истән чыгар, һич айрылалмас.

Шулай яшьләр дә: юлда күрсә алтын,
Баюдан башкага күңлен дә салмас.

Сатучылык итә бездә мөхәррир,
Әдип исме аңар тагълыр-тагылмас.

Яралганмы бу яшьләр күңле әллә
Мөрәүвәт маддәсе[1] ягълыр-ягылмас?

Ышанабыз халык көчсезлегенә,
Бабайлар шөһрәтен сагъныр-сагынмас.

Тотып милләт ливасын[2], юлга чыктык:
"Бу куллар мәңге, дип, җиргә салынмас".

Җыгылдык без икөч чакрым да китми,—
Җегетләр! бездә көч юк,—ахры, булмас!

## Татар яшьләре

Дикъкатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре:
Аңламак, белмәк, тәрәкъкый[3], мәгърифәт, хикмәт белән

Әйләнеп һәм нурланып тормакта һәрдәм башлары.
Мондый күрнеш сөйнеченнән инде мин алдан беләм:

Тик болар безгә кирәк диңгез төбе гауваслары[4].
Өсттә бу ямьсез болыт баштан китәр, яңгыр явар,

Җиргә рәхмәт күк төшәр яшьләрнең изге касдлары[5].
Шаулап аккан су булыр тау башлары, тау астлары.

Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары.

Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек,—
Без аның бик зур фәхерле[6], чын брилиант кашлары!

---

[1] Мөрәүвәт маддәсе — егетлек, кешелек сыйфаты.
[2] Лива — байрак.
[3] Тәрәкъкый — прогресс.
[4] Гаувас — чумып энҗе-мәрҗән эзләүче.
[5] Касд — теләк, омтылыш.
[6] Фәхерле — мактанычлы.

## Мәхәббәт

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас—төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы.

Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь, әйтеңез, рухланмаган?
Байроның, Лермоновыңмы, Пушкиныңмы—кайсысы?

Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк,—
Парә-парә кисмәсә гыйшык, мәхәббәт кайчысы.

Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре,—әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?

Бу татар шагыйрьләрен мөмкиндер артка калдыру,
Алга сөрсен гашыйкый анчак[1] мәхәббәт камчысы.

Һич хуҗалыкны кабул итмәм бөтен дөньяга мин,
Булмага мөмкин икән гыйшык, мәхәббәт ялчысы.

Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну!—
Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?

Барча әхраре мәхәббәт[2] миннән уңда, зан итәм[3],—
Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн!—мин аларның таңчысы!

## Сәрләүхәсез

Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.

Караңгыдыр, күңелсездер гомер юлы.
Бу дөньяда кем килсә дә сиңа туры,
Шиксез, аның җәрәхәтле күкрәгендә
Яшьрен генә янып яткан хәсрәт тулы.

Мискин адәм! Тыштан уйный, тыштан көлә,
Ямьсез якны уйлап куя эчтән генә.
Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел,
Һич кайгысыз кеше булса—адәм түгел!

---

[1] Анчак—тик, бары.
[2] Барча әхраре мәхәббәт—иң кайнар мәхәббәт ияләренең барысы.
[3] Зан итәм—уйлыйм.

Бераз вакыт шатлык таба исрек кенә,
Үз-үзенә ачы агу эчреп кенә:
“Әмма дөнья нинди кызык, нинди хозур,
Бу дөньяда кемнәр бар, дип, миннән дә зур!”

## Кыйтга

Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым,
Көннәремнең һичберен дә, чөнки ак, ди алмадым.

Булды юлда киртәләр, эттән күбәйде дошманым,
Чөнки залимнәрне, өстеннәрне яклый алмадым.

Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч—шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

## Дустларга бер сүз

Менә, дустлар, мин сезләргә бер сүз сөйлим,
“Йосыф-Ягъкуб китабы”ның көен көйлим;
Ушбу милләт ертыгының җөен җөйлим,—
Җебем—кара, инәм каләм булсын имди.

***

И кардәшләр, кул тотышып алга барыйк,
Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк;
Мәдәният мәйданында урын алыйк,—
Егъла-тора алга таба атлыйк имди.

***

Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк,
Тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк;
Диңгез якасында торып, без сусамыйк,—
Хөрриятнең диңгезләре ташый имди.

***

Чиновниклар безнең канны бик күп имде,
Имәлмәсләр, җитәр инде, җитәр инде!
Мәзлумнәргә[1] якты, нурлы көннәр килде,—
Азатлыкның кояшы тугъры имди.

[1] Мәзлум—җәберләнгән (кеше).

***

Һәр милләтләр максудларын хасил итә[1],
Депутатлар ясап, Петербурга китә;
Инде нәүбәт без бичараларга җитә,—
Җыйлып-җыйлып депутатлар сайлыйк имди.

***

Бездә күзе ачык кешеләр дә бардыр,
Бу заманда гафилләргә[2] дөнья тардыр;
Бу хөррият—Манифест государьдыр,—
Кадрен белеп, кирәкләрне сорыйк имди.

***

Бу эшләрдә зәхмәтләмик муллаларны,
Дин эшендә башчы иттек без аларны;
Яхшы булыр тапшырсак без дөньяларны
Абразауный егетләргә тәмам имди.

***

Барып керик хөрриятнең кочагына,
Тәрәккыйнең күкләренә очмагына;
Бу егетләр безне дөнья оҗмагына
Кулдан тотып җитәклиләр, белең имди!

## Даһигә

Күз карашыңда синең дөнья күренде мәңге төн;
Киттең эзләп син, аны яктыртмага, идеал утын.

Гайрәт иттең, армый-талмый йөрдең ушбу юлда син,
Чын сөбатлә[4] алга бардың, бакмый уңга-сулга син.

Мин әле хәйран һаман да, белмәдем ни булганын;
Нәрсәгә артка карыйсың, утка калгач бер адым?

Ялтырау күрдеңме артта? Ут түгел ул—алтын ул;
Юк мөкаддәс нур да анда, юк җылылык—салкын ул.

---

[1] Теләкләрен тормышка ашыра.
[2] Гафил—ваемсыз, пассив (кеше).
[3] Тәрәккый—прогресс, алга китү.
[4] Сөбатлә (сөбат илә)—ныклык белән.

Изге юлны һәрвакыт алдап шулай кыскарта ул,
Син сатылмассыңмы дип, фикрең үзенә тарта ул.

Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;
Алга барганнарга тик табыла табылса—Алла Ул!

## Милли моңнар[1]

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле,—
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

[1] "Зиләйлүк" көенә (Г. Тукай искәрмәсе).

# ШИГЪРИЯТТӘ ТУКАЙ ФЕНОМЕНЫ

*Әй Тукай, ил һәм гасырда ялкының янган Тукай,*
*Ай-кояштан, хөрриятттән яктылык алган Тукай!*
*Шигъриятең турылардан турырак бер юл табып,*
*Караңгы төн караңгысын яшендәй ярган Тукай!*
*Үлемсезлек, бөеклекнең ачкычын алган Тукай,*
*Әй Тукай, ил һәм гасырда ялкының янган Тукай!*

Шәрәф Мөдәррис.

Нинди шагыйрь соң ул безнең Тукаебыз? Тукай—шигърият тарихында бер могҗиза ул. Мин иң әүвәл татар шигъриятен күздә тотам. Талант куәте белән ул—иң югары кимәлдәге даһи. Күтәргән фәлсәфи-инсани фикерләре белән дә, сәнгатьчә оста, нәфис һәм көтелмәгән ачышлары белән дә. Традицияләрне үзендә туплап, тулы чагылдыруы белән дә, милли шигырьне яна баскычка күтәргән новаторлыгы белән дә даһи шагыйрь ул Тукай. Әмма бу сәнгати-фәлсәфи һәм иҗтимагый-инсани күренешнең, феноменның эчтәлеге моның белән генә чикләнми. Иң әүвәл аның уникаль биографик язмышы һәм ул язмышның әлеге шигъри феноменда чагылышы милләтне һәм дөнья халкын хәйран калдырырлык фаҗигале булуын алыйк. Профессор Ибраһим Нуруллин: дөнья шигърияте тарихында бүтән, тагын бер шушындый трагик шәхесне табуы кыен, дип язган иде. Икеләтә-өчләтә изелүдәге татар халкы язмышын ул үз язмышында тамчыда чагылдырган кебек чагылдырган, гәүдәләндергән шагыйрь.

Шәрәф Мөдәрриснең югарыда китерелгән "Тукай" дигән шигырендә бу феноменның асылы шактый төгәл яктыртылган.

Татар шагыйренең бөек классикка мәхәббәтен аңлау да, аңлату да кыен түгел. Әмма дөнья Тукайны үзенең бөек шагыйре итеп таныймы? Без аңа халыкара ихтирамның тирән иканлеген беләбез. Ләкин дөнья аны даһи биеклектә күрәме? Чын биеклеген тулы бәяләп бетермәсә дә, дөнья аңлый, соклана. Бөек халыкның бөек шагыйре Сергей Есенин татар шагыйренең русчага тәрҗемә ителгән беренче шигырьләрен укып карауга: "Нинди бөек шагыйрь ул Тукай!" - дигән. Ул тәрҗемәләр арасында Павел Радимов башкарган "Өзелгән өмид" шигыре дә булган. Үзе даһи шагыйрь икенче даһине танып алган. Яки менә Матвей Грубиан дигән гаять талантлы яһүд шагыйренең "Тукай" шигырен алыйк:

*Когда я прохожу по улицам Казани,*
*Мне внятен, как родной, язык моих друзей.*
*Вот площадь предо мной открылась как сказанье.*
*Там каменный поэт влюбленными глазами*
*В город свой глядит, закутан в плащ теней.*
*Скажи мне, ты читал когда-нибудь Тукая?*
*Его живой строкой я покорен опять.*
*Слова летят сквозь ночь, как молнии сверкая,*
*И над моей душой им власть дана такая,*
*Что здесь и сам бы мог татарином я стать.*

Чит халык шагыйре Тукай шигъриятендә нинди сыйфатларны күрә соң? Тукай шигыренең караңгы күкне ярып яшьнәгән ярсу үткенлеген күрә. Һәм тагын нәрсәләр игътибарга лаек? Тукайның Казан чынбарлыгы белән бердәмлеге, татар халкының рухын чагылдыруы, аның абруен гәүдәләндерүе яһүд шагыйренә нык тәэсир иткән. Дөньяга сибелгән һәм тарихта күп җәбер-золым күргән халык шагыйре

татар халкының хәлен яхшы анлый, аның шагыйренә булган мәхәббәт яһүд шагыйренең үзен татар итәрдәй көчле. Янә шунсы игътибарга лаек: Шәрәф Мөдәрриснең әле күреп үткән шигырендәге мотивлар белән Матвей Грубиан шигырендәге чагыштырулар хәрефкә-хәреф диярлек тәңгәл килә:

*Караңгы төн караңгысын яшендәй ярган Тукай!*

*Слова летят сквозь ночь, как молнии сверкая...*

Чагыштыруларның мондый тәңгәллеге очраклы була алмый: яшендәй якты үткенлек—Тукай шигъри теленең асыл сыйфаты. Әйтергә кирәк ки, Тукайның үз шигырьләрендә дә яшен сурәте еш яшьнәүчән. Өметле күз карашын татар яшьләренә төбәгәндә, ул гасыр башындагы яшьтәшләренә шундый ышанычлар баглый:

*Күк булып күкрәр һавада хөр яшәу даулашлары,*
*Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары.*
*Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек,—*
*Без аның бик зур фәхерле, чын брилиант кашлары!—*

ди ул.

Үзенчәлекле фәлсәфи-сәнгатьчә янгыраш, нәфис сурәтләр һәм, кирәксә, ихтыяр-гайрәт мотивлары гасыр башының зур шагыйрьләре Дәрдеманд белән Сәгыйть Рәмиевтә дә күзәтелә. Тукай таланты, Тукай шигъриятенең эчтәлеге алардан ни белән аерыла соң?

Бу шагыйрьләрнең өчесе дә милләтнең лаеклы яшәешкә хокукын раслаучылар, аның ихтыяҗларын, тарихка, язмышка, дәүләткә карата дәгъваларын гәүдәләндерүчеләр. Әмма Тукай шигъриятендә тарихи зар да, яшәешкә һәм янарышка ихтыяр да иҗтимагый актив, максималистларча кискен гәүдәләнә. Әйтик, Сәгыйть Рәмиев лирикасында шәхеснең мохиткә, иҗтимагый шартларга ярсу таләпләре һәм ризасызлыгы янгыраса, Дәрдемәндтә мәсьәләләр тарих һәм галәм киңлегендә куелып, фәлсәфи планда яктыртыла. Тукайда милләтнең аеруча җәберләнгән һәм рәнҗетелгән өлеше—гади халык, хезмәт иясе кайгылары үзәккә куела. Менә аның "Көзге җилләр" шигырен генә алыйк. Ул 1911 елгы ачлык шартларында язылган.

Игътибар итегез: шагыйрьнең бәгъре кемнәр өчен сыкрый—ачлыктан иң күп интегүче хезмәт кешесе өчен көенә:

*Иң сөекле эшче әуладым быел ач калды, диеп,*
*Изге, шәфкатьле анабыз—мәрхәмәтле җир җылый.*

Шагыйрь—матурлыкны, нәфислекне яклаучы. Ул—эстет җанлы зат. Ачлыкның иң тирән фаҗигасен ул гүзәллекнең һәлакәт чигендә тартышуы рәвешендә тасвирли:

*Куйса монда корткалар төшкән тешен алтын белән,*
*Бер телем икмәк дип анда назлы нечкә бил җылый!*

Шул ук вакытта Тукай—кайсы шагыйрьгә караганда да татар милләтенең уртак фаҗигасен, аның тарихка булган тирән рәнҗүләрен һәм киләчәккә өметләрен тулырак чагылдырган шагыйрь. Ул—милләт шагыйре. Әле генә яһүд шагыйреннән китерелгән бер үрнәктә бүтәннәрнең аны татар милләтенең байракчысы итеп күзаллавын күреп киттек бит.

Тукайның милләт шагыйре булуы аның барлык әсәрләрендә дә чагыла дияр идем мин. Шулай да менә аның "Милли моннар"ына гына игътибар итеп карыйк.

Сүз татар җырлары, хосусан "Зиләйлүк" хакында бара. Татар җырының тирән моңында шагыйрь өч йөз еллык милли изелү эзләрен, халык чиккән бик күп михнәтләрнең, түккән күз яшьләренең чагылышын күрә. Яки шагыйрьнең: "Мин татарга бәхет, шатлык телим; мин татарга тәхет, шаһлык телим",—дигән юлларында байсезлек һәм дәүләтчелек гамен күрмибезме?!

Тукайның демократик һәм милли идеаллары юлында, әлбәттә, беренче нәүбәттә рус самодержавиесенең рәхимсезлеге киртә булып торган. Шул ук вакытта милли мохиттә дә аның дошманнары аз булмаган. Шагыйрьне алар ни өчен күрә алмаган, яки шагыйрь аларга нәфрәтле мөнәсәбәтен ничек белдергән?

Милләтнең азатлыгы һәм алгарышы өчен янып йөрүчегә еш кына һәм башлыча татарның үз кешеләре тышау булып төшкән. Бу хәл хәзер дә шундый ук рәхимсезлек белән эшләнә. Мәскәү матбугатында безнең суверенитет идеясен мәсхәрәләп язучылар арасында "зыялы" исемен күтәргән милләттәшләребез дә бар. Тукай үзләренең идеалсызлыгын заманга сылтаучылардан һәм мохиткә яраклашырга өндәүчеләрдән җәфа чиккән. Аның "Ваксынмыйм" шигыре бу яктан характерлы. Анда шагыйрь үз чорына киләчәктән торып бәя бирә:

*Син үзеңчә изге эш эшлим дигәндә халкыңа,*
*Әллә нинди былчырак баулар салалар гакълыңа:*

*—Бу заман шундый заман, дип, бу вакыт мондый вакыт,*
*Син үзеңне дөньяда безнеңчә йөрт, безнеңчә тот.*

*Мин сыялмыйм андый шартлар, фани дөнья вактына...*

*Ашкынамын мин әбәд бетмәс урынга, мәңгегә,*
*Мәңгелеккә—мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!*

Тукай—авылдан чыккан шагыйрь. Дөрес, ул шәһәр тәрбиясе алган. Аның шагыйрь буларак житешүе, белем алуы, мөстәкыйль хезмәткә аяк басуы Уральски шәһәренә бәйле. Әмма татар халкының иң зур күпчелеге ул чорда авылда яшәгән. Шунлыктан шагыйрьнең авыл тормышы һәм авыл халкына мөнәсәбәте ул, гомумән, туган халкына мөнәсәбәте дә булып аңлашыла. Бу мөнәсәбәт анарда мәхәббәт рәвешендә дә, катлаулырак та чагыла.

Менә аның "Сайфия" шигырен генә алыйк.

Тукай авылның фәкыйрьлегенә көенә. Картинаны ул кәеф-сафа чигүче байга контраст рәвешендә тасвирли:

*Ул хәзер туктар сиңа, и ач авыл, мохтаҗ авыл!*
*Җимрек өй каршында ич оҗмах кеби кәйфиясе.*
*Җаннарым, күз нурларым, сез, бу мәһабәтне күреп,*
*Җан ачып: "во как!" дисез, мәзлум мужиклар семьясе.*

Ләкин Тукай авыл мужигын идеаллаштырмый, "Йолдыз"дан да курка" шигырендә авыл агаеның либераль-демократик, нигездә җәмгыять тәртипләренә лояль "Йолдыз" гәзитен өендә күрүдән коты алынуын яза.

Тукай иҗаты асылда төрки-татар шигъриятенең мең еллык үсешенә йомгак булып тора. Без моны Тукай шигъриятенең иҗат өчен мөһим булган барлык сыйфатларында да күрәбез. Менә иң беренче күзгә ташланган шигырь үлчәмен, шигырь калыбын гына алыйк. Тукай башлыча ике юллы шигырь строфасы белән эш итә. Шул нигездә эшләнгән лирик әсәрләрендә буйдан-буйга икенче юллары рифмалашкан газәл өлгесе дә, касыйдә калыбы да анарда мул төрләндерелә. Мәсәлән, әле генә күреп киткән "Көзге җилләр" газәл өлгесендә эшләнгән. Шигырь үтәдән-үтә бер рифмага корылган очраклар Тукайда аз түгел. Форма мәсьәләсендә Тукай, бөтен Мөселман Көнчыгышына хас булганча, гаруз системасы эчендә иҗат итә. Бу система буенча, строфаның төзеклеген иҗекләр саны тәңгәллеге, ритмик төзеклекне озын һәм кыска иҗекләрнең тәртипле чиратлашуы хәл кыла. Гаруз шигыре татар халык шигыреннән нык кына аерыла. Төп аерма икешәр юллы строфада гына түгел, башлыча ритмик тыныш-паузаларның сүз уртасына туры килүендә. Ягъни гаруз шигырен укыганда, ритмик

буыннарны саклау һәм шигырьнең музыкаль яңгырашын төгәл бирү өчен сүз уртасында да тыныш ясарга кирәк. Менә бер мисал. “Хөрмәтле Хөсәен ядкяре” дигән шигырьнең беренче строфасын гаруз нигезендә дөрес уку өчен, ритмик буын азагында тынышларны шулай ясарга тиешбез:

*Көч белән бер/гә гүзәллек/не җыйган диң/гез кеби,*
*Ул иде өс/тен вә кул җит/мәс кеше, йол/дыз кеби.*

Хәзерге заманда Тукай шигырьләре безнең чор шигырен, ягъни халык шигырен укыган кебек, сүзләр тәмамланган җирдә тыныш ясап укыла. Әйтик, әлеге мисал шулай яңгырый:

*Көч белән бергә I гүзәллекне җыйган I диңгез кеби,*
*Ул иде өстен I вә кул җитмәс кеше, I йолдыз кеби.*

Дүртәр ритмик буыннан торган шигырь юллары тәңгәл булмаган өчәр буын булып яңгырый. Әйе, мәгънә ачык аңлашыла. Әмма Тукай шигыренең иң гүзәл ягы—ритмик музыкальлек югала. Юкса, Тукай шигырьләренең барысы да саз аккомпонементына көйләнгән. Шагыйрь тикмәгә генә үзенең шигъри илһамын “Саз” дип атамый бит!

*И мөкатдәс моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз?*

Тукай шигыренең Шәрекъ поэзиясе традицияләрен чагылдыруына бу—ышандыра торган дәлил дип уйлыйм. Тукайның шигъри фикерләве тулысынча диярлек Шәрекъ традицияләренә нигезләнгән, шәркый сурәтләр белән сугарылган. Иң беренче нәүбәттә бу ислам рухындагы сурәтләргә карый: Аллаһ, фәрештәләр, Иблис, шайтан, пәйгамбәрләр, тарихи изге шәхесләр, төшенчәләр шуна керә. Менә ул баланың гөнаһсыз сафлыгын ничек тасвирлый:

*Пакь җаның һәм пакь тәнең—барлык вөҗүдең пакь синең;*
*Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең.*

Яки “Дәрдемәнд дәгелмием?” дигән мәхәббәт шигырендәге шушы юлларны алыйк:

*Тәңре гыйшкында шәһадәт итсәләр дәр Гәрбәла,*
*Бән шәһидем дәр мәхәббәт, дәр бәлаем, нәйләем?*

Хәзерге Гыйракның Кәрбәла шәһәрендә өмәвиләр тарафыннан хәзрәти Галинең улы Хөсәен үтерелә. Ягъни пәйгамбәрнең оныгы шәһит китә. Шагыйрь үзенең мәхәббәт юлында шәһитлеген шушы тарихи фаҗигале коллизиягә каршы куя, дөресрәге шушы янәшәлектә бәяли.

Тагын да характерлырагы шул: Тукай төрки шигърияттә мең ел дәвамында яктыртылган сюжет һәм легендар-әфсанәви коллизия һәм сурәтләрне үзенең диалектик фикерләвендә дәлилле шигъри чарага әверелдерә. Матурлыкның конкрет һәм нисби төшенчә булуын ул шундый мисал аша дәлилли:

*Бирмәде Ләйлә кеби мәхбүбәгә дөнья бәһа;*
*Ул болай бер кыз гына—каршында Мәҗнүн булмаса.*

Ләйлә кебек гүзәл кызга дөнья бәя бирә алмас иде, ди. Әгәр каршында шашып гашыйк булган Мәҗнүн булмаса.

Бу—XX йөз башы шагыйренең даһи гомумиләштерүе. Шушы лирик тезисның барлыкка килүе өчен мең еллык әдәбият тарихы кирәк булган. Әлеге шигырьнең тирән фәлсәфи мәгънәсен, драматизмын композитор Рөстәм Яхин нечкә күреп алган һәм аны гүзәл романс итеп яңгыраткан.

Шагыйрьнең яңа гасыр шигъриятенә нигез салуын шул ук параметрлар эчендә,

шул ук схема нигезендә барган янарышларда күрәбез. Иң элек, форма дигәндә, югарыда телгә алган "Милли моннар" халык шигыре калыбында язылган. Бу классик татар-төрки—гомумән шәркый шигърият өчен принципиаль яналык. Татар поэзиясенең XX гасыр дәвамындагы үсеше башлыча 10-9 иҗекле шушы дүртьюллы строфага таянып бара.

Сурәтле фикер һәм фәлсәфи мәгънәләр, дисәк, Тукай да, Дәрдемәнд тә, Сәгыйть Рәмиев тә—Көнчыгыш-Көнбатыш әдәби-шигъри синтезын интенсив рәвештә үзләрендә гәүдәләндергән шагыйрьләр. Алар дәртләнеп һәм эзлекле рәвештә татар шигырен аурупалаштыралар. Яшь Тукайның шигъри чагыштыруларына күз салыгыз. Ул татарга эндәшеп болай ди:

*Чыксын шәмсең, эрсен кар,*
*Шалтырап аксын ермаклар;*
*Ятмасын мәңге, җитәр!—*
*Мисле сәлеҗ Сангатар.*

Ягъни Сен-Готард (Альп) тавындагы кар кебек, ди шагыйрь.

Ниһаять, иң мөһиме, Аурупа шагыйрьләре белән фәлсәфи-хисси аваздашлык эзләве, үзенең халәтенә, кичереш һәм гамәлләренә Байроннан, Һөтедән, Һәйне һәм Шиллердән, Пушкин һәм Лермонтовтан, Шекспирдән һәм бөек фикер иясе Толстойдан таяныч эстәве һәм табуы шагыйрьнең эзләнүләр процессы гөрләп барганын күрсәтмиме? Гомумән исә дә, Тукайның шигъри таланты лирика белән сатирада бердәй чагылуы дөнья шигъриятендәге Һәйне талантын хәтерләтә.

XX йөз башында куәтле Тукай шигъри мәктәбе хасил була. Аның иң көчле вәкиле, әлбәттә, Шәехзадә Бабич. Ярсу һәм камил шигъри ритмда булсын, иман һәм инсани кичерешләрдә булсын, ул турыдан-туры Тукайдан үсеп чыга. Яшь Исәнбәтнең дә башлангыч чор шигърияте тулысынча Тукай шигъри тылсымы эчендә үсә.

Тукай иҗаты, аның феномены татар халкын даими кызыксындырып, әсәрләндереп, борчып, дулкынландырып килә. Соңгы вакытта нишләптер аның иҗаты белән махсус шөгыльләнү сүрелде дигән шелтә мотивы да яңгырый.

Әйе, бу икърарда хаклык бар. Дөрес, мин Тукайны гыйльми фикер дөньясында яктырту туктады, димәс идем. Мәсәлән, Тукай музее һәм вакыфы ел саен Тукай укулары уздыра, һәр шундый чара шагыйрьне тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Ә инде шагыйрь иҗатын максатчан һәм даими тикшерүчеләр калмады, дигәндә, кызганыч ки, бу нигездә хак. Якуб Агишев һәм Рөстәм Башкуровлар, Гали Халит һәм Ибраһим Нуруллиннар инде арабызда юк. Тукайга махсус хезмәт багышлаган Наиб Лаисов кебек галимнәр бүтән проблемалар белән шөгыльләнә. Бер Резидә Ганиева гына теманы ташламый. Өзеклек тирәнәймәсен өчен, Тукай иҗатын өйрәнүче махсус аспирантлар алабыз. Өйрәтер кешеләр барында, яна белгечләр үстереп калырга тиешбез. Әле күптән түгел генә Р. Ганиеваның бер шәкерте "Тукай иҗатында Коръән мотивлары" дигән темага кызыклы диссертация яклады. Иң мөһиме—кин колачлы "Тукай энциклопедиясе" эшләнә. Аны тәҗрибәле әдәбиятчы-текстолог Зөфәр Рәмиев җитәкли.

Тукай—ул даһи сүз сурәтчесе. "Җәйге таң хатирәсе" дигән шигыре берүзе дә менә ышандыргыч дәлил була ала. Чөнки бу шигырьдә тасвир колачы гаять киң, шагыйрьнең сулышы көр. Иҗатка һәм яшәүгә этәргеч бирә торган манзара күз алдына баса.

Тулаем исә, Тукай иҗаты—үзенең эчтәлеге белән дә, гасырдан-гасырга актуаль яңгырашы белән дә бетмәс-төкәнмәс хәзинә ул. Шагыйрьнең 120 еллык юбилее аның тирән мәгънәсен төшенә баруда мөһим бер яңа адым булыр.

**Нурмөхәммәт ХИСАМОВ,**
*филология фәннәре докторы.*

## Шәехзадә Бабич

### Габдулла әфәнде Тукаев

**Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь, Габдулладай;**
**Ул—караңгы төндә яктырткан матур, ак тулган ай.**

**Ул бөек уй, нечкә хис тәгъризләргә[1] бик бай,—диям.**
**Бар урыннардан аның урынын кадерле, дәү,—диям.**

**Бакыр эчендә көмешләр ялтырап яткан кебек,**
**Ап-ачык, ап-ак булып, тик ак күңел аккан кебек.**

**Күп китапларның арасында аның китаплары—**
**Ап-ачык нурлар чәчеп, күренеп тора һәр яклары.**

**Алса, укыса халык шигырен аның—истә кала,**
**Һәм аның шигыре халыкның күңеленә зур хис сала.**

**Галиази Габдулланың хәзер Казанда мәскәне,**
**Ул уяткыч, ул юаткыч, ул терелткеч хәстәне.**

**Билгеле, безнең мабиһельифтихар ул, мөхтәрәм,**
**Зур шагыйрь, мәшһүр шагыйрь бар бездә дә,—дип шатланам.**

**Тәсбих вә тәһлил итеп җырлап йөримен җырларын,**
**Җырлаганда, нечкәрә күңелем, эри һәр җирләрем.**

## Сәгыйть Сүнчәләй

### Инеш

**(Тукай хатирәсе)**

**Яктысы берлән сихерләп күк читен, әкрен генә,**
**Моң гына изге кояш—солтан кояш иелә, иңә...**
**Йә, ничек киң ул сәгадәтле кояшның яктысы!**
**Нинди төс юк нурларында! Һәммәсе оҗмах төсе!**
**Күр: ничек ул шәүләләр җәелә офык буйлап әнә!**
**Күр: ничек бер зәңгәре изге сәмаларга менә!**

[1] Тәгъриз—тасвирлау.

**Ул—мөкатдәс гарше әгълага тоташкан шәүләдер,**
**Ул кояшның соңгы гомереннән хәбәрләр илтәдер.**
**Ие, күп тә калмады: изге кояш тиздән иңәр!**
**Ие шул, күрсәңче, әкренләп кимиләр шәүләләр!..**
**Бетте якты нурлары... ул гел зурая, олыгая...**
**Олыгая канлы кояш... хәсрәт үтә, ул елмая.**
**Ул иңә... инде... офыкны чормады ямгын төсе,—**
**Нәкъ газиз ямьле Казанның ямгынының яктысы.**
**Инде мескен "падишаһ...", хәсрәт күңелне тибрәтә...**
**Мәрхүмнең елмайганы аңнан яшен төсле үтә.**
**Ул сәгадәтле иде... инде фәгансыз елмаеп:**
**Аһ, кояш инде, гаҗәип шәгъләләр булды гаип.**

## Мәҗит Гафури

### Тукай вафатыннан соң

**Көтмәгәндә салды безгә бу көндә фәләк:**
**Әй, сөекле яшь шагыйрькәй, син югалдың иртәрәк.**

**Тар күреп бу чикле тормышны үз башына,**
**Кайтты: "нәфсе мотмаиннәң"[1] инде үз "алласына".**

**Гали рухың бу түбән дөньяны һич тиңсенмәде,**
**Тик бүтән дөньяга китте, ул бөтенләй үлмәде.**

**Үлмәдең син: чөнки бу көн һәр татар күңелендә син,**
**Бетмәдең син: һәр кеше сүзендә син, телендә син...**

**Һичвакытта чыкмас истән монда калган эшләрең,**
**Һәрвакыт сөелеп укылыр бар "күңел җимешләрең".**

**Син сөеклесең, сине шулай сөя һәрбер татар,**
**Сиңа каршы ихтирам һәрбер татар күңелеңдә бар.**

**Югалуың зур авырлык, һәммәбезгә син әрәм,**
**Бар кешеләрдән дә артык мин елап хәсрәтләнәм.**

---

Сәма—күк.
Мөкатдәс гарше әгъла—изге күк.
Фәгансыз—кайгысыз.
Шәгъләләр—нурлар.

[1] Бу юл Г. Тукайның "Кайт, и нәфсе мөтмаиннәм, бар юнәл, кит тәңреңә..." дигән сүзенә карата әйтелә.

*Тукай турында олуг шәхесләр*

## Сибгат Хәким,

Татарстанның халык шагыйре:

***Тукай миңа бик иртә кергән. Ана сөте белән. Халык моңнарын тоя башлагач та. Татар халкы бар җирдә Тукай булган. Кайчан дигән сорауга халык сулышы белән дип кенә җавап бирә алам. Шулай булмаса, язарга мин "Пар ат"тан тотынмас идем. Миннән аның беркайчан да чыкканы да юк. Хәтта Дугада да... Сугышлар да мине аннан биздерә алмады. Нигә ул миннән чыкмый? Аңлатуы читен. Татарда Тукай туганы өчен куанам. Рухымның Тукай белән очрашуына куанам. Олыгайган саен, күңелгә бер курку урнаша бара. Мин аннан бик авыр аерылырмын шикелле.***

***"Шагыйрь кем?" дигән сорауга җавапны җитмеш өч яшемә җиткәндә Тукайдан таптым. Шагыйрьлекне шагыйрь үзе яшәгән җәмгыятькә керткән рухи көченең микъдары белән үлчәнгәнлеген Тукайны укып аңладым. "Бетте көч, сынды кылыч.—шул булды эш" менә кайчан әйтелә икән. Тукай миндә үзенең милли рухы белән яши. Шул яздыра, шул эчке энергиягә әйләнде. Яшь чакта алга-артка карамый ярыша-ярыша чапкан киләчәк шагыйрьләре дә, минем шикелле картая төшкәч, әлеге сорауга җавапны барыбер Тукайдан эзләячәкләр. "Шагыйрь кем?" Такташ, Туфан, Җәлил дип килерләр дә Тукайда тукталырлар. Шуңа бик нык инандым. Ә шагыйрьгә җавап табарга кирәк икән. Кыскасы, икенче заманда яшәсәм дә, дөньяга ике катлы тәрәзә аша карап яшәдем—Тукай аша. Бөтенесен теоретик нигезли алсам, мин шагыйрь дә булмас идем. Тукай борчу. Тукайдан аерыласым килми...***

## Мостай Кәрим,

Башкортстанның халык шагыйре:

***Татар әдәбиятының бәхете булып, дөнья әдәбиятының шатлыгы булып 1886 елны бу фани дөньяга Габдулла Тукай килде. Үз милләтенең гасырларга сузылган газапларыннан һәм өметләреннән, моңнарыннан һәм ырымнарыннан, кан катыш туфракта, изге җирлектә яралды ул. Язмыш аңа бер генә чиметем, бер генә мизгел гомер бирде. Шул ара эчендә ул Россиядә үзен дә, сүзен дә үлемсез итте. Алай гына да түгел, аның исеме һәм даны ил чикләрен узып чыкты. Көнбатыштагы караимнардан алып көнчыгыштагы уйгурларга хәтле барып җитте. Тукайны мин 20 нче гасырда төрки телләрдә иҗат иткән иң бөек шагыйрьләрнең берсе дияр идем. Аның янәшәсенә, ихтимал, Назыйм Хикмәтне генә куеп буладыр.***

***Тукай дигән могҗизаның төп сере нәрсәдә соң? Тукай дигән могҗизаның төп сере шунда, ул үзенең бөек талантын дөнья мәдәниятының казанышлары белән баета алды. Шул талантка, байлыкка баш булып, аны халык тормышының, заманның иң төп, иң олы юлы белән алып китте, алсыз-ялсыз хезмәт иттерде. Аны үз-үзенә соклану, яки кызык өчен генә сүз уйнату кебек буш, мәгънәсез нәрсәләргә исраф кылмады. Әйтер сүзен ул кешеләр башы өстеннән зәңгәр бушлыкларга карап әйтмәде, ә замандашларының, кан кардәшләренең мөлдерәмә хәсрәт һәм өмет тулы күзләренә туп-туры карап әйтте.***

Марат
Әмирханов

# И, КЫЛГАН ДОГАМ МИНЕМ...

ПОВЕСТЬ

* * *

Май башында көннәр угырып китте. Ана кадәр дә табигать-ана җинүчеләргә кырын тормады. Ел фасыллары алмашынган чакта явым-төшем була инде ул. Көнбатыш Европаның һава шартлары бездәге белән чагыштыргысыз, бөтенләй үзгә, чөнки җылырак географик киңлектә урнашкан ул. Сөн буенда әле алмагачлар чәчәккә бөреләнеп кенә киләдер, мөгаен. Ә монда куакларда җимешләр шәйләнә хәзер. Кыз-кыркын да, әнә, кыска җиңле күлмәккә күчте инде.

Шәһәр читендә машинабыз кызурак элдертә башлады. Юл элеккечә үк такыр иде. Күрәсең, монда гаскәрләр тоткарланып тормаган. Хәтта утарларга да зыян тимәгән. Каланы гына чүкегәннәр. Тик басу-кырлар барыбер ташландык ишек алды шикелле ятимлек сөременә уралган иде. Сөрмәгәннәр дә, чәчмәгәннәр дә. Ара-тирә коелып калган былтыргы бөртектән борын төрткән арыш сабаклары бу ятимлекне ничектер тагын да чарасызрак итеп күрсәтә иде.

Таныш урыннар. Смирнов утарына да ерак калмады. Чөй кебек очлы башы белән басуга ерып кергән агачлыкны аркылы чыгасы да, сулга каерылып, үр менәсе. Аннан утар уч төбендәгедәй күренеп тора. Йөрәк леп-леп итеп тибә. Эрна шундадыр, әти-әнисе янына кайткандыр сыман тоела. Ә менә очрашуны һич тәгаенли алмыйм. Үзе күз алдымда: бөдрә чәчләре, тулы иреннәре, ап-ак муены, килешле буй-сыны... Рембрандт картиналарындагы туташлар шикелле чибәр бит ул Эрна.

—Ял йортында яшәгәнсез икән, иптәш лейтенант,—дип, уены-чыны белән төрттереп куйды шофер. Мин аңа үпкәләмәдем, Эрнаны күргәч, ни сайрарсың икән, дип көлемсерәдем генә.

Смирновның йорт-җире төзек иде. Җиңел сулап куйдым. Минем һич тә утарны җимерек, хәрабә хәлендә күрәсем килми иде.

Шофер иреннәрен кыйшайтып тагын нидер әйтте, тик аның сүзләре мине кызыксындырмый. Әчке бер ашкыну белән күзләрем Эрнаны эзли. Капкадан атылып чыгар да, кош шикелле канатларын җәеп, каршыма очып килер кебек...

Мине берәү дә каршы алмады, чибәркәй дә йөгереп чыгып, муеныма асылынмады. Утар үзе дә читтән генә купшы булып күренгән икән. Дөрес, әле аны бөтенләй үк ташландык дип әйтеп булмый, йорт та, абзар-кура да урынында. Ләкин ул инде теге вакыттагы шикелле гөрләп тормый. Мал-туар да күренми. Мин көтү көтеп йөргән кишәрлекләр бушап калган...

Әйе, сугыш Смирнов дәдәйнең тормышын да кыеп алган икән, дип уйлап

*Ахыры. Башы 1 нче санда.*

куйдым. Тик кемдер булырга тиеш ич инде утарда? Шушы кадәр мөлкәтне караучысыз калдырмаслар. Смирнов белән бер-бер хәл булган очракта да, фрау Маргарита исән-саудыр. Мирас иясе Эрна да бар ич әле.

Болдыр тирәсендә бераз таптанып тордым да, йорт ишегенә төртеп карыйсы иттем. Ул ачык иде. Нидер сизенгәндәй, аякларым үзләреннән-үзләре терраса ягына атлады. Смирнов монда кичләрен ялгызы гына кәеф-сафа корып утырырга ярата иде. Ни гаҗәп, ул хәзер дә шунда иде. Алдында—сыра. Ләкин элекке хуҗаның шәүләсе генә иде әлеге Смирнов. Гәүдәсе бөкшәйгән, аркасында бөкресе калкып чыккан. Сакал-мыегына да күптән пәке тимәгән, ахры, җөнтәс маэмайга әйләнгән. Табан астыннан очкыннар очыра иде бит, җир җимертеп йөри иде. Бетерешкән агаебыз, бетерешкән...

Без күпмедер вакыт бер-беребезгә карашып тордык. Куртның күзләрендә курку да, үкенеч тә шәйләнми, киресенчә, алардан ниндидер салкын битарафлык бөркелеп тора иде.

—Алып китәргә килдеңме?—диде тамак төбеннән чыккан карлыккан тавыш белән. Исерек түгел иде ул. Сыра тустаганы да туп-тулы.—Әллә шушында гына хәл итәсеңме?

—Син, хөрмәтле Курт әфәнде, төрмәгә килеп, минем хәлне дә белеп китә ала идең...

—Һы, һундук, кызымны мәсхәрә иткән өченме?

—Беләсеңме соң син, дәдәй, бу мәрәкәне Эрна үзе уйлап тапты ич. Әйе, әйе, җир оҗмахы иде ул. Кызыңны бик яраттым мин. Өйләнергә әзер идем. Ә ул мине төрмәгә тыкты...

—Эрна юк инде,—диде әти кеше шундый ук салкын битарафлык белән.

—Ни сөйлисең син, һундук тәре,—дип тегенең якасыннан эләктереп алдым.—Нигә нервыда уйныйсың?

—Кырык дүрттә үк, бомбежкага тарды, институтларыннан йомычка да калмаган, хәрби фәнни-тикшеренү институты иде бит...

—Кабере дә юк алайса,—дидем уфтанып.

—Конрадныкы да юк, Эрнаныкы да... Ике генә бөртек иде бит алар, җан кисәккәйләрем... Хатын бу кайгыны күтәрә алмады. Тере мәет...

—Ул кайда соң?

—Өйдә... Аны бимазаларга кирәкми. Барыбер кеше танымый.

—Миннән берәр ярдәм кирәкмиме?—дип сорадым элекке хуҗамнан. Ул башын гына чайкады.

Дөнья гаме калмаган иде инде Смирновта.

* * *

Кәбир мәктәп мәшәкатьләре белән хакимият, мәгариф идарәсе бусагаларын таптап йөргән арада, Гүзәлия кибетләргә сугылды, чәчтарашка кереп, төзәнеп-ясанып чыкты. Аннан соң да вакыты калган иде әле. Элегрәк, мөгаен, сөйләшү пунктына элдерткән булыр иде. Ләкин Илһан турында уйламаска тырыша ул хәзер. Яратуы чын булса, сөйгәненең чәүчәләнүләренә игътибар биреп тормас иде, килер иде. Кызлар ялындыра инде ул. Билгеле, башта түземлеге төкәнеп, чарасызга калган чаклары да булды. Тамактан язды, йокысы качты. Тик ул һич тә муеңга асылына торганнардан түгел. Мәхәббәт үзе килә дигән әйтем дә ана туры килмидер, мөгаен. Гүзәлиянең мәхәббәтен ышанычны яулаган кебек үк яулап алырга кирәк.

Хәер, Илһан инде узган заманда калды, бу хакта баш ватып торуның мәгънәсе юк.

Алар Кәбир белән кичке дүрттә универмаг янында очрашырга сүз куешканнар иде. Әле сәгатьтән артык буш вакыт бар. Редакциягә сугылса да була. Сентябрь башында, Белем көне унае белән, аның иҗатына багышлап

сәхифә әзерләнә иде. Шуны белешер. Хисам Сабирның иҗат адымнары да кызыксындыра булыр үзләрен.

Редакция ике катлы бинада урнашкан иде. Бинасы күркәм генә. Урыны да унайлы. Әмма тирә-ягы бөтенләй каралмаган, төзүчеләрдән калган тимер-бетон плитә кисәкләре әле булса шунда аунап ята. Югыйсә, койма белән әйләндереп, агач-куаклар утыртып җибәрсән, гөлт итеп торыр иде. Чәчәк клумбаларына да урын житәрлек. Элекке мөхәррир төзүчеләр белән дәгъвәләшеп вакытын уздырды. Янәсе, алар территорияне рәткә китереп, яшелләндереп тапшырырга тиеш иде. Бәлкем, ул хаклы да булгандыр. Ләкин аны төзүчеләр киткәнче, актка кул куйганчы таләп итәргә кирәк бит. Чаллы төзүчеләренең Актаныштан китүләренә дә кайчан инде.

Гүзәлия ишек янындагы сулы зур калай тагаракны күреп туктап калды. Аны болай гына үтеп китеп булмый. Чөнки каршыда "Аяк киемегезне юып керүегезне үтенәбез" дигән язу эленгән иде.

Болайга киткәч, ишек алдына да ямь керер, бәлки, дип уйлап куйды кыз. Коридорда мөхәррир белән йөзгә-йөз очраштылар.

—О-о, әйдүк-әйдүк, Гүзәлия туташ, Ходай күктән көткәнне жирдән бирә ди, сезнең хакта уйлап йөри идем әле, бүген-иртәгә Түбән Сөннән урап килмәкче идем,—дип сайрап алды мөхәррир.

—Мин бик шат, Вәкил әфәнде, рәхмәт яхшы сүзегезгә, шундый егет солтанының уена керү үзе зур мәртәбә инде ул,—диде Гүзәлия тартынмыйча. Чөнки белә: мөхәррир уен-көлке беләнрәк сөйләшә торган наян кеше. Әле дә итләч түгәрәк йөзе балкып китте, күзләреннән мут очкыннар сибелде.

Алар шулай көлешә-көлешә мөхәррир катына уздылар. Бүлмәсенә кергәч, Хәлилов житдиләнде. Өстәл башында урын алгач, Гүзәлиягә текәлеп карап торды. Карашы элмәкле иде, үзенә буйсындыра торган караш. Бу инде шырык-шырык көлеп сөйләшүче Вәкил түгел. Баш мөхәррир!

—Ни кирәгем чыкты?—дип сорады Гүзәлия.

Яп-яшь кызның һичнинди кыенсынусыз, үзен иркен тотып сөйләшүе ошый иде мөхәррирга. Аралаша белү сәләтен ул кешенең иң зарур сыйфаты дип саный иде. Ә журналист өчен бу гамәли әһәмияткә ия.

— Гүзәлия туташ, әгәр мин сезне редакциягә эшкә чакырсам, ни әйтер идегез?

Кыз мөхәррирдән мондый тәкъдим көтмәгән иде. Дөрес, журналист һөнәре турында ул университетта укыганда ук уйлана иде. Хәтта яшьләр гәҗитендә эш тә белешеп караган иде. Корректор урыны бар, теләсән, рәхим ит, диделәр. Бүтән басмаларда да шуңа охшаш җавап алды. Ә аны корректор вазифасы гына канәгатьләндерми иде. Шуңа күрә әлеге уйларын башыннан чыгарып ташлады. Инде менә үзләре эш тәкъдим итә. Масштаб таррак, билгеле. Әмма эшкә күнегү, тормышны өйрәнү, тул җыю өчен ярап та куяр иде бәлкем...

—Әдәбият һәм сәнгать, мәдәни мәсьәләләр бүлеге оештыру артыннан йөри торгач, ниһаять, рөхсәт алдым,—диде мөхәррир шатлыгын яшермичә,— аны сезнең кебек талантлы яшь белгеч житәкләргә тиеш дип саныйм.

—Вәкил әфәнде, сез минем планнарны челпәрәмә китереп ташларга омтыласыз бит, аңлыйсызмы шуны?—диде Гүзәлия.

—Беләм, укытучы итеп билгеләнүегезне дә беләм. Тик сезнең урынга кеше табуның әллә ни авырлыгы булмастыр, мөгаен. Өметле журналист тәрбияләү өчен менә бик күп тир түгү сорала. Журналист штучный товар ул.

—Үз һөнәрегез турында бик югары фикердә икәнсез, егылып төшә күрмәгез.

—Дөресе шулай. Җә, ничек, тәкъдимемә карата ни әйтәсез?

Хәлилов урыныннан кубып, тәрәзә янына килде. Аның форточкасы кошлар ашату өчен җайлаштырылган иде. Хуҗа кошларга жим сипте, тәлинкәгә су агызды. Сагалап кына торганнар, күрәсең, сары түшле йомры песнәкләр

куанышa-куанышa тәгамгә ябырылдылар. Җәй чорында кошлар үз тамакларын үзләре дә туйдыра ала бит инде, дип уйлап куйды Гүзәлия.

—Мин сезнең янга Хисам Сабирның хәтернамәсе, үземнең шигырьләрем турында сөйләшергә дип кенә сугылган идем...

—Ярар, алайса болай хәл итик, Гүзәлия туташ,—диде мөхәррир тәрәзә янагына сөялгән хәлдә,—уйланыгыз, тәкъдим үз көчендә кала. Хисам Сабирның публикациясе беренче эшегез булыр. Киләсе җомгада шушы бүлмәдә очрашырбыз. Җавап уңай булыр дип ышанам.

—Вәкил әфәнде, бу җәһәттән сезгә бер үтенечем бар,—диде Гүзәлия,—зинһар, әлеге тәкъдим турында хәзергә икебез генә белеп торыйк әле, җәме?

—Вәгъдә!

Килешенгән урынга килеп җиткәндә, Кәбир машинасы янында бәбкәләрен югалткан ата каз шикелле муенын сузып, ялт та йолт карангалап тора иде. Кызны күргәч, йөзе яктырып китте.

—Гафу ит,—диде Гүзәлия ягымлы гына итеп,—соңардым, ахры.

—Зыян юк,—диде Кәбир,—чибәр кызлар очрашуга көттереп кенә киләләр инде алар.

—О-о, тәҗрибәгез зур икән, Кәбир Таһирҗанович,—дип бармак янады кыз,—карагыз аны, ятларга күз атасы булмагыз, үпкәлим.

—Җә, кай тарафка боерасыз, ханым-солтаным,—диде Кәбир машинага кереп утыруга.

—Агыйдел буена!

—Баш өсте.

Кузгалуга, кыз егетнең җиңенә кагылды.

—Мин тилегә карама, Кәбир, син директор кеше, мәшәкатьләрең күптер, сүземне кире алам.

—Әйткән сүз—аткан ук, Гүзәлия туташ.

—Ихтыярың. Күптәннән Әргәнеш болыннарын күрәсем килеп йөри иде. Бәләкәй чакта дәү әтисе еш кына әбисе белән икесен Әргәнешкә алып бара иде. Ветеринарларның анда үз җирләре бар иде. Шушында куна-төнә печән чабып, кибән коялар иде.

Чәчәкле-чуклы болыннары белән дә, җиләк-җимешләре белән дә дан тота иде Әргәнеш. Агыйделгә аяк сузып утырган әрәмәлекләрдә нинди генә җимеш үсми?! Иң элек җир җиләге өлгерә. Эредер үзләре, берсе-берсе күгәрчен башы кадәр. Аннан соң кызыл карагат ахак кашлы вак чулпылар шикелле янып торган тәлгәшләрен күрсәтә. Сырт җирләрдә чия өлгерә. Тиздән таллык арасында кара карлыган күзләрен мөлдерәтә башлый. Кара карлыган белән бөрлегән бергә җитешә. Игезәкләр кебек бер-берсенә сыенып утыралар. Уңганрак әрәмәчеләр унар-егермешәр сәке как коя. Икенче спастан соң шомыртка тотына халык. Чиләкләп-чиләкләп ташыйлар. Әргәнешнең шомырты баллы, авызны бөрештерми. Киптерергә дә әйбәт.

Шулай да Әргәнешнең мактанычы—балан! Бу үзе бер күркәм манзара. Яфраклар инде коелган. Бөреләр йомылган. Әрәмә шәп-шәрә. Бусагада—Пыкрау. Бүген-иртәгә кар төшәчәк. Шушы сөттәй ап-ак кар өстендә балан куаклары... Алсу төстәге тәлгәшләре кояш нурында җем-җем итеп утыралар, гүя: "Әй, без инде өлгердек",—дип кешеләрне мул табынга дәшәләр. Кар күренгәч җыелган баланның бәлеше телләреңне йотмалы була.

Боларны Гүзәлиягә әрәмә җимеше сыман тәмле телле дәү әнисе Гөлмәрьям карчык сөйли торган иде. Чөнки Гүзәлия буй җиткергәндә баланны яшел килеш кенә сыдырып бетерәләр иде инде. Баксаң, Әргәнеш ул үскәндәге купшылыгын да югалтып өлгергән икән. Унар олаулы печәнчеләрне ышыгына сыйдырган киң ябалдашлы ак тирәкләрнең эзе дә калмаган. Андый тирәкләр фәкать Әргәнештә генә үсә иде.

—Әргәнешнен Әргәнеш дип әйтерлеге калмаган икән ич,—диде Гүзәлия үпкәләгәндәй.

—Әле ярый шушы хәлендә булса да саклап калдылар,—диде Кәбир,—Түбән Кама ГЭСын төзүгә керешкәч тә, су астында кала дип, ин әүвәл агачларын рекрут чәче сыман кыркып чыктылар. Халык шаулаша башлагач, сонарып булса да дамба күтәрделәр. Табигатькә жан кереп китте әнә. Куак араларында хәзер төлке-куян ише вак киек яшеренә ала. Без бит һәрвакыт шулай, элек үз-үзебезгә авырлык тудырабыз, аннан ана каршы батырларча көрәшәбез.

—Агыйделне күккә асмаганнар әле, шунысына рәхмәт...

—Агыйделнен талканы коры, Гүзәлия туташ, сезнен кебек чибәрләр характеры бар анда. Әнә, Иделне, Каманы буып ничәшәр электр станциясе кордылар. Агыйдел муенына аркан салдырмады. Мөгаен, элекке СССРда йөгән кигертмәгән бердәнбер елгадыр ул.

—Кайчан барып житәбез сон инде, минем тизрәк Агыйделне күрәсем килә,—дип өзгәләнде кыз.

—Ерак калмады, тагын бераз гына түз.

Дөрестән дә, үр менүгә, Агыйдел пәйда булды. Татар кызларынын чәч толымы шикелле бормаланып-бормаланып ята, жанашым. Анын чибәрлеген, нәфислеген, нәчке монын тасвир итү өчен сүз генә табып бетерерлек түгел. Гүзәлләрнен гүзәле!

Машина туктар-туктамас борын ук Гүзәлия түземсезләнеп ишекне ачты. Очып диярдәй су читенә килеп басты. Көн кичкә авышса да комда аунаучылар күренгәли иде әле. Су өстендә кемнендер көймәсе чайкала, чуп та чуп килеп вак дулкыннар шаярыша, назлы жил битләрне иркәли...

Кыз киемнәрен салып ыргытты да суга сикерде. Шул кызудан колачлап йөзеп китте. Әйләнеп тә карамый. Жә, нигә шулай дуамалланырга сон, дип Кәбир борчыла ук башлады.

Агыйделнен эчендә ут кайный бит анын, вулкан ул. Бер карыйсын, нәзакәтле чибәр кыз, икенче караганда, мәкерле убырлы карчык. Елнын-елында корбан сорый. Һәм ала да...

Кәбир көймәнен чылбырын ычкындырды. Көймә кечкенә иде, жинел. Кыз елганын уртасына житеп килә иде. Анда агым көчле, Гүзәлиядән шәбрәк йөзүче егетләр дә Әргәнеш борылмасын урап үтүне мәгъкуль күрәләр. Анын үз жае бар.

—Гү-зә-лия! Агым унаена йөз, борылышны үткәч, ул сине үзе комлыкка чыга-а-ра!—дип кычкырды Кәбир. Тик анын тавышы дулкыннар өстендә йотылып калды. Ишә-ишә үзе дә нининдидер киреакмага килеп эләкте. Агыйделнен мондый һөнәре дә бар анын. Кәбир алга ишә, ә агым көймәне бөтерә-бөтерә артка каера.

Азаплана торгач, киреакманын миһербаны килеп, бер мизгелдә көймәне читкә бәрде. Гүзәлия инде комлыкта иде. Озакламый агым Кәбирнен көймәсен дә ярга сылады.

—Кәбир, син әллә йөзә белмисенме?—дип, бернәрсә булмагандай, чырык-чырык көлде кыз. Ул һич тә арыганга-шүрләгәнгә охшамый иде.

—Кыланчык бака, бу Сөн түгел сина, шулай акылсызланырга ярамый бит инде,—дип тиргәнмәкче итте егет. Гүзәлия анын сүзләрен колагына да элмәде.

—Кәбир, көн дә алып кил син мине монда, Кәбир...

Егет жылыга тигән туңдырма шикелле эреп китә язды. Гүзәлиянен шушылай якын итеп, яратып сөйләшкәне юк иде әле. Чибәр дә сон! Буй-сынына гына кара, коеп куйган бит. Мисырларнын мәшһүр Тутанхамоннары, Клеопатралары бер якта торсын.

Кәбирнен тәннәре калтыранып китте. Аллам сакласын, әллә нәрсә майтарып ташларсын. Хисам карт кыюрак кылан дип әйтә дә сон...

—Гүзәлия, әйдә, көймәне Ак тирәк атавы турысына кадәр су читеннән өстерәп барыйк та, аннан агып кына төшәрбез,—дип, Кәбир бу аулак урыннан тизрәк китү ягына карады.

—Минем үтенечемә җавабыңмы инде бу?

—Башта үзебезнең якка чыгыйк әле,—диде Кәбир сабырлыгын җуймаска тырышып,—калганы турында шунда сөйләшеп, хәл итеп бетерербез.

—Шулай дип котылсаң гына инде...

Кәбир көймәне өстерәде, Гүзәлия утырып барды. Җитмәсә, егетне әле ат, әле ишәк дип төрлечә мыскылларга да җитеште. Атау турына җитүгә исә, янә суга ыргылды.

—Әйдә, узышабыз!

—Бала-чага булма, Гүзәлия,—дип кычкырды Кәбир.—Гүзәлия!

—Минем йөзәсем килә...

Кыз үзенекен итте, Агыйделне кабат йөзеп чыкты.

Алар кузгалып киткәләгәнче Агыйдел өстенә эңгер-меңгер пәрдәсе инә башлады. Актанышка җиткәндә, ут алганнар иде инде.

Машина уты төз асфальт юлны иркәли-иркәли генә чакрымнар саный. Кәбир машинасын бик сак алып бара, әйтерсең, Гүзәлия затлы пыяладан ясалган, сикәлтәгә эләгүгә уалып китәчәк иде. Ә ул йомшак кәнәфидә ләззәтеннән оеп киткән. Егетнең эчкерсез ихтирамын тою үзенә бер рәхәт иде.

—Кәбир, суга бата күрмәсен бу хыялый нәмәстәкәй дип, бая борчылдың, ахры, әйеме?—дип үзалдына сөйләнгәндәй генә сорап куйды кыз.

Егетнең кулы аның ялангач тезенә ятты. Кулы кайнар иде. Ләкин хисләр түгелмәде:

—Кәбир, рулең кулыңнан ычкына күрмәсен,—дип көлде генә Гүзәлия.

Янә тынып калдылар. Гүзәлия үз-үзләрен белешмичә машина фараларыннан сибелгән якты нурга ябырылган канатлы бөҗәкләрне күзәтеп барды. Тормышларына куркыныч янаганны беләләрме икән? Юктыр. Белсәләр, болай орыла-бәрелә үлемгә ташланмаслар иде. Инстинкт. Ләкин тискәре инстинкт. Югыйсә, бу бөҗәкләр яшәү өчен шулай үрсәләнәләр ич. Яктылыкка алдана мескенкәйләр. Һәр ялтыраган алтын түгел шул.

Кәбирне дә инстинкт кына йөртмиме? Анлый микән үзен алда ни көткәнен? Машинага орынып җәрәхәтләнгән шушы бөҗәкләр шикелле үзенең тормышын да, минекен дә имгәтмәсме? Хәлбуки, Кәбир Илһанга караганда да төплерәк, иплерәк, акыллырак зат. Хәтта куркыныч дәрәҗәдә акыллы. Ул, мөгаен, әйберләрен дә куйган урыныннан гына аладыр, көнен сәгате-минуты белән тәгаенләп, аннан карыш та чигенмидер...

Илһан белән араны һич тә авылдагы гайбәткә карап кына өзмәде ул. Бабасы, әти-әнисе шулай уйлый икән, әйдә, уйлый бирсеннәр, аннан ни зыян? Хикмәт шунда, Илһан аңа үзенең мал-мөлкәтенә караган кебек карый башлады: һәммәсе аныңча гына булырга тиеш. Моны җайларга да булыр иде әле. Гүзәлия соңгы чиктә үзе кәҗәләнде, ярата торып кәҗәләнде. Чөнки ышанычы сүрелде. Ярата да шикелле, ә ышанычы юк. Аның исә әлеге бөҗәкләр кебек ялган инстинктка алданасы килми.

Бер француз психологының сүзләрен куен дәфтәренә теркәп куйган иде Гүзәлия. Шул хәтеренә төште. "Көнләшүче хатын-кыз бик сирәк очракта гына ялгыша,—ди ул,—аның гоманнары тулысынча диярлек аклана". Көнчелек шул ук хис ич инде ул, мәхәббәт кебек, икеләнү-шикләнүләр кебек. Ә аның хисләре мәхәббәт калыбына гына сыймый...

—Мин шундый җүләр инде, Кәбир, гафу ит, чамам чамама туры килеп бетми, яландагы тай сыман, йөгәнсез,—диде Гүзәлия уйларыннан бүленеп. Егет аның тел төбен шундук аңлап алды.

—Әллә нинди кыргый тайларга да йөгән кигерәләр, Гүзәлия,—диде Кәбир житди генә,—борчылма, йөгәннән генә эш тормас.

—Ярар сон, карап карарбыз...

ЖИДЕНЧЕ ТАСМА

## Кайту

Хикәятемнең башында үземнең өч ел немец әсирлегендә, сигез ел совет тоткынлыгында баланда чөмерүем хакында әйткән идем инде. Шул өч ел белән сигез ел арасында бер елдан аз гына артык иректә дә яшәп алдым бит әле мин. Монысы инде сугыштан кайткач булган хәл.

Мин демобилизациянең беренче төркеменә эләктем. Әлеге агымга башлыча өлкәнрәк яшьтәгеләр, теге яки бу сәбәп белән сәламәтлекләре какшаган, Армия өчен киләчәге перспективасыз саналган офицерлар керде. Мин дә шул өметсезләр арасында идем. Бу, әлбәттә, әсирлек белән бәйле иде. Мина синең шикелле намуслы командирлар бик кирәк дип, шәһәр коменданты Мөнир Исламов, жибәрмәскә теләп, йөреп тә караган иде. Хәтта анын да теше үтмәде. Дөрес, ул чакта чын хәлне берәү дә күзгә бәреп әйтмәде, тик чыбыксыз телефон мәгълүматлары шуна ишарә итә иде. Мин үзем шатландым гына. Чөнки армия тормышыннан болай да гарык идем.

Озын сүзнен кыскасы, 1945 елнын жәй башында, арыш буынга сикергән чорда, туган якка кайтып төштем. Юлда атлы да, жәяүле дә күренми. Тып-тын. Шау-шуга күнеккәнгәме, баштарак бу бик сәер тоелды. Әлеге тынлыктан хәтта колаклар чынлый иде. Басу капкасына сөялеп, бермәл тирә-якны күзәтеп тордым. Барысы да элеккечә. Әнә, янгын каланчасы бүксәсен киереп утыра. Бу—район үзәгендәге иң биек корылма. Хәтеремдә, шул каланчаны күрү өчен малайлар белән, ун чакрым ара үтеп, Актанышка килгән идек. Исебез-акылыбыз китеп, читтән генә карап торган идек. Яна гына төзелгән чагы, бөтен дөньяда аннан да биек корылма юктыр сыман иде. Хәзер төсен жуйган, такталары унган кер шикелле саргылтланып калган. Кечерәйгән дә сыман. Хәер, үзебез үскәнбездер, мөгаен. Аннан сон, күпне күрергә туры килде ич, офыклар да кинәйде, карашлар да үзгәрде.

Алда арыш кыры жәйрәп ята. Дулкынланыпмы-дулкынлана, жил дә исми үзе. Дингез кебек инде, жилбикә кузгатып жибәргәч, дингез дә атна буе тибрәлә бит.

Чемодан белән биштәремне каешка тагып, жилкәмә астым да, чайкалып утырган шушы яшел дингез арасыннан тасмадай сузылган арба юлы буйлап, туган-үскән авылыма таба атладым. Йөрәгем ашкынып тибә, күнелем алгысына. Әсирлектән котылгач язган беренче хатыма авыл Советы рәисе Кифая апа жавап бирде. 1943 елда нинди дер тамак чире чыгып, әткәй дә, әнкәй дә, үземнән ике яшькә олырак апам да үлеп киткәннәр. Авыл әнә шулай өе-өе белән кырылган. Кырда кышлаган бодай башагын жыю бәласе, имеш. Абыем Харис сугышта иде, Прага янында башын салган. Халык телендә кара кәгазь дип йөртелә торган хәбәрне хат эченә салып жибәргәннәр иде.

Сугыш безнең гаиләне әнә шулай төбе-тамыры белән тузгытып ташлады. Ялгыз башым. Туганнарым, авыр чакта таянырдай якын кешеләрем калмады диярлек.

Ишек-тәрәзәләре такта белән калакланган ятим өйгә кайтып керүе һич тә жинел булмады. Чыдаша алмадым, фронтовик башым белән ирексездән утырып еладым. Ихатаны алабута баскан. Без үскәндә алабутаны хәерчелек билгесе дип йөртәләр иде. Шуна күрә әйберләремне болдырга куйдым да, бернәрсәгә карамый, кулыма чалгы алдым. Әткәйнең хужалык кирәк-яракларын саклый торган келәтендә һәммә нәрсә үз урынында иде. Чалгысы

да, балтасы да, пычкысы да... Ул үзе дә шушында гына кыштыр-кыштыр нидер майтарып йөри кебек... Тамагыма килеп утырган төерне шактый ара йотып җибәрә алмыйча тордым. Бүген үк зиратка барып, каберләренә чардуган куям дип, күнелемә беркетеп куйдым.

Ишек алдында чүп үләне чабып йөрүемне күреп, үткән-сүткән хәл-әхвәл белергә керә башлады. Авыл әле ярым буш иде, халык—эштә. Шулай да кайту хәбәрем таралып өлгергән икән инде. Күп тә үтми, галифе чалбары өстеннән арзанлы пинҗәк кигән бер фронтовик күренде. Авызын ерып, титаклый-титаклый мина таба килә. Танйым да, танымыйм да.

—Таһирҗан!—дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым.—Таһирҗан!

—Хисаметдин!

Без сөякләребез шыгырдаганчы, ирләрчә каты итеп кочаклаштык.

—Җәле, җәле, карыйм әле, сугыш ничек үзгәртте икән үзеңне,—дип Таһирҗан артына чигенә-чигенә күзәтте,—әйбәт кайткансың, киемнәрең дә яңа, ә нигә погондагы йолдызларың ике генә бөртек?

—Сөйләшербез әле. Ә үзең? Кайчан кайттың, ниләр майтарасың?!

—Минем хәлләр мөшкел, Хисаметдин,—дип кулын селтәде дустым,—сугыш бетәргә сигез ай кала минага эләктем. Уң аягымны тездән түбән кисеп ташладылар. Рота командиры идем. Капитан. Орден-медальләрем дә җитәрлек.

—Син миннән күпкә уздыргансың. Молодец!

—Да ну, монда аларның берниндиди кадере юк,—дип чыраен сытты Таһирҗан.—Дилбегә тыл күселәре кулында. Төкерәләр алар синең орденнарыңа.

—Эшкә урнашмагансыңдыр ич?

—Өч ай инде. Агроном. Колхоз рәисе белән генә борчак пешми. Үзен әллә кемгә куеп йөргән була, сабакы...

—Бу яктан икебезнең дә хәлләр мактанырлык түгел икән шул, дускай. Әнә, минекен күреп торасың...

Без Таһирҗан белән бик якын дуслар идек. Сөндә су коенып үстек, бергә мәктәпне бетердек. Аннан соң, биштәр асып, Минзәләгә чыгып киттек. Авыл хуҗалыгы техникумына имтихан тоттык. Мин ветеринарлыкка, ул агрономлыкка укыды. Миннән ничәдер айга өлкәнрәк булганга, аны сугышка алданрак алдылар.

— Әйе, синең хәл катлаулырак,—дип килеште дустым.

Ул әле минем әсирлектә булуымны белми иде. Анысы, әсирлекнең киләчәк тормышыма нинди дә йогынты ясау ихтималы үземнең дә ике ятып бер төшемә керми иде.

—Әйдә, Хисаметдин, безгә киттек, табын көйләп, сөйләшеп утырырбыз,—диде Таһирҗан,—үзебездә яшәрсең, урын җитәрлек.

—Рәхмәт, дустым,—дип сабакташымның кулын кыстым,—бүген бик мөһим эшем бар шул, әткәйләргә чардуган ясап куймакчы идем. Иртәгә үк әткәй-әнкәйнең, барлык туганнарымның рухына дога кылдырып, Коръән чыгарырмын дип торам.

— Күрәм, сугыш сине диннән яздырмаган...

—Дога саклады да инде мине, Таһирҗан. Муенымда әле дә әнкәй язып биргән "Аятелкөрси".

—Моны кешегә чыгарма инде, дус бар, дошман бар, дигәндәй. Комсомолда белеп алсалар, күз дә ачырмаслар.

—Шуңа күрә дошманга түгел, дустыма сөйлим дә инде.

—Ярар, лейтенант, озын сүз бозау имезә ди, мин басуга киттем, кич тагын әйләнермен. Русча да сөйләшеп алырбыз. Доган моңа каршы түгелдер бит?

—Борчылма, андый чакта мин аны салып куям.

—Тоныкъ суның төбе корт ди, ике койрыклы икәнсең, хәйләкәр төлке,—

дип елмайды Таһиржан.

—Теленә салынма, бар, эшендә бул, прсидәтел абзан юксынадыр.

—Нәкъ өстенә бастың! Күзәтеп кенә йөри, сабакы.

Таһиржан киткәч, бәләкәй арбага баганалыклар, такта-токта төяп, зиратка менеп киттем. Ә ул танырлык түгел иде. Элек жир жиләге уңа иде монда. Жиргә кызыл ашъяулык жәйгәндәй мәмрәп пешәләр иде. Без малайлар белән карарга гына керәбез, авызга кабарга шикләнә идек. Чиялек тау итәгендә дә мыж ул жиләк, ерак та түгел, кул сузымында гына.

Зиратның ихатасы ни сәбәпледер юкка чыккан. Анда мал-туар тулган. Шаулап утырган сирень куакларының ялманып беткән шәрә кәүсәләре генә кукраеп утыра. Чардуганнар да күзгә чалынмый. Әллә, Ходаем, аларга да кул сузганнармы? Русларда "проходной двор" дигән әйтем бар. Безнең зират менә шушы хәлдә иде. Авыл Советы ни карый икән? Картлар ник тавыш күтәрми? Халык нигә битараф?

Портупейның каешын чишеп, кительнең төймәләрен ычкындырдым да эшкә тотындым. Ачу белән, үжәтләнеп тотындым. Әйдә, оятларына көч килсен. Бәлкем, соңлап булса да акылга килер авылдашлар.

Кичке якта миңа Таһиржан кушылды. Икәүләп тәки башкарып чыктык без бу эшне. Кайтышлый авыл Советына сугылдык.

Кифая апа безнең "тәгәрмәчкә таяк тыгып" йөрүебезне килештермәде. Йөз сулары түгелде.

—Югын бар итеп, барын бал итеп саклап калганга рәхмәтегез шушымыни инде,—диде ул рәнжеп. Аннан соң катгый гына өстәп куйды:—Райком алдында, райбашкарма алдында намусыбыз чиста, иптәш Сталинның күрсәтмәләрен жиренә житкереп үтәдек. Кешеләр ачтан үлсә үлде, әмма дә ләкин фронтны икмәксез калдырмадык.

—Кифая апа, болар өчен зур рәхмәт,—дип, сүзләре тамакка сөяк булып утырса да, юатырга ашыктым,—без сезнең алдыгызда баш иябез. Тик зиратны да болай тотарга ярамый бит инде. Материал белән булышсагыз, яшьләрне жыеп, киртәсен үзебез тотар идек.

Бүлмә хужасының ирен очларына мыскыллы елмаю кунды.

—Мокыт та: "Ит булса, бәлеш пешерер идем, ярма гына юк",—дип әйтте ди. Агач-таш житешсә, зират ихатасын сүтәр идекме? Каһарман коесы буендагы әвенне шул киртәләрдән оештырдык. Рәхәткә чыктык анысы, ашлыкны дәүләткә әвеннән генә озатабыз хәзер. Ара якынайды.

—Район ярдәм итмиме?

Рәис безгә янә үтергеч караш ташлады.

—Аңлыйсызмы, урман юк районда. Тәртәлек өчен дә Башкортка чыгабыз. Билет юнәтүе мең бәла.

Ниятебез бушны бушка бушатудан узмады.

—Иптәш фронтовиклар, житдирәк мәсьәләләр дә күп, зират качмас, алып та китмәсләр, бу кысыр хәсрәт кенә,—дип озатып калды Кифая.

—Күрдеңме,—диде Таһиржан ачу белән,—колхоз председателе дә шундый, итәк кисеп, жиң ямарга ясап куйган кебекләр, ике бозауга кибәк аерып бирә белмәгән килеш житәкче урыннарын биләп алганнар. Инициатива дигәннең и хәрефе дә юк үзләрендә.

—Шуннан артыгын булдыра алмыйлар, күрәсең, Таһиржан. Артыгын таләп тә итеп булмый. Юкка нервыңны туздырма. Алар урынына тиздән яңа кешеләр килер. Син менә, мәсәлән, махсус белемле агроном. Әйбәт оештыручы. Капитан.

—Ә үзең?—дип миңа күтәрелеп бакты дустым.

—Минем урын мал-туар янында, Таһиржан. Кубаров абый исән-сау икән әле. Элеккеге эшемә алыр, шәт.

—Актанышка күченергә мени исәбең?

—Барып-кайтып йөрермен. Әткәй-әнкәй нигезен туздырырга кулым бармас.

Йорт тирәсендә бер-ике көн казындым да, бер җомгада иртән иртүк район үзәгенә төшеп киттем. Баш табибның гадәтен беләм, ул эшкә таң белән килә. Өйләдән соң авыллардан йөреп кайта. Шуңа күрә аны урынында тотам дисәң, йокы белән булышма.

Мал хастаханәсе моннан дүрт ел элек тә авыл читендә үзе бер утар булып, яшеллеккә төренеп утыра иде. Хәзер дә шул рәвешен югалтмаган. Койма буяуларының ала-колалануын исәпкә алмаганда, үзгәреш сизелми кебек. Күрәсең, житмәүчелек. Югыйсә, Кубаров койманы болай тотмас иде. Ул тәртип, төгәллек, матурлык ярата торган кеше. Ифрат таләпчән. Үзенә карата да, персоналга карата да бердәй дәрәҗәдә катгый иде. Ә табиб буларак, гомумән аңа тиңнәр юк. Институтлар белән элемтәдә тора, практикантлар кабул итә. Күп укый. Ниндидер сәяси гаебе өчен Мәскәүдән сөрелгән профессор дип сөйлиләр иде аның турында. Бик ихтимал. Чөнки чи татар районына килеп төпләнүен башка ничек аңлатасың?

Мин аның ак офицерныкы шикелле шырпыдай төзгә каткан ыспай гәүдәсен ерактан ук шәйләп алдым. Кем беләндер кулларын изи-изи сөйләшкән мәле. Ул ат спорты белән шөгыльләнүче кеше кебек озын конычлы хром итек, яшькелт төстәге галифе чалбар, шул ук төстәге френч киеп йөри иде. Өстендә әле дә шул ук кием.

—Товарищ главный врач! Ветеринарный фельдшер Сабиров Хисам для прохождения дальнейшей службы прибыл,—дип искәрмәстән генә Кубаровның каршысына килеп бастым.

Саргылт керфекләрен челт-челт йомгалап, тыныч кына мине күңел иләгеннән уздырды бу. Таныды!

— Атакайгынам, Хисам Сабирович, сез ич бу!—дип елмаеп җибәрде.

Кубаров комплиментлар әйтә-әйтә мине култыклап алды да хастаханә бинасына таба алып китте. Бераз баргач, башын борып, әңгәмәдәшенә дәште:

—Гафу итегез, зинһар, күреп торасыз, фронтовигыбыз кайтты, берәр сәгатьсез кузгалып булмас. Атыгызны да интектермәгез, тугарып торыгыз.

Кубаров бүлмәсендә чәйләп ярты сәгать чамасы сөйләшеп утырдык. Дөресрәге, ул сораштырды, мин булдыра алганча, җавап бирдем. Бернәрсәне дә яшермәдем.

—Константин Семенович, миңа кайчан эшкә чыгарга?—дип сорадым әңгәмә азагында.

—Әле сез эшкә дип килмәдегезмени?—дип соравыма сорау белән җавап бирде бүлмә хуҗасы хәйләкәр генә елмаеп. Күр, шаяртып та сөйләшә белә икән ич безнең баш табиб. Көлештек. Ләкин ул бик тиз үз эзенә төште.

—Хәлләр катлаулы, Хисам Сабирович,—диде житди генә,—Башкортстанның безгә күрше бер авылында түләмә белән авыру очрагы теркәлгән. Сөн, Агыйдел чыгышларында постлар оештырып йөрибез. Хәзер райондагы барлык мөгезле эре терлекне берәмтекләп тикшереп чыгу бурычы тора. Сез районның төньяк-көнбатыш төбәгендәге авылларны алырсыз. Үзегезне бүгеннән эштә дип санагыз. Тарантасы белән ат беркетәм. Ә хәзер, кавалеристлар әйтмешли, по коням!

Шулай итеп, өйгә дә кайтып тормыйча, юлга чыктым. Наратлы миңа беркетелгән авылларның иң зурысы. Шунда юнәлдем. Бу авыл алтышар бригадалы ике колхоздан тора. Нигә аны икегә бүлгәннәрдер—аңлый алмадым. Үзләре дә төшендерә алмады. Табигате матур. Өч-дүрт чакрымда гына Агыйдел җәйрәп ята. Күлләр күп. Болын-көтүлекләр дә мулдан. Мал-туар өчен бик унайлы урын.

Ин элек "Таң" колхозы терлекләрен утарга кайтартып, колхоз ветсанитары белән һәрберсен җентекләп карап чыктык. Икенче колхозда да тикшерүне

әйбәт оештырдылар. Канәгать калдым. Чират аерым хуҗалыкларга җиткәч кенә эшнең көе китте. Халык сыерларны урамы-урамы белән фермага алып килергә тиеш иде. Бер көнне—бер урам, икенче көнне—икенче урам...

Беренче көнне үк тәртип бозылды. Малларын күрсәтелгән вакытка алып килмәүчеләр шактыйга җыелды. Кайберәүләр бөтенләй баш тартты. Янәсе, котыр өстенә котыр гына бу, янәсе, сыерларны хөкүмәткә җыялар икән. Андыйларның исемлеген авыл Советына бирдем. Чөнки түләмә бик куркыныч йогышлы авыру. Бер эләктеме, тиз генә котылырмын димә. Шуңа күрә чирле малның кайберләрен сәгате-минуты белән юк итү хәерле. Хәтәре тагын шунда, аның кешеләргә дә йогу ихтималы бар. Юха елан шикелле төрле кыяфәткә, төрле сурәткә керә белә: әле эчәгеләргә ябыша, әле үпкәне каезлый, әле канны агулый. Бациллалсы искиткеч мәкерле. Аны төгәл ачыклау өчен лаборатор анализлар үткәрергә кирәк, билгеле. Минем бурыч исә шикле терлекләрне ачыклау һәм башкалардан аеру. Әлбәттә инде, кайбер очракта җаваплылыкны тулысынча үз өстеңә алырга да туры килә. Бу сырхавы икеләнү уятмый торган малларга карый. Ан-сан итеп тору афәткә тиң.

Колхоз малларына тел-теш тидерерлек түгел иде. Әлегәчә тикшерелгән хуҗалык терлекләренә дә дәгъва белдерергә һичнинди нигез юк. Монда барысы да тәртиптә булырга тиеш дигән нәтиҗә чыгарып куйдым. Әллә соң башкаларны тынычлыкта калдырыргамы? Ул керебеткән адәмнәрнең миңа ни хаҗәте бар? Авыл Советына әйтәм дә, бетте китте вәссәлам. Тик соңгы минутта гына, ай-һай, Кубаров бу адымымны хупламас бит, дип кире чигендем. Ул эшне җиренә җиткереп, зур төгәллек, зур җаваплылык белән башкаруны таләп итә.

Аллага шөкер, шайтан адаштыра алмады, вакытында үземне кулга ала алдым. Шуңа әле дә кинәнәм.

—Чарасын күрегез, бүген соңгы көн,—дип кисәттем авыл Советы рәисен.—Югыйсә, эшне зурга җибәрәчәкмен.

Ниһаять, отказниклар кузгалды. Әнә, утарга чуар сөтбикәсен җитәкләп, чыра кебек кенә юка гәүдәле малай килеп керде.

—Җә, кайсыгыз монда баш, карасагыз җәтрәк карагыз да, эш ашыгыч, китәм,—дип шундук ультиматум куйды бу.

Әлеге кыю орчык башын тагын бер мәртәбә күздән кичердем. Арыкның арыгы, ә үзен бик кәттә тота.

—Син, егет, алай бик куырма әле, башта танышыйк, мин, мәсәлән, Хисам абыең булам, ә синең исемең ничек?—дип сорадым. Ошады ул миңа. Нindидер сөйкемле сөяге бар иде аның.

—Флүн, фамилиям Сабиров.

—О-о, без адашлар икән ич, дус кеше, мин дә Сабиров бит. Ничә яшьтә инде син, Сабиров?

—Бәй, абый, яшь бара инде ул,—диде Флүн өлкәннәрчә. Әйтерсең, күпне күргән ил карты.—Җәренгә аякны тугызның аргы ягына салындырмак булам.

Тирә-яктагылар елмаешып куйдылар.

Флүннең үз мәнфәгатьләре.

—Абый, син сугышта ничә фашистны дөмектердең?—дип, ул очлы күзләрен миңа батырды.

—Бер танкларын яндырдым, рукопашныйда бер фрицны бугазладым. Дөресен әйттем, чөнки "күп" сүзен кулланып, бу эчкерсез малай алдында үземнең ялган образымны тудырасы килмәде. Төптәнрәк уйлаганда, немецларның минем өлешкә төшкән югалтуы бер гаскәригә күчереп исәпләгәндә һич тә аз түгел. Әгәр һәр совет хәрбие үз вакытында дошманның бер танкын, бер сугышчысын юк иткән булса, җиңү күне хәтсезгә якынаер иде. Югалтулар да астрономик саннар белән исәпләнмәс иде.

Монысы сүз уңаеннан. Малайга танк, рукопашный сүзләре нык тәэсир итте, күрәсең, телен шартлатып куйды. Үзенекен дә кыстырырга онытмады.

—Минем әткәй дә герой. Кәгадендә геройларча һәлак булды, дип язылган. Фашистлардан әткәйнең үчен барыбер кайтарам әле, күреп торырсың. Бүген-иртәгә баюнкаматка барырга исәп.

—Буен житенкерәмәс бит, Флүн.

Бу аның авырткан жире иде, ахры, йөзе караңгыланып китте. Шулай да югалып калмады.

—Бәй, абый, үдем дур мин, гәүдәм генә бәләкәй.

—Авызына саескан төкергән малайга карап юанмыйк әле, жәмәгать, эшкә тотыныйк,—дип ветсанитар ризасызлыгын белгертте.

—Әйдә, Флүн дускай, сөтбикәңне менә шушы әрәтә арасына кертик әле,—дидем,—Харис абый дөрес әйтә, беренче урында—эш!

Чуарбикә нигәдер үзен тынычсыз тота иде. Күзләрендә дә ниндидер шом бар сыман. Селәгәе мулдан. Ләкин бу әле бернинди чир турында да сөйләми. Малларның да характеры төрле. Усаллары, юашлары, сөзгәкләре, үшәннәре дигәндәй…

—Сыерыгыз ни исемле, Флүн?

—Кит әле, сыерның исеме була ди мени? Ат түгел лә ул сиңа,—дип, малай пырх-пырх көләргә тотынды.

—Ничек итеп телен ачтырабыз соң алайса, сорыйсы нәрсәләр күренә әле монда.

—Барыбер аңламай, абый, юкка телеңне әрәм итмә, котырган нәмә бит ул. Үгед сорап Башкорт ягына да сыпырткан ие әле. Насила парумда алып чыктык. Инәкәй әйтә, чуарның йөрәге дә чуар була, ди.

—Менә хәзер аңлашылды. Бик кирәкле мәгълүмат бирдең бит әле син, Флүн дус.

Ә үземнең йөрәккә гүя тигәнәк кадалды. Чуаркайның муенында жәрәхәте бар иде. Сыртындагы үлекләрне дә шәйләп алдым. Юкка гына борчылмый икән хәйван. Түләмә! Үпкәсенә дә төшкән, әлбәттә. Тәне кайнар. Әлегә күз алдында тире түләмәсе. Фәндә аны карбункул дип атыйлар. Чуаркай үз башына башкорт егетләреннән әнә шул матур яңгырашлы чир йоктырып кайткан икән. Үз башына: ул инде дәвалаудан узган.

—Флүн, бар, тиз генә әниеңне алып кил,—дидем малайга.

—Ул эштә бит, абый, мин үдем дә…

—Әйткәнне тыңла, жир тишегеннән булса да эзләп тап.

…Нәгыймә апаның чәчләрен йолкый-йолкый елаганы әле дә күз алдымда тора.

—Сыерым белән бергә үземне дә, дүрт баламны да алып китегез. Әткәләре фрунтта калды, сыеныр кешебез барыбер юк, бар карап торганыбыз шул сыер ие, инде аяк сузарга гына кала,—дип угаланган иде, ятимә. Хәлне төшендерүнең дә файдасы тимәде.

Мондый очракта, билгеле, колхоз ярдәмгә килә. Әле аның азмы-күпме страховой акчасы да кайтачак. Фронтовик гаиләсен сыерсыз калдыралар ди мени? Шуңа күрә хатынның әлеге өзгәләнүләрен аның наданлыгы белән генә аңлатып була иде.

—Юкка борчылмагыз, апа, барысы да рәтләнер. Үзем дә катнашырмын,—дип ышандырыпмы-ышандырам тегене. Башкалар ләм-мим, әйтерсең лә телләрен йотканнар. Хәтта авыл Советы рәисе дә бәхетсез хатынның хәленә кермәде.

Нәгыймә апа түгел, мин үзем беркатлы надан бәндә икәнмен ләбаса. Колхоз рәисе калын кашларын жимереп, эре тешләре арасыннан ике генә жөмлә сөзеп чыгарды:

—Дәүләт малын таратырга минем башыма тай типмәгән иптәш Сабиров. Башымны өтермәдә черетәсем килми.

Мин бу вакыйганы бик авыр кичердем. Әйтерсен лә, үз туганнарыма төшкән хәсрәт. Югыйсә, эшемне төгәлләдем, иртәгә күрше авылга сәфәр чыгарга торам. Бәлкем, Түбән Сөнгә дә сугылырмын әле. Мактанып алсан да зыян итмәс дим, тарантасларда гына йөрим бит. Юк, Нәгыймә апанын салынып төшкән иңнәре, Флүннен мелт-мелт итеп торган иреннәре һич тынгы бирми. Төнне дә әйләнеп-тулганып диярлек уздырдым. Яктыра башлауга, хуҗабикәдән Нәгыймә апаларнын кайда яшәгәнен сорап белдем дә, шуларга юнәлдем.

Сабир солдатнын йорт-җире дүрт ел эчендә шактый бетерешкән икән. Үзе унган кеше булгандыр, мөгаен. Йорты биек, абзар-кура, келәт ише корылмалары да житеш. Тик аларга хуҗа кулы тимәү үзен бик нык сиздерә иде. Урам як читәне авам-авам дип кенә тора. Капка баганалары да кыйшайган...

—Керергә ярыймы?—дип кычкырып, капка кактым.

Көтеп-сагалап кына торгандай, ишек уемында хатыннын арык гәүдәсе күренде. Үзе бер сүз әйтми, тик аптырап басып тора.

—Ярыйдыр бит?—дидем янә.

—Я-рый... нигә я-ра-масын...

—Нәгыймә апа, Флүнне уят әле, без анын белән Түбән Сөнгә барып киләбез.

—Нинди Түбән Сөн?..

Хатын әллә курыкты, әллә оялуы иде, һаман аптырап тора.

—Туган авылым ул Түбән Сөн. Сугышта вакытта туганнарым үлеп беткән. Сыерымны карарга кешем дә юк. Флүн белән аны монда алып киләбез. Савыгыз. Калганы турында янадан сөйләшербез.

Әйе, минем сыерым да, өч баш сарыгым да бар. Әткәйләрдән калган мал. Аларнын вафатыннан сон бу терлекләрне колхоз көтүенә кушканнар. Бозау, бәрән бәрабәренә.

Күзләрен уа-уа Флүн болдырга чыгып басты.

—Әйдә, Флүн, утыр тарантаска,—дидем анын күренүенә шатланып,—кичкә әйләнеп кайтырбыз.

Малай карышып тормады, кая, нәрсә дип сорамады. "Мин дилбегәне үдем тотам",—дип житәкчелекне генә үз кулына алды.

Әнисе баскан урынында мәрмәр сын сыман тораташ каткан хәлдә безне озатып калды.

* * *

Үз гамәлемнән мин үзем бик канәгать идем. Дөрес, бу адымымны хуплап бетермәүчеләр дә табылды. Хәтта Таһирҗан да ошатмады. "Үзенне немец бюргеры дип исәплисен икән, бик нык хаталанасын, монда сыер мал гына түгел, монда сыер яшәү чыганагы",—диде.

—Бюргер шәһәр кешесе ул , дустым, син үзен хаталанасын,—дип көлдем. Дөресе дә, Германиядә бюргер дип шәһәрдә яшәүчегә әйтәләр.

Таһирҗан да фикеремне үзгәртә алмады. Үкенмим дә. Эшләп торганда бер тамакны гына туйдырып булыр, шәт. Авылга барыбер сирәк кайтам. Шөкер, амбулаториядә булмәм, йокларга урыным бар. Яраткан һөнәрен буенча эшләү үзе зур бәхет ләбаса! Күнел генә нигәдер һаман утырып житми. Төннәрен төрмә, Һейенхаген белән саташам. Смирнов та, Эрна да тынгы бирмиләр. Әткәй, әнкәй. Барысы бергә өелде. Барысы да бер башка.

Ул хатирәләрне күнелдән чыгарып ташларга да вакыт инде. Яна тормыш башланды ич. Әнә, күр, көн нинди матур! Бу сина Германия түгел. Бездә барысы да табигый, Ходай яратканча. Үләннәр дә яшелрәк, жир дә йомшаграк.

Үлән котырып унган быел. Йокле киленнәрдәй тулышыпмы-тулышканнар. Чалгы чынын көтәләр, бәгырьләр.

Кояш инде куянны иярләгән, бишегенә ашыга. Челтәр болытларга да алсу төс ингән. Агыйдел генә ак тасмадай чуалып ята. Әйтерең бармы, бездә табигать табигатьчә шул инде. Немецларда ясалма матурлык. Алар әлеге матурлыкны үз куллары белән үзләре тудыра. Һәр агачның, һәр куакның шахмат тактасындагы фигуралар шикелле катгый оясы, үз урыны бар.

Атым ялкау гына юырта. Мин аны куаламыйм. Ашыгыр җирем юк. Барып урнашасы да, оештыру мәсьәләләрен генә хәл итәсе. Эш—иртәгә. Наратлыдагы түләмә очрагы бөтен районны аякка бастырачак, билгеле. Чир әлегә таралмаган. Тик монын инкубацион чор гына булуы да ихтимал. Кыскасы, алда мәшәкатьле, борчулы көннәр көтә.

Уйларымны чуалтып, гармун тавышы ишетелгәндәй булды. Колакларым сагайды. Ялан уртасында нинди гармун ди ул, тоелгангынадыр? Җилбикә тиктормас тукранбашларның кыңгырауларын кагып йөридер әле.

Гармун тавышы аерым-ачык ишетелә башлады. Карап баксам, озын гына буйлы бер хәрби сырт өстенә баскан да, ярсып-ярсып гармун тарта. Атымны шул тарафка бордым. Ул да мине күреп алды, әмма уйнавыннан туктамады.

Оста иде гармунчы. Көйнең һәр уентыгын, һәр бормасын уята, күңел төпкелендә оеп утырган хисләрне ургылдырып өскә калкыта. Ашкындыра, җилкендерә. Күптән гармун тыңлаганым юк иде. Мизгел эчендә бөтен гомерем моң аша күз алдымнан үтте.

—Рәхмәт, якташ,—дип уйнаучының аркасыннан кагып алдым. Ә аның авызы ерык. Йөзе фәкать елмаюдан гына тора диярсең. Тик елмаюы Эрнаны кунакка алып баргач күргән әпәнең елмаюына охшаш иде. Телсез, чукрак кеше елмаюы.

Фронтовик егетнең, чыннан да, бугазы яралы икән. Казанга операциягә җыенам, хәбәр генә көтәм, ди. Бугазына көпшә куячаклар икән. Әлегә кешеләр белән язу ярдәмендә аңлаша. Куен дәфтәре дә, карандашы да түш кесәсендә генә. Без дә бик тәфсилләп "сөйләшеп" алдык. Аны сугышка Уфа культура-агарту училищесында укыган җиреннән алып киткәннәр. Вокаль бүлегендә идем, ди, инде хәзер операция уңышлы үткәндә дә җыр белән сәхнәгә чыгуым икеле, ди. Кайгыра. Музыка белән генә күңелемне юатам, ди. Бер кыз белән танышкан икән. Чибәр дә, акыллы да дип сөенә.

Яңа танышымның исеме Хәбир иде. Гармунын уйнап калды, мин үз юлыма китеп бардым.

Бу авылда мин эш алымына үзгәреш керттем. Колхоз малларын элеккечә фермада карадык. Ә менә халыкныкын өй борынча үзебез кереп тикшердек. Авыл зур түгел, болай күпкә унай иде.

Ике ярдәмче беркеттеләр. Берсе олы гына яшьтәге ветсанитар вазифаларын башкаручы абзый, икенчесен агитатор диделәр. Монысы безнең гамәлне марксистик-ленинчыл идеология белән терәтеп кую өчен иде булса кирәк. Бездә бит хәтта чүп утауга да сәяси төсмер бирелә. Әйдә, йөрсен, миңа димәгәе, килсәм кунак, китсәм ерак.

Үзем көтәм, ниндиерәк икән ул агитатор дигәннәре? Кыз кеше диделәр. Тизрәк күрәсе килә.

Берзаман идарәгә басынкырак кына гәүдәле, чем кара күзле бер сылукай килеп керде. Чәч толымнарын чүмәлә кебек баш очына чорнап куйган. Киеме дә башкаларныкыннан аерылып тора. Бик таныш йөз!

...Артыма авып китә яздым. Рабига лабаса!

—Рабига, син түгелме соң бу?—дип каршысына барып бастым. Кызның да күзләрендә очкыннар кабынды. Ләкин ул аларга түгелергә ирек бирмәде. Керфекләрен идәнгә чәнчеп кенә кулын сузды.

—Исән-сау кайтуыгыз белән тәбрик итәм, Хисам абый,—диде.

—Рәхмәт. Безнен авылдан киткәнсез икән.

—Мөмкинлек чыкты да туган авылыма кайттым әле менә. Әнкәй янына...

Бөтен кешенен күзе бездә. Шуна күрә тартынып кына сөйләшәбез. Безнен арада сагынып искә алырлык хатирә дә юк анысы. Хат алышырга сүз куешкан идек тә, насыйп булмады.

—Халык эшкә сонара, башласагыз иде, иптәш Сабиров,—дип авыл Советы рәисе мине бүгенге мәшәкатьләргә кайтарды.

—Пожалуй,—дидем мин эре бәрәнге ашаган кешедәй. Кыз алдында үземне дәрәҗәле итеп күрсәтәсе килә иде. Район вәкиле икәнлегемне сизеп торсын.

—Пожалуй,—дип кабатладым янә,—кешеләрегез жыелып беттеме сон әле? Оештыру мәсьәләсендә наратлылардан өйрәнү сезгә һич тә зыян итмәс иде, между прочим...

—Чүп утау кампаниясендә без районда беренче урында,—диде рәис зур горурлык белән.—Бу—оештыру жимеше.

—Жә, иптәшләр, уттай эш өсте, кузгалыйк,—дип, агитатор ишеккә таба атлады. Эшебез жайлы гына башланып китте. Рабига хужалар белән әнгәмә корган арада, без ветсанитар белән терлекләрне энә күзеннән үткәрәбез. Әлегә барысы да әйбәт шикелле. Йөрәгем генә урынында түгел, Рабига белән аулакта калып сөйләшәсе килә, ләкин һич жае чыкмый. Әбәт вакытына ымсынып торам. Чөнки әлеге төркем өчен ашны колхоз әзерли. Шунда бер-бер хикмәтен чыгарып булмасмы? Чынлап еласан, сукыр күздән дә яшь чыга ди, эшне көйләдем бит тәки. Ашап-эчкәч, юк йомышны бар итеп, ветеринар абзыйны фермага жибәрдем. Хужа хатын эшенә чыгып йөгерде.

Ниһаять, Рабига белән икәү генә калдык. Алма бакчасында эскәмия бар икән, кызны шунда чакырдым. Карышмады. Башта сугышка озатканда мине әсир иткән мамыктай йомшак кулларыннан алдым. Аннан сон батыраеп китеп, кочагыма керттем. Чәбәләнмәде, бөтен гәүдәсе белән сыланды. Кош баласыдай талпынган йөрәгенен тибешен ишетеп-тоеп тордым. Тәне кайнар иде. Үзеннән-үзе иреннәребез беректе...

Урамдагы арба тавышыннан гына айнып киттек.

—Житәрегез, нишләвегез бу?—дип, кыз гаепне тулысы белән минем өстемә аударды. Шул рәвешле ул тиз генә ике арага читән дә корып куйды. Әле генә нинди якын иде, читләшеп тә өлгерде. Бу татар кызларынын монарчы мина билгеле булмаган бер үзгә сыйфаты икән. Тискәрелек катыш ялындыру. Кәжәләнү ягъни-мәсәлән.

—Сугышта сине гел күнелем түрендә йөрттем, Рабига,—дип, үзем дә чын дөреслеккә печтик кенә хилафлык өстәдем. Чөнки Эрна турындагы дөреслекне ул барыбер кабул итмәячәк иде.

—Күнелендә йөрткән кеше хат яза ул,—дип үпкәсен белдерде кыз.

—Әсирлектә хат алышып булмый бит, Рабига.

—Концлагерьда газап чиктенме әллә?

—Барысы да баштан үтте, Рабига, концлагеры да, төрмәсе дә, ялчылык та...

Арадагы читән дә шул ук мизгелдә юкка чыкты. Без янә кочаклаштык, иреннәр дә бер-берсен эзләп тапты.

Бераздан ветсанитар кайтты. Гармунчы Хәбирне дә ияртқән. Рабига егетнен каршысына ашыкты. Ни турындадыр бәхәсләштеләр. Блокнот бик еш кулдан-кулга йөрде. Хәбир ашардай булып мина карап-карап ала. Шунда гына башыма ис керде. Матур, акыллы кыз дигәне Рабига икән ич!

Йөрәгем сыкранып куйды. Ничек инде? Ин авыр вакытларда Рабиганы уйлап, аны күз алдына китереп юаныч таба идем бит. Ул һәрвакыт күнелемнен түрендә булды. Эрна берара анын урынын шактый кысрыклаган иде, анысы хак. Ләкин Эрна юк бит инде. Рабига үз урынына кайтты. Инде менә кавыштык

кына дигәндә... Юк, бу мөмкин түгел. Рабиганы мин беркемгә дә бирмәячәкмен.

Бу авылдан күтәренке күңел белән киттем. Иркенләбрәк килергә дип киттем. Аңа кадәр Рабига белән өлешчә аңлашу булып алды.

—Көтмәвенә мин сиңа үпкә белдерә алмыйм, Рабига,—дидем күзләренә туры карап. Хәлбуки, бу җөмлә үзе үк үпкә белән тулышкан иде.

Кыз моны шундук аңлап алды. Озын керфекләрен сирпеп, әйтте:

—Белмим бит, кем кемгә үпкәләргә тиештер әле монда? Хат язышу турындагы вәгъдәне син үзең боздың, Хисам абый. Белсәң иде, хатларыңны ничек көткәнемне...

—Бу хакта сүз булды ич инде.

—Алайса нинди үпкә булырга мөмкин соң?

Рабига шомырттай кара күзләре белән томырылып миңа карады. Ул гүя, мондый юк-бар сүзләр сөйләп гомер уздырганчы, кочагыңа алып, иреннәремнән суырып үбәр идең, дип әйтергә тели иде. Талпынып куйдым. Тик урам уртасында кызга үрелергә кыенсындым.

—Ә Хәбир?—дип сорадым.

—Хәбир абый үзенә, мин үземә...

—Ул башкача сайрый...

—Хыялый бит ул, шулай булмаса көпә-көндез яланда бер ялгызы гармун уйнап йөрер иде мени? Аннан соң, Хисам абый, утырып каласы да килми бит. Әллә сиңа ышанырга була, әллә юк? Карт кыз булып казый кушаматы алыргамы?

—Борчылма, Рабига, миңа ышана аласың...

Без сөйләшеп торганда яныбыздан выж-выж атлап, Хәбир узып китте, шәүләсе генә шәйләнеп калды. Кыз миңа елышты.

—Хисам абый, мине үзеңнеке ит, җәме,—дип пышылдады.

* * *

Атна дигәндә кичләтеп кенә район үзәгенә кайтып төштем. Кубаров эш урынында иде.

—Түләмәгә тәки киртә куя алмадык,—диде ишектән башым күренүгә. Аның бу дәгъвасе йөрәгемне сызып алды. Әйтерсең лә, моңа мин гаепле идем.

—Сакка солдатлар җибәрүегез бик яхшы булды, Константин Семенович,—дип үземнән битәр, аны аклагандай иттем. Ничектер ябыккан, суырылып киткәндәй тоелды ул миңа. Күрәсең, чын-чынлап борчыла. Өстәгеләрдән дә шәп кенә эләккән иде, ахры. Андый чакта шулай бит ул, селкеп кенә салмыйлар.

—Иртәгә көтү чыкканчы Наратлыга китәм. Беренче секретарь да килә. Хуҗалык җитәкчеләре катнашында киңәшмә уздырабыз,—диде Кубаров.— Сез мондагы эшләрне карарсыз. Хәзер иң мөһиме—түләмә! Шуны хәтерегездә тотыгыз.

—Башка күрсәтмәләрегез булмаса, мин чыга торыйм алайса, Константин Семенович...

Кубаров кулын селкеп куйды. Бу аның, сабыр ит, дигәне иде. Утырган урындыгым гына шыгырдады, үзем кузгалмадым.

—Сез, Хисам Сабирович, үзегезнең киләчәгегезне ничек күзаллыйсыз?—дип, бераздан Кубаров минем тарафка сынаулы карашын ташлады.

Бу минем өчен көтелмәгән сорау иде. Дөресен генә әйткәндә, аңа җавап бирергә әзер дә түгел идем әле. Чөнки, чөнки...

Сугыш вакытында әткәем-әнкәем, якын туганнарым кырылып беткән. Үз әҗәлем дә пычак йөзендә генә иде. Миңа иң әүвәл шушы кайгылардан арынырга, кеше рәтенә керергә кирәк. Эчемдә хәсрәт уты. Моны үзем генә

беләм, чәчеп-сибеп йөрмим. Шул кайгы болыты эчендә якты нур булып Рабига балкый иде. Хәзер, әнә, әлеге өмет чәчәгенә дә кырау тиде. Бу хакта күп уйландым. Кыз үзе мөнәсәбәтләрне җайлап җибәрү ягында. Мине үзеңнеке ит, ди. Ләкин бу җөмлә анын Хәбир белән бәйләнешле икәненә дә ишарә итә. Офыкта пәйда булмаган булсам, аларның гыйшкына бернинди җил-янгыр да тимәс иде. Һич тә Хәбирнен ашына таракан булып төшәсем килми. Фронтовиклар ич без! Кыскасы, киләчәк әле Алла кулында. Хәзергә көннекен көнгә аударсаң, шул бик житкән.

—Һич тә сезнең шәхси тормышыгызга тыкшынырга теләмим,—дип, соравына ачыклык кертте баш табиб,—фәкать профессиональ якны гына күздә тотам.

—Анысы инде сайланган, Константин Семенович, мин—ветеринар!

—Рәхмәт, шатландырдыгыз,—диде Кубаров, – алайса, менә шушы кәгазьләр белән җентекләп танышыгыз да, чараларын күрә башлагыз. Китап төгәллекне ярата. Ярдәмемә исәп тә тота аласыз.

Әлеге кәгазьләр арасында Казан ветеринария институтына юллама, имтиханнар турында белешмә һәм башка кулланмалар бар иде. Сугышта катнашканнарга ташламалар да каралган икән.

Уку кайгысы юк иде дисәм, хата булыр. Вакыт-вакыт башны бораулап алгалый иде ул уй. Ләкин менә шулай капылт кына көн тәртибенә килеп басар дип исемә дә кертеп чыгармый идем. Ә хәзер? Хәзер ни гаҗәп, унай карыйм. Мине бернәрсә дә тотмый лабаса! Алга таба мондый форсат йә була, йә—юк. Аннан соң, сүз читтән торып уку турында гына бара.

—Соң түгелме, Константин Семенович, керү имтиханнары унбишенче июльдән башлана икән ич,—дидем икеләнебрәк.

Кубаровның уң як кашы дугаланып маңгаена менде.

—Өч көндә студент кытай телен өйрәнә,—диде ул,—ә сезнең ай ярым вакытыгыз бар. Тимерне кызуында сугу хәерлерәк.

—Алайса, мин тәвәккәлләү ягында, Константин Семенович. Сезгә бик зур рәхмәт. Зинһар, мәнсез дип ачуланмагыз инде, мин үзем башлап йөрергә тиеш идем...

—Менә монысы егет сүзе. Калганы өчен борчылмагыз.

Инде үземә иптәш табасы гына калды. Иптәш дигәнем, аңлашыла инде, Таһирҗан. Башта тыңларга да теләмәде. Шулай да ризалаштырдым.

Казанга бару, имтиханнар тапшыру турында тәфсилләп сөйләп тормыйм. Темадан читләшәсем килми. Алдылар безне институтка, икебезне дә алдылар. Көндезгегә бүлеккә дә кыстадылар әле. Ризалашмадык кына. Сессияләрдә дә булып кайтырга өлгердек инде. Без чын студентлар хәзер. Таһирҗан югары белемле агроном дипломы алырга җыена, мин табиб-ветеринар белгечлеген сайладым. Институтларыбыз да аерым.

Шөкер, тормыш та көйләнеп бара кебек. Йөрәк яралары да бөтәшеп килә. Тынычлап йоклый башладым. Йорт-җир тәртиптә. Әткәй-әнкәйләрнең рухы алдында йөзем пакь. Кызлар күзләргә дә вакыт җитте дип саныйм. Рабига белән Хәбир кавышканнар икән инде. Чират—миндә.

Әйе, авылга кайтканга нибары бер ел вакыт үтеп китте. Мин инде аягында нык басып тора торган белгеч. Кая барсаң да таныйлар, олысы-кечесе баш иеп сәламли. Институтта уку абруйны бик нык күтәрде. Чөнки районда җиде класс белемле җитәкчеләр дә шактый әле. Дустым Таһирҗан миннән дә уздырды, аны райкомга инструктор итеп алдылар. Берәр елдан үзебезнең колхозга рәис итеп җибәрмәкчеләр, ди. Әлегә тәҗрибә туплый, партия-оештыру эшенә өйрәнә.

Беркөнне милициядән шылтыратканнар, кичке якта сугылып чыксын әле, дигәннәр. Колхозлардан кайтып төшүгә, шунда юнәлдем. Соң иде инде. Әнә, Иске Идел өстенә эңгер-меңгер томаны таралып килә, каз бәбкәләре

дә оя-оя булып су читенә җыелышканнар, йокы алдыннан чөкердәшепме-чөкердәшәләр. Якында гына бозау мөгри, әнисен сагынган, күрәсең. Әледән-әле этләр аваз сала...

Шушы манзара белән хозурлана-хозурлана салмак кына атлыйм. Кечкенә авыл искиткеч аһәңле бит ул!

Милициягә болай соң чакыруларына да пошынмыйм. Чөнки авыл үз ритмы, үз кануннары белән яши. Сәгатькә карап түгел, җайга карап корыла эш вакыты. Милиция бүлегендә дә булгалыйм. Мал-туарга кагылышлы сораулары туса, миңа мөрәҗәгать итәләр. Аралашып, дустанә мөнәсәбәттә яшибез.

Дежур башлык бүлмәсенә таба ым какты, шунда кер, янәсе.

—Минем күңелем Микидә, Мики күңеле—ипидә. Әссәламегаләй...

Ярты юлда өзелеп калдым. Чөнки җитәкче кәнәфиеннән миңа ниндидер бөтенләй чит кеше текәлеп карап тора иде.

—Гафу итегез, буталдым, ахры...

Ул акланыуыма игътибар да итмәде. Күзләре һаман миндә. Ә иреннәренең читендә ниндидер салкын елмаю катып калган. Чын. Аның елмаюы, дөрестән дә, иреннәренә ябышып каткан иде. Кайчан гына карама, шул бозлы елмаю белән очрашасың.

—Утырыгыз!—диде хәрбиләргә хас көр тавыш белән.

—Ялгыш кердем бугай...

Һаман үземнекен тукыйм.

—Минем янга кеше ялгыш керми,—диде ул төксе генә.—Утырыгыз!

Бу инде әмер иде.

—Мин дәүләт иминлеге комитеты тикшерүчесе Шадрин булам,—диде бүлмә хуҗасы.

Шадрин дигәч кенә исемә килдем: без русча сөйләшәбез икән ич. Актаныш саф татар районы. Кубаров ише бер-ике генә бөртек рус милләте кешесе бар. Алар да татарчаны су урынына эчә. Димәк, бу тикшерүче читтән килгән. Димәк...

—Сабиров, сез хәрби трибунал тарафыннан атарга хөкем ителгән гаскәри. Статьягыз да хәтәр: ватанга хыянәт. Ә үзегез исән-сау. Моны ничек аңларга?

Шадринның ирен читендә шул ук бозлы елмаю.

Теге вакытта сержант Исламов камалыштан алып чыккан документлар сакланган икән, дип уйлап куйдым. Их, шунда көлләре күккә очкан булсачы!

—Мин үз гаебемне каным белән юдым, иптәш Шадрин...

—Алдашмагыз. Контузия генә алгансыз. Үлемнән немецлар коткарган.

—Шуңа күрә өч ел төрмәләрендә интектем.

—Сабиров, сез Германия хөкүмәте тарафыннан бу илдә яшәү хокукы алган сирәк хәрбиләрнең берсе. Немецларга бик мөһим эштә булышкансыз булыр. Ә төрмәгә килгәндә? Төрмә ул сугыш түгел. Шул рәвешле алар сезне саклаган гына, Сабиров. Максатлары да ачык—агент әвәләү.

Шадрин урыныннан торып, тәрәзә каршысына килеп басты. Кулларын чалбар кесәләренә тыккан хәлдә, берара тышны күзәтте. Эңгер-меңгер төн белән алышына иде инде. Урам бушап калган. Авыл иртә ята, иртә тора.

—Сез бик оста күз буяучы, Сабиров,—дип, ул кисәк кенә минем якка борылды. Сүз кыстыруымны көтеп булса кирәк, тынып калды. Дәшмәдем. Чөнки бу әңгәмә минем файдага түгел иде.

—Бик яхшы урнашкансыз,—дип дәвам итте сүзен тикшерүче,—барысы да мактый, күккә чөя. Районда түләмәгә киртә куючы да сез икән. Институтка кергәнсез, ятимнәргә булышасыз... Пәйгамбәр тәки.

—Язмышымны мин үзем сайламадым.

—О-о, күрәм, төрмәдә Фридрих Ницше философиясен дә өйрәткәннәр. Бу сүзләрдән волюнтаризм исе килә.

—Әйтегез әле, иптәш Шадрин, бу сорау алумы?

—Юк, бу сорау алу түгел, Сабиров, фәкать фактларны барлау. Һәм дә танышу.

Бу гади танышу гына түгел иде, әлбәттә. Комитетта минем турыда тулы мәгълүмат туплаганнар. Монысы көн кебек ачык. Беләм, алардан берничек тә качып котыла алмыйсың. Шул ук вакытта, ике дөнья бер кәнди, дип, ваемсыз гына нидер көтеп ятырга да ярамый. Шуна күрә тикшерүчедән чыгуга, төн димичә, туп-туры авылга кайтып киттем. Мең бәладән коткарган әнкәмнең догасы—Аятелкөрсием бар ич әле минем! Сугыштан кайткач, үз вазифасын үтәде, инде хаҗәте чыкмас дип, хөрмәтле ядкәр сыйфатында сандык төбенә салып куйган идем. Инде шул ачыкланды, иртәрәк салганмын икән, урынсызрак тынычланганмын. Хәзер менә янә сәгате сукты.

—Әллааһу ләәәә иләәһә илләә һүү...

Дөрес, Шадрин белән очрашудан соң тормышымда, шәхси борчуларымны исәпкә алмаганда, үзгәреш булмады. Мин ниндидер эзәрлекләүләр, аяк чалулар, кырын караулар көткән идем. Бәхетемә, шикләнүләрем акланмады. Бу, әйтергә кирәк, бик сөендерде. Бәлки, шулай үтеп тә китәр әле. Жинү барысын да кичерә диләр бит. Хәлбуки, мин үземне гаепле санамыйм.

Кубаров мина әле дә үзенең алмашчысына караган кебек карый, ышана, өмет баглый. Башкалар белән дә мөнәсәбәтләр элеккечә. Хәер, соңгы вакытта парторг кына нигәдер партиягә кодалаудан туктады. Бер алга, биш артка төшә иде, һич тынгы бирми иде. Мин партиягә ашкынмыйм. Әнә, Кубаров партиясез булса да алыштыргысыз белгеч, менә дигән житәкче. Дустым Таһиржан коммунист. Аны да ихтирам итәм. Хикмәт кесәдә билет йөртүдә генә мени...

Шулай да парторг авызына су капты.

• • •

Гүзәлиянең мөхәрриргә жавап бирер вакыты житте. Ә өйдә яучы көтәләр. Әйе, алар Кәбир белән якынлашып киттеләр. Үбешәләр дә, кочышалар да. Ләкин мәхәббәтме бу? Әгәр мәхәббәт икән, ни өчен Илһан күңеленнән китми. Гүзәлия үз-үзенә: "Яратмыйм, яратмыйм", дип мең тапкыр гына кабатламагандыр. Ул исә һаман әрсезләнә, төшенә керә, тынгы бирми. Үзе юкның күзе юк диган әйтем һич тә дөреслеккә туры килми икән. Шуна күрә кыз мәктәп директоры белән чәчен чәчкә бәйләү мәсьәләсен хәл итә алмый тора. Кәбирнең үзенә дә әйтте, мин сине яучы жибәрүдән тыя алмыйм, ләкин ашыкмаска киңәш итәр идем, жимешеннең әле өлгереп житәсе бар, диде.

Бер нәрсәне кире чигенмәслек итеп үзенә тәгаенләп куйды Гүзәлия, Кәбиргә чыккан очракта да, һөнәре итеп ул журналистиканы сайлаячак. Әлегә бу сер. Өйдәгеләр дә, Кәбир дә кызның катгый карарын белмиләр. Ул үз гомерен гаиләгә генә багышлап үткәрергә жыенмый. Шәхес буларак та үсәсе, танылачы килә.

Беркөнне кичләтеп кенә янына әнисе кереп утырды.

—Кызым, үз авызыңнан ишетәсем килә. Кәбирнең яучы жибәрергә жыенуы хакмы—түгелме?—дип сорады.—Безгә дә итәк-жиңнәрне жыебрак торырга иде дим. Син безнең бердәнбер кызыбыз, йоласына туры китереп, кешечә урнаштырасыбыз килә.

—Нинди йола ул, әнием?—дип, кыз белмәмешкә салынды.

—Әйдәле, кызым, уен-муенсыз, ачыктан-ачык сөйләшик әле...

Сәлиха кесәсеннән кульяулыгын чыгарды...

—Әнием, ярар инде, әнием, шаярттым гына ич, гафу ит, зинһар,—дип Гүзәлия, иркә песи баласыдай, әнкәсенә сарылды.—Әнием, мин әле хәл итмәдем, шуна күрә Кәбиргә дә сабыр итеп торырга киңәш иттем.

—И бала, бала... Менә диган абруйлы егет сорап торганда...

Гүзәлия әнисенә фикерен төгәлләргә ирек бирмәде.

—Ә кызың менә дигән түгелме?—диде.

Сәлиха яшь аралаш елмайгандай итте. Кызын янә кочаклап алды.

—Әнием, беләсеңме, минем бер генә дә кияүгә чыгасым килми. Гашыйк булырга яратам, үземне яратуларын яратам. Егетләрне ялындыру бик ошый... Ә кияүгә күнел нигәдер тартмый. Берәүнең дә үзем белән идарә итүен теләмим. Бала чүпрәге, ир дигән кешенең керле киемнәре, кухня, плитә... фу, шулар турында уйласам, саруым кайный башлый.

—Аллаһы Тәгалә хатын-кызны әнә шул син яратмый торган вазифалар өчен яраткан инде, кызым.

—Миңа малай булып туасы калган, иеме, әнием?

Гүзәлия әнисенең кочагыннан арынып, зур, йомшак кәнәфиенә чумды. Сәлиха, башын чайкап, аңа карап торды.

—Күп сайлансаң, утырып калырсың әле. Бик барырдай булырсың, алучысы тәтемәс.

—Әнием, башка сүзегез юкмыни соң сезнең, аптырыйм валлаһи, кияү дә кияү. Иҗат эшләрем, үземә генә кагылган алдагы план-ниятләрем дә бар бит минем. Нигә алар кызыксындырмый соң сезне?

Кыз иреннәрен турсайтып, читкәрәк борылып утырды. Сәлиха да күзлеген бер киде, бер салды, ахыры, халат кесәсенә шудырды. Аннан соң үзен кулга алып, сөйләп китте:

—Үзеңнекеләр булгач, белерсең әле бала кадерен. Без бит фәкать яхшылык кына юрыйбыз, кызым. Күрәсең, кайвакыт арттырып та җибәргәлибездер. Үпкәләмә, зинһар. Ничә әйтсәң дә шул бер сүз инде. Бәхетле булуыңны телибез. Шуның өчен җан атабыз. Моның ни гаебе бар соң?

—Әнием, иртәгә Актанышка төшәм, мине редакциягә эшкә чакырдылар,—дип, сүзне икенчегә борып җибәрде Гүзәлия.

—Ә мәктәп?

—Минем урыным мәктәп түгел, әнием. Ялгышны вакытында төзәтү мәслихәт.

Сәлиха кызы белән аңлашуыннан баш авыртуы гына алды. Илһанына ияреп Төркиясенә дә китмәде ичмасам, дип уйлап куйды.

Икенче көнне Гүзәлия редакциягә эшкә урнашып кайтты. Шуннан соң гына әлеге яңалыкны Кәбиргә җиткерде. Егет мондый башбаштаклыкны көтмәгән иде, әлбәттә.

—Ничек инде син шушындый мөһим мәсьәләне үз башыңа гына хәл итәсең,—дип кызып китте,—киңәшергә ярамый иде мени? Бу соң... мине санламау лабаса! Әгәр онытмаган булсаң, син дизертирларча ташлап качкан мәктәпнең директоры да ич әле мин. Уку елы башланырга ун көн кала ничек мөгаллим табарга боерасыз? Дөньяда тәртип, җаваплылык дигән төшенчәләр дә бар, Гүзәлия туташ, мин—мин микән, мин кем икән, дип борын чөеп кенә йөреп булмый.

Гүзәлия егетнең дер-дер калтыранып торган иреннәренә дикъкать белән карап торды да:

—Менә хәзер син миңа ошыйсың, Кәбир,—диде.—Югыйсә, ярарга тырышуың тешемә сылана иде. “Рәхим ит”, “Гафу үтенәм”...

—Ялгышасыз, Гүзәлия Харисовна, бу ихтирам итү, хөрмәт итү дип атала. Ләкин сүзебез бу хакта түгел. Күзгә төтен җибәрергә бик маһир икәнсез.

—Монысы ничек дип атала?

—Хәйләкәрлек.

Кыз башын артка чөеп, кылтыкланып көлеп алды. Кәбир ничек кенә чыгырыннан чыккан булып кыланмасын, мөнәсәбәтләренең дилбегәсе барыбер Гүзәлия кулында иде. Гаилә корган очракта да, бу хәл үзгәрмәячәк. Моны алар икесе дә бик яхшы белә. Шуңа күрә егетнең әлеге “бунты” ачулануга караганда яратуын, гыйшкын гына аңлата иде.

—Кәбир Таһиржанович, мине көн дә эшкә иртән илтеп куярсыз, кичен алып кайтып йөрерсез дип уйлыйм,—диде кыз күзләрен мутландырып.—Әллә дөрес уйламыйммы?

Гүзәлия назланып егеткә сырышты. Тегесе аны кочагына алды. Тыннары кысылганчы үбештеләр.

Барысы да жайланды кебек. Ләкин Хисам барыбер оныгына ышанып житми: алдалап кына йөрмиме, егетне кәкре каенга сөямәсме?

—Әбиең Гөлмәрьям мина вәгъдә кульяулыгы чигеп бүләк иткән иде, бик матур, бик мәгънәле йола, мәйтәм, искерә торган түгел,—дип, беркөнне ерактанрак суктырып, шул темага сүз кузгатты.

—Галижәнап Хисам Сабир,—диде Гүзәлиясе ясалма кылану белән,—сезне зирәклегегез өчен ихтирам итә идем монарчы, зинһар, улыгыз белән киленегез дәрәжәсенә төшә күрмәгез, мин моны авыр кичерәчәкмен. Ничә чәйнәсәң дә шул бер балык башы ич инде ул, ба-ба-кай...

И, бәбәлән йомыркасы, дип Хисам кулын селтәде.

—Безгә хәзер сезнең контракт таләпләрен ничек үтәвегез хакында сөйләшү урынлырак булыр,—дип сүзен дәвам итте кыз.—"Агыйдел" гәжитенең әдәбият, сәнгать һәм мәдәни мәсьәләләр бүлеге мөдире буларак, бу эшкә контрольлек итү мина йөкләнде.

—Эш бетте, көлтә жыясы гына калды,—диде Хисам көлемсерәп.

—Мин чынлап, дәү әти, Хәлилов белән әллә әзер өлешләрен бирә торыйкмы, дип уйлашкан идек, үземнен дә зур бер проектым булып исәпләнер иде.

Хисам башын кыңгыр салып, уйланып торды да әйтте:

—Юк, кызым, ярты-йорты килеш язманы укучыга тәкъдим итү килешеп бетмәс.

—Ул нинди стадиядә инде хәзер?

—Совет чоры гына калып бара.

—Дәү әнием бармы соң әсәрендә?

—Юк, контракт әсирлек, тоткынлык чорларын гына үз эченә ала. Аллаһы теләсә, Гөлмәрьям әбиенә бәйле гомер елларын аерым язармын дип торам.

СИГЕЗЕНЧЕ ТАСМА

## Сөрген

Мине кулга алырга 1946 елның сентябрендә, айның беренче якшәмбесенә каршы төндә килделәр. Каты итеп ишек шакыган тавыш ишетелүгә, эшнең нәрсәдә икәнлеген төшенеп алдым. Чөнки авылда йомышлы кеше күз бәйләнгәч ишекне түгел, башта тәрәзәне кага.

Таһиржанны кисәтеп куйган идем инде. Күңел сизә шул ул. Дустым бу хакта тынларга да теләмәде. Райкомда синең турыңда бер тискәре мәгълүмат та юк, дип барды. Фронтовик офицер башың белән юкны сөйләмә, син жиңүче совет солдаты, дип авызымны каплый иде.

Әле ярый нәзеремне үтәргә өлгереп калдым. Теге вакытта авыл зиратына киртә тотам дип үз-үземә сүз биргән идем ич. Таныш-белешләр аша райпланнан материаллар яздырып алдым. Кубаров ярдәме белән аларны Минзәлә урманчылыгыннан авылга кайтарттым. Белеп торгандай, шимбә көнне өмә оештырдык. Авыл Советы да ярдәмнән тайчанмады. Яшьләр район үзәгеннән дә килде. Көн эчендә киртәне сузып та куйдык. Шуннан бик күңелем булып кайткан идем.

Нәкъ шушы вакытта шатлык-кайгыларымны урталай ярып, ишек дөбертәттеләр.

—Дөп-дөп, дөп-дөп...

—Нигә ишегенне озак ачмый тордың?—дип ризасызлыгын белдерде өйгә басып кергән кешеләрнең шадра йөзлесе. Алар икәү иде.

—Ишетмәдем.

—Жыен!—дип әмер бирде Шадра.—Син ватанга хыянәт иткән һәм Германия файдасына шпионлык кылган өчен кулга алынасың. Менә ордеры, республика прокуроры кул куйган.

Шадра минем борын төбендә нindидер кәгазь кисәген болгап алды.

Сүзсез генә биштәремне җилкәмә астым.

—Син безне көткәнсең бугай...

—Сволочь,—дип агентларның икенчесе дә үз мөнәсәбәтен белдерде.

Туп-туры Минзәләгә алып килделәр, Актанышка сугылып та тормадык. Тагын бер атнадан Казанда идем инде. Суд дигәннәре дә шушында, Черек күл камераларының берсендә булды. Билгеле, башта сорау алдылар. Иң авыры сорау алу икән, дигәнне ишеткәнем бар иде. Шуңа күрә куркыбрак торган идем. Тик ни хикмәттер, эшне тиз тоттылар, чират зур иде, ахры. Утыз җиденче елгы җәзалау алымнарын кулланырга шикләнәләр иде булса кирәк. Чөнки сугыш безне күп нәрсәгә өйрәтте. Тоткыннар да үз хокукларыннан хәбәрдар иде. Өстәвенә, тешләрен кысып булса да түрәләр дөнья җәмәгатьчелегенең дәгъваларенә дә колак салырга мәҗбүр. Демократ булып күренәселәре килә. Дөрес, карцер, йокыдан мәхрүм итү, өскә бозлы су кою кебек "процедура"лардан өлеш чыгардылар анысы. Шулай да тәнгә кызган тимер басу, тырнак астына энә кертү, махсус җайланма ярдәмендә "нәзек җирне" кысуларны татырга туры килмәде. Монда немец төрмәсе башлыгы Зоммерфельд шикелле мәхбүсләрне җәзалаудан ләззәт алучы садист зат та юк иде, күрәсең. Гомумән, тәнгә кагылучы булмады. Ә калганы ари концлагеры аша узган әсир өчен алай ук түзмәслек түгел иде.

Әйткәнемчә, атна-ун көн эчендә барысы да хәл ителде. Шуңа күрә генә җиңелрәк сыман тоелгандыр, бәлки?

Мин гаебемне танымадым. Ул аларга кирәкми дә иде. Чөнки әсирлектә булуым, ирекка чыгарылуым, фермерда эшләвем, Эрна белән якынлашуым—барысы да мәгълүм. Бу фактларны берничек тә инкяр итә алмыйсың. Мине ГУЛАГка тыгу өчен әсир төшүем дә бик җиткән. Шадрин да әйткән иде ич, бу кадәр җинаятьләр букеты белән синең совет дөньясында яшәргә хакың юк, дигән иде.

Хәзер менә җавап тотам. Хөкем карарын нindидер тәрәзәсез, тар гына караңгы бүлмәдә игълан иттеләр. Хөкемдарлар өчәү, мин берүзем. Суд карарын торна муенлы озын майор укыды. Тавышы радио дикторыныкы шикелле тантаналы иде, гүя зур түрәгә нindидер җиңү турында рапорт бирә. Тегеләре дә төзгә катып тыңлый.

Шадрин яшәргә хакың юк дип әйтеп куйса да, әлегә бу төр җәза законга туры килми иде, ахры, унике ел белән чикләнделәр. Хәер, бу срок үлем җәзасына тиң иде бугай. Ник дисәң, судьяларның лискә эткә ошаган карсак гәүдәлесе олы канәгатьләнү белән реплика ташлады. "Бу сезгә ГУЛАГның унике еллыгына зур бүләк, Сабиров, утыз дүрттә утырганнарның берсе дә әлеге истәлекле датага тарта алмады, бәлки син рекорд куярсың»"—диде дә, үзенең тозсыз мәзәгеннән үзе кызык табып, ат кебек кешнәп алды. Калган судьялар да бер-берсенә карашып, елмаешып куйдылар. Мәчегә көлке, тычканга үлем.

Харьков камалышындагы трибунал да мине ватанга хыянәт итүдә гаепләгән иде. Бусының да билгеләмәсе нәкъ шундый, ана фәкать Германия файдасына шпионлык кына өстәлгән иде.

* * *

...Поезд ажгыра-ажгыра көнчыгышка таба чаба. Ул поездга безнең дә мал вагоны тагылган. Шыплап тутырылган вагон. Барысы да халык дошманнары, хыянәтчеләр. Ләкин без үзебезне чын совет кешеләре итеп хис итәбез. Сталинны мактыйбыз, социализмны күккә чөябез. Шуның белән бергә, әлеге сүзләрнең дөреслеккә туры килмәвен һәммәбез дә бик яхшы беләбез. Бу уен гына. Мондый шартларда берәү дә эчен ачарга ашыкмый. Әлегә, кем әйтмешли, бер-береңне капшап карау бара.

Без зур тизлек белән кара буранлы салкын кыш кочагына ашкынабыз. Күзгә күренеп суыта. Арада томаулылар да ишәйгәннән-ишәя. Купләрдә коры ютәл. Барлы-юклы киемнәребезгә төренеп, бер-беребезгә елышып утырабыз. Көнгә бер мәртәбә кәбестә шулпасы биргән булалар, ул кече телгә дә йокмый. Ипи дигәннәреннән кер сабыны тәме килә. Ә иң хәтәре, күңел төшенкелеге, өметсезлек. Чөнки безнең киләчәгебез юк. Шушындый халәттә кеше үз-үзенә кул саладыр, мөгаен. Ходай сакласын.

Актанышта минем турыда ни сөйлиләр икән дип тә борчылам. Таһирҗаннан, Кубаровтан башка берәү дә чын хәлне белми бит. Алары да теләктәшлек хисләрен эчтә генә йөртергә мәҗбүрдер, мөгаен. Берсе райкомда эшли, икенчесе—баш табиб. Совет власте кеше хокукларын боза, җәмгыятебез гаделсез, дип йөри алмыйлар ич инде. Минем аркада үзләренә кыенлык килмәсә ярар иде, дип теләкләр телим.

Авыр хәл. Йөрәк тоташ әрнүдән генә тора. Әле ярый башымны Рабига белән бәйләмәскә акылым җитте. Шуна сөенеп бетә алмыйм. Аның өчен бик үкенечле булган булыр иде. Яшәсен Хәбире белән. Яши-яши мәхәббәт тә килер.

Башымда мең төрле уй. Ә тәгәрмәчләр бертуктаусыз рельсларны саный.

—Тик-так, тик-так,
Тик-так, тик-так...

Бара-бара әлеге "тик-так"лар эчендә нindидер көй шәйләнә башлады.

—Кала-кала, кал-кал,
Кала-кала, кал-кал...

Тәгәрмәчләр белән бергә иреннәрем дә шул такмакны кабатлый. Бераздан алар татар җырына да әверелеп куйды.

—Каласың, каласың,
Туган илкәем...

Күзләремдә яшь. Ә күңелгә ничектер җиңел булып китте. Җыр да тәгәл рәвешенә керде.

Каласың туган илкәем,
Сөйгән ярларың белән...

Без Ак диңгез утрауларына кадәр барып җитмәдек. Чәтрәннәп торган йолдызлы төндә тайга эчендәге ярым җимерек баракка китереп түктеләр. Шушы урында юл өзелә икән. Лагерь моннан да арырак булып чыкты—көрт ера-ера тагын ике көн тәпи-тәпи бардык. Олактырдылар. Нух каргасы да очып җитмәле түгел.

Мунча керттеләр, чәчләрне кыркыдылар, баш тап-такыр булып калды. Иске-москыдан булса да, барыбызны да бертөсле итеп киендерделәр: фуфайка, сырган чалбар, аю кереп оялардай зур киез каталар, малахай бүрек—нәкъ карга көтүе. Исем-фамилияләр дә онытылды, номер белән генә дәшәләр.

ГУЛАГ—җинаятьчеләрне төзәтү урыны. Ә төзәтүнең иң үтемле ысулы—хезмәт. Һәрхәлдә, ил җитәкчеләренең сәясәте әлеге фәлсәфәгә нигезләнгән

иде, күрәсең. Шуңа күрә токтынның көне хезмәттә үтә. Без агач аударабыз, урман кисәбез. Тайгада исә урманның иге дә, чиге дә юк.

Урман эше авыр. Шуның белән бергә, минем шикелле авылда туып-үскән яшь, таза егеткә зарлану да килешеп бетмәс иде. Әмма төрле кеше бар. Берәүләр сәламәтлеккә туймый, икенчеләренең буыны йомшак, өлкәнрәкләрнең вакыты узган. Шуңа ашау-эчү каты-котысын да китереп өстәсәң, хәтта минем ишеләргә дә бу эш һич тә майлы ботка ашау түгел. Кул пычкысы белән колач җитмәс чыршыларны аударып кара әле. Моны башыннан үткәннәр генә белә.

Кешегә ярдәм итү, булышуны да өнәмиләр. Һәркем үз эшен унга-сулга карамыйча башкарырга тиеш. Күзәтүчеләр, сакчылар хәттин ашкан.

Шулай беркөнне ботак чабучы агай игътибарымны җәлеп итте. Мин аны моңа кадәр дә очрата идем. Тач Кубаров икән бу, дип уйлап куя идем. Туганы-мазары түгелме икән дип, үзеннән белешергә дә исәбем бар иде. Ничектер, җае гына чыкмады.

Аның эшен сызланмыйча гына карап-күзәтеп тору мөмкин түгел. Гомерендә дә балта тотып карамаган, ахры. Башта ботакның төбен изеп, чүпкә әйләндереп бетерә, шуннан соң кулы белән йолкырга тотына. Агачы да тиз генә бирешми бит аның, каһәр. Тамаша. Барлы-юклы көчен дә файдасызга сарыф итә. Егылып китәр дә, шунда ятып калыр төсле. Шулай үлүчеләр дә шактый.

Ничек ярдәм итәргә соң? Башы җәзадан чыкмаячак бу агайның. Кулдашым Киви исемле грузин кешесе. Тәвәккәллеге дә бар, кыюлыгы да, иләмсез дәрәҗәдә әрсез. Аралашучан. Шайтанның үзе белән дә уртак тел таба мәгәр. Әйттем менә, бригадирны җайла әле, ботак чабучы белән аралашырга иде, дидем.

—Шул мәктәп бакчасыннан качкан карачкы беләнме? Ниемә кирәк ул колга сиңа?

—Күрмисеңмени, ничек интегә? Аз-маз балта тотарга өйрәтмәкче идем.

—Мондагы бөтен ак якаларны да эшкә өйрәтеп бетерә алмыйсың, кацо.

Киви куе кара кашларын күз төбенә җыеп, миңа карап торды.

—Ярар, миннән булсын игелек, бар, калганын үзем җайлармын,—диде.

—Таныш булыйк, мин—Сабиров,—дип агайга кулымны суздым.

—Коган,—диде ботак чабучы, ләкин кулын бирмәде.

—Сезгә булышырга рәсми рәвештә куштыларммы, әллә үз белдегегез белән генә килдегезме?—диде ул як-ягына карангалап.

—Үзем теләп...

—Мин ярдәмегезне кабул итә алмыйм,—диде Коган һәм эшкә керешге. Балта сабының төбеннән үк ике куллап тоткан, физиклар әйтмешли, хәрәкәтенең амплитудасы юк. Җитмәсә, хатын-кызлар шикелле турыга бәрә.

Ул арада яныбызга бригадир килеп басты.

—Йә, Сабиров, күрсәт әле осталыгыңны, алдынгы тәҗрибә мәктәбе ачасың дип ишеттем, карап карыйк.

Киви әллә нәрсәләр сөйләп бетергән икән менә, дип уйлап алдым. Сүз боткасы. Нигә дип бригадирны җибәрергә кирәк булды икән?

Беләк юанлыгы ботакны бер селтәнүдә кыеп та төшердем. Бу шул кадәр тиз һәм шома килеп чыкты ки, үзем дә шаккаттым. Ә бригадирның авызы ерылып китте. Чын, валлаһи!

—Да-а,—дип сузды ул,—жилле егеткә охшап торасың әле, кенәз, бүгеннән бу өшегән авызны буксирга аласың, өйрәтәсең ягъни. Аңладыңмы?

Агай барыбер балта тотарга өйрәнмәде. Өйрәсе сыек иде аның. Бәлки, теләмәгәндер дә. Аның каравы, без дуслашып киттек. Дөрес, ул минем алда сер капчыгын тулысынча әйләндереп селкемәде. Шулай да профессор икәнен әйтте. Күренекле архитектор икән. СССР Архитекторлар берлеген җитәкләгән.

Кайларгадыр язып, кемнәргәдер мөрәҗәгать итеп, үз белгечлеге буенча чыга торган журналлар белән танышып барырга рөхсәт алды ул. Ә бер елдан ниндидер житди проект өстендә эшли башлады. Үзенә аерым бүлмә бирделәр. Ана балта кирәкми иде инде. Без ара-тирә очраштыргалыйбыз. Мин аннан Һейенхаген хакында белештем.

—Ренессанс чорынын гүзәл жимеше ул Һейенхаген,—диде профессор,—ишетүемә караганда, инглизләр аны жир белән тигезләгән, имеш.

—Мин әлеге хәрабәләрне үз күзләрем белән күрдем.

—Кызганыч, бик кызганыч...

Коган бераздан бөтенләй югалды. Әллә башка лагерьга күчерделәр, әллә берәр хафага юлыкты. Безнен тормыш читтән күзәткәндә генә бер төсле тоела ул. Чынлыкта һәр тоткын үз эчке дөньясы, үз холкы белән яши. Лев Толстой да әйткән ич, кешенен бөтен нәрсәсен үзгәртеп була, холкын гына үзгәртеп булмый, дигән. Шунын кебек инде, тоткынның да шәхси тормышы бар. Дөрес, әлеге тормышны иректәге тормыш белән чагыштырып булмый, чикләре бик тар анын. Шулай да, әйтик, әдәби ижат белән мавыгута берәү дә киртә куя алмый. Кем ничек инде. Киви, мәсәлән, жарияләр турында хыялланып тәм таба иде.

—Грузин өчен ин хөрмәтле үлем йә яраткан гүзәлен кочагында, йә яу кырында үлү, кацо,—дип тукый иде ике сүзнен берендә. "Мин грузиннарнын Казановасы, Гашыйк алласы",—дип тә шапырына. Бу темага афоризмнары күп иде анын. Менә тагын берсе: "Грузинга гашыйк булу өчен жиде секунд вакыт житә". Үзенә ул бер генә секунд вакыт бирә иде. Шулайдыр, хатын-кыз офыкта пәйда булганчы ук анын исен сизә иде. Билгеле инде, лагерьда хатын-кыз затлары күп түгел, шулай да кайбер хужалык боксларында берән-сәрән генә булса да ирекле ялланучылар күренгәли иде. Киви жае туры килгәндә аларны сәгатьләр буе күзәтеп утырырга әзер.

—Их, кацо, бүген шундый бер чибәркәйне күрдем, м-ма(!), битен юган суны эчсәм дә үземне ин бәхетле грузин итеп санар идем,—дип куана. Ләкин ул бергә генә канәгать түгел.

—Мина хатын-кызларнын барысы да якын, барысы да чибәр, барысы да үз,—ди фәлсәфәгә бирелеп,—янгыр да бит бер генә кырга яумый, бал корты да бер генә чәчәккә кунмый. Мин дә дөньядагы барлык гүзәлкәйләргә дә шатлык вә ләззәт китерүче зат. Хыялы тезгеннән ычкынган чакларда ул мина "боз йөрәк", дип дәшә, ягъни хиссез-нисез бәндәгә чыгара.

Үз тәкъдирен үзеннән, дигән мәкаль Кивига тулысы белән туры килә иде. Тау кешесе ич. Әнә, тау тәкәсе дә хәле бетеп егылганчы, тәмам жан-тәслим кылганчы бикәчләренен күнелен күрә икән. Дустым белән дә шуна охшаш хәл булды.

Ниндидер эчке бер сиземләү беләнме, бәлкем, кемнәндер ишетеп калгандыр, болары мөһим түгел, кыскасы, безнен лагерь тирәсендә хатын-кызлар колониясе барлыгын белеп алган бу. Шунда эләгү өчен нинди генә планнар кормады, ташбаш. Әүвәл кар көрте эченнән мәгарә юлы салу турында хыялланды. Монын аек акылга сыймаслык хәл икәнен анлагач, сакчыларны үз ягына аудару уе белән саташып йөри башлады. Монысы беренчесенә караганда да дуамалрак иде. Ике сәгать саен алмашынып тора торган сакчыларга ничек якын килмәк кирәк тә, ничек уртак тел табып бетермәк кирәк? Атып кына егачаклар. Немецларнын концлагерындагы шикелле монда да адым саен һау-һау килеп эт өреп тора.

Киви ары сугылды, бире сугылды, бабасырлы бала сыман һич үзенә-үзе урын таба алмый гына бит. Мине дә котыртып йөдәтте. "Татар барда хәтәр бар" диләр, күрсәт кемлегенне, сагынып сөйләрлек булсын дип, әле салпы якка салам кыстыра, әле өшегән авыз, жебегән дип сүгеп ташлый. Аннан

сон, җә инде, кацо, иптәш бул инде, кан кайнавын басабыз да әйләнеп кайтабыз, сизми дә калырлар, дип ялварырга тотына. Әйтерсең лә, ял паркына гына чыгып керәсе.

Дөресен әйтим, мин дустымның бу кыланышларын су чыкмаган җирдә кое казу дип кенә саный идем. Тузынып, тузынып да тынычланыр, дип уйлый идем. Ә ул тәки тәвәккәлләгән, башкисәр. Йә тәхет, йә бәхет дигәндер инде.

Бүрәнә ташучы машина платформасының төбенә ябышып зонаны чыккан, дип сөйләделәр соңыннан. Ярый, анысы шулай да булсын ди. Ә менә хатын-кызлар лагерына ничек үтеп керә алган ул? Кергән бит, кергән! Миннән дә сорау алып йөрделәр. Тикшерүче үзе дә аптыраушта иде. Аның үз-үзен тотышында, әйткән сүзләрендә хәтта Кивига карата ниндидер соклану хисе дә тоемлангандай була иде. Минем белән ачылып сөйләште.

...Ул көнне мин авырып, эшкә чыга алмаган идем. Лагерьда чират белән йөри торган ниндидер чир кузгалган иде ул вакытта. Кисәк кенә тән яна башлый, укшыта, хәл китә. Салкын тиюгә охшаган хаста. Югыйсә, җәй уртасы. Моны себерлеләр үзләре “килмешәк” чире дип йөртәләр. Ник дисәң, бу микробларның җирле халыкка тешләре үтми икән. Шуңа күрә читләргә, ягъни дә безнең ише “килмешәкләр”гә үчләнәләр ди.

Кече йомышын гына йомышларга дип киткән җиреннән Киви баткан тәки. Юк та юк икән. Кулдашы борчылып, бригадирга җиткергән. Тревога күтәрәләр. Тик ул вакытта Киви машина платформасына чытырдап ябышкан хәлдә юл сикәлтәләрен санаган инде.

Ир-атка сусаган хур кызлары—җинаятьче сөяркәләр—аны ач эт шикелле бөтереп кенә алалар. Киви кочактан кочакка гына йөри. Тик көч-гайрәт дигән нәрсәнең дә чиге бар икән шул. Ә назланырга теләүчеләр арта гына бара. Тау кәҗәсе хәленә төшә грузин Казановасы. Рольләр дә алышына. Кивины хатыннар үзләре көчләргә тотына. Арып алҗыгач, өстенә чиләк белән су коялар да, шөгыльләрен янә дәвам итәләр. Су процедурасының да файдасы тими башлагач, әгъзасына җептән балдак салалар...

Кивиның чүплектә аунап яткан гәүдәсен сакчылар өченче көнне генә күреп ала.

* * *

Гүзәлия хәзер эшкә автобус белән барып-кайтып йөри. Мәктәптә укулар башлангач, Кәбирнең вакыты бик санаулыга әверелде. Еш кына төштән соң да бушамый. Ә автобус дигәннәренә ышаныч аз. Шуңа күрә очраклы машина көтәргә туры килә. Гарьләнерсең, билләһи! Инде башына “Ока” автомобиле сатып алу уе керөп оялады. Әтисе дә булышырмын дип тора. Әлегә вакытлыча Актанышта фатир төшәргә карар итте. Ләкин бу ниятнең тормышка ашмавы да бик ихтимал. Кәбир һич тынгылык бирми. Өйдәгеләр дә колак итен ашый. “Тагын кем кирәк инде сиңа, туң йөрәк”,—дип, кыз әнинннән генә үзен-үзе дә шелтәли. Белеп-күреп тора ич, Кәбирне карату өчен башка кызлар ни генә эшләмиләр. Шулай булмыйча, үзе укымышлы, үзе акыллы, дәрәҗәсе дә бар. Иң мөһиме, ышанычлы. Хәзерге бозык заманда бу сыйфатлар алтын бәрабәре тора бит, җүләр.

...Ул төнне егетнең назларын бик теләп кабул итте Гүзәлия, карышмады. Аларның моңа кадәр болай ук якынлашканнары юк иде әле.

—Соңгы сүземне җомга көнне әйтермен,—дип ышандырды егетен кыз. Ә бүген—җомга. Ул исә бик мәшәкатьле булыр, ахры. Казаннан язучылар килгән, Мәдәният йортында очрашу буласы. Мөхәррир шушы уңай белән махсус сәхифә әзерләргә кушты.

—Камил Кәримовны иртәнге якта ук тотарга тырыш, бик шома егет,

соңыннан эләктерә алмассын,—дип кисәтеп тә куйды.

Гүзәлия бу язучының "Ком сәгате" романын яратып укыган иде. Ана кадәр ул аны ни өчендер шаян сүз остасы дип кенә кабул итә иде. Концертларында да булганы бар. Теле телгә йокмый, туп шикелле сәхнәне тутырып йөри.

Бу артист секунд та бер урында тыныч кына утырып тора алмыйдыр, дип нәтиҗә чыгарып куйганын да хәтерли әле. Баксаң, утырып романнар язардай түземлеге дә, таланты да бар икән ич. Өстәвенә, япь-яшь килеш бораулаучы булып эшләгән, бик күп актанышлыларны сулы иткән.

Камил аны күптәнге танышыдай көлеп-елмаеп каршы алды.

—Тавышың кыяфәтенә туры килә икән, сенелкәш, телефоннан сөйләшкәндә мин сине нәкъ шушылай күз алдына китергән идем. Тик Актаныш суы эчеп үсмәгәнсең, ахры, XVIII гасырдагы беренче дулкын керәшен туташларын хәтерләтәсең, дип бер минут эчендә үзенең тылсымлы сәләтен дә күрсәтергә өлгерде.

Гүзәлия телсез калды. Дөрестән дә, алар нәселләре белән аксыл чәчле, яшькелт күзле, озын буйлы. Барысы да чибәрләр. Гадәттә, аны Балтыйк буе кызларына охшаталар иде. Кәримов исә чын хаклыкны ярды да салды. Язучы үзенең акылы, күзаллавы, фантазиясе белән башка кешеләрдән күпкә өстен, дип әйтә иде университетта студентларның яраткан профессоры Хатыйп Миңнегулов.

Югыйсә, Гүзәлия үзе дә шигырьләр яза, нигә аның акылы да шулай катлы-катлы түгел икән?

Әңгәмә уен-көлке белән үрелеп барды. Фикерләр анык, җаваплар образлы, бизәкле иде. "Язучы үзенең җитлеккәнлеген кайчан һәм ничек тоя?" дигән сорауга Камил уйлап та тормыйча:

—Табында ит турый башлагач,—дип җавап бирде.

—Мин чынлап сорыйм...

—Мин дә чынлап җавап бирәм. Беләсеңме, Гүзәлия, татар егетенең иң зур теләге нинди булган?

—???

—Белмисең. Белә дә алмас идең. Син башка чор кешесе. Улы, буй җиткерә башлауга, әтисенең вафатын теләгән. Юк, юк, борыныңны җыерма. Хак. Чөнки шул көннән башлап табында ит турау хуҗа кеше буларак, аның вазифасына әверелгән. Табында ит турау үзе бер зур милли фәлсәфә ул. Хикмәт якын кешеңә үлем теләүдә түгел, хикмәт—җитлегүдә, буыннар алмашынуында.

Гүзәлия кулларын чәбәкләде, җавап искиткеч иде: нигезле, тапкыр. Аны әдәби әсәрләрдә сурәтләнгән геройларның прототибы да кызыксындыра иде. Шулай да ул аны язучыга астын өскә әйләндереп тәкъдим итте.

—Сез нинди дер могҗиза белән яшьлегегезгә кире әйләнеп кайтсагыз, Әлфинәне элеккечә ярата алыр идегезме?—дип сорады.

Камилнең түгәрәк шома йөзе җитди төскә керде. Аннан соң:

—Романда аның сөйгән егете Фазыл бит, мин түгел. Ул турылыклы калыр иде дип беләм,—диде.

—Ә сез? Үзегез?

—Минме?—Камил шук күзләрен елтыратып, кызга текәлеп карап алды.— Мин яшьлегемә сине җитәкләп алып китәр идем...

Әңгәмә шушы урында өзелде. Чөнки язучыны хакимияттә көтәләр икән, машина җибәргәннәр.

—Кич клубка киләсеңме соң?—дип белеште ул Гүзәлиядән.

—Киләм, әле сезнең фотосурәтегезне дә төшерәсе бар.

—Ярар, калганын шунда сөйләшеп бетерербез.

Гүзәлия ак болытлар шикелле иксез-чиксез күктә йөзә иде. Гүя канатлар үсеп чыкты. Менә нинди булырга кирәк икән тормышта. Кыю, тәвәккәл, тапкыр...

Ниндидер челтерәгән тавыш анның уйларын бүлде. Һич анышмый, нинди челтерәү соң бу? Әллә телефон инде. Алай дисәң, Актанышта кесә телефоны эшләми, антенна төзелеп бетмәгән, имеш. Ә ул Казандагы гадәт буенча телефонын һаман сумкасында йөртә иде.

Әлеге челтерәвек чыннан да мобильник булган икән ләбаса. Һич көтмәгәндә җан керде телефонга. Чөнки бүген иртән антеннаны эфирга тоташтырганнар иде. Гүзәлиянең болай да ашкынулы йөрәге дәртләнебрәк тибә башлады.

—Алло, тыңлыйм,—диде аһәңенә елмаю кунган йомшак тавышы белән.

—Гүзәлия, мәрхәбә, Гүзәлиям!..

—Илһан, синме бу?

—Әйе, мин, Гүзәлиям. Бик-бик сагындым, синсез тормыш юк миңа...

—Син кайдан сөйләшәсең, Илһан!

—Казан аэропортыннан. Очкычыбыз әле генә утырды. Төркиядән, әтиәниңдән бер йөк сәлам алып килдем.

—Башкаларга күз атмадыңмы? Белсәм, рәхим-шәфкать көтмә...

—Мин сине генә яратам, Гүзәлиям. Никахны Түбән Сөндә укытырбыз. Мулла алып килдем...

—Җүләрем, Төркиядән мулла ташымасаң соң?..

Алар шулай бер-берсен бүлә-бүлә бик озак сөйләштеләр. Үткән-сүткән кешеләр урам уртасында телефоннан сөйләшүче Гүзәлиягә сәерсенеп карап узалар.

Тыкрык башыннан Кәбирнең машинасы борын төртте. Тик ул Гүзәлиянең бәхетенә сыймый иде инде.

* * *

Көннәрдән бер көнне кызып-кызып урман аударган җирдән бер сәгать эчендә җыендырып, безне каядыр алып киттеләр.

—Кар-буранда килгән идек, чәчәкле-чуклы чиллә уртасында кайтарып та җибәрделәр,—дип шукланды кемдер.

Әйе, кышын китергәннәр иде, җәен янә кузгаттылар. Тик бу кыш белән җәй арасында дүрт ел вакыт ята шул.

Ике көн тәпиләгәннән соң, поездга төяделәр. Кая алып баралар, тагын нинди караңгы почмакка утыртмакчылар—анысын безгә әйтеп тормыйлар. Поезд, әнә, үз юлын бик яхшы белә, көнне дә белми, төнне дә белми, элдертә генә. Дүртенчеме, бишенчеме көнне, анык кына хәтердә калмаган, корыч бахбай, ниһаять, тәгәрмәчләренә тышау салды. Шәп-шәрә җир. Хәер, дөрес әйтмим, урманга күнеккәнгә генә шулай тоелды, ахры, диңгезне шәрә җир белән чагыштырып була мыни? Әйе, алдыбызда диңгез җәйрәп ята иде. Аптырашта калдык. Кайсы диңгез икән соң бу? Мөгаен, Ак диңгездер. Мәхбүс хыянәтчеләрне Кара диңгездә су коендырмаслар бит инде.

Йөк корабы да безне көтеп торган икән. Вакытлыча әштер-өштер генә әтмәләнгән басмадан трюмга да кертә башладылар.

Трюм эче мал вагонына караганда да тынчуырак иде. Сасы, әллә нинди исләр килә. Без кереп тулгач, кысанланып та калды. Вентиляция юньлебашлы эшләми. Тын кысыла. Бигрәк тә өлкәнрәк яшьтәгеләргә авыр. Кайбер көннәрне дулкын корабны йомычка урынына уйната, әле эчәкләр суырыла, әле йөрәк өзелеп төшәрдәй булып тартыла. Чыда гына. Тоткыннарның үлемкитеме башлыкларны борчымый икән, ваба, тиф шикелле йогышлы афәтләрдән генә куркалар ди. Шуңа күрә чисталыкны, санитария нормаларын мәҗбүри

рәвештә саклаталар. Әлеге нечкәлекләрдән хәбәрдарлыгымның сәбәбе бик гади, чөнки табибыбыз Василий Степанович Соляков мине үзенә ярдәмче итеп алды. Күрәсең, арада медицинага мөнәсәбәтле башка кеше булмагандыр.

—Син бит ветеринар, укол кадый беләсең, даруларны танысың. Температураны ничек үлчәргә дә өйрәтәсе юк. Иң мөһиме, син яшь кеше, көчле чагың, куәтле чагың. Безнең шартларда профессор табиб та әллә ни кыра алмас иде. Үземнең дә хәлләр шәптән түгел,—дип каршы килерлек итмәде табиб. Шулай итеп, "үз белгечлегем" буенча эшли башладым. Мина хәзер "доктор" дип мөрәҗәгать итәләр. Бөтен төр сырхауларны да диярлек кисәкле мал тозы белән дәвалыйбыз. Әле ярый аны бирәләр. Ни хикмәт, шул тоз температураны да төшерә, йөрәккә дә куәт бирә, тынычландыра да иде. Мин хәзер дә кесәмдә шакмаклы тоз йөртәм. Ышанасызмы-юкмы, берәр җирем борчый башлауга, шуны тел астына салам. Һәрвакыт файдасы тия. Безнең авылдагы Маһи карчык кебек инде. Ул да эче авыртып, хастаханәгә барган, имеш. Моны рентген нуры ярдәмендә тикшергәннәр. "Рәхмәт, улым, юып төшергәннәрдәй булды, терелттегез",—дип, догаларын укый-укый кайтып киткән ди. Психология, үзенне-үзең ышандыру бик зур көч ул. Практик медицина беренче чиратта шуларга нигезләнергә тиеш дип саныйм мин үзем.

Кай тарафларга йөзә корабыбыз, күпме юл үттек, тагын күпме барасы—инде кызыксынмыйбыз да. Без хәтта көнне дә сакчылар алышынуга карап кына чамалыйбыз. Авырулар гына артканнан-арта бара. Урыннарыннан тора алмаганнары да бар. Әнә, Мирзаян абый бик бетереште. Тын алуы авыр, йөрәк кыса, дип зарлана.

Мин аның янында ешрак булырга тырышам. Берсендә ниндидер көй көйләгән вакытына туры килдем. Бер ноктага текәлгән дә күнелен бушата. Ә үзенең тавышы чыкмый, иреннәре генә селкенә:

Идел бит ул тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул...

Мин үзем дә яратам бу җырны.

—Бик моңлы җыр,—дидем аны хуплагандай.

Мирзаян абый мина күтәрелеп карады. Аның күзләрендә яшь элпәсе иде.

—Шулкадәр сагындым, энем, Идел буйларын, көн дә төшләремә керә. Кайтып күрүләр насыйп түгелдер инде, болай ук сагышланмас идем,—диде хәлсез тавышы белән.

—Юкны сөйләмә Мирзаян абый, Аллаһы боерса, кайткач кунакларга йөрешербез әле. Сездә—Идел, бездә—Агыйдел...

—Авызыңа бал да май, энем,—диде ул яшь баладай куанып,—мин сине Маркиз утравына алып барырмын. Яшьрәк чакта анда йөзеп кенә чыга идем. Ышанмыйсыңмы? Валлаһи! Ипи тотып ант итә алам...

—Ышанам, Мирзаян абый, ник ышанмаска, тик кайда соң ул Маркиз утравы?

Мирзаян абый мине бүлеп: "Синең Казанда булганың юкмы әллә?"—дип сорады. "Юк" дигән җавабымны ишеткәч, шаккатты. Торып ук утырды.

—И энем, Казанда әле Швейцария дә бар. Маркиз дигәне Идел эчендәге утрау ул. Ял көнне җәен шәһәр халкы шунда агыла. Искиткеч матур урын. Без бит Бишбалтада торабыз. Пристань янында гына. Кунакка килгәч, бөтен Казанны йөреп чыгарбыз. Аның Кремле генә ни тора? О-о, Казанмы, Казан ул... Тукаебызның шигъри юлларын гына хәтеренә төшер: "И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Артык дулкынлануданмы, Мирзаян абыйның хәле китте. Мин аны иплән кенә урынына яткырдым, күз карасыдай саклап тоткан валидолымны авызына каптырдым.

Туган шәһәрен дә, эшләгән заводын да бик ярата иде инженер Мирзаян Гатауллович. Аны корткычлык өчен утыртканнар. Янәсе, аңлы рәвештә станокларны сафтан чыгарган. Югыйсә, мәчене дә рәнҗетә торган кеше түгел. Гөнаһ шомлыгына, авария нәкъ ул эшләгән сменага туры килгән. Бөтен гаепне ана аударганнар.

Янадан урап килгәндә тынычланган кебек күренсә дә, йөзе әле һаман кәгазь шикелле ап-ак иде. Мирзаян абыйның Казанын, цех башлыгы сыйфатында эшләгән "Урак һәм чүкеч" заводын, Иделне, Маркиз утравын кайтып күрә алуы, ай-һай, бик икеле иде. Үз хәлен үзе дә белә иде, әлбәттә.

—Энем, Хисаметдин, син авылда әби-бабай белән яшәгән кеше, алар сиңа дога өйрәтми калмагандыр. Берәрсен укы әле, иман инсен,—дип үтенде.

Мин ялындырып тормадым, колагына догамны пышылдадым.

—Әллааһү ләәәә иләәһә илләә һүү...

Мирзаян абый иртәнгә җан тәслим кылган иде инде. Башкаларныкы сыман аның мәетен дә котырынган диңгез йотты.

Соляков сүзләре хак булса, безне Татар бугазындагы Ванино дигән порттан ерак түгел бер җирдән төяп алып киткәннәр икән. Мин моны бүген иртән генә белдем, диде. Кайсы утрауда түгәрләр—бу серне аңа да әйтмәгәннәр.

—Мин Камчатка яки Чукот ярымутрауларының берсендәге лагерьда калдырырлар дип уйлаган идем,—диде,—юк, калдырмадылар. Төньяк боз океанына алып чыгачаклар, күрәсең. Кыскасы, бара-бара күзләр күгәрер әле.

Шушы әңгәмәбездән күп тә үтмәде, мәхбүсләр табибы Соляков үзе дә дөнья белән мәңгелеккә хушлашты. Иң кирәк чакта. Үлем сайланып тормый шул ул, бәхәсләшә дә алмыйсың, барыбер үзенекен итә. Хәзер дилбегәне үз кулына алырдай кеше кирәк. Мин мал фельдшеры гына, андый җаваплылыкны үз өстемә ала алмыйм. Алырга да теләмим.

—Соляковның кәгазьләрен, сумкасын кемгә тапшырырга икән, казна әйберләре бит,—дип өлкән сакчыга мөрәҗәгать иттем. Ул мине икенче бер сакчыга ияртеп, палубага менгереп җибәрде.

Палубада үземне терелеп кабердән чыккан кеше сыман хис иттем. Тынчу, сасы мөхиткә күнеккән үпкә саф һавадан тончыгып калды: башым әйләнеп китте, чак кына аңымны җуймадым. Шулай да күнелне иң җилкендергәне, кинлек иде. Башта куркып калдым. Өермә кубар да, очыртып алып китәр кебек. Ә көн дымык, күктә бер болыт әсәре дә күренми. Шуңа күрә, ахры, ул очсыз-кырыйсыз сыман тоела. Очсыз-кырыйсыз күк белән очсыз-кырыйсыз диңгез бербөтен куркыныч манзарага әверелгән.

Бу халәтне күп тә үтми хозурлык алыштырды. Нинди иркен икән дөнья! Нинди киң икән ул! Американың мәшһүр җырчысы Поль Робсон тавышлары ишетелеп киткәндәй булды.

Широка страна моя родная...

—Нәрсә катып калдың, базар ишәге түгелсең бит,—дип сакчы артыма төрткәч кенә киң дөньяның пыялалары кырылып төште. Иркен дөнья минем өчен түгел икән. Мин—тоткын. Урыным тимер рәшәткә артында.

Корабль табибы сумканы да, документларны да кабул итеп алмады.

—Эшеңне дәвам ит, авыруларга булыш,—дип, мина рәсми рәвештә әлеге вазифаны такты. Карышуның файдасы юк. Бу минем язмышым иде, күрәсең. Алдагы тормышым да шушы очраклы юнәлештән тәгәрәде.

Төньяк боз океанын инләп, ниһаять, Яна дигән елга тамагына килеп җиттек. Шушында безне корабтан төшереп, елга пароходына төяделәр. Шул кадәр кысан, борылырга да урын юк. Корабыбыз курорт булган икән. Берәр йогышлы авыру баш калкытса, сәгате-минутында таралачак. Бу хакта өлкән сакчыга әйттем. Ул кулын гына селтәде.

—Кырылмагайлары, урыннары буш тормас, артыбыздан тагын ике кораб тулы хыянәтче килә,—дип тешләрен ыржайтты.

Бәхетебезгә, барасы жиребез өч-дүрт тәүлеклек кенә юл булган икән. Бу тайга түгел иде инде. Агачлары сирәк, үзләре кәрлә. Тик шунысы хак, безне бу жәһәннәм артына озын юллар үтә-үтә тоткынлык шартларын үзгәртү өчен генә алып килмәделәр, билгеле. Монда ниндидер рудник булачак. Котып файдалы казылмаларга бай бит ул. Тоткыннарга кайчан да булса һәйкәл куярлар әле. Сүз хезмәт батыры дигән һәйкәл турында бара. СССРда атом, водород бомбалары эшләү буенча сәнәгать корылмаларын нәкъ менә мәхбүсләр төзеде ләбаса. Гомумән, Себер һәм Ерак Көнчыгышка цивилизацияне тоткыннар алып килде. Мона гажәпләнергә дә туры килми, чөнки эчке эшләр министры маршал Берия кулында Советлар Союзынын ин күп санлы, иң булдыклы, ин белемле хезмәт армиясе тупланган иде. Анын ташчылары, балта осталары да югары квалификацияле инженерлар, табиблар, язучылар, политологлар, артистлар, генераллар ич.

Лагерь корылачак урында күтәрелгән тәүге объект мүк жиләге шикелле кып-кызыл төскә буялган агитплакат иде. Анда зур хәрефләр белән Сталиннын 1930 елда партиянен XVI съездында әйткән канатлы сүзләре язылган: "Труд—дело чести, дело славы, дело доблести и геройства". ГУЛАГның асылын ярган да салган юлбашчы.

Иосиф Виссарионовичнын карикатуралары да мәгълүм иде тоткыннарга. Политбюро утырышларында ул аерым дәфтәргә карикатуралар ясый торган булган. Әлеге карикатуралар башкаларны агрессив асылы белән шурләткән. Ник дисән, генераллисимус тиздән кулга алыначак таныш-белешләренен сурәтен образ итеп файдалана икән.

Эшкә тотыныр алдыннан лагерь башлыгы Мехас Бондарчук иренмичә, иркенләп кешеләрнен һөнәрен ачыклады.

—Балта осталары, бер адым алга! Ташчылар, ике адым алга!..

Сүз, билгеле, мәхбүсләрнен тоткынлыктагы хезмәт күнекмәләре турында иде.

Иң ахырдан чират медицина хезмәткәрләренә житте. Башлык соравын берничә мәртәбә кабатлады, ә саф алдына чыгучы юк. Мине күршеләрем төрткәләпме-төрткәли, чык та чык, дип пышылдыйлар. Моны Бондарчук та күреп алды, жәт-жәт атлап каршыма килеп басты. Берара чабатадай калын кашлары астыннан күзләрен тондырып карап торды да:

—Карцерга эләгәсең киләмени, ник һөнәренне яшерәсен?—диде. Кыскача гына хәлне анлатып бирдем.

—Яка разница, зараз человечьим хвершалом будэшь, ха-ха-ха...

Сонгы пароход белән чын табиб та килеп төште. Йомрырак гәүдәле, жинел сөякле, бөдрә чәчле яшь ханым иде ул. Бик аралашучан. Мина үзенен Башкортстанда туып-үсүе, Уфада институт бетерүе, быел гына кияүгә чыгуы, монда ире белән акча эшләү ниятеннән килүләре турында түкми-чәчми сөйләп бирде. Ире Григорий исемле икән. Инженер, ди. Рудникта эшләячәк.

—Мин Вера Павловна булам,—дип, курчакныкы чаклы гына кечкенә кулын сузды. Әйтерсен лә, без тин кешеләр. Югыйсә, тоткын белән иреклe эш башкаручы затларның үзара мөнәсәбәте каттый кагыйдәләргә нигезләнә, әшнәлекне кабул итми. Аптырабрак калдым. Ә анын исе дә китми, һаман үзенекен тукый.

—Берүк мине Чернышевскийнын "Нәрсә эшләргә" дигән әсәрендәге Вера Павловна белән буташтыра күрмәгез. Мин ана тамчы да охшамаган...

Техникумда укыганда рус әдәбияты укытучысынын әлеге Вера Павловна дигән революционерга кергән төш буенча инша яздырганы исемә төште. Ә ана төшләр күп кергән. Шуларнын дүртенчесе белән жәфалыйлар иде безне.

Искиткеч бәйләнчек апа иде мөгаллимәбез. Начар билгесе алдынмы, шуны төзәттермичә тынычланмый иде. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, минем иншага укытучыбыз начар билгесе куйган булып чыкты. Шуннан башланды инде низаглар. Үзем дә киреләнеп маташам ич әле. Әйтерсең лә, чебен дулап тәрәзәне вата. Тагын ике кат яздырды. Ул укытучыны күрәлмас дәрәҗәгә җиттем. Шуңа күрә табиб Вера Павловнаның Чернышевский сурәтләгән Вера Павловнага охшамавына сөендем генә.

Без аңлашып эшләдек. Дөрес, ул зонага кермәде, анда мин җаваплы идем. Шулай да ныклап чирләп киткән авыруларны карау аның өстендә иде. Андыйлар өчен махсус изолятор бар. Тик лагерь башлыкларына авыру мәхбүскә караганда үлгән мәхбүс яхшырак. Кешесе юк икән, мәшәкате дә юк. Ә мин үзем тоткын—булдыра алганча, бәхетсезлеккә тарган иптәшләремә ярдәм итәргә тырышам.

Бер вакыйга Вера Павловна алдында минем абруемны тагын да күтәребрәк җибәрде. Шуннан соң ул күп кенә мәсьәләләрне хәл итүне бөтенләй үз иркемә куйды. Дөрес, алар дәвалау сферасыннан битәр санитария-гигиена, оештыру өлкәләренә карый. Барыбер шуңа күңел кинәнеп тора. Кешенең, бигрәк тә үзеннән югары профессионал-белгечнең игътибарын, ышанычын тою рәхәт ич инде ул.

– Харитон, дезинфекцияне син үзең генә үткәр, бер дә баракларга кереп йөрисем килми; Харитон, изолятордагыларның температурасын үлчәгәч, журналга төшерергә онытма... Харитон, Харитон...

Әйе, мин Харитон булып киттем бит әле. Алман төрмәсендә дә исемемне боздырмаган идем. Смирнов булып Смирнов та вата-җимерә үз исемем белән дәшә иде. Колониядә дә Хисам дип йөрттеләр. Шушы бөтерчек кебек кенә хатын бар нәрсәнең астын өскә әйләндерде дә куйды. Әйтүнең, каршы килүнең дә файдасы юк, четер-четер көлә генә. Миңа шулай ошый, ди, тыңларга да теләми.

Ә Ходай, бер дә каударланма, Хисаметдин бәндәм, алда аның үзен дә шундый ук гамәл көтеп тора, дип күңелемә тынычлык орлыгы салып куйган иде, күрәсең. Шуңа күрә, ахры, артык борчылмадым.

Хәер, мин абруемны үстереп җибәргән вакыйга хакында сөйләмәкче идем ич. Әйдә, әүвәл шуны хәтердә яңартып алыйк, монысын ахырданрак тәфсилләрбез.

Хәл болай булды. Тарасенко атлы бер белорусның рудникта ничектер кулы җәрәхәтләнгән. Егылдым, диде. Белгәнрәкләр, үчлек, диделәр. Анысы да булып кына тора монда. Чокындың ни, чокынмадың ни—барыбер очына чыга алмыйсың. Тоткынлыкта кеше мәкергә, астыртынлыкка өйрәнә икән. Кыскасы, Тарасенконы медпунктка алып килделәр.

—До свадьбы заживает,—дип, Вера Павловна тегенең ярасын юып-чистартып, әйбәтләп бәйләп кенә куйды, хәтта эштән дә азат итмәде. Тарасенко шуңа өмет иткән иде булса кирәк, ишек катында таптанып тора бу.

—Юкка боргаланасың, җитен чәч, барыбер бюллетень бирмим, бар, юлыңда бул, чебен тимәс чер итмәгез инде, валлаһи, дип табиб аны куып җибәргәндәй җибәрде.

Икенче көнне Тарасенко тагын күренергә килде. Ул инде хәзер минем пациент. Беренче тапкырында гына авыруларны доктор кабул итә, аннан соң алар үзләреннән-үзләре фельдшерга күчәләр.

—Кулым төне буе сызлады,—дип зарланды Тарасенко. Чыннан да ярасы шешкән иде, сәер рәвештә кызарып тора. Мин моны Вера Павловнага җиткердем. Ул кулын гына селтәде. Имеш, җәрәхәтнең төн эчендә төзәлүен кайчан күргәнең бар, түзәргә кирәк.

Иртәнгә Тарасенконың шешә гөбе кебек булып кабарган иде. Хәтта

надзиратель булып надзиратель дә докторга язу юллаган, эшкә яраксыз, бераз ял бирегез, дигән. Башта авыруны үзем карадым. Шеш тирәли җәелгән кызыллык инде чит-читләрендә зәңгәрсу төс алып бара. Бу һич тә галәти күренеш түгел, алай гынамы, куркыныч күренеш. Ветеринар акылым белән дә мин моның гангрена билгесе икәнен төшенеп алдым.

—Шешне ярып чистартырга кирәк,—дидем Вера Павловнага. Бу сүзләрне ишетүгә, ханымның кабарынкы матур иреннәре калтыранып китте.

—Харитон, бәлкем, мазь белән дә кайтарып булыр?—дип миңа карады.

—Гади шеш кенә түгел бу, Вера Павловна, яра эченә инфекция кергән. Моның нәрсәгә китерәсен аңлатып торуның хаҗәте юктыр дип беләм.

—Бәлки үзең генә башкарып чыгарсың, Харитон, ә? Оят булса да әйтергә туры килә, мин... мин... пычактан, каннан куркам, шуңа хирург һөнәрен сайламадым.

Ә-ә, менә нәрсәдә икән хикмәт, менә ни өчен калтырана икән чибәркәйнең матур иреннәре. Ләкин куралэтә Тарасенконы да Әҗәл бабай кулына бирмәскә иде бит. Лагерь хәзер карантиндагы авылны хәтерләтә. Килүче дә, китүче дә юк. Монда азык-төлекне, кирәк-ярак, рудник җиһазларын җәйнең бер вакытында, Котып дингезенең бозлардан арчылган вакытында гына туплап куялар. Әле кышның башы гына. Шуңа күрә кайдандыр ярдәм килер дип өметләнәсе юк.

—Ярар соң, тырышып карармын,—дидем,—әгәр инде эш узмаган булса...

Тарасенконың бәхетенә, инфекция таралып өлгермәгән иде. Шешне ярып бик җентекләп чистарттым. Бу алай катлаулы гамәлләр рәтенә керми, мал белән эш иткәндә дә шешләр ярырга туры килгәләде. Шулай да хәтсездән инде кулга операция пычагы тоткан юк, куллар калтыранып-калтыранып китә, моны Тарасенкога сиздермәскә тырышам. Шаярткан булам, сөйләнәм, сөйләндерәм. Авырта инде, әлбәттә, юньле дарулары булса иде.

Түзде егет. Ахырдан спирт белән сыйладым үзен, бераз тынычланып китсен, дидем.

Бервакыт карыйм, Вера Павловна ничектер шомарыбрак, түгәрәкләнебрәк киткәндәй күренә башлады. Эчемнән генә, бәрәч, түтәебезнең көмәненә кадәм төшкән ләбаса, дип уйлап куйдым. Әмма күрмәмешкә, белмәмешкә салындым. Кирәк тапса, үзе әйтер әле. Әйтмәсә дә, кешедән яшерә торган гаеп хәл түгел. Аның урынына кем килер—миңа шунысы мөһимрәк. Пошаманга төштем. Вера Павловна белән без уртак тел тапкан идек. Ул мине кыерсытмады, кимсетмәде, үзенә тиң күрде.

Вераның үз-үзен тотышы тамчы да үзгәрмәде. Элеккечә үк чикерткә урынына сикерә, шаяра, көлә. Мәзәкләрне дә сиптерә генә. Алар минем башымда тормый, бер колагымнан керә, икенчесеннән чыгып китә.

Мин Верага еш кына: “Вы умная женщина”,—дип комплимент әйтәм. Ә ул башын артка чөеп көлә генә.

Вакыт үтә торды, вакыт үткән саен, Вера Павловнаның рәвеше үзгәрә барды. Ул хәзер тавык йомыркасына охшап калды. Ләкин йөзе ямьсезләнмәде, сөйкемле сөяге һаман үзенә тартып тора.

Көннәрдән бер көнне бүлмәсенә чакырып алды бу. Үзенә хас булмаганча, җитди, күзләре уйчан.

—Вера Павловна, берәр хәл юктыр бит?—дип сорамыйча булдыра алмадым.

Ул күтәрелеп миңа карап куйды да:

—Шул хакта сөйләшергә чакырдым сине, Харитон,—диде.

Бүлмә тын калды. Вера үкчәләре белән идән тактасына орынып-орынып ала. Дулкынлана, сәбәбе җитдидер, мөгаен.

—Әле моны Гриша да белми,—дип өзелгән сүзен ялгап китте ул бераздан. Ләкин шунда ук тотлыгып калды. Бит алмаларын чылатып, яшь бөртекләре

тәгәрәде. Сүз кушарга кыймыйм, тынычлануын көтәм.

Вера, чыннан да, кулъяулыгы белән күзләрен корытты да, елмайгандай итте.

—Гафу ит, Харитон, хатын-кызның күз суы шулай бик якында инде аның,—диде.

—Зыян юк, Вера Павловна, ир-атлардан да ерак йөрми ул.

—Хәлләрем шәптән түгел минем, Харитон,—диде Вера, калтыраулы тавыш белән. Бу юлы яшен тыйды, чыгармады.—Бәбием аркылы яткан бит минем, Харитон. Аны ярып кына алырга мөмкин. Ә монда, үзең беләсең, бала табу йорты, гинеколог кына түгел, гап-гади акушер да юк. Юл ачылырга исә ярты ел вакыт бар әле...

—Бәлки...

—Юк, Харитон, бернинди бәлки дә була алмый, төп-төгәл билгеле. Минем үземнең дә, бәбинең дә тормышы синең кулда...

Бу сүзләрне ишеткәч, ике такта арасында калгандай булдым. Мизгел эчендә чәч төпләренә дым бәреп чыкты. Бу соң... бу... чәч үрә торырдай хәбәр ләбаса!

—Эчендә нинди уйлар кайнаганын бик яхшы беләм, Харитон,—диде Вера,—шулай да, батмас борын күбеккә тотынмыйк әле. Ятып калганчы атып калырга кирәк. Синең кулың килешеп тора. Тарасенконы, әнә, гангренадан арындырдың. Иң мөһиме, мин сиңа ышанам, Харитон!

—Вера Павловна, мин бит...

—Беләм. Атна тирәсе вакыт бар әле. Бергәләп күнекмәләр ясарбыз. Кайдан ярырга, баланы ничек алырга икәнен үзем өйрәтеп торырмын. Операцияне наркоз белән ясарсың. Кирәк-яракларны хәзерләп куйдым инде.

—Соң...

—Борчылма, анысын да беләм, Харитон. Юридик якларын үзем көйләрмен. Барлык язу-сызулар да тәртиптә булыр. Син—токкын. Мин—хуҗаң. Ул-бу була калса, мәҗбүр иттем дигән белешмәм инде язылган.

Вера Павловнага каршы килә ала идемме соң? Атым юк урамда, кайгым юк буранда дигәндәй, үземә буласы булган, бәлкем, бу ике затның җанын саклап кала алырмын, дип тәвәккәлләргә ниятләдем.

—Минем бер теләгем бар, Вера...

Ә бу теләгемне фәрештәләр пышылдады, ахры. Чөнки ул уема капылт кына, искәрмәстән генә керде. Кабул итәрме-юкмы, анысы инде башка мәсьәлә.

—Тынлыйм, Харитон,

—Операция алдыннан әйтермен, яме?

—Килештек.

Эштән соң ишекне бикләп, төннәр буена Вера Павловна тән төзелеше, кесарево сечение схемасы, аналык яткылыгының үзенчәлекләре турында дәрес бирде. Ул үзе мөгаллимә дә, күргәзмә әсбап та иде.

Вераның тулгагы таң алдыннан башланган. Мине ире Григорий килеп алды. Бу мәсьәләне алар лагерь җитәкчелеге белән (операция хакында ләм-мим әйтмичә), әлбәттә, алдан ук хәл итеп куйганнар иде. Минем кендек әбисе (бәлкем, бабасыдыр?) булуыма шуңа күрә каршылык күрсәтмәделәр.

—Тәвәккәллик, Харитон,—диде хатын. Иреннәре күмкүк иде. Төн чыкканчы йөзе суырылып, күзләре генә утырып калган. Үзе сер бирмәскә тырыша, хәтта елмайган да була. Тик бу елмаюның күләгәсе генә иде.

—Вера Павловна, бүлдермичә генә минем сүземне тыңлагыз әле,—дидем тулгагы җибәреп торган бер арада.—Алдан кисәтеп куям: бу фәкать тәкъдим генә, сез аннан икеләнмичә дә баш тарта аласыз. Һәм аңа карап минем сезгә булган ихтирамым бөртек тә кимемәячәк.

—Сузма, Харитон, мин барысын да дөрес аңларга тырышырмын, ә гамәлен йөрәгем кушканча эшләрмен,—дип Вера кулларыма кагылып алды. Сиздем, күзәнәкләренә кадәр борчу белән тулы иде табибәнен.

—Мин сезне бик якын күрәм, шуна күрә үпкәләмәссез дип уйлыйм,—дип башладым сүземне.—Дөресен әйткәндә, операциягә җөрьәт итүемнен сәбәбе дә...

—Харитон, интектермә мине!

—Гафу, Вера Павловна. Менә бу бөти-догалыкка күз төшерегез әле,—дидем батыраеп, ниһаять, үгезне мөгезеннән алдым.—Сез мөселманнар каласында, Уфада яшәгән кеше, ислам дине кануннары хакында ипилектозлык кына мәгълүматыгыз бардыр, мөгаен. Әлеге бөтине сугышка киткәндә әнкәем язып биргән иде. Мине берничә үлемнән, күп бәлаләрдән коткарып калды ул. Әлегәчә яшәвем белән шушы догалыкка бурычлымын. Нигәдер догам сезнен үзегезнен дә, бәбиегезнен дә гомерен саклар иде дигән тирән ышанычым бар...

Анлыйсызмы, дигәндәй, каш астыннан гына хатынга күз төшердем. Ә анын янә тулгагы килергә чамалый иде, ахры. Кисәк кенә авызы чалшаеп китте, йөзенә эреле-ваклы тимгелләр бәреп чыкты. Сүземне түгәрәкләргә ашыктым.

—Кыскасы, Вера Павловна, операцияне мөселманча дога белән үткәрүгә сез ничек карыйсыз?

—Ри-и-за-а...

Веранын шулай бик тиз ризалашуы көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты, аптырабрак калдым димме. Ләкин бу хакта баш вата торган чакмы сон?

—Алайса минем арттан кабатлагыз,—дидем әмер биргәндәй.—Лә иләһә илләл-лаh Мөхәммәдүр-расүлүллаh...

Вера булдыра алганча, башкарып чыкты.

—Туганым, исемен хәзер Варисә булыр,—дип, ханымнын колагына өрдем дә, учына, бисмилла әйтеп, догамны салдым....

Фәрештәләр канатларын җилпи-җилпи, эше унса иде бу бәндәбезнен дип, теләктә тордылар, күрәсен, Варисә өйрәткәннәрне төп-төгәл үтәп чыктым бит, кулларым да ятышып кына торды.

Бала мен дә тугыз йөз дә илле өченче елнын бишенче мартында иртә белән, җәллад Сталин вафаты көнне җиһанга аваз салды. Без ана пәйгамбәребез Гайсә галәйhиссәлам исемен сайладык.

Операция минем бөтен өнемне алды, бер айга якын игә килә алмыйча йөрдем. Шул ике сәгатьтә организм бар маясын сарыф итеп бетергән булган, ахры. Йокы да алмый, тамактан да үтми. Кибәргә элгән балык кебек үтә күренмәлегә әйләндем. Хәзер әлеге халәтне стресс дип атыйлар. Шулай булмыйча сон? Үземә төшкән бу авыр вазифанын нәтиҗәләре турында әле дә бик еш уйланам. Әйтик, дөньядагы кешеләрнен тамыры уртак ич. Кара тәнлеме ул, ак тәнлеме? Татарча сөйләшәме, русча яки японча мы? Монысы мөһим түгел. Ин мөһиме, без барыбыз да бер ата, бер ана балалары: атабыз Адәм, анабыз Хәүва. Диннәргә авышу, бүгәләнү сонуннан килә. Димәк, бу Тәнрегә шулай кирәк булган. Әлеге фәлсәфәдән чыгып караганда, Вераны авыр чагында динен үзгәртергә мәҗбүр итеп, бәлки, үзем зур гонаh кылганмындыр? Уйланам-уйланам да, кеше шулай җинел генә үз асылын үзгәртергә тиеш түгелдер дим. Мисал өчен, үзем ислам диненә хыянәт итә алыр идемме икән? Аннан китереп, минем, гади бер ветеринарнын андый хокукы бар идеме сон? Бу хакта уйлыйсы да килми хәтта. Ихтимал, фәрештәләр Веранын да колагына изге сүз пышылдаганнардыр, анын дин үзгәртүендә минем бернинди катнашым да юктыр? Һәммә гамәл дә Ходай кушуы буенча эшләнә ич!

Башым тубал була. Тик Варисә дә, Гайсә дә үзләрен бәхетле хис итәләр.

Аларны күргәч кенә тынычланып китәм. Шөкер, аралашып, килешеп-китешеп яшибез. Григорий, әнә, улының мөселман булып тууын, хатынының ислам диненә күчүен күтәрә алмады, араны өзде, үз диненә турылыклы калды.

Тормышымның афәтле сугыш чоры, рәхимсез мәхбүслек еллары менә шулай көтелмәгән вакыйга белән тәмамланды.

Ходайның рәхмәте, шушы соңгы җөмләне теркисе көнне торыр алдыннан гына бер хикмәтле төш күрдем. Котыптагы лагерь, имеш. Кулымда азат ителүем турында рәсми белешмә. Шатланырга гына югыйсә. Шатлана алмыйм, нигәдер моңсулык баскан. Дистә елга якын көтеп алган куанычны утраклашырга Варисә дә юк ичмаса, дим. Алар беренче пароходка утырып Уфага кайтып киттеләр шул.

—И, Хисаметдин бәндә, тәкъдиреңә язылган сынаулар өчен Тәңреңә үпкә тотмыйсыңдыр бит?

Әллә нишләп киттем, бизгәк тоткандай бермәл бөтен тәнем калтыранып торды. Кем бу кырыс вә таләпчән тавыш иясе, нигә бик коры кылана? Карыйм, янымда беркем күренми. Тавышы бар, үзе юк.

—Син кичергән авырлыклар, бәндә, доганың могҗизалы көчен дәлилләү өчен зарур иде.

Ничектер үзем дә батыраеп киттем, телем ачылды.

—Болар миңа мәгълүм,—дидем,—күктән иңгән һәр сүзнең асылында кодрәтле тылсым ята. Ул һәр барчабызның да күңел тәрәзәсен шакырга әзер. Кальбеңне генә керләмә, монафыйк булма. Шуңа күрә әнкәемнең догасы да нәсел-нәсәбебезнең иң мөкатдәс рухи мирасы сыйфатында буыннан-буынга тапшырылыр. Бу минем васыятем.

—Хак сөйлисең, бәндә. Ләкин җирдәгеләргә шуны җиткер, әгәр син әйткән тылсым кемнеңдер күңел тәрәзәсен читләтеп уза икән, моңа фәкать үзе генә гаепле.

Тавыш тынды. Ә минем авызымда дога иде:

—Әллааһү ләәәә иләәһә илләә һүү. Әлхәййүль каййүүм...

*2004 ел.*



## Әхсән Баян

# ҖЫРЛЫ, ТУКАЙЛЫ ХАЛЫК БЕЗ...

### Каек

**Айкала су, чайкала**
**Без йөзеп барган каек.**
**Гасырлар кичкән монда**
**Көй сузып, җырлы халык.**

**Кушылган җырга Тукай,**
**Узган үз юлын җырлап.**
**Җырлары еллар буйлап**
**Бара яңгырап ерак,**

**Ул үзе—халык җыры,**
**Без—дәвам, юк ахыры...**

**Уйласаң исләр китә**
**Дәрьяның агышына.**
**Тау елгасы түгел ул,**
**Тик аннан калышмый да.**
**Бусагалар—таш, кыя,**
**Бәрелеп оча кебек.**

**Узабыз исән калып,**
**Ми селкенми, баш аек:**

**Беләбез шуны күптән,**
**Фатиха безгә—күктән.**

**Батсак чыгабыз калкып,**
**Чорлар шаһит булсыннар.**
**Без утырган каекны**
**Йоталмады упкыннар.**
**Китәбез йөзеп ары,**
**Өр-яңа төсле каек.**
**Җырлы, Тукайлы халык**
**Үлемсезлеккә лаек.**

**Шулай диеп җырлыйбыз,**
**Хаклыбыз дип уйлыйбыз.**
**...Дәвам итә юлыбыз.**

* * *

**"Без китәбез инде, сез каласыз!"—**
**Диеп җырлау кергән йолага.**
**Елауларны тыяр өчен җырлап,**
**Күпләр чыккан ерак юлларга.**

**Киткән идем күптән, җырлап шулай,**
**Аерылып туган җирләрдән.**

**Хәзер сизәм: дөнья белән бергә**
**Әкерен-әкерен мин дә үзгәрәм.**

**Офыкларга таба атлый торгач,**
**Чират җитә бүтән җырларга:**
**"Без калабыз инде, сез китәсез,**
**Сез китәсез аргы елларга".**

Әхсән БАЯН (1927) — *Татарстанның халык шагыйре, прозаик, драматург; күпсанлы китаплар, шул исәптән биш томлык "Сайланма әсәрләр" (2004) авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

* * *

Әле кайчан гына ак болытлар
Җиргә шатлык сибә иделәр.
Кайларгадыр инде ашыгалар,
Ярсыналар, тыныч түгелләр.

Чабышалар берсен-берсе узып,
Көтү-көтү атлар диярсең.
Әллә җилләр, әллә җеннәр куа,
Тотып калыр өчен бирәрсең.

Ярсый-ярсый аргач, аргамаклар
Тынып кала, бергә җыелып.
Томалый да шулай күкне, болыт
Сибелә җиргә яшьле моң булып.

Болытларны, безне ашыктырган
Көчләр, гүя, офык артында...
Офыклардан салкын хәбәр килә
Вакыт хаксызлыгы хакында.

## Яшьлек акылы

Гомерләрнең аргы ярларында
Ниләр көтә безне, кем белә...
Бала акылы кирә дигән чакта,
Бөтен-бөтен җуләрлеген саклап,
Яшьлек акылы кирде күңелгә.

Ул мәхәббәт төсле кала һаман
Уйларымда, җырым, көемдә.

Ак атларда ал таңнарга чабам,
Яшь чибәргә чәчәк илтә барам
Әле төштә, әле өнемдә.

Чибәр кача уйнап, әллә чынлап...
Күзләренә аның карасам,
Мин күрмим дә барны, күрәм юкны:
Әллә карлы, әллә ак шомыртлы
Яшь язларга китеп адашам.

* * *

Юлларымның азагына барып
Җиталмадым—ашыгып, соңлап та.
Уйларымның очына чыгалмадым,
Гомер буе эзләп, уйлап та.

Сорауларның Ходай гына белгән
Җаваплары, беләм, табылмас.
Башларында уе булган кеше
Сырхау булмаса да сау булмас...

Эзләмикме әллә, уйланмыйкмы?
Мөмкин. Әмма яшәү ул чакта
Әйләнәчәк утсыз учакка.

## Уел

Бала чакта ишетелгән "Уел"
Яңгырады гомер буена,
Казакъ ягындагы елга ничек
Кучте икән татар моңына?!

Язмыш йөрми агач башларыннан,
Адәм башларыннан йөри бит.
Илдән китеп, ерак дәрьяларга
Башлар куйган күпме ир-егет!

Җирсәүләрдән туган хисләр, уйлар
Илгә кайткан моңлы җыр булып.
Йөрәклардән чыккач "Уел" булып,
Күңелләрдә калган уелып.

Еллар түгел, гасырлардан соң да
Киткән җаннар йөри Җир иңләп.
Күптән тамган кан-яшьләрне җәлләп,
Ник җилкенә икән бу йөрәк?

Җырлаганда эткәм "Уел"ларны,
Моңайгандыр Себер таулары.
Туган суым Базы елгасының
Уелып-уелып калды ярлары.

Иделләргә—ярсуларын Уел
Күпме гасыр аша коядыр.
Аңнарыбыз инде белми бугай,
Каннарыбыз ләкин тоядыр...

## Көнбагыш

Сагыш кына сары түгел диптер,
Сары чәчәк ата көнбагыш.
Көнбагышлар чәчәк аткан чакны
Күрми кала күрмә син ялгыш.

Мәк чәчәге кызыл, алсу иде,
Төсе уңды, исеме каралды.
Киндер орлыклары, чәчелеп, тузып,
Яман чирләр булып таралды.

Көнбагышны безнең—төнбагышка
Боралмаслар, Алла боерса.
Сары төсләр кайгы таратмаслар,
Тыныч ындыр, имин кыр булса.

Кояшлы көз, алтын гомер теләп,
Сары чәчәк ата көнбагыш.
Туган җирнең көнбагышлы чагы—
Гомерләргә җитәр куаныч.

Сары төсне Ходай сөя диләр,
Шул төстә бит бодай һәм арыш...
Мәхрүм итмә Кояш төсләреннән
Шәфкатьле бул Җиргә, и язмыш!

## Хәйямны укыганда туган уй

Җиңел тормыш сорамадым, Ходаем,
Авыр тормыш бирдең шуңар, мөгаен.
Авырлыкны бу дөньяда күп күрдем,
Инде, зинһар, бир димен, җиңел үлем.

* * *

Беләм инде, син дә сагынасың,
Уйларыңда минем сурәттер.
Җырларыңа исememне кушып
Җырламаган көнең сирәктер.

Минем өчен сүзләр әзерлисең,
Берсеннән дә берсе назлыдыр.
Күңелемә алар, көйгә кушылып,
Җуелмаслык булып язылыр.

"Ул синсез дә матур яши",—дигән
Хәбәр килсә, кертмәм ишектән.
Мине сөймәгән син дөньяда юк...
Әгәр булса, бар дип хис итмәм.

Үзем иҗат иткән синнән башка
Һичкемне мин күрмәм, ишетмәм.

## Ышандым

Күзләремдә олы мәгънә,
Тирән моңнар күргәнсең.
Сорап алмадым бәяңне,
Дуслар миннән көлмәсен.

Кемнәрдер читкә борылган,
Йә кызарып игән баш,
Йә бүлмәдән киткән чыгып,
Мин текәлеп карагач...

Бу беренче күзәтүләр
Әйләнсә дә мәзәккә,
Мәзәкләрдән әзрәк узып,
Бәйләнгән мәхәббәткә.

Ничек каршы килим инде
Шундый матур сүзләргә!
Ышандым—дөньяга сөеп
Караган саф күзләргә...

## Җәйдә калдың

Җәйрәп яткан август үзәнендә
Коръән сүзе торды яңгырап.
Хәтерләрдә—син шул җәйдә калдың,
Ә без киттек бераз арырак.

Калдың җәйдә, ахры күрмәс өчен
Яшь түгүен көзге көннәрнең.
Күрмәс өчен бакча тутырып калган
Гөлләреңнең кара көйгәнен.

Җәйдә калдың, анда—урак өсте,
Инешләр күк агыла игеннәр.
Инешләрне тыеп, якташларың
Сиңа баш ияргә килделәр...

Узмас җәйдә калдың, ялгыз түгел,
Әнкәң-әткәң анда, туганнар.
Борчымасын сине без күрәчәк
Яшьле көзләр, ачы бураннар.

* * *

Кай арада сүндең әле,
Минем кичке шәфагым?
Кайда күңелем күкләренә
Ал нурлар сипкән чагың?

Барча көннәр яктылыгы
Син идең минем өчен.
Мең мәгънәле төсләр белән
Бизәдең гомерем кичен.

Таң бул димим, көн бул димим,
Кичем булсаң, җиткән, дим.
Кара болытлар аркылы
Балкуыңны көтәм мин.

*2004—2005*

# "ДӨНЬЯДА БИК АЗ БУЛЫР ЧЫН ШАГЫЙРЬ"

Тукайның матбугатта күренгән беренче шигырьләре үк замандашлары тарафыннан "чын безнең көй" кебек җылы кабул ителә, аларның йөрәгендә, җанында җавап хисләре уята. Хәзер—XXI гасыр югарылыгыннан карагандa бу аңлашыла да: халык җырларының садә моңын, нурлы өметен үзенә алган тирән мәгънәле, сәнгатьчә нәфис лирика, усал да, мөлаем дә була алган кинаяле, кабатланмас поэмалар, "кирәкле шәйдер" тәнкыйть—һәммәсе милләт турында кайгырту, борчылу, аның аң-белем, мәдәни-сәяси дәрәҗәсен Ауропаның алдынгы мәмләкәтләре дәрәҗәсенә күтәрү хыялы, өмете җимешләре. "Шүрәле", "Кичке азан" әсәрләрендә татар тарихының шанлы үткәнен инләү... З. Бигиев, Х. Ямашев, Ш. Мәрҗани, Г. Исхакый кебек мөрәүвәтле шәхесләр тормышын, эшчәнлеген үрнәк итеп сурәтләгән мәдхия-одалары белән халыкта горурлык тәрбияләү, киләчәккә ышаныч уяту... Гаделсезлеккә, искелек калдыкларына каршы күтәрелгән "Пыяла баш"лары, печән базары сәрхүшләрен кояш яктысына тартып чыгарган "Яңа Кисекбаш"лары күңелдә нәфрәт хисе уята, аның халык әхлагы, дин нигезләре, яшәеш кануннары турындагы фәлсәфи уйланулары киләчәккә ышаныч уты дөрләтә. Еллар узып, шигырь олимпына күтәрелә барган саен Тукай, олуг шагыйрь булу белән беррәттән, яшәргә өйрәтүче, игелеккә, хакыйкатькә өндәүче олпат шәхес, "илатасы" кебек тә кабул ителә башлый. Халык биргән "туры Тукай" исеме шагыйрьнең асыл сыйфатын чагылдыручы тәхәллүсе булып күңелләргә сеңеп кала.

Меңъеллык татар поэзиясе тарихында Тукай—һәр тарафтан уникаль шәхес. Ятимлек гарасатымы, тормышның ачысын-төчесен яшьли татуымы, талант чишмәсенең тирәннән, халык бәгыреннән бәреп чыгуы нәтиҗәсеме, хәзер кистереп әйтүе кыен (бәлки барысы бергә укмашкандыр), Тукай поэзиягә пар атта килеп керә, ягъни өйрәнү, тәҗрибә чорын белми кала диярлек. Яшь шагыйрьгә тормыш һәм язмыш андый мөмкинлекне бирми. 1906 елда инде ул "Пушкинә", "Пушкиннән" кебек остазын, кумирын ачыклаган (үзенең дә милли шигърияттә шул югарылыкка күтәреләсен пәйгамбәрләрчә сизенгәндәй) шигырьләрен дөньяга чыгара. "Тукай үзен Пушкинның, рус реалистик поэзиясенең шәкерте... дип шатланып игълан иткән беренче Көнчыгыш шагыйре",—дип яза Тукайны рус телендә яңгыратучы тәрҗемәче Семен Липкин. Шул ук елда язылган, хәзер модернистик алым дип аталган юнәлешкә җавап бирерлек, "Пыяла баш" та ул шартлы алымга өстенлек биреп, бер хәсрәт хәзрәтнең миен үтә күренмәле пыялага әйләндерү аша аның азгынлыгын, милләт, мәгърифәт турында хафаланмыйча, үз шәхси мәнфәгатьләре белән яшәвен күпертеп күрсәтә, "Сорыкортлар" һәм "Государственный Думага" кебек шигырьләрендә сәяси-иҗтимагый лириканың, сатирик памфлетның югары үрнәкләрен бирә. Ягъни 1906 елда инде Тукай—фәлсәфи-әхлакый концепциясе калыплашкан шәхес, сәнгатьлелек җәһәтеннән җитлеккән шагыйрь. Шул рәвешле, быел—2006 елның апрелендә—хәзрәти Тукайның туына 120 ел булса, XX гасыр татар шигърияте даһиенең сүз остасы буларак ачылуына 100 ел икән! Бу күренекле даталарны бәйрәм иткәндә, Тукайның үз милләтенең киләчәге, теле, мәгърифәти-сәяси үсеше өчен җан атып яшәгән татар баласы булуын һәм татар әдәбиятын дөнья киңлекләренә алып чыккан милли шагыйрь икәнлеген һәрдаим истә тотарга тиешбез.

"...Россиядә Көнчыгыш милләтләре язучыларының берсе дә башка милләтләрнең әдәбиятына Тукай кебек тәэсир итә алмады, аларның берсе дә башка милләтләр арасында Тукай кебек хөрмәт һәм дан казанмады. Бу тарихи чынлык",—дип яза күренекле казах язучысы Сабит Муканов.

Тукайның башлангыч, өйрәнү чоры дип аталырга тиешле дәвер нибары бер—1905 ел. 19 яшьлек егет тарафыннан "шәкертлек" чорында язылган, күпчелек җыентыкларын ачып җибәргән "Мужик йокысы", "Дустларга бер сүз", "Хөррият хакында" шигырьләре дә күпләрне көнләштерерлек—аларда инде тиз арада үсеп китәчәк табигый сәләт орлыклары шытып ята.

Рус шагыйре М. Кольцовның (1809—1842) "Что ты спишь, мужичок" шигыренә тәкълид итеп язылган "Мужик йокысы" шигырендә үк Тукай тормыш ихтыяҗларын кайгыртып, гади кешенең тормышын җиңеләйтү юлларын эзли. Тыйнак Тукай үзен "мөтәрҗим" ("тәрҗемәче") дип куйса да, өлкән каләмдәшенең шигырен татарча яңгырату белән генә чикләнми, шәхси уй-фикерләре белән уртаклашып, үзен иҗтимагый юнәлешле автор буларак таныта. Шәкли яктан караганда ике тезмә арасында аерма күз алдында: Кольцов шигыре 52 юлдан тора һәм нигездә ялкау игенчене турыдан-туры фаш итеп, нәтиҗә ясауга корыла. Тукай шигыре 79 юлга сузыла, шагыйрь эш сөймәс мужиктан ачы көлү белән генә канәгатьләнмичә, унган, хәлле кеше белән ялкау арасында чагыштырулар ясый, бер яклы булса да, хәерчелекнең сәбәпләрен эзли. Үгет-нәсихәткә, киңәш бирүгә корылган "Мужик йокысы"—мәгърифәтчелек рухында язылган дидактик әсәр.

Бөтен барлыгын, изге теләк-ниятләрен милләтенең киләчәгенә багышларга җыенган яшь шагыйрь иген үстереп, мал карап, көне-төне бил бөгеп эшләгәндә баеп булуга әле ихластан ышана; хәерчелек, ярлылык, бәхетсезлек хөрәсәнлектән генә килә дип уйлый, ягъни мәгърифәтчелек фәлсәфәсе кысаларында кала, житди иҗтимагый нәтиҗәләр ясамый. Нигездә, 6-6 иҗекле шигырьгә таянып, җөмләләрне бүлгәләп, инверсия алымын кулланып, строфаны катлауландырырга тырышса да, Тукайга чын шигъри нәфислек әле соңрак киләчәк. Метафоралар, катлаулы чагыштырулар булмау, сүзләрне туры мәгънәсендә генә куллану, боерык фигыль формасына өстенлек бирү исә бертөслелеккә алып килә.

Аннары инде Тукайның шәхес һәм шагыйрь буларак үсеше гаҗәеп көчле, тизләтелгән адымнар белән бара. Казан тарафларына юл тотып, баш-аягы белән иҗтимагый-әдәби тормышка кереп чумганчы, Тукай үзен журналистикага бурычлы саный, вакытлы матбугатның җәмгыятьтәге урынын дөрес аңлап, андагы барышка "тәртип" салу рухы белән яши. 1906 елда үз вакытының матбагасына ифрат катгый, урыны белән үтергеч бәя биргән "Дөнья бу", 1907 елда "Тавыш хакында", "Кем ул!", "Бер газета идарәсе хәленнән", "Матбага белән уйнаган бер байга" шигырьләрен язып чыга, аларда Тукай полемист, көрәшче, үз фикерен өздереп әйтүче шәхес буларак ачыла. "Дөнья бу" памфлетында шагыйрь үткен кылычын хәнҗәреннән чыгарган, берәүне дә кызганмый, аямый торган сугышчы. Иң әүвәл вак җанлы байбәтчә Сәйдәшев кылыч астына "килеп керә". "Бәянел-хак" газетасының нашире, буржуа хезмәтчесе, сәүдәгәр Әхмәтҗан Сәйдәшев үз матбагасын иркенрәк яшәтү нияте белән Мәскәү байларыннан бурычка акча алса да, халык күңеленә юл таба алмау сәбәпле, дөнья аны кызганып тормый—"көлен күккә" очыра. Бу хәбәрне Тукай каһкаһә белән, кулын билләренә куеп, көлеп әйтә сыман.

"Һәр басма мөстәкыйль, ирекле булганда гына әйбәт яши ала" дигән фикер уздыра шагыйрь. Тукайның "Мөселман иттифакы" фиркасын оештыручы, хәзерге тарихчылар фикеренчә, беренче татар сәясәтчесе Габдерәшит Ибраһимовка (1857—1922) мөнәсәбәте дә үзенчәлекле (кара: *Хабутдинов Айдар. Лидеры нации.—Казань, ТКИ, 2003.—46-55 б.*) Ул Габдерәшитнең тәрәккыятьне яклап, яшьләр, шәкертләр, зыялылар арасында патша сәясәтенә каршы алып барган эшчәнлеген хуплаган хәлдә, шәхси тормышында тотнаклылык житешмәү, милләт хезмәтчесеннән корсак колы булып китүен, байлык артыннан кууын тәнкыйтьли. И. Гаспринскийның барча төрки халыкларны җәдидчелек идеяләре белән берләштерү, агарту хыялын алга сөргән, Кырымда нәшер ителгән "Тәрҗеман"га да артык игътибар бирүне хупламый. Драматург Г. Камал 15 санын гына чыгарып кала алган, цензура тарафыннан ябылган "Азат халык" (1906) гәзитен аяныч белән телгә алып, "Йолдыз" (1906—1918) нашире Һади Максуди эшчәнлегеннән дә, артык төчелеге, либераллыгы

өчен бик канәгать булмаганлыгын сиздерә. Соңыннан, каты бәрелгәнлеген аклап, гафу үтенгән сыман, дөньяның әшәкелегенә ишарә ясый, үзенең кырыслыгын аңлатмактан, ясалма сылтау таба:

*Һай, боларны бер дә сүкмәс, бер дә рәнҗетмәс идем!*
*Нишлим инде, чарасызмын, тел тидерткән дөньядыр.*

"Бер газета идарәсе хәленнән" шигырендә ул монсу юмор белән татар матбугатының хәерче хәлен, анда хезмәт итүчеләрнең бәйрәм көнендә дә өйләрендә "бер бөртек чәй шикәр бер шакмак юк" дип, хәзерге чорда трактир ачу, эчемлек сату (безнең көннәр мәгыйшәте Тукай чорына якын икән) файдалырак дигән кинәшен бирсә, "Матбага берлән уйнаган бер байга" шигыренең нигезендә булган хәл ята. 1907 елда Җаекта нәшер ителгән "Фикер" газетасы һәм "Әл-гасрел-Җәдит" журналы басыла килгән типографияне Мортаза Гобайдулла атлы кеше сатып ала. Бай бик саран ("карун икәнсең син") һәм мәгариф белән мәгърифәттән бик ерак хали (буш) кеше булып чыга.

Типография һәм басмалар табыш китерми башлагач, бай абзый һәммәсеннән баш тарта, җиһазларны сатып җибәрә, төбәктә татар матбугаты яшәүдән туктый. Без: "хәзерге калын кесәлеләр мәдәнияткә ярдәм итмиләр, сараннар, аларның аң дәрәҗәләре түбән шул,—дип зарланырга яратабыз...—XX йөз башы байлары матбугатка иганәчелек кылып яшәгәннәр"—дип төрттерәбез. Күрәсең, Хөсәенов, Рәмиев, Апанаев кебек юмарт байлар ул заманда да бармак белән санарлык булганнардыр. "Юан корсаклылар" һәр чорда да күбрәк үз кесәләре һәм тамаклары турында кайгыртканнар, милли хис кебек "сантиментларны" йөрәкләренә үткәрмәгәннәр.

XX йөз башында да татар матбугатының, мәгърифәтенең таянычы рухи бай зыялылар, милләтпәрвәрләр булган. Тукайның "Кем ул?" (1907) шигыре шундый мөхтәрәм затларның берсе Гаяз Исхакый турында. Киң колачлы, танылган язучы Г. Исхакый, Тукай фикеренчә, милләтнең үсеше, киләчәге өчен җан атып, борчылып яшәүче гаярь мөхәррир, журналист, кыскасы, һәр тарафтан мактауга лаеклы олы зат икән.

Патша цензурасы Исхакыйның "Таң йолдызы"н япкач, татар эсерлары "Тавыш" газетасын нәшер итә башлыйлар. Тукай яңа басманы ихластан хуплап, "Тавыш" хакында" (1907) исемле шигырен язып чыга, үз хокуклары өчен эшчеләрне көрәшкә күтәрүдә аңа зур өметләр баглый: "Тавышланган! Эшче халык, Тавыш белән... Тартыш, эшче! Тартыш, зинһар, тартыш, тартыш!"

Вакытлы матбугат мәшәкатьләре белән яшәгән 1907 елда Тукай, бер караганда, бик вак темага, натурализм чалымнары өстенлек иткән яшәеш вакыйгасын үзәккә алган "Сөткә төшкән тычкан" шигырен язып чыга. Сөткә егылып төшкән тычкан, әүвәл аптырап калса да, язмышка баш бирмичә, тормышы өчен көрәшә башлый, аркылыга-буйга йөзә-йөзә сөттән май туглый һәм "үз урынына" чыгып кача. Тукай каләменнән төшкән шигырь житди нәтиҗәсез тәмамлана алмый. Тормышы белән саубуллашырга җыенып та, яшәүгә омтылышы аркасында исән калган җәнлек язмышы аңа милләткә киңәшен әйтеп калырга җай тудыра.

*И карендәш! Син кирәксә, суга бат йә сөткә бат!*
*Ит сабыр, күрсәт чыдамлык һәм дә ит гайрәт, сәбат!**

Шул ук чорда (1906—1907) патша охранкасы "Государственная Думага", "Китмибез" кебек усал сатирик памфметлары, сәяси публицистикасы өчен шагыйрьне "ышанычсызлар" исемлегенә кертә.

Тукайның даһилыгы бигрәк тә үткен телле сатирасында ачык күренә. Әдәбиятның бу төрен ул күңел ачу, кәеф-сафа кору чарасы дип бәяләүдән бигрәк, җәмгыятьне, кешеләрне көнчелек, ваклык, шапырыну, мактану кебек житешсезлекләрдән

*Сәбат – ныклык.

арындыру, намуслы, иманлы яшәү өчен үтемле көрәш чарасы дип бәяли, шунарда аның үсешенә, иҗтимагый яңгырашлы һәм сәнгатьчә камил булуына игътибар бирә.

1908—1909 елларда, замана алып килгән вәзгыятьтән вакытлы матбугат (хәзер аның күз унында күбрәк сатирик журналлар) низагъларыннан читләшмәсә дә, Тукай иҗатының үзәгенә милли мәсьәләләр дулкыны килеп керә, татар халкының яшәеше, киләчәге, теле, мәгърифәте аның бәгырен телгәли, иҗатының төп юнәлешен миллилек, милли идея, татарлык билгели. Милләт яшәеше өчен көрәш идеясе аның һәр әсәрендә диярлек ярылып ята. Бередә Тукай характерының шактый кырыс булуын һәм эчке мөстәкыйльлекне югары бәяләвен онытырга ярамый.

"Бу үлек вөҗданны җанландыр, җылың белән җылыт" ("Өмит") дип, үз иҗади көченә ышанган шагыйрь теләсә кайсы катлау кешеләре, танылган абруйлар белән конфликтка керүдән, ачы, усал бәясен күзләренә карап әйтүдән тайчынып тормый.

Күк көчләре, күрәсең, татарларны тарих юлларында күп сынадым, кыерсытуны дәвам итәм дип фараз кылып, гомерен, барлыгын шигърияткә, халыкка багышлаган, хәтта гаилә, балалар мәшәкатеннән (тарих бер дәһиның да үзенә тиң баласы булганны хәтерләми), башка тышкы богаулардан азат илаһи бер талантка ия титанны бүләк итим әле дип, Тукайны юллагандыр. Менә шул урында Тукай варисы саналган хәзерге поэзиябезгә карата лириклыктан ерак чигенеш ясамыйча булдыра алмыйм, Тукайның соңгы елларда гаять якын күргән кешесе Л. Толстой әйткәнчә, "дәшми кала алмыйм". Хәзерге шигъриятебезнең, бигрәк тә хатын-кыз өлешенең үзәк мәүзигын ата-ана, туган-тумача, гаилә, балалар образлары, олыракларының оныкларын иркәләү тәшкил итә. Әлбәттә, бу теманы да интим лирика читләтеп үтә алмыйдыр. Тукай үзе дә әнисен, аның каберен җылы итеп телгә ала. Р. Фәйзуллин, Р. Миңнуллин, М. Галиевләрнең әниләренә багышланган классик җыр-шигырьләре мәгълүм. Әмма татар поэзиясе кебек рәсми яклаучысыз, үзенә зур җаваплылык алган шигърият тар, шәхси кысаларда гына калса, иҗтимагый йөзен югалтачак. Тукайлар заманында да "шәкерт дәфтәре", "гаилә көндәлеге" кебек төшенчәләр яшәгән, ләкин гаилә сөенеченне халыкка ирештерү, матур сүзләргә төргән информацияне матбугатка күтәреп бару илләм мәҗбүри түгелдер. Татар хатын-кыз шигъриятендә хәзер балалары, оныклары белән шигъри сокланулар эпидемия төсен алды.

Сайланып тормастан, шул көннәрдә мөхтәрәм газетабызда басылган бер дүртьюллыкны китерәм.

*Бер улым, бер кызым иде,*
*Бер улым булды тагын.*
*Оныгым бар! Җан бөртегем!*
*Алма битем! Илһамым.*

Татар теленең җанны эретердәй татлы чагыштыруларга бай булуы белән сокланган хәлдә, бу юлларда фикер яңалыгын, фәлсәфи-әхлакый уйлануны таба алмадым. Ә бит бу шигырь искиткеч әйбәт җырлар, тирән мәгънәле лирик шигырьләр авторы каләменнән төшкән. Авторы талантсыз, үзешчән булса, сүз куертып, Тукай бөеклеген искә төшереп тә тормас идем. Әйе, татар поэзиясенең "үлчәү берәмлеге", сәнгатьлелек бизмәне Тукай, Такташ, Җәлил, Туфаннар белән үлчәнә шул!

1908 елдан алып, соңгы сулышына чаклы Тукай милләт хәсрәтен, халык язмышын арык иңнәренә салып, тарихыбызга, үз чоры проблемаларына караган, самимилекләре белән нәфис, гүзәллекләре белән камил шигъри энҗеләрен иҗат итә. Тукайның бөеклегенә ышану өчен бөтен иҗатын күзаллау мәҗбүри түгел. Бередә һәркайсы өч шигъри юнәлешкә караган—"Шагыйрь", "Милләтчеләр" һәм "Милли моңнар" кебек шедеврларына гына тукталып үтәсе килә. Шагыйрьдә хис, кичереш ташый. Бер ел дәвамында гына да аның күңелендә икеләнү, эзләнү, борчылу бара, сагыш белән беррәттән кискенлек, кичереш, шатлык...

"Өмит" шигырендә ул, мәсәлән, фикер кояшын, сүнә барган өметен эзләсә, шул ук елда (1908) иҗат ителгән "Шагыйрь"дә үзен тапкан, раслаган, романтик рухлы лирик геройны мөнбәргә күтәрә. "Шагыйрь" (1908)—аның иҗатының Казан чоры башында, поэзиянең тормыштагы урыны, җәмгыятьтәге олы вазыйфасы турында уйланып, шагыйрьнең үз рухи халәтен ачуга багышланган шигъри энҗеләренең берсе. Яшь әдип төшенкелек, югалып калу, пессимизм кебек төшенчәләрне катгый кире кага, аның рухына оптимизм, киләчәккә ышану, дөньяны алсу төсләрдә кабул итү хас. Идеалының тормышка ашасына ихластан ышана. Алдагы көннәрдән килеп, ул шартлы дөнья тудыра: янәсе, еллар узган, шагыйрь картайган, сәлперәйгән, бөкресе чыккан, шул хәлендә дә аның тыныч, салмак, үзагышлы тормыш белән яшисе килми, чөнки күңеле һаман яшь, җаны көчле, йөрәгендә яз, ул салкын кышны, карны, ягъни бертөслелекне, рухи сүлпәнлекне, битарафлыкны танымый, кабул итми. Күкрәгендә шигырь уты дөрләп торганда, рухы сәламәт чакта ул картлыкка, физик йомшаруга бирешмәс, күңеле белән гел яшь, горур булып калыр. Үзәккә яшьлек белән гомер ахыры арасындагы мөнәсәбәт, үзара тартышу кебек мәңгелек фәлсәфи проблема алына. Яшәеш барышына реалистларча карый алган шагыйрь барча адәми затлар кебек берзаман үзенә дә картлык киләсен белә. Тик ул шунда да "юк бар теләк тели-тели" мич башына менмәс, ана кирәкле җылылык, дәрт халыкка рухи азык шигырьләреннән бөркелеп торыр, үлем фәрештәсе—газраил—җанын алырга янына килгәч тә, югалып, дәшми калмас, туфрак белән күмгәндә дә, күтәренке рухта "без китәбез, сез каласыз", дип җырлар. Шигырь соңгы юлларда иҗатчы шәхесен, поэзиянең рухи дөньяда тоткан урынын романтикларча идеаллаштыруда үзенең апофеозына, иң югары ноктасына күтәрелә. "Шагыйрь" әсәрендә Тукай катлаулы метафораларга, сынландыруларга мөрәҗәгать итми, сүзләрне туры мәгънәсендә куллана, алынмалар да юк. Шигырьнең буеннан буена сузылган шартлылык алымы арттырып, күпертеп сурәтләүгә юл ача. Бу ысул лирик геройны—иҗатчыны—вакытлы, узучан хисләргә бирешмичә, үзенә, иҗатының киләчәгенә, поэзиянең үлмәс көченә, мәңгелегенә ышанган олы, мөрәүвәтле шәхес итеп тасвирларга мөмкинлек бирә.

"Милләтчеләр" исемле 1908 елның азагында иҗат ителеп, шул елда ук "Г. Тукаев диваны" исемле җыентыкта нәшер ителгән, эчтәлеге, композицион төзелеше, образлар системасы җәһәтеннән җитлеккән, шул ук вакытта эчке драматизм белән сугарылган әсәрендә бер төркем ялган зыялыларны фаш итә.

Тукай үзләрен зыялы милләтчеләр, халык киләчәге өчен яшәүчеләр дип, аерым игътибарга дәгъва кылып йөргән адәмнәр белән милләт арасындагы мөнәсәбәт кебек җитди проблеманы калкытып куя. Шагыйрь гавамны алдап, сүз куертып, шомартып, үтәлмәс вәгъдәләр биреп, чынында халыкның соңгы тиенен үзләштерү кәсебенә керешкән алдакчыларга мөнәсәбәтендә ул рәхимсез, кырыс, кисәтеп чаң суга. Үзләрен милләтче дип йөргән икейөзле, алдакчы, сатлык җаннар сүздә "татар халкы яши, тиз арада җанлана, аякка баса" дип сөйләнеп йөрсәләр дә, үзләре милләтнең үзанын уяту өчен берни эшләмиләр, шәүләләреннән куркып яшиләр. Аларның буш куыклыгын кискен ачып салу өчен сатирик метафора да табыла: "Кайсы чакта күперсә дә, тиз шиңә бит. Тегә ишек алдындагы ата күркә". Син, милләтем, ди шагыйрь, ялагай, купшы сүзләргә ышанма, чөнки аларның "барчасы да эшсез шәкерт", "Алданма син, шәкерт алар, шәкерт, дип "шәкерт" сүзен кат-кат кабатлап, аңа символик, гомумиләштерелгән мәгънә бирә. Тукай бу катламның хәл-әхвәлен, белем дәрәҗәсен, милли рухын яхшы белә, кемгә хезмәт итүләрен "Бер бай үләргә ятканда үзең күрерсең", гыйбарәсе белән чын йөзләрен ачып салган дәлилен китерә, үтәлмәс вәгъдәгә ышану "Тәһарәтсез намаз илә, корбансыз хаҗ"га тиңләнә.

Әсәрнең эчтәлеге милләтчеләрнең битлекләрен салдырып, кояш яктысына тартып чыгаруга гына кайтып калмый. Тукайның максаты—халыкка чын хакыйкатьне җиткерү һәм торгынлыктан чыгу юлларын күрсәтү. Шагыйрь яраткан халкын иркәләп, кызганып, мәдхия яудырып кына утырмый, кырыс һәм усал сүзләрдән дә тартынып тормый: "Татар халкы! Син үләргә мәхкүм (хөкем ителгән)

инде. Дару үтмәс дәрәҗәдә мәсмүм (агуланган) инде". Фикеренә ышандыру көче бирү ниятеннән, мифологик элементны сурәткә кертә, нәкъ әкияттәгечә, татар халкы явыз балык иркендә калган көймә хәлендә икән. Көймәне-милләтне йоттырмас өчен нәрсәләр эшләргә соң? Буш вәгъдәләргә ышанып, "рәхмәт берлә җанлансаң да, алар сине тагын сугып екмасмыни?"—дип, риторик соравын бирә дә, халкын терелтү, яшәтү өчен ихтыяҗи фикерен калкытып куя. "Син бер гали (бөек), сатылмаслык иргә мохтаж".

Бер төрле сөйләп икенче төрле эшләүче, үзләрен милләтче дип йөрүчеләрнең "пәрәнҗәсен салдыруны" Тукай "Шартлар", "Милләтче" шигырьләрендә дәвам итә.

"Милли моңнар" шигыре (1909) телгә килүгә исә күңелдә каяндыр тирәннән, тарих чоңгылларыннан килгән татар халкының гасырлар дәвамында рәнҗетелгән милли моңы яңгырый башлый кебек. "Милли моңнар", әүвәл "Әдәбият" исемле җыентыкта (10 нчы дәфтәр), соңрак "Халык әдәбияты" китабында урын алган, Тукайның җыр, көй белән халык тарихы арасындагы якынлык турында уйлануы буларак туган шигъри гәүһәрләреннән берсе ул. Шигырь берсе икенчесеннән үсеп чыккан ике өлештән тора: әүвәл лирик герой берәүнең "чын безнеңчә, матур, моңлы" җыр башкаруын ишетә, күңел кыңгырауларын уяткан көйнең исемен белү теләге туа. Икенче, төп кисәктә, ул халкы үткән фаҗигале юл турында уйлана, аның аянычлы тарихын ачы дөреслеге белән сигез юлга сыйдыра. Чөнки җырның әтрафле, фәһемле сүзләре, "зарлы, моңлы" көе йөрәгенә үтеп керә, зиһенен били һәм лирик геройга милләт язмышына бәйле гамь-борчулары белән уртаклашырга мөмкинлек бирә, җитди фикерләр уята. Татар җыры, моны гади һәм гадәти күренеш, күңел ачу чарасы гына түгел икән. Ул халыкның өч йөз ел дәвамында михнәт чигеп, изелеп, авыр тормыштан күз яшьләрен агызуын, йөрәгендә кайгы-хәсрәт саркып ятуын, сызлануын эченә алган сәнгать әсәре икән.

Авыр, кыен мизгелләрдә халыкның төп таянычы, юанычы, юлдашы, бар сызлануын үзенә сеңдергән, киләчәккә ышанычын саклаган моңлы җыры булган. Аның рухи халәте "Милли хисләр белән ялкынланып, Сызланып-сызланып чыга күңеленнән", бары тик моңга баткан җыры гына "татар күңеле ниләр сизгәнен" әйтеп бирә алган. Шагыйрь халкының яшәеше өчен борчылып, сызланып, милләт хәсрәтен үз шәхси кайгысы дәрәҗәсенә күтәреп сурәтли.

Совет чорында нәшер ителгән Тукай җыентыкларында "Милли моңнар" шигыренең халык тәкъдире, язмышы турындагы уйлануларын калкытып куйган 2-3 нче строфалары, ягъни шагыйрьнең төп фикерләрен эченә алган юллары төшерелеп калдырыла килде. Мондый кыскартылган вариантта әсәр очраклы тыңланган җырның исеме "Әллүки" икәнлекне ачыклау максатын гына куйгандай тәэсир калдырды. Шул рәвешле, "Милли моңнар"ның төп мәгънәви йөген үзенә алган халыкның ачы тормыш тәҗрибәсен бәян иткән өлеше белән танышудан күп еллар дәвамында укучы мәхрүм иде. Шигырь үзәгендә моң-җыр образы, лейтмотивы ятса да, чынында "Әллүки"нең исемен ачыклау шагыйрьнең халык тарихы турында уйлануларын, җан җәрәхәтен ачу чарасы гына. Шигырьнең "милли моң", "бер көй тарихы" дип кенә аталмыйча, "Милли моңнар" дип исемләнүе, "моңнар" төшенчәсенә гомумиләштерелгән, символик мәгънә бирә.

Саф татар әдәби телендә язылган бу шигырьнең композициясе үзенчәлекле. Көйне ишетү белән аның атамасын ачыклау барышына тарих ташкыны, халык язмышы килеп керә, "милләтнең үткәне аның җырына, моңына сарылып калган" дигән фикер үткәрелә.

Халык җырының тарих һәм халык язмышы белән үрелеп баруы, рухи дөнья җимеше булган моңны, көйне олы бер мирас итеп саклау кирәклеге турында "Милли моңнар"да күтәргән уйлануларын Тукай халык иҗатына багышланган мәшһүр лекциясендә дәвам иттерә.

Шунысы үзенчәлекле: әлеге шигырьләрдә соңыннан билгеләмәләре табылган иҗат юнәлешләренең төп-ачкыч сыйфатлары табыла. Тукай өйрәнчеклек чорын бик тиз узып, мәгърифәтчелек реализмы ("Мужик йокысы"), романтизм

("Шагыйрь"), тәнкыйди реализм ("Милләтчеләр") аша милли реализмга ("Милли моңнар") аяк баса. Тукай—югары вөҗданлы, саф күңелле, иманлы шәхес. Аның холкы хөсетлек, көнчелек, шәхси үпкә кебек түшенчәләрне күңел түренә үткәрми. Татар тарихының шанлы сәхифәләрен үзәккә алган парчаларын, усал, чәнечкеле сатирасын, моңлы сазын бары бер максат белән—халкын кол булып, гомер бакый баш иеп яшәүдән коткару хыялы белән—иҗат итә.

Үлемсезлек чиген, вакыт һәм алышынып торган сәяси-иҗтимагый сынауларны намус белән узган Тукай лирикасы, халык вөҗданы байрагыдай, гасырлардан гасырларга уза. XX гасыр башының күренекле шагыйре Ш. Бабич 1911 елда, ягъни Тукай исән-имин чакта ук, болай дип язган:

*Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь, Габдулладай;*
*Ул—караңгы төндә яктырткан матур, ак тулган ай.*

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**

*Тукай турында олуг шәхесләр*

## Әмирхан Еники,

Татарстанның халык язучысы:

***Минем буын язучыларга Тукай, билгеле, якынрак тора. Без туганда Тукай үзе дә исән булган әле. Өч яшьтән үк без аны белеп, укып үстек. Тукай белән телебез ачылды, дөньяга күзебез дә ачылды. Безнең рухи дөньябызга иң тирән эзне салучы да Тукай булды. Әлбәттә, Тукайның чын мәгънәсендәге кешелекле, халыкчан, демократик иҗаты бүгенге буынны һәм киләчәктәге бик күп буыннарны да рухи тәрбияләп, баетып торачак. Тукай мирасы тирән диңгезне хәтерләтә. Аның төбендә яткан шигъри һәм мәгънәви гәүһәрләрне эзләү, табу һаман да дәвам итәчәк. Бу урында бөек шагыйрьнең бер бик мөһим сыйфатына тукталасым килә. Тукай үз халкының үткәнен бик яхшы белгән һәм исендә тоткан. Тукай үз халкының хәзерге, ягъни үзе яшәгән чордагы тормышны гаять тирән аңлаган. Ниһаять, Тукай үз халкының киләчәге турында даими уйланып, кайгыртып яшәгән. Мина калса, һәр заманда да чын язучыларга Тукаебызның әнә шул сыйфаты, ягъни үз халкының үткәнен белү, бүгенгесен аңлау, киләчәген кайгырту хас булырга тиеш.***

## Кайсын Кулиев,

балкар шагыйре:

***Төрки телләрдә язган язучыларның татар әдәбиятыннан өйрәнмәгәннәре юктыр дип беләм мин. Казахларга, кыргызларга, үзбәкләргә, төрекмәннәргә дә, безгә—Кавказда яшәүче балкарларга, карачай, кумык, әзәрбәйҗан халыкларына да татар әдәбиятының шифасы, файдасы бик күп булды. Без бүген дә мәңгелек тарихы булган бу әдәбиятка, аның язучыларына зур рәхмәтлебез. Тукай... Тукай иң олуг уртак шагыйрьләребезнең берсе. Безгә аның иҗаты яхшы таныш, Кавказда аны укыйлар, татар телендә дә укыйлар, тәрҗемәдә дә. Ул безнең иң сөекле шагыйребез генә түгел, халыкларны берләштерүче күпер дә.***






*Казанда "Шәрык" клубы урнашкан бина. (Хәзерге Татарстан урамы, 8 нче йорт.) 1910 нчы елның 15 апрелендә Г. Тукай үзенең "Халык әдәбияты" дигән лекциясен шушы клубта укыган.*

*Г. Тукайның Уральскида типографиядә эшләгән вакыты. 1905 ел.*



*Сулдан, алгы рәттә: Г. Тукай, Ф. Әмирхан; басканнар: Г. Коләхметов, К. Коләхметов. 1912 ел.*



*Сулдан: Г. Тукай, С. Рәмиев, Ф. Агиев. 1908 ел.*




*Г. Тукайның 1908 елда балалар өчен чыгарылган "Җуаныч" исемле шигырьләр җыентыгының тышлыгы.*



*Г. Тукайның соңгы көннәре.*

# ТУКАЙНЫҢ "ЗОЛЫМ" ШИГЫРЕН УКЫГАНДА ...

XIX гасырның икенче яртысында—XX гасыр башында Көнбатыштан үтеп кергән фәлсәфи-фәнни фикерләр йогынтысында мөселман дөньясында ислам диненең һәм Коръән тәгълиматының асылын дөрес аңлау буенча уйлану-эзләнүләр башлана. Беренчеләрдән булып, бу эшкә Аурупа мәдәнияты, рус иҗтимагый-фәлсәфи фикере белән таныш булган күренекле гарәп-фарсы, төрки-татар голямәләре, дини реформаторлары алына. Җәмалетдин әл-Әфгани, Мөхәммәд Габдеһ, Шиһабетдин Мәрҗани, Муса Бигиев, Габдулла Бубый (Нигъмәтуллин), Закир Кадыйри, Зыяэтдин Камали, Галимҗан Баруди, Гатаулла Баязитов, Габдерәшит Ибраһимов, Ризаэтдин Фәхретдинов кебек дин галимнәре, Коръән тәгълиматын акыл һәм фән белән уртак тел таптырырга омтылып, ислам диненә реформа ясап, халыкка аны янача аңлату кирәклеген көн тәртибенә куялар. Бу юнәлештә хәрәкәт иткәндә алар урта гасырлардагы мөселман Ренессансының бөек акыл ияләре һәм әдипләре мирас итеп калдырган радикаль эчтәлекле фикерләрне дә эшкә җигәләр. Шул сәбәпле XX гасыр башы татар иҗтимагый, этик һәм әдәби-эстетик фикерендә дә ислам диненең заман һәм гавам өчен искергән дип исәпләнгән схоластикасын, догмачылыгын, сәләфчелеккә, тәкълидчелеккә корылган традиционализмын тәнкыйть итү көчәя. Реалистик һәм романтик язучылар тарафыннан антиклерикаль эчтәлекле, хәтта дәһрилек элементлары булган кайбер әсәрләр языла. Гаяз Исхакыйның "Ике йөз елдан соң инкыйраз" антиутопиясен, Мәҗит Гафури һәм Сәгыйт Рәмиевнең гыйсъянчылык рухы белән сугарылган кайбер шигырьләрен, Габдулла Тукайның "Золым" шигырен шундый әсәрләр рәтенә кертеп булыр иде.

Текстологлар Р. Гайнанов һәм З. Рәмиев тикшерү-эзләнүләренә караганда, "Золым" шигыре (1911) әле Тукай исән вакытта укучылар игътибарына тапшырылмый калып, беренче мәртәбә Фәтхи Бурнаш җыеп бастырган "Г. Тукай шигырьләре" исемле китапта дөнья күрә. Төзүче анда "Бер җирдә дә басылмаган" дигән искәрмә биргән (кулъязмасын кайдан алуын да күрсәтмәгән). Аннан соңгы күп томлы басмаларда, Ф. Бурнаш культ елларында репрессияләнү сәбәпле, шигырьнең "Тукай кулъязмалары арасыннан табылып, Октябрь революциясеннән соң гына басыла башлавы" әйтелә. Тукайның 1929—1931 елларда чыккан өч томлы "Әсәрләр"дәге искәрмәдә Ф. Сәйфи-Казанлы Ф. Бурнашта әлеге шигырь кулъязмасы булуын әйтүен хәбәр итә, әмма үзе аны кулына тотып карамаган, текстны исә Ф. Бурнашта төзегән китап буенча гына урнаштырган. Ф. Бурнаш исә әсәрнең язылу датасын 1911 ел дип күрсәтә. Мәгълүм булганча, 1910—1911 елларда Урта Иделдә ачлык хөкем сөрә. Шунлыктан "Золым" шигыренең нәкъ менә ачлык күренешләре тәэсирендә язылуы фараз ителә.

XX гасыр әдәбият белемендә һәм әдәби тәнкыйтьтә Габдулла Тукайның "Золым" шигыре төрлечә шәрехләнгән. Ул һәм антиклерикаль, һәм атеистик әдәбият үрнәге итеп каралган.

"Золым" шигыре 12 иҗекле дүрт юллык өч строфадан тора. Аның үзәген тәшкил иткән төп мәсьәлә дин белән фәкыйрь мөселманнар арасындагы үзара мөнәсәбәт. Мөселман әдәбиятлары өчен бу—традицион тема. Төрле социаль катламнар белән ислам дине арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләү буенча шәригать гыйльмендә "мөгамәлә" дигән термин да яшәгән. Тукай шигырендә ислам дине белән гавам

арасындагы “мөгамәлә”, ягъни мөнәсәбәт мәсҗедтә намаз укучы, “Әшһәдү” дип, Алланың барлыгына һәм Берлегенә шаһидлек (гарәпчә)—гуаһлык (фарсыча) бирүче мөслим, ишанга иярүче җаһил мөрид, яшәү белән ач үлем арасында интегүче “мискин фәкыйрь” образы мисалында гәүдәләнгән һәм ул Коръән тәгълиматында олуг рухи кыйммәт дип саналган “иман” төшенчәсе тирәсенә бер фокуска туплап бирелгән.

“Золым” шигыренең беренче строфасында ук автор:

*Фәкыйрь кеше! Кемнәр сиңа иман таккан?*
*Тәзкирәңә мөслим диеп игълан таккан?*
*Кемнәр сине, намаз диеп, сәҗдә диеп,*
*Юкка тузанлы мәсҗедләрдә аунаткан?—*

дигән юллар белән автор фәкыйрьләрнең Коръән сурәләре һәм аятьләренең мәгънәсен төшенмичә, иманлы мөселман булу өмете белән шулай фарыз дип, тузанлы мәсҗедләрдә гыйбадәт кылулары яна тарихи шартларда үзен аклыймы, хакыйкатьне танып белүгә ярдәм итәме-юкмы дигән бәхәсле сораулар тезмәсе белән укучыны сискәндереп җибәрә, шик-шөбһәгә батыра. Югарыда китерелгән юллар һич тә Тукайның Аллаһыга һәм дингә каршы чыгуы, илаһият фәлсәфәсен танымавы дип аңлашылырга тиеш түгел. Чыгышы белән мулла гаиләсеннән булган, мәдрәсә тәрбиясен һәм гыйлемен үзләштергән шагыйрь беркайчан да дәһри булмаган. Ул бары тик халыкның ислам дине белән бәйле кыйммәтләрне җир тормышына ярашлы һәм файдалы итеп үзләштермәүләренә, ахирәткә нисбәттә дә дини йолаларны ихлассыз башкаруларына борчулы уй-кичерешләрен белдерә. Шагыйрь фикеренчә, үзләрен мөселман дип йөртүче фәкыйрьләр Коръән өйрәтмәләренең үзеген тәшкил иткән, анда 40 мәртәбәдән артык кабатланган, Аллаһының Барлыгын һәм Берлеген раслаган, Мөхәммәд пәйгамбәрнең җир кешеләренә илче итеп җибәрелүен таныган “Әшһәдү әллә илаһә иллӛллаһ. Әшһәдү әннә Мүхәммәдәррәсүлүллаһ” дигән изге аятьләрнең тирән эчтәлеген, мәгънәви әһәмиятен, аларның әҗере һәм савабы нидән гыйбарәт, нигә яраклы, кемгә файдалы икәнлеген хөр акыл һәм ихлас кальб белән зиһеннәренә сеңдерүдән, хакыйкатьне аңлаудан бик тә ераклар. Шуңа күрә дә автор фәкыйрь кешегә кабат:

*Гуаһлыклар бирәсең син, “әшһаде” дип,*
*Син ни беләң? Кемгә мәкъбүль шәһадәтең?—*

дигән риторик эндәш белән мөрәҗәгать итә.

Ярлы-ябагайларның наданлыклары аркасында тормыш төбенә—түбәнлеккә (сәфаләткә) тәгәрәүләренең сәбәбен Тукай ул заманда яман исемнәре чыккан ишаннарга кул бирүдә, аларга “иярченлек” кылуда, кол-мөритләр булып йөрүдә дә күрә:

*Тагын сиңа иярченлек сәфаләтең,*
*Корал итеп йөретәләр җәһаләтең.*

“Золым” шигырендә генә түгел, шагыйрь үзенең байтак әсәрләрендә ишаннарны халыкны наданлыкта калдыручылар, талаучылар, диннең асылын бозучылар дип гаепләде. Әйе, Г. Ибраһимов язганча, “халкымызның уяндыгы елларында “яңа фикерле” булганнардан кем иске фикерле голяманы сүкми дә, кем ишаннарны милләтнең зарарлы микроблары дип чәйнәми иде. Кем боларга ачу вә дошманлык сакламый иде? Ә Тукаев моны азмы җырлады?” *(Әсәрләр. “Татар шагыйрьләре”.— 5 том.—142-143 б.).* Ислам диненең сакчылары булган руханиларга бу рәвешчә каты бәрелү, билгеле, буш урында гына тумады. Аның тамырлары ерак гасырлардан килгән ислам традиционализмына, Тукайлар заманындагы татар тормышын канәгатьләндермәгән дини-фәлсәфи карашларга һәм шәригатьчә яшәү тәртипләренә барып тоташкан иде.

* * *

Мәгълүм ки, ислам дине кешеләрне ахирәт өчен дә, дөнья көтәр өчен дә ижтиһадка—изге гамәлләр кылырга, рухи камиллеккә чакыручы монотеистик тәгълимат буларак мәйданга чыкты. X-XI гасырлар дәвамында сәләфләр—борынгы ислам голәмәләре тарафыннан абсолют акыл бары тик Аллаһы Тәгалә өчен генә хас, ул халикъ иткән (яраткан) коллар—Габдуллалар өчен ижтиһад заманы артта калды дигән карашларны канунлаштыру җир кешесенең матди һәм рухи яшәешендәге ихтыяри көчен чикли, дин һәм илаһият гыйльме өлкәсендәге үсеш-үзгәрешләргә юлларны яба, тәкълидчелеккә юл ача. Әдәби иҗат өлкәсендә дә теге яки бу авторга ияреп, аның мәгълүм әсәренең сюжетын, әйтергә теләгән фикерен, образ-сурәтләрен өлешчә төсмерләрдә генә яңартып иҗат итүнең, ягъни нәзыйрәчелекнең дистәгә якын төре барлыкка килә һәм киң кулланылыш ала.

Шәрекъ Ренессансының атаклы философлары һәм шагыйрьләре ортодоксаль динчеләрнең барысы да Аллаһы әмере һәм ихтыяры (ирадәи лә әзәл) буенча бары тик язмыш фәлсәфәсенә басым ясаулары, ижтиһад мәсьәләсен күләгәдә калдыру белән килешеп бетмәделәр; Коръән өйрәтмәләрен һәм хәдисләрне шәрехләүдә дә, әдәби эшчәнлектә дә элгәреге гасырлардагы традицияләр кысаларында гына бикләнеп калырга теләмәделәр, тәкълидчелек, нәзыйрәчелек җепләре белән бәйләнгән хәлдә дә фикер әйтүдә, хисләрне белдерүдә иҗадилыкка, яңалыкка омтылдылар.

XVI гасырдан башлап, мөселман дөньясын кабат "ижтиһад мөнкарыйз" дулкыны чолгап ала. Аннан котылырга тырышу татарлар арасында беркадәр иртәрәк—XVIII гасыр азагында ук Габденнасыйр Курсавиның (1776—1812) диндә ислахчылык таләп иткән үткер чыгышлары белән башланып китә. Һәр адымы дин белән регламентацияләнгән татар тормышына реформалар кертүне таләп итү XIX йөздә тагын да көчәя, ә инде XX йөз башында ул җәдиди муллалар, зыялылар, язучылар, шәкертләр тарафыннан бөтен кискенлеге белән зарурият рәвешендә көн тәртибенә куела. Габдулла Тукайның "Золым"ы да "гакылларны тар иткән" (С. Рәмиев) дини торгынлыкка юнәлтелгән, "исляхат өметләре дулый башлаган заманның" (Г. Ибраһимов) ислам фәлсәфәсен, гыйбадәт кылудагы кимчелекләргә карата бик тә ачынып язылган шигыре иде.

* * *

Җәдитчеләр белән кадимчеләр тартышы, милли азатлык хәрәкәте көчәйгән, татар халкы Яңарыш дәверенә аяк баскан бер чорда Тукай иске фикерле голәмәләрнең "иман" төшенчәсен бакыйлыкка—мәңгелеккә генә бәйләп аңлатулары, тузанлы мәсҗедләрдә гыйбадәт кылуны кырыс мәҗбүрият итеп куюлары белән килешми. Чөнки шәригать буенча да Аллага инану, иманлы булу мөэминнәрнең җир тормышына зыян салырга тиеш түгел. Аныңча, татар тормышында моның капма-каршысы—рухи кыйммәтләрнең изгесе дип саналган иман белән дә фәкыйрьләрне көчләү күзәтелә:

*Мискин фәкыйрь, иркен сулыш та алмыйсың,*
*Аһ-ваһыңнан һичбер вакыт бушанмыйсың;*
*Көчләү сине сарих золым иман белән,*
*Иртәгә ач үлмәм дип тә ышанмыйсың!*

Шул рәвешчә, шигырьнең соңгы өченче строфасында ачлык афәте белән янәшә куелган иман төшенчәсе социаль яңгыраш ала һәм ул риторик мөрәҗәгать белән көчәйтелеп, гавам (кара халык) җилкәсенә төшкән җәбер-җәфа, иҗтимагый золым булып аңлашыла башлый. Моңа артык гаҗәпләнергә дә кирәк түгел. Чөнки динилек белән дөньявилык (социаль яшәеш) арасындагы мондый каршылыклы, икелекле мөнәсәбәтләрне сәнгати чаралар белән гәүдәләндерү ислам динендә гасырлар

дәвамында яшәп килгән. Габдулла Тукайның "Золым" шигырендә ярлы халык белән дин арасындагы үзара мөнәсәбәтнең "иман—золым" антиномиясе рәвешендә укучыга җиткерелүе шул ерак гасырлардан килгән традицияләрнең яна тарихи шартларда калкып чыгуы һәм дәвам итүе иде. Фикри-хисси конфликтның бу рәвешчә бирелүе шигырьнең жанрын да үзенчәлекле иткән. Ул дини-әхлакый әдәбиятта, аеруча аның иман категориясе белән бәйле гакыйдә (ышану) юнәлешендә кин кулланылышта булган рәдд (каршы кую) жанрында иҗат ителгән.

Рәдд жанрына хас кануннар таләп иткәнчә, "Золым" шигырендә Тукай XX гасыр башы татар чынбарлыгында "диндә исляхка каршы хәрәкәт иткән дин сакчыларын" да (Муса Бигиев) тәнкыйтьли; сукырларча һәм битараф калып, дини йолаларны үтәргә мәҗбүр ителгән фәкыйрьләрне дә битәрләп ала; аларның ихлассыз догалары, иманнары дөньявилык һәм ахирәт өчен ни дәрәҗәдә изге һәм файдалы икән дигән сорауга җавап эзләп шөбһәле уй-кичерешләргә бата. Үзенең икеләнүгә, шикләнүгә корылган эчтәлеге һәм өслүбе белән әсәр борынгы грек фәлсәфәсендә һәм Шәрекъ Ренессанс шагыйрьләре Мәгарри, Хәйям, Хафизның гыйсьянчылык поэзиясендә күзәтелгән ышанмаучылыкны—скептик карашларны хәтерләтә.

Габдулла Тукай—бөтен вөҗүде белән Алланың барлыгын һәм Берлеген таныган шагыйрь. "Золым" шигырендәге скептицизм һәм тәнкыйтькә карап, алда искәрткәнебезчә, Тукай әт-Тәүхидне кабул итмәгән икән дигән нәтиҗә ясарга ярамый. Шуны да искәртергә кирәк: илаһият гыйльме белән дини фәлсәфә тәнгәл түгелләр. Алар үзара никадәр генә тыгыз үрелсәләр дә, һәрберенең үзенә генә хас өйрәнү объекты, үз проблемалары бар.

Татар тормышын алгарышка илтүдә Тукай дингә зур өметләр баглаган. Г.Ибраһимов язганча, аңа "тәрәккъыйнең дә (алга китүнең дә), тәдәннинең дә (артка тәгәрәүнең дә) якүнә (төп) сәбәбе дин булып күренгән" (Әсәрләр.—5 том.—120 б.). XX гасыр башы татар зыялылары арасында кин таралыш алган, теләктәшлек тапкан дини ислахчылык хәрәкәте һәм бу хактагы җитди хезмәтләр Тукай иҗатын да читләтеп үтмәгән. Габдулла Бубыйның дингә үзгәрешләр кертү идеясен яклаган "Хакыйкать, яхуд Тугърылык" исемле фәлсәфи хезмәтләр циклы шагыйрьгә аеруча зур йогынты ясаган. Бу фикерне раслап, Г. Ибраһимов болай ди: "Г.Бубыйның "Хакыйкать"ләрендә шул, шагыйрьдә шул иде" (Әсәрләр.—5 том.—121 б.).

"Золым" шигыренә беркадәр генә шәрехләр биргәч тә, Тукайга Габдулла Бубыйдан тыш, башка дини реформаторларның, аеруча Муса Бигиев хезмәтләренең һәм Шәрекъ Ренессанс шагыйрьләренең тәэсире тирән эз калдырганлыгын кабат ассызыклап үтәсе килә.

Дин белән гавамның үзара бәйләнышын фәлсәфи уйланулар һәм бик тә тәэсирле риторик эндәш-мөрәҗәгать, сорау-җаваплар рәвешендә чагылдырган, фәкыйрьләрнең аһ-зарларын, сыкрау-сызлануларын, инрәүләрен ишеттергән "Золым" шигыре—экзистенциаль эчтәлекле тәнкыйди реализм әсәре. Шигырь Тукайның шул ук 1911 елда Корбан гаете унае белән язылган, Идел буендагы ачлык афәтләрен тасвирлаган, романтик контрастларга корылган "Көзге җилләр" шигыре белән дә аваздаш. Анда да шагыйрь дини гореф-гадәтләрне, йола-ритуалларны үтәүгә бәйле рәвештә: "Тилмереп торса бу ачлар, безгә бәйрәмнән ни ямь?!" дигән сорауны куйган иде.

Төрле социаль катлам кешеләренең белем дәрәҗәләренә, һөнәри һәм шәхси мәнфәгатьләренә бәйле рәвештә гыйбадәт кылу, намаз укуның сыйфаты бик тә түбән, ихлассыз, ялган диндарлык киеменә төрелеп башкарылуы турында Габдулла Тукай "Дин вә гавам" шигырендә дә (1912) яза. Аныңча, мәсҗедләрдә бер тыныш та Коръән сүзен, намаз рәтен белмәгән агайларның "кем ятар да, кем торыр" дип, "тонган күз"ләре белән башкаларга ияреп кенә бөгелү-сыгылулары, яисә базардагы алыш-биреш һәм тиреләрдән табыш алу турында гына уйлаган сәүдәгәрнең, тәкъва булып хаҗилар күзенә күренер өчен генә Алла йортына кереп чыгуы һәм дә анда, ачлы-туклы яшәгән мәдрәсә шәкертләренең бүген кайда, кемдә аш бар икән дип иснәнеп, "Коръән вату"лары ислам тәгълиматына зур зыян сала, динне "иске, аварга торгучы чергән дивар"га әвереләдерә. Шагыйрь фикеренчә, мона гаепләләр

иман агачының башына оя корган, аны корыткан "каргалар", ягъни җаһил руханилар.

* * *

Дин белән бәйле ритуалларның, гореф-гадәтләрнең нинди фәлсәфи эчтәлектә булу һәм аларны гамәли яктан ничек башкарылырга тиешлек мәсьәләсе мәдәни барыштагы күчеш-үзгәреш дәверләренең һәркайсында диярлек калкып чыккан. Ерак Багдадтан Идел буе Болгарстанына Ибн Фадлан илчелеге килгәндә дә (922) дини йолаларны ничек үтәү, мәсәлән, азанны ничек әйтү мәсьәләсенә игътибар ителгән. XIX гасырның икенче яртысыннан—Каюм Насыйрилардан, Шиһабетдин Мәрҗанилардан башланып киткән уяну дәвере XX гасыр башында Габдулла Тукайлар, Гаяз Исхакыйлар заманында, шаулап-гөрләп үткән күп ермаклы язгы ташудан, Яңарыш хәрәкәте булып үсеп китә. Бу алгарышка омтылыш беренче чиратта җәдитчеләр белән кадимчеләр тартышы рәвешен ала; борынгы голямалар—сәләфләр кебек һәр яңалыкка рөхсәт юк дигән мөһер суккан тәкълидчелекне канун дип санаган дин әһелләре тәнкыйть утына тотыла. Кадимчелек тарафдарларының "Фәлән сәләф фәлән әйткән, фәлән бул" дигән дини фикерләүдәге коллык тозагыннан "хаким гакыл вә хөр гакыл" ярдәмендә котылырга һәм иҗтиһад ишекләрен ачарга теләү омтылышы Габдулла Тукайның "Шиһаб хәзрәт" (1913) шигырендә аеруча үткер һәм тулы чагылыш тапты. Моның белән ул дини ислахчылык фикере үсешенә һәм тарихына үзеннән өлеш кертте.

Дәһрилек белән сугарылган совет чоры үтеп, дин халыкка әйләнеп кайткач та, XX гасырның азагы—XXI йөз башында Коръән тәгълиматын ничек аңлау, дини йолаларны ничек үтәү мәсьәләсе кабат актуаль яңгыраш алды. Татар вакытлы матбугаты битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында Коръән тәгълиматының асылын ничек шәрехләү, дини йолаларны ничек үтәү кирәклеге турында даими рәвештә калкып чыккан мәсьәләләр, төрле мәзһәбләр, евроислам, аеруча дин сакчыларының әхлакый сыйфатлары, белем дәрәҗәләре ничек булырга тиешлек турындагы бәхәсләр менә шул хакта сөйли.

Вакыт агышы һәм заман таләпләре басымы белән зарурият рәвешендә килеп туган ислам фәлсәфәсендәге һәм дини йолаларны үтәүдәге искергән традицияләрне, торгынлыкны кискен тәнкыйтьләү мөселманнарда гына түгел, башка конфессияләрдә дә еш кабатланып торган һәм тора. Тәнкыйть ярдәмендә динне заманга, халык тормышына ярашлы үзгәртергә тырышу күренеше башлыча кавемнәр, милләтләр иҗтимагый һәм рухи яшәешендә зур Яңарыш хәрәкәте алдында торганда күзәтелә. Чөнки ничек кенә мәгънийуннар—материалистлар булып күренергә тырышмыйк, дөньяви Яңарыш иң элек дини Яңарыштан башлана, андагы кыйммәтләрне кеше рухын иманга кайтарып, камиллеккә юнәлтүдән тамырлана.

**Резеда ГАНИЕВА**



Фәнис
Яруллин

# БЕР НӘРСӘ ДӘ БУЛМЫЙ МӘҢГЕЛЕК

* * *

**Яшь чагында дуслар бик күп иде,
Уртак иде бөтен уебыз.
Кочаклашып урам ураганда
Күккә үрли иде җырыбыз.**

**Тыңлый иде кызлар тәрәз ачып:
Кайсыбызның тавышы көчлерәк?!
Без беләбез алар тыңлаганны,
Безнең өчен бары шул кирәк.**

**Кайчагында матур кызлар өчен
Бераз бәргәләшеп алсак та—
Дуслашабыз бик тиз арада без,
Ачу озак бармый яшь чакта.**

**Чөнки әле җаннар керләнмәгән,
Бөтенебез әле бер төсле.
Киемнәр дә затлы түгел, ләкин
Яшь чагында барсы килешле.**

**Күңелебездә һичбер хөсетлек юк,
Бер-беребездән нигә көнләшик?!
Маллар да юк безнең, даннар да юк,
Бөтен байлыгыбыз шул яшьлек!**

**Бер учакка бәрәңгеләр күмдек,
Бер учакка җыелып җылындык.
Җил-давыллар бәрсә йөзебезгә,
Бер-беребезгә ныграк сыендык.**

Фәнис ЯРУЛЛИН (1938) — *Татарстанның халык шагыйре, прозаик, драматург, публицист, күпсанлы китаплар, шул исәптән биш томлык "Сайланма әсәрләр" (2004) авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Еллар үтте, без дә үзгәрештек,
Тигезсезлек керде арага.
Кем баеды, кемдер фәкыйрьләнде.
Кемдер түрә булды калада.

Еллар белән җырлар үзгәрделәр,
Һәрберебезнең хәзер үз җыры.
Әкрен-әкрен сиздермичә генә
Өзелә барды дуслык чылбыры.

Бергәләшеп учак ягар өчен
Вакыт та юк хәзер, теләк тә.
Бөгәрләнеп яткан елан кебек
Бер салкынлык ята йөрәктә.

Бер нәрсә дә мәңге түгел икән,
Тормыш тора безне үзгәртеп:
Арба тарткан ярлы дустын—байлар
Машинадан кала күзәтеп...

## Ике юл

Зур чатта ике юл,
Берсе киң һәм шома.
Киң юлны тутырып
Агыла машина.

Машина эчендә
Бик кәттә егетләр.
Сөяркә - җанашлар
Хур кызы кебекләр!

Ашыга һәммәсе
Тиз-тиз—тизерәк!
Иң яхшы урыннар
Барсына да кирәк.

Узышып баралар
Бу атсыз арбалар.
Күбесе бәрелеп
Канауга авалар.

Сүгенә ауганнар
Һәм артта калганнар.
Сөенә һәммәсен
Тик уза алганнар.

Икенче юл башка—
Үләнле тар сукмак.
Монда гел карт-коры
Ял итә еш туктап.

Шулай да хәлсезләр
Көтмәстән авалар.
Андыйны юлдашлар
Күтәреп алалар.

Зур юл да, сукмак та
Баралар бер якка.
Максатлар бер генә:
Әләгү... оҗмахка.

* * *

Мин беләмен дошманнарым барын,
Каһәрләмим ләкин аларны.
Һәрбер кеше сөенеп күзәтми бит
Алга бара торган атларны.

Егылуын, абынуын тели
Күңеле тарлар—яхшы атларның.
Ул егылса алга чыгуы бар
Көч-хәл белән барган чаптарның.

Беләм, тормыш сабан туе түгел,
Ярышмыйбыз чыгып мәйданга.
Тик ниндидер бер көнчелек яши
Сиздермәскә тырышып күп җанда.

Ул йокларга мөмкин озак-озак,
Уянмаска мөмкин һичкайчан.
Камчы булып үрелми ул сиңа ,
Томырылып алга чапмасаң.

Кайнар канны тыеп буламыни,
Камчы канатса да йөзеңне—
Узасың син күкләр юлы аша
Айга салып тояк эзеңне.

Ә дошманнар була икән—булсын,
Аларның да булуы кирәкле.
Алар бетсә, кем ярсытып торыр,
Кем камчылап торыр йөрәкне!

## Болыннар булырлар чәчәкле

Чәчебез чәчләргә бәйләнгән,
Башыбыз сөюдән әйләнгән.
Нигә соң, нигә соң куркабыз
Язмышны язмышка бәйләүдән?

Тормышның һәр көне—зур байлык,
Байлыкны кадерлик, югалтмыйк.
Гөл булып үсик тә тауларда
Тирбәлик төннәрен айларда.

Йолдызлар сибәрбез юлларга,
Гашыйклар чыгарлар җырга.
Дөньяны матурлап бизәрбез
Гаҗәеп тылсымлы нурларга.

Болыннар булырлар чәчәкле,
Аланнар булырлар җиләкле.
Эләрбез күкләрнең түренә
Сөюдән тулышкан йөрәкне.

* * *

Һәркөн йөрим уйлар урманында,
Куера бара уйлар урманы.
Кергән чакта сукмак табылса да
Чыгар өчен булмый юллары.

* * *

Кемдер туа тансык булып,
Кемдер—артык булып...

* * *

Кошларга канат биргән,
Кешегә акыл биргән:
Теләсәң акылың белән
Күкләргә атыл, дигән.

* * *

—Нигә очынасың болай,
Нәрсә булды, күңелем?
—Шатлыгым шул: буш үтмәде
Минем бүгенге көнем.

* * *

Канатлылар оча, дибез,
Оча ерак җирләргә;
Канатсызлар да «очалар»—
Сүз әйтсә түрәләргә.

* * *

Биегрәк менә барган саен
Кечерәя бара кешеләр.
Алар бары тормыш китабының
Бер ноктасы гына төслеләр.

* * *

Ташкыннар булып агыла,
Дөньяны баса буш сүз.
Буш сүзне алучылар күп—
Чөнки бәясе очсыз.

* * *

Кемдер алыштыра исемен,
Оҗмахка керер өчен.
Тик... куып чыгара алмый
Күңелендәге иблисен.

* * *

Чумдым тирән уйларга,
Баскычлар юк чыгарга;
Гомеремнең очын эзлим
Кулларыма урарга.

* * *

Көз үзенең кулъяулыгын
Каен ботагына элеп киткән.
Җилфер-җилфер итә бу кулъяулык
«Онытмагыз көзне!»—дия микән?

* * *

Уйлар буранында адаштым,
Юл табалмый озак маташтым.
Ул юл булган икән янымда—
Яшәү уты йөрткән җанымда.

* * *

Бик еш атыла йолдызлар,
Әллә күктә дә сугыш?—
Яшен шары шартласа да
Кысылып куя сулыш.

* * *

Әллә көлү, әллә елау,
Ишетелә нинди өннәр?
Әллә туалмый ятамы
Киләчәк матур көннәр?

* * *

«Елаганың бармы?»—диләр,
Елап кемне куркытыйм?
Аны да елап үткәрсәң—
Гомер бит ул бер йотым.

* * *

Биек-биектән кошлар очып бара,
Ишетелми канат тавышлары.
Язылып кала бары офыкларга
Җаннарында йөрткән язмышлары.

Укый гына белү кирәк безгә:
Ни язылган анда—күк йөзенә.
Күкләр серле—анда ниләр барын
Күрә алмый маңгай күзе генә...

## Нилектән

Кешеләр бер-берсен яратмый,
Нилектән икән бу, нилектән?
Замана тудырган чирме бу,
Әллә соң калганмы электән?!

Бу яман гадәтнең тамыры
Дым ала ниндирәк инештән?
Һәм күккә язылды шундый сүз:
—Җаннарга яшеренгән иблистән.

## Булмый кичереп

Кичереп була авыр кайгыларны,
Кичерүе булса да читен:
Кайгылардан өстен итә сине
Киләчәккә булган өметең.

Кемдер сине батырырга теләп
Упкыннарга таба этәрә.
Калкып чыккач кичерәсең аны,
Җиңүдән соң күңел нечкәрә.

Тормышта бит була төрле хәлләр:
Юлда ташлап китә юлдашың.
Карурманда юлны табар өчен
Бер уч нуры җитә кояшның.

Кичерәсең тагын юлдашыңны,
Ташласа да авыр минутта.
Адашмыйча чыга алган кеше
Ул мәкерне инде оныта.

Саф кешенең күңеле олы була,
Кичерә ала хәтта ялганны.
Кичерә алуы белән бәхетле ул,
Кичерүе белән саф җанлы.

Бу дөньяда бары бер нәрсәне—
Хыянәтне булмый кичереп:
Мәхәббәттә булган хыянәтләр
Гел агуын тора эчереп...

*2005*

Заһид
Мәхмүди

# ҺӘРКЕМНЕҢ ҮЗ ЮЛЫ

РОМАН

## Саташу

Әхәт Казанга кичке сәгать өчләр тирәсендә килеп төште. Көн эссе. Асфальт мунча ташы кебек кызган. Машина тотып туп-туры Эчке эшләр министрлыгына китте. Трамвай белән өлгермәячәк, министр сәгать өчтән дүрткә кадәр генә кабул итә.

Түрә аны дүрт тулып ун минутта гына кабул итте. Күрәсен, вакыты бар иде әле.

Карап торышка, бик сөйкемле кеше булып күренә. Спорт белән дә шөгыльләнә, ахрысы. Буй-сынга таза, гәүдәсе төз, мускуллары костюм аша сизелеп тора.

—Күпме булдыгыз Чечняда?—диде ул, утырган кәнәфиендә башын артка ташлап. Арган күзләре челт-челт килә.

—Бер ел, иптәш генерал.

—Документларыгызны карап чыктым, Гафуров. Нигә судны ахырына кадәр житкермәдегез?—диде ул, өстәлдә бармакларын биетеп.—Сезнең жинаять эшегез дәлилләр житмәү аркасында вакытлыча гына ябылган дип санала. Ә бу әле, закон күзлегеннән караганда, сезнең гаепсез булуыгызны исбат итү дигән сүз түгел.

Министр янынннан тәмам изелеп, кыйналып чыкты Әхәт. Болай булгач, ул инде беркайчан да милициядә эшли алмаячак. Чөнки документлары пычранган. Судны махсус рәвештә ахырына кадәр житкермәделәр инде. Юкса, аның яклы дәлилләр кирәгеннән артык күп иде.

Әхәт кайгыдан беренче очраган рюмочныйда ук литрга якын аракы эчте. Янына килеп баскан ике сукбай хатынны да сыйлады. Өстәл өсте кипкән балык калдыклары, сыра, пластик стаканнар белән тулды. Йөзләре шешенеп, тешләре коелып беткән бу карт чәчбиләр яшь вакытта матур булганга охшый. Бозыклык юлында йөри-йөри шундый хәлгә төшкәннәрдер. Әхәтнең кесәсендә акча барлыгын беләләр, үзләренә алып кайтып йоклатырга маташалар.

—Ну что, сладенький, пойдем?—диде Лида исемлесе, аны култыклап.

—Беркая да бармыйм мин,—Әхәт юләр түгел, аларга ияреп китсә, аны йоклап китүгә үк чишендерәчәкләр.—Иди отсюда!

—О, какой грубый!—диде икенчесе, авызындагы балыкны суырып. Аннары бокал төбендәге сыраны кабып куйды.—Давай-давай, а то тебя менты заберут. Вишь, сколько их здесь ходит!

Әхәт милиционерларны исереклеге белән генә абайламаган икән.

*Ахыры. Башы журналыбызның 3 нче санында.*

—Мин үзем милиц...—Терсәге турысында торган бокал «шалт» итеп идәнгә төшеп ватылды. Рюмочныйдагылар барысы да шул якка борылды.

Игътибарны үзенә җәлеп итте инде. Өстәл янына шундук ике милиционер килеп басты.

—Хулиганим? Ваши документы, гражданин!

—Какие документы?—Әхәт күтәрелеп милиционерга карады. Сержант. Тәбәнәк кенә буйлы. Кайдадыр күргәне бар.

—Бәрәч, Гафуров ич бу!—Милиционер авызын ерып кулын аның җилкәсенә куйды.—Таныйсыңмы мине?

Әхәт аны искә төшерергә тырышып карады, ләкин булдыра алмады.

—Кем син?

—Во, дает!—сержант кычкырып көлеп җибәрде.—Милиция мәктәбен хәтерләмисеңмени? Кызлар артыннан бергә чаптык бит.

—Адаш?—Әхәт айнып киткәндәй булды.—Менә сина мә! Нишләп йөрисең монда?

—Безнеке билгеле инде, тәртип саклап йөрибез. Ә син үзең нишләп йөрисең? Каян таптың бу хатыннарны?

—Мин аларны сыйладым гына.

Сержант авыз ачып калган чәчбиләргә таба борылды:

—А ну, быстро ноги!

Аларны рюмочныйдан чыгарып җибәргәч, адашы Әхәтне култыклап алды.

—Әйдә, кайтарып куябыз... Кайда яшисең?

—Энекәштә. Кольцодан ерак түгел.

Милиционерлар аны култыклап машинага өстерәделәр. Тау белән тау гына очрашмый икән шул. Адаш белән бик дус иде алар. Баулыдан иде ул. Әхәт Сәрия белән танышкан көнне дә Горький паркына бергә бардылар.

—Хатының ни хәлләрдә?—дип сорады адаш, машинага утыргач.

—Син аны хәтерлисеңмени?

Сержант көлеп куйды.

—Хәтерлим, кәнишне. Мин аның иптәш кызына өйләндем бит. Беләсең инде син моны, исереклегең белән генә исенә төшерә алмыйсың. Ике балабыз үсеп килә. Берсе малай, берсе кыз. Синеке ничәү?

—Кыз гына бар.

—Син, адаш, бер дә болай эчми идең кебек.

—Сәбәбе бар, димәк.

—Милициядә эшлисеңме соң әле?

—Юк.

—Нигә?

—Кудылар.

—ЧП килеп чыкты, ызначит?

—Бер каракны кыйнауда гаепләделәр.

—Гаҗәпләнмим, туган. Безне бөтен нәрсәдә дә гаепләргә мөмкиннәр. Узган елны мин син утырган рюмочныйда аунап яткан бер исерекне айнытыкчка тапшырган идем. Баксаң, китереп җиткергәнче теге үлеп киткән. Миңа кадәр кыйнаган булганнар. Туганнары гаепне минем өскә өя башлады. Көчкә котылдым, малай. Аны кыйнаганнарын бармен күреп торган икән... Кольцога җиттек. Сиңа кай тирәгә?

—Ерганак урамына... Кырыгынчы йорт.

Кәбир өйдә юк иде. Әхәт үзенең адашы белән кочаклашып аерылышты. Тегесе, бер килеп чыгармын әле, дип вәгъдә дә бирде.

Инде кичке сәгать тугыз. Кая барырга? Иттакый ага нихәлдә икән? Әхәт инде бераз айный башлаган иде, куып чыгармас әле.

... Ишекне Иттакый ага үзе ачты. Башта ул Әхәтне танымыйчарак торды.

Калын күзлеге аша текәлеп карап торгач, монсу гына әйтте:

—Йә, хода, Кәбирнең энесе бит син... Исемеңне онытып җибәргәнмен.

—Әхәт исемле мин.

—Әйе шул, син гафу итә күр инде мине. Картлык—шатлык түгел. Уз, әйдә!

Кухняга узгач, Иттакый ага чәй кайнатырга куйды.

—Йә, балакаем, нихәлләрең бар?—диде ул, ниһаять, урындыкка утырып.

—Ярыйсы гына болай. Ә сезнең остаханәгез кайда, Иттакый ага?

—Юк инде минем остаханәм,—картның күзләренә яшь килеп тыгылды.—Инсульт кичердем бит. Зиһен бетте. Куллар да калтырый башлады. Бөтен нәрсәне подвалга төшереп бикләдем.

—Алай икән... Скрипкалар ясамыйсыз инде?.. Ә сез бүләк иткәнне мин кадерләп саклыйм. Чечняда булдым бит мин, Иттакый ага. Сезнең скрипканы хәзер Грозный хәрабәләре дә белә.

—Кәбир әйткән иде. Исән-сау кайтуың әйбәт булган, балакаем.

Карт чәй ясаган арада Әхәт үзенең биштәреннән скрипканы чыгарды.

—Танырсызмы? Әр-яна!

Иттакый ага скрипканы кулына алды.

—Ие шул, бүген ясаган кебек. Рәхмәт. Уйнап җибәр әле «Урман кызы»ын!

Әхәт скрипкада уйный башлауга, карт ике терсәге белән өстәлгә таянып битен каплады. Нәрсә турында уйлый. Яшьлегенме?

Син кем, белмим, синең шаян күзләр,
Нигә, белмим, шулай багалар?

Үксеп елый ук башлады. Димәк, Иттакый ага да хәзер бәхетсез кеше. Әллә теге вакытта әйткән үз поездына соңга калганга пошынамы? Дөнья хәзер икенче, кешеләр дә бөтенләй башка. Ә ул алар арасында бер ятим кебек кенә. Аның чорында булган дуслык, татулык, ярдәмчеллек, күңел матурлыгы мәңгегә үткәннәрдә калды микәнни? Шул рәвешле киләчәккә атлап барган адәм баласы үзенен ятимлегенә, бетүенә, ахырына ашыга микәнни? Бу йортта инде бүтән скрипка ясамыйлар. Скрипка ясамый икән, оста дөньяда яшәүдән туктады дигән сүз. Менә аның чын ятимлеге нәрсәдә! Ул аерылмас дусты скрипка белән саубуллашкан. Үзенең моның, җанын индерә торган кадерле скрипкалары белән саубуллашкан. Авыр бу саубуллашу. Соңгысы бу саубуллашуның! И, адәм баласы! Үткәннәр белән киләчәк арасында яшәп, син иң матур мизгелләрне эләктереп калдырырга теләгәндәй, аларны тасмага яздырып аласың, фоторәсемгә, киноглı төшерәсең. Әмма ул мизгелләр дә тора-бара кеше кебек саргая башлый. Бүгенгене үткәннәрдә калды дип сана, киләчәгең дә барыбер үткәннәрдә калачак. Тотып алып, урлап калып булмый мизгелләрне. Вакыт кына һәрнәрсәгә хуҗа, аңа туктарга ярамый, ул безнең барыбызны да тарих чүплегенә ташлап, ашыгып чапкан поезд кебек һаман алга ашкына. Аңа туктарга ярамый, юкса, ул үзе дә безгә охшап калачак.

Скрипка тынды. Иттакый ага һаман елап утыра.

—Чыннан да, җаны бар бу сазның,—диде ул, үз-үзе белән сөйләшкәндәй, ярым пышылдап.

—Сазның?

—Төркиләрдә бөтен кыллы уен коралларын да “саз” дип атаганнар.

—Саз...—Әхәт кулындагы скрипкага карап алды.—Матур яңгырый.

—Телебез бай безнең, онытып кына барабыз.

—Иттакый ага, сез бәхетлеме?

—Бәхетсез мин, балакаем. Чөнки бөтен белгәннәрем үзем белән китеп бара.

—Мин дә бәхетсез,—диде Әхәт, кашын жимереп.—Гомерем инде үтеп бара, ә үземнән соң сокланып искә алырдай нәрсә юк.

Әхәт Иттакый агаларда озак утырмады. Алардан чыккач, ул поездда үзенен адресын биреп калдырган маржа янына китмәкче булды. Ләкин кәгазь кайдадыр төшеп калган. Шул рәвешле маржа әрәм булды.

Төнге унбер. Фронтовик алпан-тилпән Ерганак урамына юл тотты.

Кәбир әле кайтмаган. Ишектә коллы йозак эленеп тора. Аны куен кенәгәсенә язып куйган иде Әхәт. Кодны жыеп йозакны ачкач, ул уйлап куйды: « Ничек караклар керми икән өенә? Бу йозакны ватып та була бит. Әчке йозак куйса, караклар өйдә кеше бармы, юкмы икәнен дә белә алмас иде».

Өйгә кергә, ул кунак бүлмәсендәге иске кызыл диванга сузылып ятты. Ята торгач, йокыга киткәнен дә сизми калды.

* * *

... Бөек прокуратор Понтий Пилат бакчасы. Арттарак Рим императоры жирле идарә башлыгынын мәһабәт колонналар белән бизәлгән ике катлы ак сарае күренеп тора. Һәр тарафта ожмах кошлары сайрый, борынга клумбаларда үсеп утырган ал, кызыл, сары, зәнгәр чәчәкләрнен хуш исе бөркелә. Кояшнын күтәрелеп кенә килгән чагы. Һәр йөз адым саен басып торган горур Рим яугирләренен күзләре дә йомылмый. Бу сакчылар императорнын иудейләр наместнигы иминлеге өчен жавап бирәләр.

Әхәт—Понтий Пилат. Ул Гайсә белән Рим императорларынын бюстлары тезелеп киткән аллея буйлап әңгәмә корып йөри.

—Гайсә, синен көндәшләрен күп. Син Иерусалимга ишәккә атланып кергәч, яһүдләр синедрионы жыен жыйды. Алар сине хөкемгә тартырга уйлый. Синен әле качып котылырга вакытын бар.

—Беләм. Иуда, утыз көмеш тәнкәгә сатылып, мине синедрион әһелләре кулына тапшырачак.—Гайсә тыныч, анын озын, таза гәүдәсе хәтта тауны чыдатырлык кебек.—Ә Иерусалимга ишәккә атланып керүем белән мин тынычлык сөюемне генә күрсәтергә теләгән идем.

—Ул бит синен шәкертен.

—Аллаһы аны гафу итсен.

—Син үзенне һаман да Аллаһынын улы дип саныйсынмы?

—Әйе, бөек прокуратор, Ул мине жиргә адәм балаларын акылына китерергә, аларнын кылган гөнаһыларын юарга жибәрде.

—Мин Тиберийга синен турыда хат язып жибәрдем. Мактадым. Ләкин ул сине фетнәче дип саный.

—Күктәге илаһи Атабыз аны да гафу итсен.

—Бел, пасха алдыннан сине кулга алачаклар. Бер ай вакытын калып бара, пәйгамбәр. Иудейлар синедрионы сине тәрегә кадаклатырга тели.

—Калакласыннар, мин алардан курыкмыйм.

—Мин сине коткара алмаячакмын, Гайсә.

—Аллаһы сезне гафу итсен.

Яугирләр Гайсәне урамга озатып куйдылар. Әхәт—Понтий Пилат. Ул Гайсәгә аны коткарачагын юри әйтмәде. Иман ныклыгын тикшереп карарга теләде. Ә сатлык Иуданы Гайсә тәрегә кадаклангач ук, анын шымчылары асып куячак. Халык Иуда үзе асылынган дип уйларга тиеш. А, Гайсә, синен бөек пәйгамбәр булуына Понтий Пилат тамчы да шикләнми. Газиз халкын сине атаклы башкисәр Вараамга караганда да күбрәк күрә алмый. Халык... Кара сарык көтүе кебек ул. Надан, хөсетле, мескен, түбән.

Бөек прокуратор әле бакчада. Хәзер аңа йөзем жимешеннән ясалган шәраб йотып бераз ял итеп алырга кирәк. Ләкин башта ул скрипка ясау остасы Итакины күрергә тиеш.

Прокуратор җинелчә генә кул чабып ала. Сакчылар башлыгы Антонио инде аның янында. Батыр Антонио! Узган ел, герман кабиләләрен тураганда, ул бер күзен югалткан. Аның легионыннан кырык кеше генә исән калган, дип сөйләделәр. Император Тиберий аңа үзе хәмер эчә торган алтын касәне бүләк итте..

—Нәрсә телисез, бөек прокуратор?

—Вифлиемнан оста килеп җиттеме?

—Ул монда.

—Китерегез аны.

Менә нинди икән ул Вифлиемда яшәүче атаклы оста! Кечкенә генә буйлы, зәп-зәңгәр күзле. Чыгышы белән грек. Өстендәге плащы инде тәмам искереп, тузып, тишелеп беткән. Шундый мәшһүр шәхес, үзе хәерче. Ул ясаган скрипкаларның тавышы көн дә император сараенда яңгырый. Нигә хәерче? Мөгаен, бөек кеше байлыкка мохтаҗ түгелдер. Ләкин нәрсәдәндер курка кебек.

—Тынычлан, Итаки,—диде ул, эре генә кыланып.—Мин сине хөкем итәргә чакырмадым.

—Ә нәрсәгә чакырдыгыз?—Оста—горур, шөбһәләнсә дә, сиздермәскә тырыша.

—Миңа яңа скрипка кирәк. Адәм баласы кебек елый торган скрипка кирәк.

—Ясарбыз, бөек прокуратор. Бер айдан ул сезнең хозурыгызда булачак.

—Син көләсең мәллә миннән?.. Бер ай!

—Адәм баласы кебек елый торган скрипка ясар өчен агачны елатырга кирәк.

—Ничек, ничек?.. Агачны елатырга?.. Беренче тапкыр ишетәм.— Прокураторның күзләрендә кызыксыну очкыны кабынып алды.—Минем агач елаганны күрәсем килә.

—Алайса, сез бүген минем белән Иерусалим читендәге урманга барырга тиешсез.

Бөек прокуратор риза булды, шундук атларны җигәргә кушты.

... Урман авызына җиткәч, Понтий Пилат авырта башлаган билен уа-уа, иренеп кенә ике тәгәрмәчле арбадан төште. Алда чаптырып барган ике яугир дә алтынсу төстәге бакыр очлам башлыкларында кояш нурларын уйнатып, матур, көчле кара атларын туктаттылар. Итаки һәм аның ярдәмчеләре утырган җигүле атны көтәләр. Оста шактый артта калган.

Ниһаять, ул да артында тузан өере калдырып, бөек прокуратор басып торган җиргә килеп туктады.

Урманга керделәр. Бик озак сайлана торгач, Итаки үзенең ярдәмчеләренә әмер бирде:

—Менә бу җиләк агачын тунарга.

Агач биек һәм шактый юан. Җир җиләгенә охшаган җимешләре җиргә кадәр асылынып тора.

Ярдәмчеләр балта белән агачны каезларга кереште.

Понтий Пилат көлеп әйтте:

—Бу агачны кисеп каезлау җинелрәк булмасмы?

—Менә шунда шул бөтен хикмәт,—диде оста, серле елмаеп.—Агачны елату өчен тере килеш каезларга кирәк. Газап күрмәгән адәм скрипка тавышына елый алмаган кебек, газап күрмәгән агач та адәмне елата алмый. Яфраклары соңгы суын суырып бетергәч, без аны кисәчәкбез.

Каезладылар агачны, кызганмыйча каезладылар. Моны күзәтеп торган бөек прокуратор уйга калды. «Адәм баласы да менә шулай бер-берсен каезлый,—дип уйлады ул.—Бичара агач, шәп скрипка чыгачак аннан. Ул үзенең елавы белән барысының да күзләреннән яшь агызачак».

Агач шәп-шәрә калды. Нибары өске өлешендәге яшел ботаклары гына жиләк тәлгәшләрен асылындырып жиллә тирбәлә.

—Димәк, скрипка бер айдан әзер булачак?- дип сорады Понтий Пилат.

—Пасха алдыннан, хөкемдар.

—Кара аны, сонга калсан, башынны кистерәчәкмен!

Нәкъ шул урында Әхәт уянып китте. Шактый макмыр төшкән. Ул ялан тәпи килеш кенә өялдына чыгып, андагы кисмәктән тустаган белән су алып эчте.

Тышта чыпчыклар чыркылдый, күгәрченнәр гөр-гөр килә. Иртәнге сәгать дүртләр тирәсе генә әле. Табигатьнең йокыдан уяна башлаган чагы.

Әхәт янадан юрган астына кереп ятты. Төшендә күргәннәрне тагын бер кат исенә төшереп, уйга калды. Кирәк бит, Әхәт Гайсә белән әңгәмә кора! Гел чынга охшаган төш. Каезланган жиләк агачы... Жир йөзендә мондый матур агач барлыгын белми дә иде ул. Кәбир дә кайтмый ичмаса. Кайда йөри? Йөрсә йөрер шунда, егет кеше бит, ана кайтмау килешә. Кызлар артыннан чаба торгандыр. Исән генә булсын.

Баш авыртуы көчәйгәннән-көчәя барды. Колак тирәсендә нәрсәдер зырылдап очкан кебек.

Чү! Кемдер эндәшә... Кәбир тавышы түгел. Әхәт күзләрен ачып як-ягына каранып алды. Тәрәзәдән озын бөдрә чәчле, кара сакаллы адәм карап тора. Яше утыз-утыз бишләрдә булыр.

—Нәрсә кирәк?—дип кычкырды Әхәт, ачуы чыгып, һәм кулын авырткан башына куйды... Тәрәзәдән караганчы, ишек шакылдатса ни була?

Сикереп торып тәрәзәгә күз салды. Сәер адәм. Кыйнаганнармы? Йөзеннән әллә пычрак тир, әллә кан саркый.

—А, бөек прокуратор!

Нәрсә? Нинди прокуратор? Төштә күрде бит ул аны. Әллә берәрсе шаяртамы?

—Кем син?

—Сез газаплы үлемгә хөкем иткән Гайсә мин, бөек прокуратор.

Әхәт кычкырып көлеп жибәрде. Һы, чыннан да бөек прокуратор ич ул! Кайда хезмәтчеләр, тән сакчылары? Нәрсәдер буталды анын миендә. Әхәт иде ич ул... Күптән түгел Чечнядан кайтты...Чечня?.. Нинди Чечня?... Беренче тапкыр ишетә. Булмады ул беркайда да... Бер ай элек кенә Гайсә белән үз биләмәсендәге бакчада әңгәмә корып йөрде.

—Антонио!—дип акырды ул, галибанә тавыш белән.—Кая югалдыгыз, кәмшек танаулар?! Жәзага тартам барыгызны да!

Һәр тарафны куе томан төреп алды. Ул кайда? Колак пәрдәләрен сызлатып, елаган, ыңгырашкан, нәләт укыган тавышлар ишетелә.

Томан тарала... Йа Раббым! Иерусалим читендәге Гарәфә калкулыгында ул! Тән сакчылары беркая да китмәгән, баһадир, горур Антонио да анын янында басып тора. Каршыдагы өч баганага өч адәм кадакланган. Уртада—Гайсә. Аның битендә, кулларында, күкрәгендә, шәрә ботларында буй-буй булып агып кипкән кан эзләре. Бөтен тәне камчы белән сыргаланып беткән.

Пәйгамбәр күккә багып инәлеп кычкыра:

—И бөек атам, кичерә күр бу адәмнәрне!

Тирә-юньдә кара халык. Берәүләре көлә, икенчеләре башын жиргә орып елый. Якында гына йөзтүбән килеш яткан хатынның ташлы туфракны тырный-тырный тырнаклары төшкән. Ләкин ул авыртуны сизми, ыңгыраша-ыңгыраша туфракны ике кулы белән бер үзенә жыя, бер читкә этә.

Берәү Гайсәгә акыра:

—Атаң күктә булгач, нигә коткармый?

—Ха-ха-ха!

Шул сүзләрне генә көткәндәй, каты итеп жил исте. Мона кадәр аяз булган күктә кара болытлар пәйда булды.

—А, бөек атам!
Халык, бер-берсен таптап-изеп, кайсы кая кача башлады.
—Яшенле янгыр килә!
—Гайсәнең күктәге атасы бездән үч ала!
—Кичер безне, и, Аллаһы!
Понтий Пилат кына бернәрсәдән дә курыкмый.
—Антонио!
—Тыңлыйм, бөек прокуратор!
—Иуданы асып куйганыгызны кеше күрмәдеме?
—Юк, бөек прокуратор... Дөресен генә әйткәндә, ул без килеп җиткәнче үзе асылынган иде.
—Әйбәт булган. Сенидрион әһеле Иосифка әйт, бүген төнлә каравыл алышынганда Гайсәнең гәүдәсен баганадан төшереп, үзенә алып кайтсын. Мин аның янына иң яхшы табибләрне җибәрермен.
—Яхшы.
—Яхшы түгел шул. Тиешенчә җавап бир миңа!
Антонио үрә катып тагын җавап бирде:
—Үтәлер, бөек прокуратор!
—Карагыз аны, Гайсә үләргә тиеш түгел,—Понтий инде яшен уйнатып җиргә янгыр коя башлаган күк йөзенә күз салды.—Хәер, Аллаһы аны ярдәменнән ташламас.
... Понтий Пилат инде үз биләмәсендәге бакчада йөзем шәрабе эчеп утыра. Кәефсез. Кулында Итаки ясап биргән скрипка. Изге уен коралы бу. Адәм кебек елый. Тереләй тунадылар бит агачны.
Прокуратор грифта бармакларын йөгертеп ала. Күңелендә баганага кадакланган пәйгамбәр сурәте. Әкрен генә борын астыннан җыр суза:

Күктән көлгән адәм көлгә әверелер,
Җилкәй көлен чәчәр урларга.
И , Аллаһы, Рим да бер көн җимерелер,
Азык булыр кара бурларга...

Скрипка тынды. Понтий Пилатның күзләрендә яшь. Эчтән генә уйлый: «Аллаһы каршында саваплы эш эшләдем. Ләкин адәмнәр пәйгамбәрне Рим прокураторы коткарган дип уйламас. Алар әле гасырлар буена мине каһәрләр».
—Бөек прокуратор!—Антонио эндәшә.
—Нәрсә булды?
—Император Тиберийдан чапкын килде. Ул сезгә бик тә ашыгыч яшерен хәбәр калдырды.
—Нигә миңа үз куллары белән тапшырмады?
—Көнбатышта весготлар баш күтәргән, Иерусалимдагы легион башлыгы Кантарийга хәбәр белән чаптырды.
—Ярый, ачып укы!
—"Хәрби тәртип" буенча миңа бу хатны ачарга рөхсәт ителми, бөек прокуратор.
—Мин сиңа ачарга кушмыйм бит, укырга гына боерам. "Хәрби тәртип"тә яшерен хатны ачкан өчен үлем җәзасы каралса да, аны уку турында бер сүз дә әйтелмәгән.—Понтий Пилат мыскыллы елмаеп куйды.—Мескен империя, хәзер аның хәрби тәртибе генә түгел, законнары да чиле-пешле.
Антонио пакетны ачып император Тиберийның хатын укырга кереште:
Кадерле дустым!
Яшерен канцелярия синең Гайсә исемле фетнәче иудейны үлемнән коткаруың турында хәбәр итте. Шәхсән мин үзем бу әләккә ышанып бетмим.

Чөнки монда калэр син минем ин ышанычлы идарэчелэремнен берсе идең. Исендэ тот, бер айдан син Римда булырга тиеш. Сенат та сине түземсезлек белэн көтэ.

Хат шактый озын иде. Понтий Пилат Антониога, житте, дип кул изэде.

—Манка,—дип мыгырдады ул, тешен шыкырдатып.—Гайсэне бер генэ тапкыр күрсэ дэ, болай димэс иде ул. Анын аркасында мин Аллаһынын үзе тарафыннан жибэрелгэн пэйгамбэрнең изге канын агыздым. Тэрэгэ кадакланган гадэти кеше өч көндэ терелэ аламы? Юк! Сөнге уң як кабыргасыннан кереп сул як кабыргасыннан чыккан гадэти адэм үлмичэ кала аламы? Юк! Сенаттан курыкмыйм мин. Телэсэ нэрсэ эшлэсеннэр. Туйдырды мине бу эш. Адэм язмышлары белэн уйнап кара гөнаһыга чумып беттем. Инде, ичмасам, үлэр алдыннан булса да изгелек кылып яшэргэ кирэк.

Прокуратор скрипканы кулына алып тагын жырлый башлады:

О Цезарь, синең империяннең
Шанлы чаклары кайда?
Үткэннэрне сагынам мин күп чак,
Үлэсем килэ яуда.

—Абый! Абый, дим!—Кемдер Понтий Пилатнын аркасына төртэ.

Кемнең кодрэте житте! Антониомы?! Бөек прокуратор скрипка белэн кизэнмэкче булды, лэкин үзенең энесен күреп туктап калды. Кэбир! Кесарь аны империянең көнчыгышына легион башлыгы итеп жибэргэн иде. Кайтып житкэн, димэк.

—Исэн!—диде ул, аны кочаклап.—Утыр, йөзем шэрабеннэн авыз ит, юлда йончыгансыңдыр. Тиберий жибэргэн хатны укыйсың килэме?

—Нинди шэраб? Нинди Тиберий?—диде Кэбир, тэмам аптырап.

Әхэтнең күзлэре зурайган. Өстэлдэ һичнинди шэраб та, хат та юк.

—Тэртип бетте Рим империясендэ. Мин лыгырдап утырган арада тэн сакчылары бөтен шэрабемне урлап бетергэн! Асам барысын да!.. Антонио!

Башын-күзен аларткан абыйсы, өй буенча арлы-бирле йөренеп, авызыннан төкереклэр чэчэ-чэчэ сөйлэнүен дэвам итте:

—Нигэ Тиберий үзенең кайчан да булса мэңгелеккэ китэчэге турында уйламый икэн? Икегэ икене кушкач дүрт килеп чыккан кебек гап-гади хакыйкать, югыйсэ! Шуна жаным сызлый минем, энекэш. Үлем барыбер килэчэк. Колга да, түрэгэ дэ, императорга да килэчэк.

—Син авырыйсың, абый,—диде Кэбир, аны тынычландырырга тырышып.

Лэкин Әхэт тынычланмый, киресенчэ, ниндидер Антонионы эзлэп юлында очраган бөтен нэрсэне кыра башлады.

«Чечен синдромы,—дип уйлады хужа.—Дөресрэге, Рэсэй синдромы. Ычкынган абый!»

Кэбир өйдэн сиздермичэ генэ чыгып күршелэреннэн «ашыгыч ярдэм» машинасы чакыртты. Ярдэм тиз килеп житте. Кылыч дип белеп пычак болгап йөргэн Әхэтне таза медбратлар шундук бөклэп салды. Әхэткэ укол кададылар. Инде каршылык күрсэтэ алырлык хэлдэ булмаса да, ул дулаудан туктамады:

—Антонио!.. Хыянэт!... Фетнэ!!—дип акырды ул бар көченэ.

Медбратлар инде аны урамга алып чыгып бара. Такыр башлысы—кизү табиб икэн.

—Авыр очрак,—диде ул, Кэбирнең хэленэ кереп.—Аңлавымча, бу—абыегызмы?

—Әйе.

—Өйлэнгэнме?

—Бер баласы бар.

—Кайда яши?

—Шәмәрле бистәсендә.

Урамга чыктылар. Машина эченнән тавышы урманнарны тоткан Әхәтнең хурланып елаганы ишетелә:

—Рәхмәт сиңа, энекәш! Белмәдем мин синең Тиберий шымчысы икәнеңне. Карап тор, вакыты җиткәч, ул синең дә башыңны кисәчәк!

Ашыгыч ярдәм машинасы китеп баруга, Кәбир өйгә кереп абыйсына дигән кирәк-яракны пакетка тутыра башлады. «Менә сиңа, күрәселәрең булса,— дип уйлады ул, эче пошып.—Эше барып чыкмаган инде, стресстан ычкынган».

Рамиләдән генә кайтып килеше иде аның. Кичә Северный бистәсендә яшәүче бер эшмәкәр хатыннан арзан гына бәягә ак төстәге мебель гарнитуры алып кайттылар. Иртә беләнгә кадәр җыйдылар. Булачак кияү генә Галия белән төнге унбергә кадәр телевизор карап утырды. Эшкә ярамый икән шәһәр егете. Нәрсәсен ошатты аның Рамилә, һич кенә дә башына китерә алмый! Студент, имеш. Сөйләштереп карады инде, «Муму»ны Достоевский язган дип тартыша. Мөгаен, сессияләр вакытында да имтихан алучы укытучыларына акча түләп котыладыр. Югары уку йортларында хәзер шулай, «өчле»нең дә үз бәясе бар. Юридик факультетта уку өчен киң эрудицияле кеше булырга кирәк, ә Илсурның көн дә Рамиләләрдә ятып укырга нинди вакыты булсын? Авызында гел затлы тәмәке. Кәбир әнә гомере буе эшләп тә иң очсыз «Прима» тартып йөри. Сәерлеге дә бар егетнең. Матур гына йөри дә, йә балконга, йә урамга чыгып кергәч, лампочка кебек кызарган күзләре челт-челт итеп йомыла башлый. Бу турыда Рамиләгә дә әйтеп караган иде. Хатын, аллергиядән ул, Илсур хастаханәгә ятарга җыена, дип җавап бирде. Бәлки аллергиядәндер дә, әмма Илсурның дусты Рәдифнең күзләре дә гел кызарган була бит. Ул да ике көннең берендә шушында ята. Кайчан кермә, телефонда утыралар. Әйтерсең, нииндидер бер җитди эш кыралар. Гомумән, нәрсә генә булмасын, сырыктай егетләрнең Рамилә өендә җыелып ятуы бик ошап җитми иде Кәбиргә. Үз гаиләсе булса, ул аларны инде күптән куып чыгара иде. Ә Рамилә йомшак, кызының егетен үпкәләтүдән курка. Галия бүген дә иртәнге алтыда гына кайтып керде.

Бүген иртә белән Кәбир Рамиләгә тәкъдим ясады. Төштән соң алар кибеткә барып булачак хатынына туй күлмәге сайларга тиешләр. Очрашу урыны—“Балалар дөньясы” кибете. Ә хәзер аңа абыйсы янына хастаханәгә барып кайтырга кирәк. Аннары эшкә барып бер күренеп алгач, аның вакыты буш булачак. Журналист хезмәтенең җайлы бер ягы бар: телисең икән, эшендә утырып эшлә, телисең икән, өеңдә ят. Иң мөһиме—мәкаләң генә вакытында әзер булсын. Ә Кәбирнең материалы җитәрлек. Бөтендөнья татарлары конгрессына килгән унлап чит ил кунагыннан бер дигән интервью алган иде ул.

... Биек таш койма белән уратып алынган ике катлы таш хастаханә бинасына кергәч, һәр ишекне ачкыч белән бикләп йөрүче яшь кенә шәфкать туташы аны табиб янына кертеп җибәрде.

Табиб—кечкенә генә буйлы, урта яшьләрдәге ир-ат—аны бик җылы кабул итте. Башта ул Әхәтнең тәрҗемәи хәле белән кызыксынды, аннары гаиләсе турында сорашты. Кәбир, һичбер нәрсә яшермичә, барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

—Да, эчергәннәр егеткә Лаеш шулпасын,—диде табиб, башын чайкап.—Тяжелый случай. Тиз генә терелтә алырбыз дип вәгъдә бирә алмыйм. Терелеп беткән очракта да, практика күрсәткәнчә, рецидивлар булырга мөмкин. Бүгенгә без аминазин белән генә чикләнергә булдык. Иртәгә дә хәле яхшырмаса, бүтән төрле препаратлар кулланырга туры килмәгәе.

Кара хәсрәттән тәмам коелып төшкән Кәбир редакциягә сәгать уникеләр тирәсендә генә килеп житте. Сергач татарларына багышланган мәкаләсен көч-хәл белән генә номерга әзерләп бирә алды.

Ул редакциядән чыкканда инде ике минуттан дүрт тула иде. Трамвайга

утырмады, алар Тукай мәйданына кадәр диярлек бер-бер артлы тезелеп туктап калган. Бүген коммунистлар Печән базары тирәсендә пикет ясарга тиеш иде. Мөгаен, шулар эшедер. Очрашу урынына Кәбир җәяүләп кенә китте.

Рамилә аны инде көтеп тора. Нинди сылу хатын! Киенә дә белә бит. Озын итәкле өрфия кызыл күлмәге әллә каян күрсәтеп тора үзен. Чыраена карап кырык яшь бирмәссең, йөзе шома, ак. Зифа буе яшь кызларны көнләштерерлек.

Алар бик озак кибетләр буйлап йөрделәр, әмма күнелгә ярардай туй күлмәге таба алмагач, кечкенә генә бер кафега кереп әфлисун суы эчтеләр, туңдырма ашадылар.

Рамиләне Кәбир таксига утыртып җибәрде. Абыйсын хастаханәдән чыгара калсалар, ул өйдә булырга тиеш.

## Фаҗига

Төнге уникегә кадәр компьютер артында утырды Кәбир. Мәкаләләр бик коры чыкты. Чөнки игътибарын туплый алмый интекте. Мантыйгы булгач, шул җиткән. Анларлар әле.

Башта акылдан язган абыйсы күнелдән чыкмады. «Эти-әнигә хәбәр итәргәме, юкмы?—дип уйлады ул.—Карт бит инде алар, шундук урын өстенә менеп ятачаклар. Сәриягә хәбәр итеп тору кирәк булмас. Ятсын үзенең Витясы куенында. Аждаһа! Бусы да чүп өстенә чүмәлә булды».

Аннары Кәбир Рамиләне искә төшерде. Балдан татлы бу хатын ана үтә күренмәле кебек тоела. Үбеп туя алмый. Матур йөзенә, озын керфекләренә сәгатьләр буе карап торса да армас иде. Йә, илаһы, нигә ул шундый сөйкемле?

Мәкаләләрне принтердан чыгарып бетергәч, ул утны сүнлереп караватка сузылып ятты. Тышта сибәләп торган яңгыр, дивар сәгатенең текелдәве күнелдә шом хисе уята. Ялгыз тормыш туйдырды. Хатын-кыз җылысы булмаганга шомлы бу тынлык. Их, янда бер-ике сабый да йөгереп йөрсә, дөньялар түп-түгәрәк булачак лабаса. Нәрсә ул язу? Ятимлекнең башы. Һәм ятимлекнең дәвамы да иҗат була торгандыр инде. Укымыйлар безне. Такташлар бәхетле булган, аларны егылып укыганнар. Чөнки татар маңкортларга бүленмәгән булган ул чакта. Булгандыр берән-сәрән, ләкин моның кадәр үк булмагандыр. Бетә татар дип кайгыралар. Беткәне бетә торсын. Аның каравы, өч кенә татар булса да чын татарлыгын саклап кала икән, бу мең тапкыр кадерлерәк.

Алдагы көндә Кәбир сәер төш күрде. Имеш, тирән генә ерганакта яп-яшь егетләр һәм бер кыз үтерешкә карта уйный. Бер мәлне кызның аркасына пычак белән кададылар.

—Әни-и!—Кыз үкерә-үкерә үргә таба чабып китте.

Кәбир, мине дә үтереп ыргытмагайлары дип, куркудан ярга үрмәләде. Яр бик текә. Өскә менсә, анда баракка охшаган иске агач йорт тора. Тәрәзәдән генә эчкә сикерде.Анда шыгрым тулы шәрә хатын-кыз иде. Арада берсе бик чибәр, ачык сары төстәге озын чәче биленә кадәр салынып төшкән. Кыз чәчен тарады да тәрәзәдән чыгып китте. Баксаң, аның гәүдәсенең билдән алып аягына кадәр булган өлеше зәп-зәңгәр!

Төштә шәрә хатыннар күрү хәерлегә түгел. Менә шул да Кәбирне бик борчый иде. Инде йокыга китәм дип ятканда, тәрәзә артында машина килеп туктаганы ишетелде. «Кем булыр бу?—дип уйлады ул, тәрәзә пәрдәсе аша үтеп кергән фара яктысына карап.

Менә капка дөбердәттеләр. Торып пәрдә читеннән генә урам якка күз салды. Милиция машинасы икән. Өстендә зәңгәр «ут» уйнап тора. Нишләп йөриләр? Хәер, бу урамда еш була алар. Әле өченче көн генә каршы яктагы йортта яшәүче ике үсмер малай артыннан килгәннәр иде. Мәктәптә бер

укучыдан акча кысканнар. Бирмәгәч, кыйнаганнар. Хәзер кыйналган малай хастаханәдә ята. Ә ике атна чамасы элек урамның аскы ягындарак яшәгән Матрена түтәйне талап чыкканнар. Авызын скотч белән ябыштырып, аркасына үтүк белән басканнар. Үтермәгәннәр үтерүен. Әмма гомер иткән карчыкка бусы да бик җитеп тора. Авыр хәлдә ята, дип сөйләделәр.

Кәбир трусиктан гына болдырга чыгып басты.

—Кем бар анда?

—Милиция! Ачыгыз!

Капканы ачуы булды, мыеклы милиционер фонарь белән Кәбирнең йөзенә яктыртты. Барысы да плащтан. Фуражкаларының козырегыннан яңгыр суы агып тора.

—Гражданин Гафуров?

—Мин.

—Киенегез. Хәзер сез безнең белән китәчәксез.

—Ә нәрсә булды?

Ул арада берсе Кәбирнең кулларына тимер беләзек кидереп куйды. Сизми дә калды, каһәр.

Тимер беләзек белән киенү авыр иде. Булдыра алмаган җирдә ментлар булышты, булышмаганнары авызларын ерып карап торды.

...Кәбирне култыклап иске «ВАЗ» машинасының арткы кәнәфиенә утырттылар. Берәү дә сөйләшми, әйтерсең телләрен йотканнар. Ике яктан шундый каты итеп кыстылар, муенны гына борып була.

—Кая алып барасыз мине ?—дип сорады аңына да килеп өлгермәгән Кәбир.

—Баргач күрерсең.

«Ярый, бара торыйк,—дип уйлады ул.—Минем бернинди дә гөнаһым юк. Бутаганнар кем беләндер».

Машина иске аэорпортны узып заманча төзелгән биш катлы бина янына килеп туктады. Яңгыр койса да—яп-якты. Бетон баганаларда люминисцент лампалар яна. Сул ягтарак озын ак чыршылар үсеп утыра.

Пыяла ишектән атлап керделәр. Кизү милиционер документларны тикшереп тормады. Алар инде баскыч буйлап икенче катка күтәрелә.

Озын коридор. Кайдадыр бер хатын-кызның үкереп елаганы ишетелә.

Уникенче бүлмә ишеге каршында туктадылар. Тагын бер «берле»се булган инде, анысы урынында келәй эзе генә күренә. Милиционерларның берсе шакып кына ишекне ачты:

—Гафуровны алып килдек.

Кәбир эчкә узды. Бүлмә шыксыз. Балта асып куярлык тәмәке төтене. Диварга ябыштырылган ак обой ертылып-таушалып беткән. Уртада бер өстәл, аның артында утыз яшьләрдәге бер ир утыра. Өстәлнең икенче ягында тагын бер урындык тора. Бүлмә хуҗасы иске генә костюмнан, күлмәк изүе ачык. Баш сөяге ике яктан тиски белән кысылган кебек озынча күренә. Күзләре кечкенә, карашы аркылыга тишеп чыгарлык.

—Узыгыз!—диде ул, урындыкка күрсәтеп.

Кәбир урындыкка утыргач, хуҗа өстәл лампасын аңа табарак борып, сүз башлады:

—Минем фамилиям Голубцов. Следователь по особо важным делам. Сез беләсезме үзегезнең монда нәрсә өчен утырганыгызны?

—Белмим.

Голубцовның күзләре кысылып куйды. Елмая.

—Гражданка Айбулатова сезгә танышмы?

—Айбулатова?... Беренче тапкыр ишетәм.

—Ялган.—Голубцов өстәлгә зәңгәрсу төстәге китап чыгарып куйды.—Сезнекеме?

Кәбир терәлде дә катты. Анын китабы ич бу!

—Әйе, минем китабым.

—Ә анын беренче битенә нәрсә язылган?.. Укыгыз, укыгыз.

—Укыдым.

—Димәк, сез бу китапны гражданка Рамилә Айбулатовага бүләк иттегез, шулаймы?

Рамиләнен фамилиясен белми икән Кәбир. Вәт, ангыра! Ә үзе аны яратам дип йөргән була. Алдашкан кебек килеп чыкты, каһәр.

—Рамилә белән берәр нәрсә булган мәллә?- диде ул, мич кебек агарынып.

—Менә, ә сез аны, андый кешене белмим дигән буласыз.

—Фамилиясен генә белмәгәнмен мин анын. Без якын араларда кавышырга жыена идек.

—Беләбез. Шунын өчен дә сез...

—Әйтеп бетерегез.

—Галия сезгә комачау итә иде, шулаймы? Ялгыз хатын, ике бүлмәле фатир, дача...

—Мин сезнен тел төбегезне анламыйм.

—Бик яхшы анлыйсыз. Галияне сез үтердегезме?

—Нәрсә?..—Кәбирнен башы әйләнеп китте. Ниндидер саташу бу! Галия... Йә, Раббым!—Аны үтерделәрмени?

—Кичке сәгать бишләр тирәсендә кайда булдыгыз?

—Рамилә белән кибетләрдә йөрдем. Сәгать сигез тулгандарак таксига утыртып өенә кайтарып җибәрдем.

—Гражданка Айбулатова белән йөрдегезме?

—Әйе. Анын үзеннән сорамадыгыз мыни?

Тикшерүче Кәбиргә ышана башлады кебек. Һәрхәлдә, ул ана инде каш астыннан карамый.

—Айбулатова сөйләшә алырлык хәлдә түгел иде,—диде ул.—Килене аны үзләренә алып кайтып китте. Фатир сак астына алынды. Анда тикшерү бара.

—Ә нигә мине кулга алдыгыз?

—Айбулатова гел сезнен исемне кабатлап торганга күрә. Өстәвенә пианинода сезнен китап ята.

—Нинди ахмаклык,—диде Кәбир.—Мин кирәк булганга кабатлаган инде ул исемемне. Ә сез...

—Димәк, без аны анлап җиткермәгәнбез. Хәле авыр иде, хәтта ашыгыч ярдәм машинасын чакыртырга туры килде.

... Иртәнге сәгать өч. Кәбир такси алып Рамиләләрнен киленнәренә китте. Машинага утыргач кына акчасы юклыгын искә төшерде ул. Рульдә яшь егет иде. Хәлне анлатып биргәч киреләнмәде, аны шәһәрнен икенче башындагы Кол Шәриф урамына—тугыз катлы йорт янына китереп куйды.

Кәбирнен монда булганы бар. Бер көнне узып барышлый Рамилә белән киленнәре Людада чәй эчеп чыкканнар иде. Энесе аннан инде аерылган, хәзер ул икенче хатын белән Түбән Камада яши. Ә Рамилә ана гына карап туганлык җепләрен өзә торган хатын түгел. Ул Люда белән дә, анын кызы Римма белән дә аралашып яши.

Ишекне Люда ачты. Теге вакытта чәче каштан төсендә иде, бу юлы сарыга буяган. Күзендә нур әсәре юк. Хәсрәт шундый итә адәм баласын.

Борынга корвалол исе килеп бәрелде. Үле тынлык.

—Йокладымы мәллә?—дип пышылдады Кәбир, керә-керешкә.

—Юк, диванда утыра,—Люда үзе дә елап беткән.—Акылдан язмагае дип куркам, инде ике сәгать бер ноктага карап утыра.

Чыннан да, кунак бүлмәсендә утырган Рамилә бөтенләй үз-үзенә охшамаган иде. Чәчләре тузгыган, елаудан йөзе шешенеп беткән, күз төпләре эчкә

кереп баткан, ә зәңгәр күзләре ниндидер бер чиксезлеккә төбәлгән кебек.

—Рамилә,—Кәбирнең күзенә яшь килеп тыгылды.

Дәшми. Янына утырып, аны бер кулы белән кочаклап алды. Таш кебек катып калган, бахыр. Акылдан язмагае. Болай калдырырга ярамый. Нишләргә?

Нашатырь иснәтеп караган иде, сизми дә. Яңакларгамы? Кинода күргәне бар, хәсрәттән телсез калган кешене яңаклагач, ул башта елап җибәрә, аннары акылына килә.

Шулай итте дә. Рамилә башта әкрен генә, аннары ыңгыраша-ыңгыраша елый башлады. Йөзе белән диванга капланды. Булды, димәк, акылдан язмаячак.

Хатыннар төне буе елашып утырдылар. Хет стенага үрмәлә! Рамилә инде үтерүчене белә:

—Илсурны кулга алырга кирәк. Ул—наркоман!

Нинди наркоман? Бу хакта сүз чыкканы юк иде кебек. Ә-ә, менә ни өчен кызарган булган аның күзләре! Димәк, аның дусты Рәдиф тә наркоман! Каян белә?

Серне Люда чиште.

—Рамиләгә бер көн алдан гына, Илсур наркотиклар белән сату итә дип, бер хатын шылтыраткан булган,—диде ул.—Үзенең исемен әйтмәгән.

«Юләр,—дип уйлады Кәбир.—Нигә чара күрмәгән? Миңа әйткән булса да...»

Иң газаплы көннәр алда иде әле...

## Моргта

... Иртәгә Россия суверенитеты бәйрәме. Шуңа күрә бүген бөтен җирдә дә кыска эш көне. Галиянең гәүдәсен моргтан алып өлгерергә кирәк. Бәйрәм көнне һәм аннан соң килә торган шимбә белән якшәмбе көннәрне исәпләсәң, аны аннары өч көннән соң гына алып булачак. Татарда мәетне никадәр тизрәк күмсәң, шуның кадәр саваплырак.

Көн прокуратурада узды. Морг ябылырга инде ярты гына сәгать калып бара. Прокурор кул куймыйча мәетне бирмәячәкләр.

Ниһаять, ул кайтып керде. Ниндидер киңәшмәдә булган икән. Ләкин секретарь кыз кертергә ашыкмый. Хуҗа телефоннан сөйләшә, имеш.

Кәбир түзмәде, эре-эре адымнар белән аның кабинетына кереп китте. Баксаң, ул кофе эчеп утыра икән. Озын-озак киңәшмәдән соң хәл алуы үзенчә.

—Иптәш прокурор, безгә сезнең имзагыз кирәк!—диде Кәбир, шартлатып.—Морг ябылырга унбиш минут калып бара.

—Ә?.. Морг?.. Китерегез кәгазегезне,—Прокурор торып ук басты.—Нигә шулай бик соң?

—Сез киңәшмәдә идегез бит.

—Әйе, әйе, киңәшмәдә идем шул.

Морг ябылырга биш минут кала гына барып җиттеләр. Озын өстәл артында утырган ак халатлы карт маржа Кәбир сузган кәгазьне алып, аңа күтәрелеп тә карамыйча сорап куйды:

—Кая күмәсез?

Ир югалып калды. Бу турыда уйларга өлгермәделәр әле.

—Белмим,—дип җавап бирде ул, аптырап калып.

Маржа авызын зур итеп ачып җикеренә башлады:

—Ничек инде белмисез? Миңа журналга теркәп куярга кирәк. Белмәсәгез, мәетегезне бәйрәмнән соң килеп алыгыз. Ә минем эш сәгатем бетте. Все, досвидания!

Кәбир шундук үз-үзен кулга алды.

—Гафу итегез... Мин сезне аңлап житкермәгәнмен икән. Самосырова зиратына күмәбез без аны,—диде ул, йомшак кына тавыш белән. Дорфа кыланырга ярамый, юкса, чыннан да кайтып китәчәк.

—Күптән шулай дияргә иде аны,—Маржа мәет турындагы мәгълүматны өстәлдәге кенәгәгә теркәп куйды.—Хәзер алсагыз да була. Бишенче рефрежератор.

Мәетләр саклана торган ишек ачылгач, Кәбир цинктан эшләнгән тәгәрмәчле арбада яткан Галиянең гәүдәсен күреп өнсез калды. Өстен ак җәймә белән каплаганнар, йөзе генә күренеп тора.

Кычкырыш, елаш башланды. Рамилә инде аягында да басып тора алмый, аны ике ягыннан култыклап алдылар. Түбән Камадан, Кама Тамагыннан, Башкортстаннан кайткан туганнары да, Галия белән уйнап үскән, бергә мәктәптә укыган егетләр-кызлар да монда. Илсур белән Рәдиф кенә юк. Галияне килен дип атап йөргән ата-ана да күренми. Юкса Илсурның әнисенә операция булгач, Галия аны өч көн буе саклап утырган иде..

Галиянең гәүдәсен алып кайткач ике сәгатьтән артык урамда басып торырга туры килде. Фатир һаман да сак астында иде.

Ниһаять, керделәр. Кунак бүлмәсенең ишеген салдырып, мәетне шунда урнаштырдылар. Тагын елаш башланды. Рамилә берничә тапкыр аңсыз егылды. Ашыгыч ярдәм машинасы чакыртып, беләгендәге кара кан тамырына укол кададылар. Ул йоклый сыман, ләкин барыбер ыңгыраша. Мондый чакта ана күңелен оныттырып буламыни?

Ике тапкыр телефоннан шылтыраттылар. Һаман бер егет тавышы:

—Галю можно?—Галияне урысчалатып әйтүе инде.

Кем бу? Җинаятьче һәрвакыт корбаны белән кызыксына, диләр. Бәлки ул чыннан да Галиянең үтерүчеседер? Номеры чыкмый. Димәк, автоматтан шылтырата. Тавышын да үзгәртеп сөйләшә кебек...

## Үтерүче кайда?

... Галияне Самосырово зиратына җирләделәр. Мәрмәрдән эшләнгән кабер ташына Кәбир үзенең шигырен язып куйды:

> Язган безгә, язган очрашырга,
> Туфрак булып мәңге кавышырга...

Аннары Кәбир белән Рамилә прокуратура юлын таптый башлады. Рамилә тәмәке тартырга өйрәнде. Әле аңа каты бәрелергә ярамый. Тартсын. Ул— бердәнбер кызын югалткан бәхетсез ана. Аның төннәр буе йокы күрмичә багып үстергән чәчәк кебек унтугыз яшьлек кызын үтерделәр. Сулган, кибә башлаган чәчәк рәвешенә керде ул. Бүтән беркайчан да элекке матурлыгын, сылулыгын кайтара алмас инде Рамилә. Аның күз чагылдыргыч матурлыгын кызы Галия белән урладылар.

Прокуратурада Илсурдан инде сорау алганнар. Ул берни дә белми. Имеш! Качып йөрмәс иде гаебе булмаса. Нигә наркоманны университетта тоталар, дип сорагач, тикшерүче, наркотик кулланган өчен генә университеттан кумыйлар шул бездә, дип җавап бирде. Закон сакчысының шундый сүзеннән соң аңа ничек ышанырга?

Кәбир белән Рәсимә үҗәт булмасалар, Рәдифне эзләргә дә уйлаучы юк иде. Тикшерүче алар килгән саен зарлана. Янәсе Совет районында шушы арада гына да сигез кеше үтерү очрагы теркәлгән, барысына да өлгереп булмый. Баксаң, Илсурның дусты Рәдиф Галия үтерелгән көнне үк юкка чыккан. Качканмы? Үтергәннәрме? Аны шундук оператив эзләүгә бирделәр. Милиция эзләп килгәч, әнисе: "Белмим мин аның кайда икәнен, белергә дә теләмим",—дигән. Алар

аны, үзләрен фатирсыз калдыра күрмәгәе дип, пропискадан да төшереп куйганнар. Акча бирмәгән өчен Рәдиф бертуган сеңлесен дә буып үтерә язган.

Тикшерү өч айга сузылды. Рәдиф һаман да табылмагач, прокуратура җинаять эшен туктатып торырга булды. Оператив эзләү берни дә бирмәде. Җылы кабинетта компьютер артында гына шаһитләрдән сорау алып утырып җинаятьчене тотып булмый шул. Ялган күрсәтәләр икән детектив фильмнарда. Аларга тавык суйдылар ни дә, кеше үтерделәр ни. Кыскасы, адәм кайгысына күнеккән бәндәләр бу. Кайда соң бездә халык тарафыннан яратылган гаярь егетләр? Алар юк. Булса да, бик аз гына булыр. Беркетмә төзергә кәгазьләре дә юк бит бу мескеннәрнең!

Ниһаять, Кәбир Рәдифне үзе эзләргә алынды. Ул кайчан да булса әти-әнисе фатирына кайтачак. Җан тартмаса да, кан тарта, дигән борынгылар. Шуңа күрә дә һәр көнне төнге сәгать уникеләргә кадәр Рәдифләр подъездын саклады. Һәм бер көнне...

## Төнге очрашу

Шимбә көн иде. Төнге уникe тулгач, Кәбир трамвай тукталышына юнәлде. Бу вакытта Рамилә яшәгән йортка кадәр кизү трамвай йөрергә тиеш. Трамвай озак көттермәде, ун-унбиш минуттан килеп тә җитте. Ишектән уйланып кына кереп барганда, салонның арткы мәйданчыгында басып торган кечкенә генә буйлы, җирән чәчле, җирән сакаллы бер егеткә күзе төште. Рәдиф!

Янына килеп баскач, егет башта Кәбиргә игътибар итмәде. Танып алгач, каушап калды.

—И... исәнмесез,—диде ул, тотлыгып. Исәнләшмәс тә иде, Кәбир инде нәфрәт белән аның чыраена карап тора.

—Мин исән, энем,—диде ул, кулын йодрыклап.—Ә менә сине исән калдырырга ярамый.

Егетнең күзләре йөгерә башлады- сызарга уйлый. Бер кулын кесәсенә тыкты. Анда нидер бар. Пычакмы? Ул гына коткара алмас.

—Ни... нигә шулай дисез, Кә... Кәбир абый?

—Рамилә апаның пешкән тәмле ризыкларын ашаган минутларың күз алдына килеп, намусың бугазыңнан алмыймы?

—Нәрсә сөйлисез сез?

—Сөйләселәр алда әле... Чыгар кулыңны кесәңнән!

Аһ, бүре баласы, ул инде пычак белән кизәнде. Күргәне бар Кәбирнең синең кебек маңкаларны. Чик буенда хезмәт иткәндә берәү кизәнеп карады инде. Һап! Пычак идәнгә тәгәрәде. Кырыкның теге ягында булса да, аяк шәп эшли икән әле, ботинка очы авыртудан күзләрен акайтып чүгәләгән хәшәрәтнең терсәгенә тиде.

—Тор!

—Галиягә тимәдем мин! Тырнак очы белән дә кагылмадым!—Елый да белә икән хәшәрәт.

—Киттек минем белән!—Кәбир аның якасыннан эләктереп алды.—Прокуратурада акланырсың.

—Башта аны Илсур чәнечте!

—Аннары?

—Аннары... мин.

—Телевизорны да бергә алып чыктыгызмы?

—Әйе. Бе... без аны беренче очраган кешегә мең тәңкәгә сатып җибәрдек. Ломка башланган иде ик...икебезнең дә. Рамилә апаның алтын медальонын ломбардка тапшырмакчы булган идек, Галия тавыш куптарды. Ну, аннары Илсур да кызып китте, пычак белән... Үтерергә уйламаган идек, валлаһи!

... Рәдифтән сорау алу ике атна дәвам итте. Хәзер ул башка төрле сөйли.

Имеш Галия үтерелгән көнне ул әбисендә булган, беркемнән дә качып йөрмәгән. Тикшерүче үз файдасына бер генә дәлил дә китерә алмый. Чөнки пычакта бармак эзләре калмаган, анын Рамиләләр фатирына кергән-чыкканын да күргән кеше юк. Эшләр хөртиләнә бара, житди дәлилләр табып булмаган очракта, Рәдифне чыгарып жибәрергә туры киләчәк. Тикшерү барышында тагын шунысы мәгълүм булды: оператив эзләүдәге үтерүчегә фатир талаган өчен шәһәрнен Идел буе районында суд булган. Срок бирмәгәннәр, амнистиягә элəгү сәбәпле, ирекка чыгарганнар. Милиция кая караган? Монда да Кәбирнен үткенлеге ярдәм итте. Рәдиф: "Әбидә яшәдем"—ди бит, бәлки анда анын канга буялган киемнәре сакланадыр?

Тапты Кәбир әбине. Рәдифнен дусты булып исәнләште. Үзе килә алмый, анын Мәскәүгә китәсе бар, булган киемнәрен миңа бирер жибәрергә кушты, дип алдады. Хәзер инде анын кулында бер джинса чалбар һәм кара күлмәк бар иде. Нәкъ менә шушы киемнән йөрде инде Рәдиф соңгы вакытта.

Киемнәрне тикшерүчегә алып барып тапшырды. Теге, рәхмәт әйтәсе урында, канәгатьсезлек белдереп тора. Янәсе Кәбир прокуратура эшенә тыгыла.

Ун-унбиш көннән эспертиза нәтижәләре әзер булды. Джинсада табылган кечкенә генә кан таплары Галиянеке икән.

Инде хәзер Галияне үтерүдә Илсурнын да катнашы барлыгын дәлилләргә кирәк иде. Ләкин Рәдиф үз гаебен таныса да, дустын акларга керешге. Күрәсен, алдан сөйләшеп куйганнар. Илсур бай малае, күп итеп акча төрткәндер. Хәзерге законнар буенча кеше үтергән өчен нибары сигез-ун ел гына бирәләр. Ә инде икәү булган очракта, аларны тагын да зуррак срок көтә. Әлбәттә, бу Рәдиф өчен дә, Илсур өчен дә иң кулай вариант иде.

Суд булды. Рәдифкә унике ел бирделәр. Судья мораль зыян өчен Рәдифтән Рамиләгә егерме мең сум түләттерергә дигән карар чыгарды. Менә бездә кеше гомере бәясе! Егерме мең! Ничек сыкрамыйсын да, ничек хурланмыйсын! Мөртәт дәүләт! Шуннан соң сина ышанырга, сине яратырга мөмкинме?!

Кәбир бер үзендә, бер Рамиләдә кунып йөрде. Әхәтне хастаханәдән чыгаргач кына гел кайтып йөри башлады. Абыйсы инде элекке типсә тимер өзәрдәй кеше түгел. Үз акылында булса да, бизгәк тоткан кешедәй калтырап тора, кайвакыт әйткән сүзен дә аңлап булмый. Бигрәк тә гасабиланган чагында авызында ботка пешерә башлый. Ләкин скрипкада һаман да шәп уйный әле. Аны кулыннан төшергәне юк. Әйтерсен, кемдер тартып алырга жыена. Вакыты-вакыты белән ул скрипка белән сөйләшеп тә утырган кебек.

Кәбир редакциядән китте. Бу вафасыз дөньяда каләмнең көче юклыгына ышанды ул. Нигә кәгазь әрәм итәргә? Дөнья дигәннәре барыбер үз юлы белән бара. Дөнья инде тайгак сукмакта.

### Өч

Жиргә беренче кар төште. Ул чүп баскан Казан урамнарын бер генә көнгә булса да матурландырып, пакъләндереп жибәрде. Иртән адәм баласы бу пакълекне таптар, ул ком һәм тоз белән аралашыр, аны машиналарга төяп шәһәр читенә түгәрләр. Аннары тагын күбәләк-күбәләк карлар явар, жир өстендә тагын күзләрне чагылдырырлык пакълек тантана итәр.

Кәбир Әхәтне житәкләп урамга алып чыкты. Көннәр буе өйдә утыра бит, ул да бераз саф һава суласын, ап-ак бәс кунган агач ботакларында күч-күч булып утырган каргалар туен күзәтсен. Башка кошлар булмаганда, карга да матур. Аларның каркылдауларына карап, без яз исен тоябыз. Песнәкләр дә матур, пырх-пырх очып, тәрәзәләргә асып куелган тартмалардан, савытлардан ипи валчыкларын чүплиләр. Түшләрен берәр рәссам сары карандаш белән буяп куйган дип уйларсың. Ә бу сарылык нигә кирәк? Сере бар моның

ниндидер. Тик бу турыда бер дә язылганы, әйтелгәне дә юк. Әхәт скрипкада уйнап, җырлап җибәрде. Бөтен урамга йөрәкләрне әрнетердәй моң таралды:

Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә?
Ник монсу бу җирдә, әйтсәнә!..
Кайгыңны кошларга сөйләргә...
Урамга чык әйдә, Гөлсинә.

Абыйсы нәрсә уйлагандыр, ә Кәбир Рамиләне кызганып торды. Туй ясамадылар инде. Туйны Илсур белән Рәдиф “ясады”. Рамиләнең хастаханәдән башы чыкмый. Яфрак кебек кипте, саргайды. Ул инде тәмәке тарта, аракы эчә. Күпме саклады инде ул Рамиләне, ләкин барыбер эчә. Сагышына чыдый алмыйча эчеп, үзенең ахырына бара. Сөенеп бара, чөнки шул рәвешле кызы белән очрашачак минутларны якынайтырга тели. Ә анда пычагым да юк. Барысы да—кеше үзе уйлап чыгарган ялган.

Аяк тунганчы басып тордылар. Әхәтне өйгә кертеп куйгач, Кәбир университетка юл тотты.

Бүген ул Илсурны теге дөньяга олактырачак. Наркоман юрист! Никадәр тизрәк котылсаң, шуның кадәр яхшырак. Юкса, бу адәм актыгы университетны тәмамлагач, үзе дә кемнәрнедер хөкем итә башлаячак. Рәдифне төрмәдә үтерделәр. Хәзер чират аңарда! Кылган гөнаһың өчен теге дөньяда түгел, шушы дөньяда җавап бирергә кирәк. Аллаһы булса, калганын үзе карар.

Пистолет пальто кесәсендә. Предохранительдән алынган. Уң кул чакмада тора.

Озак көтте Илсурны. Ул инде мыек җибәргән. Кызлар белән көлешә-көлешә университет ишегеннән чыгып килә. Мөгаен, хәзер башка ананы алдап йөридер, аның өендә туган көннәрдә утырадыр. Мөгаен, аның кызын да хәйлә белән бозлы ләхет юлына өстеридер. Бу юлы барып чыкмас. Ата-анасының унбиш мең доллары әрәм. Шул акчаны ятимнәр йортына бирсәләр иде ичмасам. Савабы булыр иде. Хәзер... Бераз якынрак килсен дә... Нәрсә булды кулга?.. Кузгалмый. Кесәдә ябышып каткан кебек... Булмады... Илсур инде күздән югалып бара.

Кәбир оятыннан йөзен кая куярга белми карга тезләнде. Хурлык! Үтерә алмады бит! Нигә? Артта басып торган яшь Ульянов та, их, булдыра алмыйсың, егет дип, өстән генә караган шикелле.

«Яшә,—дип уйлады ул.—Үлеп кенә котылма әле. Балалар үстер, кайчан да булса аларга карап, намус дигәннәре синдә дә уяныр, төнлә төртеп уята башлар. Аннары син дә канлы күз яшьләре агызырсың. Син дә дөньяга ник килгәненә үкенерсең».

## Ялгызлык

Кәбир кыңгырау төймәсенә баскач, эчүдән шешенеп беткән Рамилә ишекне ачып йокы бүлмәсендәге караватка барып ауды. Күз төпләре кара көйгән, беләкләре дә бәрелеп-тырналып, кызарып беткән. Күлмәк кию дигән нәрсәне онытты инде, өстендә күптән кер порошогы күрмәгән иске тишек зәңгәр кофта, күтендә джинса чалбар. Исән вакытта аны Галия киеп йөри иде. Кулындагы гади металлдан эшләнгән «неделька»лар да кызыныкы.

—Уф! Яшисем килми-и-и!—дип сыкрады хатын.

Бүлмәләрдә элекке тәртип юк инде. Пәрдәләр каптыргычларыннан ычкынып идәнгә асылынып төшкән, челтәрләр керләнгән, кайберләрендә зур-зур сары таплар күренеп тора. Аш бүлмәсендәге ак өстәлнең бер аягы янтайган, раковинада тау булып юылмаган савыт-саба, тәмәке төпчекләре, шешә бөкеләре өелеп ята.

Үтерүчеләр урлап алып чыккач, Рамилә яңа телевизор алмады. Ул торган

матур кара тумбочканы да, пианинонны да, Галия башын куеп жан биргән диванны да сатып жибәрде. Ә кызының китапларын, киемнәрен туганнарына таратты. Йокы бүлмәсендәге мебель гарнитуры да юк. Анда нибары тимер карават, тышлыгы ертылып беткән мендәр белән матрас кына бар. Стенада—Галиянең мәктәптә укыган чагында төшкән фотосурәте күренә... Күзләре монсу, әйтерсең лә, әнисенең шушы көнгә калганына әрнеп карап тора.

Кәбир Рамиләнең аяк очына килеп утырды.

—Акчаң бармы?—Ыңгыраша хатын, башы авырта.

—Бар.

—Утыз тәңкә бир әле.

—Эчәргәме?

—Бирәсеңме?

—Сиңа инде акылыңа килергә вакыт.

—Галияне гел төшемдә күрәм.—Рамилә мышык-мышык елый башлады.—Бар микән ул теге дөнья? Булса, мин шунда гына китәр идем. Анда мин кызымны күрер идем.

—Аллаһы берәүләрне бәхет, икенчеләрне бәхетсезлек белән сынармын дигән,—диде Кәбир, авыр сулап.—Сиңа, миңа түзәргә генә кала инде.

—Нигә ул минем бердәнбер кызымны тартып алды? Шундый сынау буламыни?

—Киен, хәзер безгә кайтабыз.

—Юк, мин беркая да бармыйм.

—Алайса, мин монда үзем күчеп киләм.

—Килмисең. Мин инде сиңа бәхет бирә ала торган кеше түгел, Кәбир. Юньле хатын була алмам.

—Вакыт барысын да дәвалый, бергә-бергә булсак, бераз онытылып торыр идең.

—Нинди онытылу? Минем Галияне бер генә минутка да исемнән чыгарганым юк. Илсур нихәлләрдә икән? Кызлар белән типтерә торгандыр. Ә Галия кабердә ята.

—Аңа да бирер әле Ходай... Киен. Миңа авыру абыеңны да карарга булышырсың.

—Әйттем бит инде, беркая да бармыйм дип. Чыгып кит, минем ялгызлыкта каласым килә.

Кәбир Рамиләне өстерәп торгызды.

—Киен!

—Кара, кара, әллә сугыша да башлады инде?—дип мыгырдады Рамилә.—Хәзер мин милиция чакырам.

—Чакыр. Мин сине барыбер монда калдырмыйм.

—Кит, зинһар! Мин синнән туйдым, аңладыңмы? Мин бөтен кешедән дә туйдым. Мине ялгызлыкта калдыр. Ул гына хәзер минем сердәшем.

—Аһ, әле син шулаймы?!—Чарасызлыктан арган ир урындыкны алып тәрәзәгә томырды.—Яшә, алайса, үзең генә! Әллә Галия сиңа рәнжеп ятмый дип уйлыйсыңмы? Кыяфәтеңә кара, вокзалларда аунап беткән бомжалар да сиңа караганда чистарак!

Ишекне шап итеп ябып чыгып китте. Трамвай туктлышына барып җиткәнче дулап барды. Аннары гасабилянудан калтырый башлаган куллары белән тәмәке кабызгач, кинәт хушына килә башлады. Үкенү хисе биләп алды аны. Рамилә урынында булса, үзе нишләр иде икән? Күтәрә алмас иде бу кайгыны, үләр иде. Ә Рамилә әле ничек тә булса яши. Ләкин бу болай озак дәвам итмәячәк, элмәккә менмәгәе. Урындыкны тәрәзәгә төбәп атмаган иде ул, шулай килеп чыкты. Хәлләр була иде жиденче каттан төшеп китсә. Бәхеткә, балконнан ары уза алмады.

Тәрәзәне куярга кирәк. Кире кайтыргамы? Кәбир үзенең келәтендә зур гына пыяла кисәге барлыгын исенә төшерде. Хәзер кайтып шул эш белән шөгыльләнергә кирәк. Рамилә милициягә хәбәр итсә? Юк, бу эшкә бармаячак ул. Кире булса да, күзләреннән күренеп тора, Кәбирне һаман да ярата. Нигә ана кияүгә чыкмый? Мөгаен, депрессиядән котыла алмаганга, кимсенгәнгә, кеше күзенә күренергә теләмәгәнгәдер.

Ул кайтканда Әхәт тәрәзә төбендә скрипкада уйнап утыра иде.

—Бик озак йөрдең,—диде ул.—Почтадан бандероль кәгазе килде.

Кәбирнең уйлары Рамилә янында иде әле.

—Ярар, өстәлгә куй, иртәгә барып алырмын,—диде ул, өстенә спецовка киеп.—Мин келәткә чыгам, берәүгә тәрәзә пыяласы кисеп бирәсе бар.

Келәткә кергәч Кәбир тәрәзәнең размерын белмәвен исенә төшерде. «Каһәр генә икән!—дип уйлады ул, үз-үзен сүгеп.—Бергә эшләгән Артурга шылтыратып алырга кирәк. Ул да Рамиләләрнеке кебек йортта яши бит».

Күршеләреннән шылтыратты. Артур өйдә булып чыкты. Кәбир аларның тәрәзә размерын язып алгач, дөнья хәлләре турында сөйләштеләр. Артур гонорар аз булуга зарланды. Нигә бездә шулай да, нигә Башкортстанда шулай имеш. Башкортларга җитәсе бар әле безнең. Алар каләм иясе турында кайгырта беләләр. Алар милли каһарманнары Салават Юлаевны да атка атландырып куйдылар. Ә бездә милләтебез азатлыгы өчен башын салган меңнәрчә каһарманнарыбыз булса да исемнәрен дә белүче юк.

Пыяла яхшы киселде. Аны трамвайда күтәреп йөреп булмас, такси алырга туры киләчәк. Көн инде кичкә авышкан. Ноябрь җылы килде. Урамда тагын җепшек кар ява.

Кәбир өйгә кереп абыйсы белән чәй эчәргә утырды.

—Сәрия кызыма велосипед алды микән?—диде Әхәт, моңсу күз карашын тәрәзәгә текәп.—Хәер, хәзер ана чана кирәктер инде.

—Хат язып җибәрәсең мәллә, абый?

—Язмыйм. Шулай да яңа ел бәйрәмендә кызны булса да күреп кайтырга исәп.

—Әти-әни дә картайды,—диде Кәбир.—Киләсе атнада кайтмыйча булмас. Абзар чистартып булса да китәрмен.

Шулай сөйләшеп утырганда кемдер капка дөбердәтте. Килер кеше юк кебек. Кем?

Чыгып капканы ачкач, Кәбир башта, әллә күземә күренәме дип, аптырап калды. Каршында Рамиләсе басып тора иде аның. Бизәнгән, өстендә ак пальто.

—Тәрәзәне кайчан куясың?—диде ул, елмаеп.

Әйе, һичбер ачуланмый. Күзләренә чак кына булса да элеккеге нур кайтып кергән кебек иде.

—Пы... пыяланы кистем инде,—Кәбир тотлыга ук башлады.—Ки... килергә җыена идем.

—Өенә чакырмыйсыңмыни?

—Әйттең сүз. Түргә уз, бәгърем!—Кәбир аны култыклап алды.

Рамиләнең монда беренче тапкыр гына булуы әле. Моңа кадәр тәрәзә ватканына үкенгән ир, кул астына килеп эләккән урындыкка күнеленнән генә рәхмәт укып, аны суыра-суыра иреннәреннән үбеп итте.

**Юл**

Кәбирдә бер ай чамасы торгач, Рамилә балага узды. Аның йөзендәге сагыш сарысы инде әкрен генә кимү ягына таба бара. Ул янадан үзенең яраткан эшенә урнашты, сирәк кенә булса да көлә, шаяра башлады.

Әхәт кенә тагын сәерләнде. Ул көннәр буе кем беләндер сөйләшеп утыра, аларны ачулана, көлә, елый. Скрипкада уйнап туйгач, аны йә караваҭ астына,

йә шкафка качырып куя. Кайвакыт скрипканы кая яшергәнен онытып, бөтен өй эчен актарып ташлый. Аны тапкач, сабый баладай сөенә, сыйпый, үбә, матур сүзләр әйтә. Кәбир табиб биргән даруны эчертә башласа, аннан качарга теләп, сәгатьләр буе юрган астында ята. Мәҗбүр итсән, үпкәли, сүгенә, тыпырчына.

Менә бүген дә Кәбир белән Рамилә эшкә киткәч, ул кемнәрнедер сүгә-сүгә, чүплектән изелеп-ватылып беткән курчак маникен алып кайтып, аны кадерләп кенә өстәлгә салды.

—Бичара Гайсә, мин сина качарга куштым, ә син качмадың,—дип пышылдады Әхәт, курчакның башыннан сыйпап. Ул тагын—Понтий Пилат.—Син Аллаһы каршында корбан булып, безне гөнаһылардан коткарырга теләдең. Пәйгамбәр булсаң да бер катлы икәнсең. Адәм балаларының гөнаһысын юып бетереп булмый. Бер ишләрен коткара алсаң да, аларның яңалары туып тора.

Мәгарәдә салкынча. Аңа керү юлы зур таш белән каплап куелган. Синедрион әһеле Иосиф белән алар яшерен юлдан гына керделәр. Табиб Никодим Гайсәнең кан саркып торган яраларына пальма мае сөртә.

—Исәнме ул?—Прокуратор иелеп колагын пәйгамбәрнең күкрәгенә куя.—Йөрәк тибеше ишетелми.

—Җаны күккә ашкан булса, яраларыннан каны саркып тормас иде, бөек прокуратор,—диде Иосиф.

—Шундый яралардан соң адәм баласын үлемнән алып калып булыр дип уйлыйсынмы?

—Булыр, чөнки ул—Аллаһының улы.

—Без барыбыз да аның уллары. Тик шунысы кызык, нигә ул синең белән мине пәйгамбәр итмәгән?

—Мөгаен, гөнаһыларыбыз күп булгангадыр.

—Китерегез миңа агачны.

Тән сакчысы Антонио Понтий Пилатка скрипканы тоттырды.

—Менә бу уен коралы да пәйгамбәр кебек,—диде Римның бирегәге идарәчесе, аны сыйпап.—Ул адәм балаларына моң бүләк итәр өчен тереләй туналган агачтан эшләнгән.

Понтий Пилат, скрипкада уйнап, әкрен генә җырлап җибәрде:

> Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә?
> Бәян ит шул хакта, пәйгамбәр.
> Кадаклар тәненне тишкәндә,
> Хакыйкать турында сөйләрләр...

Прокуратор башын иеп мәгарәдән чыгып китте.

...Тирә-юньдә трамвай-троллейбуслар, машиналар чаба. Һәркемнең үз юлы: берәүләр башын-күзен акайтып эшкә ашыга, икенчеләре үз пары белән әңгәмә корып әкрен генә урам буйлап атлый, өченчеләре авыр сумкаларын асып сүгенә-сүгенә кибеттән өстерәлеп кайта, дүртенчеләре инде иртән иртүк кайгыдан исереп аяк астында аунап ята.

Әйе, һәркемнең үз юлы. Ләкин берсе дә дөрес юлдан бармый. Аларның бу турыда уйларга вакыты юк. Күк йөзенә багып, бер генә минутка булса да мәңгелек турында уйланырга вакытлары юк. Әллә теләмиләрме?

Әхәт скрипкада уйный-уйный тимер юл буйлап атлады. Ул елый, агач та кычкырып елый. Икесе дә кичергән газаплы минутларын искә төшереп, ыңгыраша-ыңгыраша елыйлар.

> Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә?
> Ник моңсу бу җирдә, әйтсәнә!

Инде поезд кычкырта. Ул да ыңгыраша төсле, чөнки дөрес юлдан бармый. Бу юллар бик күпләрне билгесезлеккә алып киткән. Ә хәзер кая алып бара? Мәңгелеккәме?.. Юктыр, уйланмыйча, ыжгырып бара.

Әхәт тынып калды. Скрипка да тынды. Туктатырга кирәк бу поездны. Ул дөрес юлдан бармый!

—Тукта-а-а!

Машинист юлда скрипка тотып басып торган ялан башлы, хәрби бишмәтле ир-атны күреп күзләрен йомды.

Тормоз... Поезд тәгәрмәчләре инде колакларны сызлатырдай шыгырдау авазлары чыгарып рельсларда шуып бара.

Орды... Әхәтнең гәүдәсе һавага күтәрелеп, тигез итеп җәелгән вак-вак ак ташлар өстенә килеп төште. Скрипка әле оча, хуҗасын эзләгәндәй, һаман өстә бөтерелә.

—Даң-н-ң!—Әхәтнең күкрәгенә килеп төште.

Ир күзләрен ачты. Ул кап-караңгы тоннель буйлап югарыга очып бара.

Алда—күзләрне чагылдырырдай рәхәт яктылык. Анда сызлаган тәнне, колакларны иркәләп изге дога сүзләре яңгырый:

—Лә илаһә илләлаһы!

## Соңарган мәктүп

Газета редакциясенә мәкалә китереп биргәч, Кәбир кайтышлый үзенең бер танышы белән очрашты. Шактый озак сөйләштеләр. Телефонын язып алыйм дип күлмәгенең алгы кесәсенә кулын тыкса, анда бандероль алырга чакыру кәгазе ята. «Вәт, тишек баш!—дип сүкте ул үзен.—Абыйның күлмәге ич бу. Мин бит ана бу язуны өстәлгә куярга кушкан идем, ә ул күлмәк кесәсенә тыгып куйган».

Кәбир шундук почтага барып бандерольне алды. Аның эчендә кулдан тегелгән кыш бабай курчагы һәм хат ята иде. Хатны Сәрия язган.

Ачты. Хатта бала кулы белән язылган җөмләләр дә күренә.

*"Әхәт!*

*Мин сине кайтырсың, дип уйлаган идем. Җиргә инде карлар төште, ә син юк та, юк. Гаебемне беләм, кичерә күр. Кыйнасаң да түзәрмен, кызыбыз хакына булса да кайт.*

*Сагынып һәм яратып—синең Сәрияң."*

*"Әтием!*

*Хәзер минем велосипедым бар. Минем чанада шуасым килә. Илшатның чанасы бар, ә минеке юк. Без сине бик тә, бик тә сагындык. Син булмагач, минем елыйсым килә. Сиңа Яңа ел бүләге итеп үзем теккән Кыш бабай курчагын җибәрәм. Мин ана сине алып кайтырга куштым.*

*Әтием, кайт!*

*Сәлам белән кызың Гөлия."*

## Соңгы сүз урынына

... Әхәтне Шәмәрлегә алып кайтып күмделәр. Сәрия Витяга кияүгә чыкты. Ә Рамилә йөз чалымнары гел Галияне хәтерләткән матур гына кыз бала тапты. Әле генә күкнең үзеннән иңгән бу җан иясе пәйгамбәрдән кайсы ягы белән ким? Ул үзенең бер яңгыравык көлүе белән генә дә бөтен дөньяга нур чәчә. Ләкин бу фани дөнья пәйгамбәрләрне яратмый, ул аларны кайчан да булса үз төсенә буйый.

## Хәсән Туфан

### Без һаман бергә

Син ерактан күргән кырларның
Ал гөлләрен сибеп юлыңа,
Баш ия Ил,—ятимгә түгел,
Сиңа—үзенең бөек улына.

Бишенче ел таңы каршында,
Калкып чыгып тормыш төбеннән,
Кул биргәнсең
Яңа Рәсәйгә,
Сәлам китереп моңлы илеңнән.

Бүген сине
Үзе сәламли
Залимнардан азат замана...
Ничә дәвер үтте, ничә чор,—
Ә син һаман безнең арада.

Бергә кичтек
Кара төннәрне,
Бергә киттек иске дөньядан,
Җуймадык без сине беркайда,—
Заман белән бергә син һаман.

Халык гомере мәңгелек, диләр,
Ә син, Тукай, халык куенында;
Илең белән мәңге бергә син
Мәңгелекнең олы юлында!

## Гамил Афзал

### Габдулла Тукайга

Илдә туган ил улы син, илдә яндың
нур булып,
Ил күгендә яз идең син, илдә калдың
җыр булып.
Илне яклап яуга чыктың, ил иңендә
изге син,—
Җанлы иттең, аңлы иттең, данлы иттең
безне син.
Ил йөзендә күз идең син, ил уенда
аң булып;
Кичләрендә моң буласың, көннәренә
таң булып.

## Шәүкәт Галиев

### Тукайга

Тормышыңда бәйрәмнәр аз булган—
Тартыш белән тулган көннәрең.
Шуңа, ахры, искә алынмыйча
Үткән синең туган көннәрең...

Бәйрәмнәрең алда икән әле,
Кара, шагыйрь, бүген текәлеп—
Халкың килде сиңа, мәхәббәтен
Ал чәчәкләр белән күтәреп.

Син күрмәгән яңа буын килде,
Котлап бүген туган көнеңне;
Киләчәккә барган улларыңнан
Ишетәсең "Туган тел"еңне.

Буын арты буын алмашыныр,
Гасыр арты узар гасырлар.
Шигърияте һәйкәленә шулай
Язлар һаман гөлләр ташырлар.

Халык моңы—синең моңың булды,
Халык күңеле—синең күңелең.
Ил гомере, халык гомере кебек
Озын булыр, шагыйрь, гомерең!

## Илдар Юзеев

### Син яшьтәш тә, замандаш та...

Синең сының хәзер гөлбакчада
Бронзадан коеп куелган;
Мин бер вәкил булып килдем менә
Син күрмәгән яңа буыннан.
Нәрсә әйтим, Тукай,
Синең алда
Телем көчсез минем, сүзем аз.
Мин китергән чәчәк яз ясамас,—
Үзең бакча бит син, үзең—яз.
Печән базарлары,
кярханәләр...
Берсе дә юк...
Үзең дә бит күреп торасың.
"Миңа һаман егерме җиде",—диеп,
Син елмайган кебек буласың.

Үссәләр дә,
Синең даның өчен
Тарайдылар инде бистәләр,
Җырларыңны төрле-төрле телләр,
Ерак-ерак илләр ишетәләр.

Син калдырган язның гөлбакчасын
Бар күңелләр якын тоялар,
Сине хәзер безнең заманалар
Бронзадан коеп куялар.

Син яшьтәш тә, замандаш та булып,
Дөнья буйлап җырлап йөрисең,
Дөрес әйткәнсең шул,
Әйе, Тукай,
Коеп куйган гына түгелсең...

## Равил Фәйзуллин

* * *

Яздан аерып булмый Тукайны!
Язда килгән, язда ул янган.
Язы—киләчәге барлар ничек китсен,
Ничек югалалсын дөньядан?!

Язны җуймый
Кара елларда да,
Халыкның ул гүзәл гамьнәрен,
Хыялларын чорлар аша безгә—
Бүгенгегә китереп бәйләде.

Тел яшергән Тарих кына белә
Бар кылганын аның, күргәнен.
Ә шулай да булалган бит илгә
Игелеклелек кылу үрнәге.

Бу Тарихта мәшһүрләрне куйсаң
Ул яшәгән хәлгә, урынга,—
Байтагының шаулы даны түгел,
Чыкмас иде, бәлки, тыны да!

Яшәрен һәм үлемсезлеген
Дәлилләүгә мохтаҗмы халык?
Шикләнүче булса, кара, тикшер,
Бер бәгырен—Тукаен алып!

Апрель.
Кемнәр көтми ышанулар, гөлләр,
Яшәрүләр биргән бу айны?
Яздан, гаделлектән, киләчәктән
Мөмкин түгел аеру Тукайны!

# Ренат Харис

## Китмибез!

*Китмибез без, безгә анда...*
Г. Тукай

“Китмибез!”—дип әйткән шагыйрь китте...
Ләкин китте ләйсән яңгырга.
Күк гөлдерәү булып күңелләрдә
“Китмибез”е калды яңгырап.

Советларны Казан диварына
терәгәч тә китереп фетнә көз,
Вахитовлар каны ташка сеңде—
ташка сеңде каттый “Китмибез!”

Йөрәкләрдән окопларга күчте,
дошман белән килде йөзгә-йөз.
Газинурлар батырлыгы булып
яңгырады кабат: “Китмибез!”

“Китмибез!”—дип әйткән шагыйрь китте.
Ләкин китте ләйсән яңгырга...
Күк күкрәү булып күңелләрдә
“Китмибез”е тора яңгырап.

“Азат Европа”лар күңелләрне
аздырмакчы була. Безнең сүз—
корал тотып алган чикләрдән дә,
йөрәк яулап алган үрләрдән дә
бер адым да артка чикмибез.

Һич кирәкми безгә башка һава,
башка нигез безгә—чит нигез.
Кызыл байраклардан китмибез без,
яшел аланнардан китмибез.

Ил тамыры белән без тип-тигез,
сөт чишмәсе белән без игез—
сөт тамыры корган халык китә,
без яшибез әле, китмибез!

“Китмибез!”—дип әйткән шагыйрь китте...
Ләкин китте ләйсән яңгырга.
Һәр күңелдә мең мәгънәле булып
“Китмибез”е яши яңгырап.

## Рәдиф Гаташ

### Тукай урамында

Кышкы көндә, февраль буранында,
Килдем тагын Тукай урамына.
Ишелеп кар ява юлларыма.
Мәңге кояш—Тукай урамында—
Шагыйрь урамында.

Ыгы-зыгы трамвай юлларында,
Тормыш тавышы—завод җырларында,
Басып торам шулар уртасында.
Кушыла уй җилгә, буранына...
Шатлык туа Тукай урамында.

Булдым илнең күп урыннарында,
Кавказ, Себерләрдә, Уралымда.
Күп илләрдә булдым—уйларымда.
Булдым мин Бөекләр урамында...
Ләкин һаман кире кайттым монда,
Кайттым һаман Тукай урамына.

Юлларымда
Яңгыр була, җил, бураннар була,
Һаман киләм, йөрим һаман монда;
Җырлар да күп монда, бакый моң да...
Шул урамнан күрим сине, дөнья!
Булыйм мәңге Тукай урамында—
Халык урамында!

## Мөдәррис Әгъләмов

### Тукай көне

Илдә кояш,
Җирдә кояш,
Йөздә кояш, күздә кояш.
Көндәгечә көлә кояш,
Әмма бүген үзгә кояш.

Бүген аның каршысына
Канатланып чыккан бөре...
Аваз сала томшыклары:
Тукай көне!
Тукай көне!

Килә язлар, китә язлар,
Һәр ел саен үзгәрелә...
Үзгәрелә...
Һәр ел саен Тукай гына
Яшь-яшь хәлдә килә безгә.

Киңлекләрдә язгы аваз—
Чыр-чу килә кошлар иле,
Чеңләп тора аһәңнәре:
Тукай көне!
Тукай көне!

Илдә кояш,
Җирдә кояш,
Тукай көне канат җәйгән.
Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген,
Тукай көне—
Безнең бәйрәм!

## Роберт Миңнуллин

### "Әллүки"

Мондый җырны еллар, заманнар
Тыңласыннар
Һәм баш исеннәр!
Мәңгелеккә туган җырлар бар бит,
Мәңгелеккә туган исемнәр...

Заманында дөньяларын онытып
"Әллүки"не Тукай тыңлаган.
Әллә Тукай сөеп тыңлаганга,
"Әллүки"ләр һаман тынмаган.

"Әллүки"не тыңлап,
Моңлагандыр Тукай,
Елагандыр, бәлки, сиздерми.
Елагандыр...
Елатканга микән,
"Әллүки"ләр безне биздерми...

Заманалар белән бергә һәрчак
Безнең җырлар дөрләп яналган.
"Әллүки"не һәр тыңлаган саен
Мин Тукайны уйлыйм яңадан.

Моң агыла, моң кагыла җанга—
Әллә тылсым инде, әллә көй?!
Нәкъ Тукайны тетрәндергән кебек,
Тетрәндерә мине "Әллүки"!

*Тукай турында олуг шәхесләр*

Абдулла Арипов,
үзбәк шагыйре:

***Тукай татар халкының гына түгел, ә бәлки барлык төрки халыкларның, шул исәптән үзбәк халкының да сөекле шагыйре булып санала. Тукайның теле дә, Тукай әсәрләренең рухы да безгә гаять тә үз, гаять тә якын, аның сазы моңнары безнең күңелләрдә дә аваздаш яңгыраш таба. ...Тукай һәм башка татар язучыларының иҗаты Үзбәкстан җиренә демократик фикерләрне, алдынгы карашларны үткәрүче бер күпер булды дисәк, шәт бер дә ялгышмабыз сыман.***

# ЕРАКТА ДА ЯКЫН ТУКАЙ

Безнең Кол Гали һәм Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр һәм Утыз Имәни, Кандалый һәм Гафури, Такташ һәм Җәлил кебек бөек шагыйрьләребез бар. Әгәр дә бу затларны җыеп, татар шигъриятенең таҗ-тәхетен кемгә бирик дип сорасаң, алар мона, һичшиксез, Тукай лаек дип санарлар иде. Киресе булган очракта да, Кырлай егете барыбер шаһ-шагыйрь, дисбе төймәсенең Мәрьям анасы булып калыр иде. Чөнки ана мондый могтәбәр урынны халык үзе, язмыш биргән. Аның халык тарихыннан, хәтер төпкеленнән чабып килгән ашкынулы паратлары Вакыт белән бергә һаман алга бара, күңелләрне яшәүгә дәртләндерә. Тукай—үзенең чордашлары, киләчәк буыннар өчен генә түгел, ә татарлыкның, миллилекнең олуг бер символы да. Татар дигәндә Тукай, Тукай дигәндә татар искә төшә. Алар, ничектер, сиам игезәкләре кебек, бер төшенчә буларак күзалланалар.

* * *

Рәчәй тарихы гомер-гомергә сугыш, канкоюларга бай. Әйтерсең, бу мәмләкәт аларсыз яши алмый. XX йөзнең беренче яртысында исә орыш-җанкыюлар хәддин аша. Шуның нәтиҗәсендә Евразия киңлекләрендә гомер кичерүче күп кенә адәм балалары, халыклар, аеруча татарлар, мәхшәри газапларга түзә алмыйча, таралырга, сибелергә мәҗбүр ителәләр. Аларның шактый өлеше чит илләргә качып, күчеп китә яисә әсирлектән Ватанына кайтмыйча кала. Шунысы гыйбрәтле: Идел-йортта туып-үсеп, мөһаҗәрәткә эләккән милләттәшләребез, кайда гына яшәүләренә карамастан, күңелләре, зиһен-хәтерләре белән туган халкыннан, кендек каны тамган туфрагыннан аерылмыйча, татарның телен, моңын, сүз сәнгатен, гореф-гадәтләрен, кыскасы, аның барлыгын, менталитетын сакларга, алдагы буыннарга җиткерергә тырыша. Шуны күздә тотып, төрле чаралар уздыра, юк мөмкинлеген бар итеп, газет-журналлар чыгара, китаплар бастыра. Бу изге эштә Тукай милли байрак һәм символ вазифасын да, халык рухының бетмәс-төкәнмәс чыганагы ролен дә, сибелгән-таралган милләт балаларын берләштерүче магниттай көч функциясен дә үти.

Татарлар яшәгән һәр төбәктә диярлек Тукайның туган-үлгән көннәре төрле кичәләр, аш мәҗлесләре, лекция-конференцияләр рәвешендә уздырыла. Аларда шагыйрь әсәрләрен сөйләү, аның сүзләренә язылган җырларны көйләү, милләт язмышы турында фикерләр алышу еш күзәтелә. Мәсәлән, Хельсинкида Тукайның туына 100 ел тулуга багышланган махсус кичә уздырыла (25.10.1986). Аның программасы, сценарие китапчык рәвешендә дә басылып чыккан. Анда Тукай әсәрләреннән ("Гали белән кәҗә", "Яз галәмәтләре", "Көз", "Туган авылым", "Пар ат", "Туган тел" h.б.) өзекләр урнаштырылган. Шагыйрьгә багышланган шигырьләр, җырлар да бар. Гәүһәр Туганай Тукайны "күктә янып торган йолдыз", шигырьләрен "алтын-бриллианттан кыйммәтле" дип бәяли. Син үлсәң дә, - ди шагыйрә, - күңелләребездә "мәңге яшисең". Мөһаҗәрәттә Тукай исемендәге төрле оешмаларның һәм җәмгыятьләрнең эшләве дә мәгълүм. Мәсәлән, 1963 елда Истанбулда Тукай гәнечлек (яшьләр.—Х.М.) клубы эшли башлый, 1965-1968 елларда "Тукай бюллетене" чыга (барлыгы—24 сан). Ул, шагыйрь иҗатын пропагандалау белән беррәттән, татар мәдәниятен өйрәнү, яшьләрне милли рухта тәрбияләү белән дә шөгыльләнә. Шушындый ук вазифаларны үзенең төп бурычы итеп куйган "Тукай җәмгыяте" узган гасырның 60-80 нче елларында Финляндиядә дә эшли. Аның белән күренекле милләттәшебез, Хельсинки университеты профессоры Гомәр Таһир (Даһер) җитәкчелек итә. Бу мөхтәрәм затның тырышлыгы аркасында Татарстаннан Суомига күпләгән артистлар, галимнәр, әдипләр чакырыла, милли рухлы күп төрле чаралар үткәрелә. Хәзер бу игелекле эшне Гомәр аганың улы, Финляндиядәге "Ислам җәмгыяте"нең президенты Окан әфәнде бик уңышлы дәвам иттерә.

Мөһаҗәрәттәге татарлар, илдә басылган китапларны файдалану белән бергә,

үзләре дә шактый гына әсәрләрне, дәреслек-әсбабларны нәшер кылалар. Болар арасында Тукай язмалары мөһим урынны били.

Токиода татар мөһаҗирләре нигезләгән "Матбагаи исламия" 1933 елда гарәп хәрефләре белән бөек әдипнең әсәрләрен биш томда түбәндәге исем белән бастырып чыгара (Барлыгы—646 бит): "Габдулла Тукай. Мәҗмугаи асаре. Мәрхүм милли шагыйремезнен вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәте илә хатирә уларак басылды. 1913-1933". Күптомлык техник яктан шактый сыйфатлы, рәсем-иллюстрацияләр дә очрый. Һәр том азагында берәр бит япунча язмалар да бар. Томлыклар Җәмал Вәлидинең 1914 елда төзегән текстына нигезләнгән. Әсәрләрнең урнаштырылышы түбәндәгечә: I том (бүлем) - "Житди шигырьләр", II том—"Балалар кыйсеме", III том - "Көлке вә һөҗү (сатира-юмор.—Х.М.) кыйсеме", IV том - "Нәсер кыйсеме". V том - "Тәрҗемәи хәле". "Тукаевнын шигырьләре хакында мөляхәзәләр (фикер-күзәтүләр, тәнкыйть.—Х.М.)" һәм "Тукаев тугрысында матбугат" бүлекчәләреннән гыйбарәт. Биредә Ж.Вәлидинен үз язмалары гаять кызыклы һәм тирән. Шулай ук Тукай хакында әйтелгән фикерләр дә гыйбрәтле. Мәсәлән, Ризаэддин Фәхреддин "Вакыт"та Тукайны "заманымызның Мәгаррие" дип атаган (100 б.). Бакуда чыга торган "Икбал" газетасы "татар әдәбияты буна кадәр Тукаев кадәр бер шагыйрьне күрмәде һәм бундан соң да күрмәячәк",—дип яза (103 б.) "Төрек йорды"ның (журналының.—Х.М.) бер номеры Тукай үлеменә багышлана. Анда Фуад Күприлезадәнең озын бер мәкаләсе булуы искәртелә. Шулай ук "Ислам дөньясында", "Тасвире әфкяр" басмаларында да Тукай турында язмалар бар (104 б.) Шушында ук Тукайның русча басылган "Изгнанник" (Нәсыйхәт) шигыре (Когда к дверям твоим придет бедняга, И помни: может быть то был Илья пророк) фарсы классигы Сәгъди парчасы белән дә чыгыштырыла, алар арасында охшашлык булуы әйтелә.

Япуния башкаласында бөек шагыйрьнең 1930 елда "Юаныч" исемле җыентыгы чыгуы да мәгълүм. Анын "Бер-ике сүз" дип исемләнгән кереш мәкаләсендә мондый юллар бар: "Хәзерге көндә анын (татарның.—Х.М.) мәдәният вә әдәбиятын караңгылык вә болыт каплаган, вә мең еллык мәдәни вә әдәби тарихы хезмәте бик зур зарбка (кыйналуга, һөҗүмгә.—Х.М.) очраган булса да, төннән соң көн вә авырлыктан соң йинеллек киләчәгенә ышанычыбыз камилдер. Милләт үзе бетмәсә, анын тел вә әдәбияты бетмәс, тел вә әдәбияты бетсә, ул милләт дөньяда яшәмәс (ассызык безнеке.—Х.М.). Милләтебезнең яшәвенә иманыбыз безне анын әдәбиятын сакларга чакырадыр... Шул фикер вә ышаныч берлән без бу юлы татар әдәбиятыннан беренче мәртәбә уларак шагыйребез Габдулла Тукайнын "Жуаныч" атлы әсәрен басабыз". Китапта "Су анасы", "Таз", "Ата илә бала", "Яхшы хәбәрләр", "Тургайлар ашыйбыз" шигырьләре урнаштырылган. Рәсем-иллюстрацияләр дә бар.

Финляндиядә яшәгән Хөсәен Садыйк (1906-1973. Ул үзе шагыйрь дә) 1969 елда Хельсинкида Тукай мәжмугасын нәшер итә (102 б.). Чыганакларда шагыйрь әсәрләренең Икенче бөтендөнья сугышыннан сон Алманиядә басылып чыгуы да искәртелә.

Узган гасырда Харбин, Хайлар, Токио, Киото, Өремче, Хельсинки, Тампере һәм чит мәмләкәтләрдәге кайбер башка калаларда татар мәктәпләренең эшләве билгеле. Аларда Тукай иҗатын өйрәнүгә зур урын бирелә. Педагогик ихтыяжны күздә тотып, төрле дәреслек-әсбаплар да төзелә. Бу яктан аеруча шагыйрә Сания Гыйффәт язган "Уку китаплары" игътибарга лаек. Аларда бөек шагыйрьнең "Пар ат", "Исемдә калганнар" һәм башка бик күп әсәрләре урын алган. 1953 елда Тукайнын "Мәктәптә милли әдәбият дәресләре" исемле мәшһүр хрестоматиясе дә кабат басыла (Хельсинки.—138 б.).

Мөһаҗирлектәге татарча гәҗит-журналларда да шагыйрь әсәрләренә зур урын бирелә. "Яна милли юл" еш кына Тукайнын ижтимагый-милли, сәяси рухлы юлларын мәжмугага эпиграф рәвешендә дә урнаштыра. Мәсәлән:

*Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,*
*Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары...*

(1932.—№5)

*Юк, кояшым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә,*
*Син дә, вөҗдан, бер торырсың: ятмагансың мәңгегә.*

*Юк, түбән калмас бу җан: фитърәтдә гали (тугмыштан олы.—Х.М.) булган ул.*
*Кисмәк өстендә—кара кош иттифакый (очраклы гына.—Х.М.) кунган ул.*

(1938.—№3)

Тукайга аеруча 1970-1980 елларда Төркиядә нәшер ителгән "Kazan" журналы зур урын бирә. Татар мөһаҗирләре тарафыннан чыгарылган бу мәҗмуганың һәр санында (барлыгы—23 сан) диярлек бөек шагыйрьгә мөнәсәбәтле материаллар бар. Мәсәлән, 7-8 саннарда (1972) "Шиһаб хәзрәт", 10 нчы санда (1973) "Шагыйрь", "Өзелгән өмид", "Кемнән ярдәм эзләргә?", 12 санда (1974) "Мөхәрриргә" (Анын Г.Исхакыйга багышлануы да искәртелә), 14 нче санда (1975) "Таз", "Теләнче", "Нәсыйхәт", "Театр", 17 нче санда (1976) "Су анасы", "Кадер кич" шигырьләре татар һәм төрек телләрендә басылган. (Тәржемәчесе—Наилә Бинарк) Шагыйрьнең рәсемнәре, әсәрләренә иллюстрацияләр дә бирелеп бара.

Чит илләрдә Г.Тукайның китапларын, әсәрләрен бастыру, пропагандалау белән бергә, аның хакында гыйльми-тәнкыйди язмалар, уйлану характерындагы мәкаләләр дә дөнья күрә. Бу төр материаллар аеруча "Яңа милли юл" журналында күп [Бу хакта карагыз: Х.Й.Миңнегулов а) "Яңа милли юл" журналы һәм Тукай // Казан утлары.—2002. - №1.—168-179 б; б) Тукай турында Исхакый кызы / КДУның фәнни язмалары: 2001.—Казан: Школа, 2002.—246-253 б.; в) Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты.—К.: Таткитнәшр., 2004.—268-288 б.]. Һәр елны диярлек мәҗмуга Тукайның тууына һәм үлеменә мөнәсәбәттә мәкаләләр урнаштырып бара. Алар Г.Исхакый, Сәгадәт Чагатай, Солтан (Әхмәд Виргаз), Хөсәен Габдүш, Шаһвәли Келәүле (Илдәр) һәм башка милләттәшләребез тарафыннан язылган. Аларда барыннан да элек Тукайның "милли шагыйрь", "милләт хезмәтчесе" булуына басым ясала. Әдипнең вафатына "25 ел тулу мөнәсәбәте илә" язылган бер мәкаләсендә (Яңа милли юл.—1938.—№4.—1-9 б.) Г.Исхакый Тукай хакында болай ди: "Үзенең мохитенең шатлыгын, кайгысын, дәрден шигырь төсенә сугучы бер тел остасыдыр. Аның яшәгән, язган дәвере бездә милләтчелекнең ин кайнаган, милли теләкләрнең берсе өстенә берсе үсеп, тирә-якны тутырган вакыт булганга, ул шул теләкләргә, шул омтылышларга бер шигырь төсе бирүче, чуалчык фикерләрдән туган агымларга тугры юл күрсәтергә теләүче милләт хезмәтчесе, милли шагыйрьдер... Бөтен кыска гомере буенча ул... милли юлдан һичбер тайпылмаенча, кабергә кадәр милләт ерын ерлап, милләт кайгысын көйләп, милләт көлкесендән көлеп, үзенең милләтчелек калыбына сугып киләдер." Белүебезчә, Тукай Исхакыйның бөеклеген, милләт юлында никадәр олуг эшләр башкаруын таныган. Үз чиратында "Инкыйраз" авторы да Кырлай егетенең татар яшәешендә, милли барлык, хөрлек өчен көрәштә бөек бер көч, рухландыргыч әләм, символ булуын бик яхшы аңлый һәм гомере буена ана ихтирамын, хөрмәтен белдереп килә.

Г.Исхакыйның кызы Сәгадәт Чагатай язмаларында да (Яңа милли юл.—1936.—№6.—14-17 б.; 1938. - №4.—9-14 б.) Тукай милли, инсани яссылыкта карала. Аның фикеренчә, шагыйрь милләтне бергә туплаучы, "илне" танытучы "бөек мәгънәви байлык", татар яшәешенең бер символы, милләтнең "күңел көзгесе". "Тукай, - ди ул, - бүген яшемезне, картымызны үземездән меңләрчә чакрым ераклыкта булган илемез берлә шундый оста баглап тора ки, без аңардан да куәтле бер милли багны мөһаҗирлектә күрсәтә алмыйбыз. Илдән читтә торып үскән яшьләр Тукай аркылы илне таныйлар... Җәмгыяте хәятемездә, кичәләремездә Тукайның йөрәккә кереп утырган берничә шигыре янә дә милли аң вә рух бирү өчен җитәдер".

Мөһаҗир татарлар арасында Тукайга иң мөкиббән киткән затларның берсе, мөгаен, Хөсәен Габдүшдер (1901-1944). Ул—әдип, мөгаллим, артист, режиссер, драматург ("Үги кыз"—4 пәрдәдә, "Балалар күнеле"—1 пәрдәдә һ.б.), журналист, Ерак Шәрыктагы, аеруча Кытайдагы милләттәшләребезнең яраткан, хөрмәт иткән улы. Кайбер фактлар аның Тукай әсәрләренең биштомлыгын чыгаруда да катнашы

барлыгын күрсәтәләр. Мөһаҗәрәттәге татар матбугатында бу зат бөек шагыйрь хакында шактый гына мәкаләләр бастыра. Ул 1932 елда Харбинда Тукайның үлеменә 20 ел тулу алдыннан шагыйрь турында "программ" характерындагы бер китап та нәшер итә. Шулай ук Хөсәен Габдүш катнашында 1938 елда "Габдулла Тукай" исемле янә бер китап дөнья күрә. Шагыйрьнең үлеменә 25 ел тулу унае белән чыгарылган 98 битлек бу мәҗмугада 20 мәкалә, шигырьләр булуы искәртелә. (Кызганыч ки, бу ике китап та безнең кулыбызда юк).

Хөсәен Габдүшнең "Бөек Кушлавыч ятиме" исемле мәкаләсе (Яңа милли юл.—1936—№5.—4-8 б.) гыйльми-тәнкыйди, публицистик, лирик-эмоциональ башлангычларның синтезын хәтерләтә. Язма шагыйрьнең исем-тәхәллүсе хакында уйланулардан башлана. "Аның исеменнән үк,—ди мәкалә авторы,—халкыбызның үзлегендән аерып алынмас бер нота янгырый: Тукай! Ата-анасы кушкан исеме—халкыбыз арасында иң күп таралган вә сөелеп әйтелә торган исем—Габдулла. Тукай—бу Габдулланы башка бик күп Габдуллалардан аерып, аны "Кечкенә Апуш"лыгыннан аерып, "зур-зур" төрк-татар шагыйре дәрәҗәсенә күтәргән исеме дә арабызда сирәк очрый торган саф үзебезчә, милли бер исем..."

Хөсәен Габдүш фикеренчә, Тукай һәм татар—игезәкләр кебек. Автор шагыйрь әсәрләренең яшәүчәнлегенә басым ясый. "Безнең милли аңыбыз, милли хисебез, үсә барып, мәгънәви тормышыбызның офыклары киңәя вә тәҗрибәбез арта барган саен,—ди ул,—Тукай шигырьләре күбрәк аңлана барачаклар".

Истәлекләрдә Хөсәен Габдүшнең һәр ел апрель аенда бөек шагыйрьгә багышлап әдәби-музыкаль кичәләр оештыруы әйтелә. Шундый кичәләрнең берсендә, ягъни 1944 елның 14 апрелендә ул сәхнәдә йөрәге тотып вафат була. Бу уңай белән аның дусты Солтан "Хөсәен Габдүшкә" дигән махсус мәрсия яза. Анда мондый юллар да бар:

*Син безгә милләт өчен кирәк идең,*
*Синең кебек милләт сөюче сирәк иде,*
*Күңелеңдә янып торган милләт уты*
*Безнең өчен һәрвакытта үрнәк иде.*

*Каләм белән бизәкләдең телебезне,*
*Ил белән багладың син күңлебезне.*
*Чит илләрдә, ерак илдә яшәсәң дә,*
*Милли эшкә чакыра идең син бит безне.*

*Күңел әрни: сине бүген югалттык без—*
*Милли тәсбих төймәсеннән өзелдең син.*
*Милли иман көчле иде күкрәгеңдә,*
*Милли эшче, милли көрәшче син идең—син...*

Хәзерге төрк-татар дөньясының билгеле шәхесе, профессор Надир Дәүләт тә заманында Тукай иҗатын өйрәнү белән шөгыльләнгән. Аеруча аның "Kazan" журналында басылган "Казан төркләре һәм Габдулла Тукай" исемле язмасы (1971.—№3.—6-12 б.) игътибарга лаек. Милләттәшебез үз мәкаләсен "бөек халык шагыйребез",—дип башлый. Тукай,—ди ул,—СССРдагы һәм читтәге татарлар арасында "иң бөек мәртәбәдәдер". "Сөембикә манарасы казанлыларның истикъляль (азатлык, бәйсезлек.—Х.М.) символы булса, Тукай да татар халкының әдәби бер символыдыр". Алга таба Надир Дәүләт шагыйрьнең өйрәнелү тарихына кыскача күзәтү ясый. Ф.Күприлезадәнең "Төрк йорды" журналында (1913.—497-515 б.) Тукайны "ислам дөньясының зур шагыйре" дип атавын, соңгы ун елда Габдулла Баттал, Рәшит Рәхмәти Арат, Әхмәд Тимер, Зөлфикарларның шагыйрь хакында мәкаләләре басылуын телгә ала. Шулай ук язмада Тукайны өйрәнүче башка галимнәр дә атала, китаплары басылуы, кичәләр уздырылуы искәртелә. 1965 елда,—ди ул,—Анкарада Гали Акыш, Сәйдә Арсланбәк, Наилә Бинарк тарафыннан "Тукай бәйрәме" исемле брошюра чыгуы һәм Наилә Бинарк язган "Тукайның вафаты"

исемле драманың 1965 елның 22 нче маенда сәхнәгә куелуы әйтелә. Н.Дәүләт үз мәкаләсен Тукай—"милләтнең баш таҗы" сүзләре белән тәгалли.

1952-1953 елларда Мюнхендә нәшер ителгән "Азат Ватан" журналында да Тукай исеме еш күзәтелә. Татар әдәбиятына күзәтү рәвешендә язылган бер мәкаләдә (8-10 нчы саннар) Тукайга зур урын бирелә. Германиядә Гёте, Россиядә Пушкин, Англиядә Байрон нинди урынны алып торса, Тукай да татар әдәбиятында шундый ук урынны били,—ди автор ("Арча малае"). Шагыйрь иҗаты идея-тематик яктан төркемләп тикшерелә. Тукайның гадәттән тыш сәләтле булуына, тел-стиленең үтемлелегенә басым ясала, аның сатира-юмор өлкәсендәге осталыгы ассызыклана. Мәкалә авторы фикеренчә, Тукай—шагыйрь—көрәшче, хакыйкатькә, яктылыкка омтылучы.

Шагыйрьнең шәхесе, әсәрләре һәм гомумән эшчәнлеге мөһаҗәрәттәге каләм әһелләрен иҗатка да илһамландыра, аларның язмаларында теге яки бу дәрәҗәдә урын ала. Хөсәен Габдүшнең "Нидән мин кечек Апуш түгел..." исемле әсәре турыдан-туры Тукай белән бәйләнешле. Аның хикәяләрендә шагыйрь яшәгән "номерлар", ул тасвирлаган "шүрәлеләр" һ.б.лар телгә алына. Кореяда туып, Төркиядә яшәгән, узган гасырның 70 нче елларында бераз вакыт Финляндиядә татар балаларын укыткан Наилә Бинарк Тукайга мөнәсәбәтле берничә сәхнә әсәре яза: "Тукайның хәяты" (4 пәрдәдә), "Тукайның хатасы" (Әкият. Бер пәрдәдә), "Су анасы" (2 күренештә), "Мәдрәсәдә булган бер малай" һ.б.

Мөһаҗир шагыйрьләрнең Тукайга багышлап язылган махсус шигырьләре дә бар: Гәүһәр Туганай. "Тукайны сагыну", "Бөек шагыйребез Габдулла Тукайга"; Нәркиз Дәвеш. "Тукайга хөрмәт белән" һ.б. Дөрес, бу төр парчаларда сәнгати кимчелекләр, ритмик төгәлсезлекләр еш очрый. Әмма фикри яктан аларда бөек шагыйрьгә хөрмәт, иҗатының халык рухы белән бәйләнеше, үлемсезлеге ачык сизелеп тора. Мәсәлән, Минһаҗ Исмәгыйли Тукайны "йолдызыбыз", "даһи", ди, аны дөнья әдәбиятының олуг классиклары белән янәшә куя:

*Син бит Данте, син бит Гёте,*
*Син бит Байрон татар халкына.*

Тукай традицияләре аеруча Хәсән Хәмидулла (1900-1988) иҗатында көчле. Мәгълүм булганча, бу зат чыгышы белән Сергач төбәгендәге Актук авылыннан, Рәшит Ваһапов, Хәйдәр Бегичев, Рифат Фәттаховларның якташы. 1915 елда ул Финляндиягә күчеп килә. "Мәгърифәт" гәҗитен, "Шималь очкыннары" журналын чыгара, "Коръән" һәм аның тәфсирләрен бастырып тарата. Хәсән Хәмидулла—күпләгән китаплар авторы. Алар арасында шигърият тә, чәчмә һәм сәхнә әсәрләре дә бар.

Хәсән Хәмидулла да, нәкъ "Шүрәле" авторы кебек, милләт тематикасын, татарны хөр, белемле, әхлаклы, бәхет-сәгадәтле итү проблемасын үзәккә куя, "Коръән"не, элеккеге рухи-әхлакый кыйммәтләрне үз иҗатында иркен файдалана.

*Милләтем, кодрәтем, син минем бөтен дәртем,*
*Син кайгырсаң—мин кайгырам, син бит минем милләтем.*
("Милләт маршы")

*Сөям мин бик татарлыкны, татар булып үлим, Раббым,*
*Сүгән бер эшне эшләү берлә мин гомремдә тәм таптым.*

*Күченмәк юк бу фикеремдән, оялмыйм һич татарлыктан,*
*Үкенмим, сакласын Аллам, мине андый начарлыктан.*
("Куанычым")

Тукай файдаланган күпчелек шигъри үлчәмнәр, жанрлар, поэтик шәкелләр Хәсән Хәмидулланың әдәби мирасында да бар. Хәтта Суомидагы милләттәшебезнең аерым парчалары ("Тәрәддед вә шөбһә", "Булмаса", "Мөнафикъка" һ.б.) бөек әдип

әсәрләренең атамалары кебек исемләнгән дә. Шагыйрь урыны белән Тукай әсәрләренә сылтамалар да ясый: "... Гадәт бездә җыйналу бер кибеткә йә трактирга, "Печән базары" дип йөртә Тукай шуларны шигырендә." "Туган тел" авторы кебек, Хәсән Хәмидулла да фольклор әсәрләрен туплый, өйрәнә, бастыра, аерым шигырьләрен халык көйләренә туры китереп яза: "Күнелгә" ("Ак каен" көенә), "Төшде яфрак" ("Әй мөкаддәс" көенә), "Уян, бәгърем" ("Уян, татар" көенә) һ.б.

Мөһаҗәрәттә гомер кичергән милләттәшләребезнең шактый өлеше үзләре яшәгән илнең, үзләре аралашкан халыкның телен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен теге яки бу дәрәҗәдә үзләштерәләр. Мәсәлән, Рәшит Рәхмәти Арат, Әкъдәс Нигъмәт Курат, Садрый Максудый, Хәсән Хәмидулла, Хәмит Зөбәер Кошай, Сәгадәт Чагатай, Надир Дәүләт, Окан Таһир һәм башка күренекле затларның күпләгән телләрне белүләре мәгълүм. Япуниядә туып-үскән, хәзер Төркиядә яшәүче Фазыл Агишның япуннар белән иркенләп сөйләшкәнен минем үземнең дә күргәнем бар. Финляндиядә яшәгән һәм яшәүче милләттәшләребезнең барысы да диярлек фин һәм швед телләрен камил белә. Мондый шартларда мөһаҗир татарлар, үзләре теләсә дә, теләмәсә дә, халкыбызны, аның рухи байлыкларын билгеле бер дәрәҗәдә башка кавемнәргә танытучы, илләр, халыклар арасында аралашу, дуслык күперләрен салучы вазифаларын да башкаралар. Аларның катнашында яисә тәкъдиме белән Тукай шигырьләре дә аерым телләргә тәрҗемә ителә. Наилә Бинарк бөек шагыйрьнең дистәләгән әсәрен төрек теленә күчерә. Г.Исхакый киңәше белән Тукайның берничә шигыре поляк, гарәп, француз, алман телләренә тәрҗемә ителә. Минһаҗ ага Исмәгыйли сөйләвенчә, Кырлай егетенең аерым парчалары мөһаҗир милләттәшләребез катнашында япун, кытай, инглиз телләренә дә күчерелгән. Әмма бу төр факт-мәгълүматлар әле юньләп барланмаган, тикшерелмәгән.

Төрек галимәсе Фатма Өзканның Г.Тукай хакында монография язуы, аның шигырьләрен төрекчәгә тәрҗемә итеп, 1994 елда Анкарада 958 битлек китап рәвешендә бастыруы күпләргә мәгълүм. Ә бит бу эшнең башында Фатма ханымның гыйльми җитәкчесе, остазы, күренекле милләттәшебез Әхмәд ага Тимер (1912-2003) тора. Чөнки бу зат, үсмер вакытта ук туган җиреннән китсә дә, гомере буе татар теленә, әдәбиятына тугры кала.

Мөһаҗирлектәге татар әдәбияты һәм Тукай—бу гаять зур һәм тиешенчә өйрәнелмәгән тема. Без бу язмада аның аерым тармакларына, буыннарына гына тукталдык. Тагын шунысы да бар: без Советлар Берлеге таркалганнан соң аның җирлегендә барлыкка килгән илләрдәге (Үзбәкстан, Казакъстан, Кыргызстан, Төркмәнстан һ.б.) татар әдәбиятына бөтенләй кагылмадык. Ә бит аларда безнең сүз сәнгате, аеруча Тукай киң таралыш тапкан, ул җөмһүриятләрдәге әдәбиятка көчле тәэсир иткән. Бу хакта Садреддин Айни, Сабит Муканов, Гафур Голәм, Берды Кербабаев, Самед Вургун, Чыңгыз Айтматов, Олжас Сөләйманов һәм башка күренекле әдипләрнең бик тә мәгънәле, кызыклы фикерләре бар. Миңа Тукай шигырьләрен яттан сөйләгән кыргыз, үзбәк, казакъ, төрекмән, таҗик зыялылары белән берничә мәртәбә очрашырга туры килде.

* * *

Халыкта "Күздән ераклашса, күңелдән дә ераклашыр" дигән мәкаль бар. Әмма Тукай, Исхакый, Җәлил кебек бөекләр моннан чыгарма булып тора. Алар инде якты дөньядан китеп, күздән югалсалар да, күңелдән һич тә китмиләр. Тукай да илдәгеләр өчен генә түгел, ерактагы милләттәшләребезгә дә һәрчак үз һәм якын.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ**

*Тукай турында олуг шәхесләр*

## Фатыйма Өзкан,

төрек галимәсе:

***Г.Тукай, башка төрки халыклар кебек үк, Казан татарларының да тормышы авыр иҗтимагый сәяси вәзгыять хөкем сөргән чорда—XIX гасыр ахырында, XX йөз башында яшәгән. Ул, Казахстанда—Абай, Үзбәкстанда—Чулпан, Әзербайҗанда Сабир һәм Төркиядә Мәхмәт Гакыйф кебек, милләтенең кыен язмышын үз йөрәге аша кичергән шагыйрьләрнең берсе. Яшь Тукайның гомере ятимлектә үткән. Тукай иҗат итүне үзен бу тормыш белән бәйләүче бердәнбер чара итеп санаган һәм аны яшәү рәвешенә әвереллергән.***

***Ни кызганыч, нибары 27 яшендә үлемнең салкын җиле аны бу дөньядан аерып ала. Шулай да, санауны гына еллар дәвам иткән иҗат гомере эчендә ул озын бер гомергә җитәрлек әсәрләр язып калдырган.***

***Дөньяга карашлары һәм сәяси омтылышлары ни дәрәҗәдә үзгәрәчәге безгә нәмәгълүм булса да, Тукайның иҗат потенциалы нинди зур куәткә ия булуын күзаллау кыен түгел. Бу яшьтә күп кенә шагыйрьләр үзләренең иҗат юлларын әле башлаган гына булса, Тукай халыклар күңеленә нык кереп урнашкан әсәрләр тудырган бөек шагыйрь булып танылырга өлгерә. Әдәби кыйммәте ягыннан аның хәтта тәрҗемәләре дә оригиналга караганда да мөкәммәлрәк. Шушы сыйфаты гына да Тукайның никадәр югары шигъри осталыкка ирешкәнен раслый. Татар әдәбияты тарихчылары үзләре үк язганча, бу җәһәттән Тукай белән һичкем ярыша алмый.***

***...Тукай шәхси тормышын, шәхси кичерешләрен сурәтләгән әсәрләрендә үзен көчлерәк, иркенерәк хис итсә дә, иҗатында ул беренче урынга җәмгыятьне борчыган иҗтимагый проблемаларны куя, милләт алдында килеп баскан кичектермәс мәсьәләләрне күтәрә. Тирә-як мохитне чорнап алган тискәре күренешләрне тәнкыйтьләүне дә ул үзенең намус эше дип саный. Мондый әсәрләрнең кайберләрендә берьяклылык та күзгә ташлана. Вакыт-вакыт ул үзенең иҗат кешесе булуын да онытып, үзе дә сизмәстән башы-аягы белән сәясәткә кереп бата. Ләкин ни генә булмасын, Тукайның шигырьләре ихластан һәм хаклыкны, гаделлекне яклап язылган булуы белән төньяк төркиләр арасында киң тарала, гади халык тарафыннан яратып кабул ителә. Аның күп кенә шигъри юллары мәкаль һәм әйтемнәргә әверелеп телдән-телгә күчеп йөри.***

***Төрек әдәбият сөючеләре арасында Тукай XX йөз башында ук танала башлый. Моны Казанлы Аббас дигән бер әдипнең "Төрек Дәрнәге" мәҗмугасында дөнья күргән "Татар әдәбияты тарихы" дигән язмасы, Фуат Көпрүлүнең "Төрек йорты" журналында басылган "Габдулла Тукаев" исемле мәкаләсе һәм башкалар раслый. Мәгълүм булганча, Советлар берлеге заманында СССР белән Төркия арасында тимер пәрдә корыла, шул сәбәпле бөтен әдәби-мәдәни бәйләнешләр өзелә. Соңгы 20 елда гына Төркиядә төрки халыклар әдәбиятына, шул исәптән Тукае булган татар әдәбиятына карата кызыксыну яңадан уяна башлады һәм бу кызыксыну елдан-ел артыр дип ышанасы килә.***



*"Бәләкәй Тукай". Рәссам Х. Казаков.*
*1958 ел.*



*"Бәләкәй Апуш һәм Сәгъди абзый".*
*Рәссам Л. Фәттахов.*
*1970 ел.*



*"Былтыр һәм Шүрәле".*
*Скульптор Г. Зяблицев.*
*1957 ел. Майолика.*



*"Шагыйрь Г. Тукай". Рәссам Е. Симбирин.*
*1976 ел.*



*"Тукай һәм Шүрәле". А. Абзгилдин.
1976 ел. Керамика.*



*"Шагыйрь. Тәфтиләү". Рәссам И. Әхмәдиев.
1976 ел.*



*"Шагыйрьнең туусы". Рәссам А. Абзгилдин.
2001 ел.*

## Джованни Жерманетто

итальян язучысы

### Туры Тукай

*(Өзек)*

**Юк, үлмәдең, галыллы ир, мәшһүр Тукай!
Тавышың яши кабатланып һәр буында.
Халкың кебек бөек, матур җырларыңдай
Даһилыгың яңгырап барыр гасырларга.
Ялагайлык пәрәвезен тоттың тупка,
Туры булды юлың, ныклы һәр адымың.
Эзләмәдең шөһрәт, охшап Геркулеска,
Каршы тордың үчкә, шүрләтеп дошманың.
"Хөр Россия—безнең бөек максат",—диеп,
Чакырдың син үз халкыңны, янып-көеп...
Ил куенында үсә бүген Татарстан.
Урманнары шаулый; иркен басу, кыры.
Фикере айнык: дус гаилә булып халык
Бөтен җирнең бәхте өчен бергә эшли.
Көчле фәннәр, якты сәнгать, ирек алып,
Язгы тополь кебек үсә гөрли-гөрли.
Шигырьләрең яшен булып кара төндә,
Ватан өчен сугышканда безнең сафта,
Ишетәм, Тукай, чакыру тавышыңны мин дә
Байрак тотып җиңү даулап барган чакта...
Юк, үлмәдең, гакыллы ир, мәшһүр Тукай!
Тавышың яши кабатланып һәр буында,
Халкың кебек бөек, матур җырларыңдай
Даһилыгың яңгырап барыр гасырларга.**

***Н. Хәмит тәрҗемәсе.***

## Җәлил Камалетдин

Гыйрак шагыйре

### Багдадтан сәлам!

**(Өзек)**

**Күкнең зәңгәр нурларының фонтанына,
Сиңа, Тукай, шигъриятнең ал таңына,
Ерак Ефрат буйларыннан, Багдадымнан
Йөрәгемне алып килдем мин янына!**

**Озак юлның газапларын йөкләп иңгә,
Алып килдем, бөек Тукай, синең илгә,
Бүләк итеп мәхәббәт һәм җырларымны,
Хуш исле бер букет итеп бәйләп бергә.**

***Әхмәт Исхак тәрҗемәсе***

## Кәрим Җаманаклы

кырымтатар шагыйре

### Үч кылычың сынмады

**Син җыйнадың көч белән гүзәллекне**
**Һәм күрсәттең җырлап яшәү үрнәген.**
**Һәр адымың бүләк булды халкыңа,**
**Россиягә багышланды йөрәгең.**

**Халкың үчен чагылдырган хисләрең,**
**Әйтче, шагыйрь, әйтче, Тукай, тынармы?!**
**Көрәшләрдә кайралган булат кылыч,**
**Әйтче, шагыйрь, әйтче, Тукай, сынармы?**

**Гомер буе мактап, зурлап җырладың**
**Халкың көткән нурлы, азат таңнарны.**
**Алгы сафта килә рухлы җырларың,**
**Дуслар тыңлый, хөрмәт итә аларны.**

**Янып типкән йөрәктәге хисләрең,**
**Әйтче, шагыйрь, әйтче, Тукай, тынармы?!**
**Халык моңына кайралган кылычың,**
**Әйтче, шагыйрь, әйтче, Тукай, сынармы?!**

## Михаил Львов

рус шагыйре

### Түбәтәй

**Булдым мин Жаркентта,**
**Чимкентта, Ташкентта.**
**Утырдым идәндә,**
**Үләндә, брезентта.**
**Май ае кымызын**
**Киң дала түрендә**
**Эчтем мул мәҗлестә,**
**Казакълар җирендә,**
**Түбәтәй кигәнгә**
**Дусларны каратып,**
**Казакълар татарча**
**Сөйләште яратып.**

**Күрәсең, түбәтәй**
**Аларга ошаган:**
**Син, диләр, кадерле**
**Тукайга охшаган.**
**Ә Абай токымы**
**Мактагач, бигрәк тә**
**Май булып урнашты**
**Яхшы сүз йөрәккә.**
**Тукайга, Тукайга**
**Охшауны сөям мин,**
**Башыма таҗ итеп**
**Түбәтәй киям мин.**

***Мөхәммәт Садри тәрҗемәсе***

## Сырбай Мәүленов

казакъ шагыйре

### Тукай кабере янында

Киттең, Тукай,
Үттең, Тукай,
Йөрәкләрне яндырып,
Иңрәде ул,
Тетрәде җир,
Каплады кара болыт.

Кыска булды,
Иртә сүнде
Яшь гомерең, моңлы-зарлы.
Утка атып,
Кан елатып
Ташлап киттең Казанны.

Үтте еллар,
Үсте җырлар,
Син яңадан уяндың,—
Озын гомерең!
Кабат мендең
Биегенә кыяның.

Тукай—яшь-яшь,
Абай—ак чәч,
Үлмәс җаннар булдыгыз,
Берегез—монда,
Берегез—анда,
Йөрәкләрдә урыныгыз.

*Нури Арсланов тәрҗемәсе*

## Нажар Нәҗми

башкорт шагыйре

### Габдулла Тукай

Булганнар бит бөек шагыйрьләр!
Туган, урын—алтын бишектә;
Үскәч—киткән; кайткан чакларда—
Кеше торган саклап ишектә.
Булган башка бөек шагыйрьләр:
Тар бүлмәдә сулып сүнгәннәр;
Бала чакта исә базарда:
"Асрарга бала бирәм!"—дип,
"Кем ала?"—дип, сатып йөргәннәр.
Әй язмышның шомлы агышы!
Бөеклекнең алтын ярлары...
Гомерендә—халкы язмышы,
Җырларында—халкы моңнары,
Хәзер инде башка заманнар,
Заманнарда—башка базарлар;
Базарларда—башка малайлар,
Малайлар да—башка: Нажарлар.
Күңелемнең заман кошчыгы
Басып сайрый алтын киртәгә.
Сатсалар да бүген әзермен,
Тукай чыкса миннән иртәгә.
"Йә, кем ала?"—Сезгә кирәксәм,
Мин тукталам, табып мәрхәлә...*
Ах, алай да килми кешегә
Шагыйрь дигән бөек мәртәбә.

*Мәрхәлә—юлчылар туктый торган урын (гарәпчәдән).

# ӘДӘБИЯТ ӨЛКӘСЕНДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ (1958–2005)



**1958. Фәйзуллин Әхмәт Сафа улы (Әхмәт Фәйзи)**—язучы, "Тукай" романы өчен.



**1959. Әпсәләмов Габдрахман Сафа улы**—язучы, "Сүнмәс утлар" романы өчен.



**1960. Хәкимов Сибгат Тажи улы (Сибгат Хәким)**—шагыйрь, "По зову Ленина" (русча), "Жил исми, яфрак селкенми" исемле шигырь җыентыклары өчен.



**1960. Вахитов Габделхәй Каюм улы (Хәй Вахит)**—драматург, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелган "Беренче мәхәббәт" драмасы өчен.



**1966. Туфан Хәсән Фәхри улы (Хәсән Туфан)**—шагыйрь, "Сайланма әсәрләр" китабы өчен.



**1968. Исәнбәт Нәкый Сиражетдин улы (Нәкый Исәнбәт)**—язучы, галим, фольклорчы, "Татар халык мәкальләре" дигән өч томлы хезмәте өчен.



**1969. Миңгазиев Ибраһим Зарифулла улы (Ибраһим Гази)**—язучы, "Онытылмас еллар" трилогиясе өчен.



**1972. Хөснетдинов Фатих Хөснетдин улы (Фатих Хөсни)**—язучы, "Гыйльмениса һәм аның күршеләре" дигән китабы өчен.



**1972. Һидиятуллин Шәүкәт Галиулла улы (Шәүкәт Галиев)**—шагыйрь, "Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр", "Котбетдин мәргән", "Шәвәли", "Тәмле йорт", "Кызык" һ.б. китаплары өчен.



**1973. Ахунов Гарифҗан Ахунҗан улы (Гариф Ахунов)**—язучы, “Чикләвек төше” повесте, “Хәзинә” романы өчен.



**1974. Әмиров Мирсәяф Мәсәлим улы (Мирсәй Әмир)**—язучы, “Агыйдел” пьесасы өчен.



**1974. Юзиев Нил Гафур улы**—әдәбият галиме, тәнкыйтьче, “Шигырь гармониясе”, “Хәзерге татар поэтикасы” дигән китаплары өчен.



**1976. Вәлиев Диас Назыйх улы**—драматург, “Дарю тебе жизнь” пьесасы өчен.



**1976. Шабаев Марс Садри улы**—шагыйрь, “Жикән камыш”, “Онытма”, “Сине эзлим” дигән китаплары өчен.



**1977. Афзалов Гамил Гыймазетдин улы (Гамил Афзал)**—шагыйрь, “Айлы кичләр” шигырьләр җыентыгы, “Борылам да карыйм” дигән шигырьләр циклы өчен.



**1978. Фәйзуллин Равил Габдрахман улы**—шагыйрь, “Шигырьләр һәм поэмалар” китабы өчен.



**1979. Миңнуллин Туфан Габдулла улы**—драматург, “Ай булмаса, йолдыз бар” драмасы өчен.



**1980. Юзеев Илдар Гафур улы**—шагыйрь, “Таш диварлар авазы”, “Өзелмәс кыллар”поэмалары өчен.



**1981. Рәсүлов Атилла Кадыйр улы (Атилла Расих)**—язучы, “Язгы авазлар”, “Ике буйдак”, “Сынау” һәм “Ямашев” романнары өчен.



**1982. Нуруллин Ибраһим Зиннәт улы**—язучы, "Тукай" ("Атаклы кешеләр тормышы" сериясеннән) һәм Габдулла Тукай" дигән китаплары өчен.



**1983. Гыйләҗев Аяз Мирсәет улы**—язучы, "Жомга көн кич белән", "Әтәч менгән киртәгә" повестьлары өчен.



**1984. Еникиев Әмирхан Нигъмәтҗан улы (Әмирхан Еники)**—язучы, повестьлары һәм хикәяләре өчен.



**1984. Родионов Григорий Васильевич (Гәрәй Рәхим)**—шагыйрь, "Кара йөзләр" операсы либреттосы өчен.



**1985. Арсланов Нури Газиз улы**—шагыйрь, "Иделем—илем" исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы өчен.



**1986. Камалов Хисам Нуретдин улы (Хисам Камал)**—язучы, "Һәркемнең гомере бер генә", "Безне өйдә көтәләр" исемле китаплары өчен.



**1987. Зарипов Марсель Харис улы**—язучы, "Поступь моей республики" һәм "Выгодный оборот" дигән очерк һәм публицистик китаплары өчен.



**1988. Хәсәнов Мәхмүт Максуд улы**—язучы, "Язгы ажаган" романы өчен.



**1989. Мәхмүтов Хуҗиәхмәт Шәһиәхмәт улы**—язучы, фольклорчы галим.

**Ярмөхәмәтов Хәмит Хөснетдин улы**—язучы-фольклорчы галим (Хәмит Ярми) (үлгәннән соң)—һәр икесенә дә "Татар халык иҗаты" дип исемләнгән унике томлык фәнни хезмәткә керткән зур өлешләре өчен.





**1990. Мәһдиев Мөхәммәт Сөнгат улы**—язучы, "Кеше китә—жыры кала", "Торналар төшкән җирдә", "Бәхилләшү" повестьлары өчен.



**1990. Салахов Ибраһим Низами улы**—язучы, "Колыма хикәяләре" романы өчен.



**1991. Кәримуллин Әбрар Гыйбадулла улы**—галим, "У истоков татарской книги" ("От начало возникновения до 60-х годов XIX века"), "Татарская книга пореформенной России", "Татарская книга XX века" дигән трилогиясе өчен.



**1991. Зәйнашева Гөлшат Хисам кызы**—шагыйрә, "Илле жыр" китабы өчен.



**1992. Әгъләметдинов Мөдәррис Зөфәр улы (Мөдәррис Әгъләмов)**—шагыйрь, "Киләчәккә кайту", "Мин әйттем" дигән китаплары өчен.



**1992. Липкин Семен Израилевич**—шагыйрь, татар халык эпосы "Идегәй"нең һәм татар поэзиясе классиклары әсәрләренең тәржемәсе өчен.



**1993. Мөхәммәдиев Ринат Сафа улы**—язучы, "Сират күпере" романы өчен.



**1994. Фәттахов Нурихан Садрилмән улы (Нурихан Фәттах)**—язучы, "Сызгыра торган уклар" әсәре өчен.



**1995. Яруллин Фәнис Гатаулла улы**—язучы, "Жан авазы" китабы өчен.



**1996. Бәширов Гомәр Бәшир улы**—язучы, "И язмыш, язмыш..." китабы өчен.



**1997. Харисов Ренат Мәгъсүм улы (Ренат Харис)**—шагыйрь, "Хисемнен җисеме" дигән шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы өчен.



**1998. Миңнуллин Роберт Мөгаллим улы**—шагыйрь, "Күчтәнәч" дигән балалар китабы өчен.



**1999. Баянов Әхсән Фәтхелбаян улы (Әхсән Баян)**—язучы, "Урланган ай" китабы өчен.



**2000. Маликов Дөлфәт Госман улы (Зөлфәт)**—шагыйрь, "Ике урман арасы" һәм "Йөрәгемне былбыл чакты" китаплары өчен.



**2001. Әхмәтҗанов Роберт Вәли улы**—шагыйрь, "Тургай тәрәзәсе", "Кичке кошлар" китаплары өчен.



**2002. Зәнкиев Якуб Камали улы**—язучы, "Иртеш таңнары" китабы өчен.



**2003. Хәбибуллин Мөсәгыйт Мөдәррис улы**—язучы, "Кубрат хан" китабы өчен.



**2004. Юнысов Миргазиян Закир улы (Миргазиян Юныс)**—язучы, "Альбатрос язмышы" китабы өчен.



**2005. Мингалимов Рөстәм Гали улы (Рөстәм Мингалим)**—"Дәрт чүлмәге" шигъри җыентыгы өчен.



Роза
Мулланурова

# БҮРЕ ЧАГАСЫ

хикәя

Айзарәнең кеше арасына беренче мәртәбә Зөлфияне житәкләп чыгуы иде әле бу. Яңа халәтенә—сигез яшьлек бала анасы булуына бердән, үзе күнегеп житмәгәнгә, икенчедән, моны кемнең ничек кабул итәсен тәгаен күзаллый алмаганга киерелгән жәя сыман иде ул: аз гына саксыз хәрәкәт, бер ялгыш сүз, мин-минлегенә тиярдәй ишарә—ук очачак, тартылган жәя генә торып калачак. Кемгә кадалыр угы? Ихтимал, кире үзенә очып кайтыр да, янә бер жәрәхәт ясар.

Ә табиб ишеге төбендә су буе чират. Урак өсте шул—бала-чаганы мәктәпкә әзерли торган чак, кемгә белешмә, кемгә киңәш зарур, һәммәсе күзен алартып иртәдән чиратка тезелгән. Ә мондый жирдә тик торганнан тел кашырга яратучылар күп була. Телчән апа-жиңгә тын, тыныч утыра алмый. Юри кара күзлек киеп, текә-горур кыяфәт сакларга тырышып утырса да, Айзарәне дә игътибарсыз калдырмады чират. Ак чырайлы юантык хатын сорау арты сорау яудырыпмы яудыра:

—Беренчегә барабыз, диген, ә! Ничек бер дә күзгә-башка чалынмый гына үсте соң әле бу тәти кыз? Кайсы бакчага йөрдегез?

Назыйм кисәтте югыйсә: "Табибны өйгә чакырыйк та жайлап сөйләшеп куйыйк. Аралашу өчен чират-мазар кулай урын түгел ул",—дип тәкърарлады. Тик Айзарә хатын-кызларча—беркатлырак фикер йөрткән: "Кеше сүзеннән куркып, качып ятып булмас, барыбер бер чыгасы... Иялешик",—дигән булды.

Ак чырайлы исә үжәтнен дә үжәте икән, Айзарәнең сүзен ишетмәмешкә салышып утыруына бер тамчы гарьләнү галәмәте күрсәтми, сүз үрчетүен белә:

—Мине танымыйсың ахры, ә мин сине бик яхшы беләм бит,—ди.—Хәер, данлыклы Сабитов бичәсен кем белми? Тик кызыгыз юк дип йөри идем...

—Авылда—әнидә үсте,—диде Айзарә үзен ничек тә тыныч-табигыйрәк тотарга тырышып.

* * *

Яшерен-батырын түгел, монарчы көйле генә келтерәп барган тормышының шушы кыз аркасында көе китүенә эче бик поша иде Айзарәнең. Бу кыз урынында үз баласы булуын бик теләр иде дә... Нишлисең, бәндә юрар, Ходай юллар, дигәннәр. "Читләр баласы—бүре чагасы" диләр. "Көндәш баласы—бүре чагасы" дигәнен Алмапасы әйтте... Базда үскән зәгыйф бәрәнге

сабагыдай аксыл-төссез Зөлфияне күргәч, түзмәде, теленнән ялгыш ычкынды.

Әле кайчан гына дөньябыз—түгәрәк, бәхетебез—тулы, мөбәрәк, дип ышанып йөриләр иде бит! И язмыш, язмыш!

Хәер, бәхетебез тулы-түгәрәк, дип алданучы бер алар гынамы?! Кителеп төшкәнен сизми дә каласың. Бәхет бик нәзберек—пыяла, саксыз сүздән дә уала.

Ә бер чите китек бәхет—бәхет түгел инде ул! Бу—бәхетсезлек!

Күз тидерделәр, дисән дә... Күптән чатнаган булган мәхәббәт көймәләре. Тормыш ваклыклары, очраклы хәлләр ташкынына бәрелеп челпәрәмә килгәнен генә абайламаганнар! Әллә сизеп тә сизмәмешкә салышканнармы?! Анысы да хактыр. Алдану күз йомдырган. Ә бит Алмапасы—әнкәсенең бертуган сеңлесе—кисәтмәде түгел, кат-кат искәртте:

—Дөнья куабыз дип бик бетеренмәгез әле, туктап хәл алыгыз бер тын,—дия иде.—Дөньяны куып тотардай адәм тумаган. Кеше бу дөньяда кунак кына. Нәсел-нәсәп калдыру өчен генә килә ул. Кошлар да шулай... Бәбкә чыгара...

—Тукта инде, Алмапа, менә эшләрне җайга салып бетерик...

—Һай җаным, үлгәндә йөз яшьлектән дә өч көнлек эш калыр. Бетәсе юк мәшәкать-мазарның. Йорт өлгертик, дидегез, алпавыт утарыдай кәттиджегез көлеп тора, мебель, машина алыштырасы, дип изаландыгыз... Барысын берьюлы хәстәрләп бетерсәң, үләсе генә кала ич. Бәби сөеп юанасы да юк.

Атадан калган мал белән мантыганнар дөньяда бихисап, мәгәр Сабитовлар ирешкән кадәресенә хәләл көчләрен куеп, зур тырышлык белән ирешә алдылар. Тир тамызмый энә дә күктән үзе төшмәде. Назыймның тәвәккәллеге аркасында иш янына куш өстәлде. Үз вакытында зур гына суммага курыкмыйча ссуда алганнар иде. Берзаман акча алышынды. Кичәге йөз сум меңгә әйләнде дә куйды. Кем уйлап чыгарган хәйлә булгандыр, әмма Сабитовлар бу галәмәттән отты гына. Бер-ике айлык хезмәт хакы ун ел буе түләнергә тиешле ссуданы капларга җитте. Хикмәт инде! Заман хәйләсе шифалы яңгыр булды. Бизнес дигәне дә адәм баласы башкармастай эш түгел икән. Эшмәкәрлек канында булгандырмы, бизнес серенә дә теше үтә булып чыкты. Эшкә кулы ята торган ир бик тиз бизнес хикмәтләренә төшенде—җаен алды. Үз түбәбез булсын, үз машинабыз, үз эшебез, үзебезгә, үзебезнеке, дип иртә таңнан сикереп тордылар, арып-талып кайтып яттылар. Йокы тансыкка әйләнде, башны мендәргә тидерүгә мәрткә киткәндәй онытылалар иде.

Алар корган ипле ояны җил-давыл, хәвеф-хәтәр читләтеп үтәр кебек иде дә... Үтмәде шул. Бәреп керде, тормышның астын-өскә китереп ташлады.

Назыймны ул бер ымнан, күз карашыннан аңлыйм, дип уйлый иде. Ә соңгы вакытларда ир үз эченә бикләнде, йомылды. Моны хәтта килеп-китеп кенә йөргән Алмапа да сизми калмаган икән.

—Тагын Казанга чыгып чаптымыни?—диде беркөнне керә-керешкә.—Бигрәк ешлады. Алып калмасыннар тагын дип тә борчылмыйсың? Ә!

Айзарә яңа күлмәк тектергән, шуны киеп карау белән мәшгуль. Көзге каршында бөтерелә. Алмапасы энәләрен тырпайтып аны ирештерергә тотынды:

—Чибәр, чибәр! Бел шуны, баласыздан, хәтта хан кызы булса да, ир бизәр! Иртәме-соңмы чибәрдән дә гайрәт чигә...

—Читләр ник көнләшмәсен, үз туганың шулай дигәч...—дип еламсыраган туганын юатасы килепме, апасы янә фәлсәфәгә бирелеп китә:

—Акылың кая синең? Ник көнләшим газиз туганымнан? Син бәхетле булганга шат мин. Тик байлык—бер айлык, ярлылык белән бәхетсезлек кенә—гомерлек. Авызыңны ачып калма, дип борчылуым...

—Әллә мин сизми дисеңме иремнең үзгәргәнен? Дорфа. Кырку. Төн буе борсаланып чыкты. Мин белмәгән яшерен сере бар! Битәрләмә, акыл бир!

—Хәйлә кирәк сиңа! Ә хатын-кыз хәйләсе—наз. Иркәлә, иркәлән. Ятсынмасын, читләшмәсен, дисәң, элеккедән дә назлырак бул! Һәрдаим сизеп торсын яратуыңны! Сырпалан, тәмле сүзең җәлләмә. Чәчбиләр күп жирдә...

* * *

Ә күнелгә кергән—алга килә, диләр.

Ул көнне ирен көязләнеп, бизәнеп-матурланып көтеп тора иде югыйсә. Табынны да башка көндәгеләрдән затлырак итеп бизәргә тырышты.

Кыңгырау тавышына ишеккә килсә...

Тырпаеп торган тыңлаусыз, кыска чәч толымына күбәләкләндереп ал тасма бәйләгән җиде-сигез яшьлек кыз бала күзен чекерәйтеп тора. Менә сиңа мә! Уңып беткән ямаулы күлмәге керләнгән, әллә юынмаган да..."Сөальче кыз!" дигән уй йөгереп үтте уеннан. Кулына иске сары чемодан тоткан ирен күргәч, тәмам телсез калды. Назыйм, сак кына кызны алгарак эткәндәй итте дә, сәер генә елмаеп:

—Исәнләш, Зөлфия, Айзарә апаң белән...—дип алгарак узды.

Базда үскән бәрәңге сабагыдай нечкә буй-сынлы бала ят хатынга каш астыннан ятсынып карап тора. Иске-москыга төренгән хәерче баласыдыр бу! Әллә хәер сорашып утырган җирдән ияртеп кайтканмы? Киңәшү юк, ризалык алу... Йә, ни инде бу?

Хатынның йөзе чытылды. Буяулы озын керфекләре, гүя, агу сибә. Бала бер адым алга атлауга ук, куркып артка чикте. Ә ир, Айзарәдән бөркелгән салкынлыкны эретергә теләп, авыз ерып маташа:

—Минем Зөлфиям булыр бу! Прошу любить и жаловать!

Әттәгенәсе! "Нихәл, карчыгым!"—дип кайтып керә торган кеше дә шулкадәр рәсми итеп:" Прошу..."—дип торыр икән! Әллә җен алыштырганмы?

Хатынның һаман шулай, үзен-үзе кочаклап, тораташ булып катып торуын өнәмәгәндәй, ир кырыс кына әмер бирде:

—Булды. Баррикада корып маташма. Юлдан кайткан юлчыны ашат башта.

Айзарә кырт борылып аш бүлмәсенә кереп китте. Итле шулпа кайнап утыра. Никтер кәстрүлне тәрәзәдән тотып атасы килде. Әмма алай итмәде.

...Алар, чит кешеләр кебек, дәшми-тынмый ризык җыйдылар. Хатын кырын күзе белән ят кунакка күз салгалады. Кыяр-кыймас кына кулына кашык алган кыз кабаланып шулпа кабуы булды—күзеннән яшь атылып чыкты. Авызы пеште. Чәчәде. Назыйм кесәсеннән кульяулык чыгарып кызга сузды. Айзарә монарчы күрмәгән, чите челтәр-челтәр, почмагына чәчәк чигелгән яулык иде бу. Кыз сискәнеп, яулыкны йөзенә каплады, иснәп торды. Елмайгач, чырае язылып, ачылып киткәндәй булды. Өйгә әчкелтем дару исе таралды. Ипи турап, шулпаны болгата-болгата әзрәк юангач, кыз тәлинкәне тиз генә ялтыратып та куйды. Борын очлары тирләп-кызарып чыкты. Сай тәлинкәгә Назыйм җылы өчпочмак салды. Учына учлап, йотылып, шулкадәр ләззәтләнеп-тәмләп ашарга кереште, Айзарәнең ирексездән күңеле йомшарып, күзенә яшь тулды. "Ходаем, ачлыклар гына күрсәтмә!"—дип һәр ашау алдыннан озаклап дога укый иде әнисе. Бер телем ипигә тилмереп, михнәт күреп яшәде шул әнкәсе-бәгъре. "Ризыкка туйгач кына китеп барды бит!"—дип әтиләре ул үлгәч, бик озак ис-акылга килә алмый тинтерәп йөрде. Михнәтле елларны исән-имин кичкән хатынының ипигә туйгач кына мул табынлы гаиләсен ташлап китүе акылга сыймаслык хәл иде. Әнисен уйлый-уйлый Айзарә табынны җыйды. Урын салды. Ир, хатын, бала—һәркайсы үз уен, үз бәхетсезлеген уйлап йокларга ятты.

"Иртә кичтән хәерлерәк, аңлар әле", дип юанды ир.

"Өйләре җылы, матур. Күңелләре суык. Ходаем! Бер көн дә тормас идем бу чит адәмнәр янында. Әниемә гомер бирсәнә!",—дип ялварды бала.

“Бала кадәр бала ияртеп кайткан, кинәш-табыш итү юк”,—дип борсаланып ятты хатын.—Бала түгел, бәла булмагае. Монысы бәланен баласы, мичтә калган анасы...” Айзарәнең сынар керфегенә дә йокы кунмады. Каян килгән бала бу? Кайда үскән? Артык кашыкка әйләнгәнме? Әллә берәр дусты бәхетсезлеккә юлыгып бу кызны аларга вакытлыча—асрамага гына биреп торганнармы? Арыганга салышып, бер сүз әйтми ятты да йоклады Назыйм. Жинел котыла бу! Ә бәлки юри сынавыдыр... Янәсе, сабыр савыты сай түгелме? Вакытлыча, кунак булып килгән кыз булса ярый ла. Уйның монысы зарарсыз тоелды. Күнеленә хуш килде, жаны-вөжүде монын шулай булуын теләде. Ниһаять, тынычлап, онытылып, йокыга ойый башлауга...Сискәнеп торып утырды.

Назыймның кучермәсе түгелме соң бу? Ул янә кызны күз алдына китерде һәм... Күзе шар ачылды: Килеш-килбәтенә, кыланмыш-кыяфәтенә кадәр Назыйм бит! Нәкъ үзе!Янагына таянып утыруына кадәр шуныкы! Ә күзләре? Кара каймалы яшькелт-зәнгәрсу күзләр! Әле егет чагында, бер карагач та тәне чымырдап, өнсез иткән иде шул серле күзләр Айзарәне. Бу кызга күз салуга... Каушады. Күрсәнә: “Кызым!”—дигән була бит. Ярату һәм ярлыкау сорый, үтенә. Кызганып буладыр, әмма ярату... Ике арада упкын ятканын анламыймы? Бәлки болай ук куертмаскадыр. Мөгаен, сынавы гынадыр бу? Хыянәтче ирләр, хатыннар хакында элегрәк сүз чыкканда, бала хакына гаилә бөтенлеген сакларга омтылган кешеләрне аклыйсы килә иде Айзарәнен. Ә Назыйм: “Хыянәтне анлап та, кичереп тә булмый, фәкать язмыш сынавына буйсыну гына мөмкин”,—дияр иде. “ Яратуың чын булса...”—дип тә өсти. Юри берәр танышының баласын ияртеп кайткан да, сыный ул Айзарәне! Бу татлы ялган күңелгә хуш!

Таш тутыргандай авырайган башын йокы басты. Төшендә ул чәчләре тузган кыз бала янында тупырдап торган ир бала күрде! Үзе бәби тапкан, имеш! Шуңа юрыйсы килгәнгә кергән төш идеме? Назыйм төсле малай булса... Һай, юану... Уянгач та шул төш тәэсирендә йөрде, кайгысы эрегәндәй булды...

* * *

Котып бозларын эретерлек дәрт-дәрманың була торып та, үзеннен хыял канатларынны бәйләп куй әле! Өйдә тәмәке көйрәтү гадәте булмаса да, Назыйм капшанып шырпы, сигарет эзләп азаплана...

Әйе, бәхетле гаиләләрнең һәммәсе бертөрле: бәхетле, ә менә бәхетсез гаиләнең һәркайсы үзенчә бәхетсез. Менә алар... Ратышып өйләнештеләр, матур гына яшәп яталар иде бит әле. Кем уйлаган башларына менә шундый... Менә шундый... Бәхетсезлекме бу, әллә бәхетме? Кем белә моны, кем әйтә ала?! Балалары юк иде. Кинәт кенә, кУктән төшкән кебек кенә балалы булды... Аныкымы соң ул бала? Әллә кемдер сихер белән күз будымы, акылны томаладымы... Юләр димә инде үзен дә, Айзарәгә әйтү юк, килешү-сөйләшү юк, беренче кат күргән, беренче мәртәбә исемен ишеткән үксез баланы иярт тә кайт. Хәтта әнисе янына барып хәл-әхвәл дә белешмәде. Капылт кына, кинәт кенә. Юк, дөрес эшләде. Ярар, моңарчы дәшмәде, аны акларлык сәбәп бар, чөнки кызның дөньяда яшәү-яшәмәвеннән бихәбәр иде ләбаса. Белмәде шул. Әнисе дә эзләтмәгән. Ә бәлки сорашкандыр, белешкәндер, Айзарә белән әйбәт кенә яшәп ятканнарын белеп, кеше гаиләсен җимерүне бәлки кирәксенмәгән, ә бәлки яхшысынмагандыр. Кеше күңеле—карурман, сер... Мәңге ачылмаячак сер ул. Ә кызны яратты ул. Бер күрүдә үзенеке дип таныды. Чөнки алар нәселенә, әниләре ягына тарткан иде. Нәкъ шушы кыз төсле сеңелләре бар иде. Назилә исемле. Бик ярата иде ул сеңелесен. Гомерсез булды. Суга батып үлде. Бәлки Ходай шул кызның жанын кабат

жиргә индергәндер. Сөйлиләр ич. Булуы да ихтимал. Ни генә булмас дисең, төпсез-кырыйсыз күк бит ул. Әллә жирме икән?!

Барысы да көн кебек ачык һәм карурмандай серле дә…

* * *

…Диплом язасы елны, тулай торакта шау-шу, дип, фатир эзләмәкче булды. Игълан буенча фатир тапты. Хуҗабикә Фәүзия апаның тәмле телле, ачык йөзле булуы күнеленә аеруча хуш килде. Үсмергә тартым кызы юка-чандыр гәүдәле, ак чырайлы: егет аңа ялгыш та күз төшермәде дисә дә, ялган булмас. Авылында Айзарәсе диплом яклап кайтуын дүрт күзләп көтә. Чибәрен—жан сөйгәнен уйламаган сәгате сирәк, бер түгел йөз сылу чакырып, ымсындырып торса да, иманы какшамас. Хәер, Фәүзия апа кызы иман какшатып, аздырырга җыенмый, барлыгы-юклыгы да сизелми. Укый идеме ул, берәр яры эшлиме—монысы егет өчен сер булып калды. Чөнки кызыксынмады. Тыйнак, сөйкемле—хуҗа апа кызы гына ул. Баш иеп, күргәндә елмаеп исәнләште, атналар буе очратмаса да, кая икән бу кыз бала, дип баш ватып интекмәде. Бәләкәй йортның чоланы—аныкы. Һәм аңа шул бик җиткән. Иртүк тора да китапханәгә китә, соң гына кайтып ята. Тамагын күбесенчә ашханәдә үткәрә. Тик кайчакта, ял көннәрендә, татар хатыннарына хас булганча, берәр тәмле мич ашы пешерсә, квартирантын да кыстап табынга утырта апа. Назыйм, тәмле ризыкларны кыенсынып кына авыз итә. Үзе дә вакыт-вакыт, кулына акча мулрак кергәндә, ягъни кесә төбе тәмам коргаксыгач, баржа-мазар бушатып, акча эшләп кайткан чакларда, апаны сыйлардай тәм-том сатып ала. Кешегә бурычлы булып калырга бер дә яратмый иде ул. Бүлмәсендә бикләнеп, язу-сызу өстендә утырган егеткә хуҗалар да битараф. Дипломын тизрәк язып-яклап, туган ягына кайтып китәргә ашкынуын аңлыйлар булса кирәк.

Бер ел элек кенә укуын тәмамлап, Акъярда эшли башлаган Айзарәдән хат арты хат килә. Телдән әйтмәсә дә егетне сөйгән яры көткәнен хуҗалар, әлбәттә, сизенә.

Иртән иртүк юлга кузгаласы иде ул. Диплом кесәдә, юклы-барлы әйберкара җыеп төйнәлгән. Кичтән китәргә әзерләнеп бетсә дә күкне каплап алган болыт күңелгә шом салды. Ярар, бер төндә арпа баш ташламас әле, иртәнге автобуска өлгерермен, дип җинелчәрәк фикер йөртте—каласы итте.

Кисәк кенә уянып китсә… Берни аңламый торды. Төн уртасы узган, таң сызылырга азаплана. Кинәт бар дөнья яктырды. Көтүче чыбыркы чыжлаткандай унлы-суллы яшен кылычы уйнады, күп тә үтмәде, күк күкрәгән тавыш бәләкәй өйне тетрәтте. Шак-шок килеп нидер дөберди. Жил, күрәсең, кухня тәрәзәсен ачып ташлаган, шул туктаусыз шап-шоп килеп йөрәккә бәрә. Кузгалган кеше юк. Назыйм теләр-теләмәс кенә торды да, тәрәзә ябарга теләп коридорга чыкты. Шулчак идәнгә төшкән энә дә табылырдай булып дөнья яктырды, гөлт-гөлт итеп яшен яшьнәде, артыннан ук күк күкри башлады. Шул мизгелдә аның күзе хуҗалар йоклый торган бүлмә ишегенә төште. Ишек шар ачык, ә караватта ап-ак җәймәгә төренгән берәү бәргәләнә-бәргәләнә елый.

—Зөлхия! Синме ул?

—Назыйм абый! Җаным! Куркам! Үләм бит, коткар!—Кыз кулларын сузып, таш йөрәкләрне эретерлек итеп сулкылдап-ачыргаланып кычкыра.

—Фәүзия апа кая соң?

—Зурапаларга киткән иде. Төне буе күзем йомалмадым, саташып беттем. Бер-бер хәл булгандырмы, кайтмый. Йөрәгем ярыла, зинһар дару гына табып бир!—Кызнын тумыштан йөрәк чирле икәнен ул шунда белде. Ут юк, әллә яшен суккан, әллә сүндергәннәр. Кармаланып, шырпы сызып эзли торгач, тапты даруны. Кыз әзрәк тынычлангандай булды.

Әмма, егет китәргә кузгалуга, беләгенә чытырдап ябышты

—Китмә! Калдырма ялгыз, үләм.

Дөбердәү ерагайган кебек булды. Кыз бер мәлдә тынычлангандай була, янә сикереп тора: "Китмә, китмә!"—дип ялвара. Егет кочагына сыена…

…Иртән уянып китте дә чәчләре үрә торды: ничек булды бу хәл, йә Ходай? Нишләде ул, йә, ник чорсыз кыланды, үзен тыймады! Җавап бер—ул юньсез, әшәке, тәртипсез ата мачы! Хыянәтче!

Ни эшли ала ул? Бата башлаган корабны иң элек күселәр ташлап кача, диләр. Күсе икән ул! Алданган кыз баланы ташлап качты.

Бервакыт кире әйләнеп кайтырмын, гафу үтенермен, дип уйлаган иде, кыюлыгы, батырлыгы җитмәде. Аннан әкрен-әкрен тынычланды. Авылына артыннан эзләп килмәделәр. Димәк, аның бу харам эше эзсез, шома гына узды. "Үпкән-кочкан, җилгә очкан"—дип, тиккә генә әйтмиләрдер шул.

Әмма… "Тузан кадәрле яхшылык та, тузан кадәрле яманлык та эзсез югалмас"—ди Китап. Хактан яшерен гамәл булалмый икән.

Хәер, вөҗдан газабы кичереп әлләни газапланмады ул. Тик Зөлхиянең йөрәк чире исенә төшсә генә тәне эсселе-суыклы булып китә: һай кирәкмәс иде, табигать болай да рәнҗеткән кешегә яра ясау килешкән эш түгел, дип өзгәләнә… Махсус уйланган явызлык түгел ләбаса! Аны өзелеп көткән Айзарәне ташлап, бәхетсез Зөлхияне эзләп китә алмый ич инде ул. Туй көне билгеләнгән, вәгъдәләр бирелгән… Онытырга, барысын да сызып ташларга, искә дә алмаска! Айлар, еллар буе үз-үзен ышандырырга, алдарга тырышты, юк, гаеп эш эшләмәде ул. Чәчләреннән генә сыйпады. Ефәк кебек йомшак иде чәче… Аннан… Үзе кочакка килеп кергән алмабитне суырып үбү гөнаһмы?!

Бу вакыйганы онытып та бетергән булыр иде, берзаман көйле барган эше артка тәгәри башлады. Үрчеми эше. Әллә нинди вак-төяк адәмнәр тәгәрмәчкә таяк тыгу җаен таба. Арыды-ялыкты ул. Дөньяның яме, кызыгы югалды. Мал, дәрәҗә, дип тырышты. Нәрсә соң ул дәрәҗә? Ирек-хөрлек. Барысы да рәшә… Акча дип чаба халык, акча булса хөрлек килә дип ышана. Янәсе, беркемгә дә буйсынмаска була. Акча күп булган саен богаулар да тыгызлана. Кызыгы калмады, яшәү ориентирларын югалтты. Бала-чагасы юк, хатыны белән дә ара суынып бара. "Бозу күп хәзер, күрәзәчегә күренеп карамыйсыңмы?"—дип бер танышы эчкә коткы салды. Барды багучыга. "Берәүне бик нык рәнҗеткәнсең, шул бәхилләми. Үлә дә алмый, үзең уйлап бел кем икәнен. Барып бәхиллеген сора!"—диде тегесе. Башына китереп суккандай булды: "Фәүзия апа кичерми мине!"

Көннәрдән беркөнне, юк йомышын бар итеп ул Казанга китте. Юл уаенда күчтәнәч-мазар алган булды, ә йөрәге дөп-дөп типте: ояты йоклаган гына, бөтенләй үлеп үк бетмәгән икән әле! Таныш йортны эзләп тапты, яртылаш җиргә сеңгән, кыйшайган түбәле иске йорт аны кочак җәеп каршыламады. Капка эчтән бикле, тәрәзәләргә такта кадакланган. "Күчкәннәр! Күпме йорт сүтелгән!"—диде эчке сизенүе. Сонарган. Эшне беткәнгә санап борылып китеп бармакчы иде, көянтә-чиләк аскан бер карчыкның судан кайтканын шәйләп туктады. Карчык чибәр-таза ир-егеткә сынап карап торды да:

—Берәрсен эзлисең ахыры? Кем кирәк соң?—дип үзе сүз кушты.

—Ие. Фәүзия апа бар ие… Күчкәннәрдерме?

—Ишетмәгәнсең алайса, җиде-сигез ел элек үк гүр иясе булды ич Фәүзия. "Мина рәнҗеп үләлми яткан ул түгел!"—дигән уй ярып үтте. Ә кем соң?

—Ә кызы… Зөлхия? Ул кайда соң?

—Зөлфияне сорыйсыңмы, анасынмы?

—Бүтән кызы юк иде бугай.

—Зөлхия инде алайса. И, җаныкаем! Әллә сине Ходай Тәгалә үзе юлладымы? Авыр бит хәлләре, урын хастасы анасы, бала—беркемгә хаҗәт

түгел, детдомга бирсәләр, кача, хастаханәгә—анасы янына кертмиләр. Бетләп бетте инде. Фәкыйрьләрне онытты Ходай да, хөкүмәтне әйткән дә юк... Әнә, күр...

—Мин белмәдем. Баласы дисез? Атасы юкмени соң?

—Булгандыр инде, җилдән дигәч тә... Итәгенә салып апкайтты шул, бик итәгатьле, оялчан гына кыз ие юкса. Нишлисең, дөнья бит! Бәхетсезгә җиле дә каршы анын. Тома ятим кала инде бахыр, Зөлхиянең көннәре санаулы, диләр. Берәр иманлы адәм асрамага алса, тынычлап үләр иде, ичмасам. Белмисенме, бала тансыклаган берәрсе юкмы? Кызы бик матур. Акыллы. Кәтүк буе бала йорт тота. Мескен-ятимгә кем ипи бирсә, шул ата булыр ие. Юньлерәк җиргә урнаштырасы ие. Күрше-тирә, җыелышып, хөкүмәткә хат та язган иек. Ярлы-ябагай кайгысымени аларда? Анасының күзе йомылса, сорап тормаслар шул. Теләсә кемгә тоттырып җибәрәсе дә килми. Уйла әле, башың йомры күренә.

—Каян табып була соң аны?—Сузчән хатынның зары мәнге бетмәс кебек иде, жылы хәбәр колагына керүгә, көянтә-чиләген ашыгып җиргә куйды.

—Өендә. Шушы нигезгә ябышкан инде. Детдомга алып китәрләр дип беркемгә капка ачмый. Югыйсә... И, башыңа бәла ишелә башласа, син ялгыз шул. Почмакка поскандыр. Сүз тынлап торадыр әле. Әнисен "Ашыгыч ярдәм" төнлә алып китте, исәндерме, белмим.—Ул бар көченә тәрәзә какты.

—Зөлфия, дим, Зөлфия! Ач әле... Туганың абый килгән сине сорап.

Калганы төштәге кебек кенә булды. Тузган чәчле кызны күрүгә үзенең сабыйчагын таныгандай булды ул. Һәм өнсез калды. Ходай биргән хәзинәме бу, гөнаһына күрә җәзасымы?! Бәлки барысы биргәдер. Дөнья, диген, дөнья!

—Җыен, кызым! Өйгә кайтабыз!—диде. "Әни!"—дип еламсырый башлаган сабыйның башын сыйпап:—Хәсрәтләнмә! Әнкән дә сыяр,—дип өстәде.

Ике хатынны бер түбә астына ничекләр итеп сыйдырасын белми иде әлегә. Җае чыгар. Бүген, бу мизгелдә күзләре яшь белән туп-тулы кыз бала язмышы мөһим. Ә Айзарәне белә ул, кайнарланыр, пар чыгарыр, авыз турсайтып йөрер-йөрер дә, көннәрдән беркөнне Зөлфияне үзе тапкан, үзе баккан баладан да артык күреп ярата башлар. Чөнки йөрәге олы анын, күңеле кин, җаны якты! Ә якты җанлы кешенен күнелендә кара болыт озак кунак булалмый, кар-бозга чорналса да!

* * *

Кайчаннан бирле суда чыпырдый бу... Чәй суынып бетте. "Баттың мәллә?"—дип кычкырырга итте, тыелды. Ят кеше баласы бирегә аяк басканнан бирле үзен бу йортта чит, хәтта ки артык итеп тоя Айзарә. Урынлы-урынсыз сүз ычкындырудан, кычкырып көлүдән курка. Гүя күзгә күренмәс берәү—көндәш сиздерми генә аны күзли. Чит кеше гаеп итә күрмәсен дип йозак элгән кебек бар дөньясы—бикле. Күнеле дә, теле дә, һәммәсе—бикдә. Назыйм да бүтән... Эчкә йомылды. Күктән төшкәндәй, көтмәгәндә пәйда булган кызы—анын йөрәк ярасы ләбаса! Яшьлек хатасымы, хыянәтме бу? Кайсы ялгыш, кайсы дөрес—анлармын димә.

Сөенеч, газап, икеләнү-шөбһәләнү—барысы бергә буталды.

Айзарәнен тагын күзләре кызарган. Качып елый да елый. Чит кеше сыман аяк очларына гына басып, башын сөлге белән урап, нидер җуйгандай, гел аска карап, сагышланып йөрүе тагын... Ирне болар барысы да ярсыта, чыгырдан чыгара. Тик мөнәсәбәтләрне ачыклау максаты белән сүз кузгатудан әллә курка, әллә... кыенсына шунда. Ни булса шул... Ә кызын, хәтта хатыны ультиматум куйган очракта да, ташламаячак ул.

—Әй, кызый, әллә баттынмы?

Әллә нинди эчке сиземләү Айзарәнен йөрәген өтте. Ялгыз калуны хуп

күрә кыз. Үги әни белән аралашырга атлыгып тормый. Әмма һәр нәрсәнен чиге бар.

Ишек эчтән бикле, хәтта су тавышы да ишетелми…

—Назыйм!—Айзарә куркудан шашардай булып ачы итеп кычкырды, ир кулындагы касә төшеп ватылды.—Дәшми бала! Бу ни инде? Каер ишекне!—Ул арада су ишек астыннан ташып чыгып, идәнгә җәелде.

—Ашыгыч ярдәм чакыр!

Күршедә яшәүче табиб—Василий Петровичның ишеген төя иде инде Айзарә…

•

—Күлмәк киеп туган булгандыр бу! Бәхетле бала, сулый!—Күршеләре алдында эчке күлмәк-ыштаннан басып торуына унайсызлангандай, табиб мангаендагы тирләрен сөртте дә, ишеккә таба атлады.—Ишегемне шар ачык калдырганмын. Әле дә ничек өлгердек?! Бер секунд сонарсакмы?!

—Мен рәхмәт инде сезгә! Гомер онытмабыз яхшылыгыгызны!

Василий Петрович Айзарәне ымлап, читкәрәк чакырып алды.

—Суицид уе башка бер керсә, хәтәр хәвефле нәрсә... Сак булыгыз. Күз карасыдай сакларга кирәк баланы… бик бетерешкән. Яшәү дәрте—нуль! Ягымлы, назлы булырга, ялгыш та үпкәләтмәскә, рәнҗетмәскә.... Сабый бит ул!

Айзарәнен күзенә мөлдерәп яшь тулды. Дөрес әйткән Алмапасы, көндәш баласын карап та бетерә алмассын. Хак-нахак бәлаләрдән үзен ярлыка, Ходаем!

• • •

—Зөлфия, тәтием! Ялгыш таеп егылдынмы? Ник кычкырмадын? Без бит шундый курыктык. Бүтән болай эшләмә, яме!

Кыз бүре баласы кебек каш астыннан сөзеп карап тора. Ачуланалармы аны, исән булуына шатланалармы—һич анлый алмый. Менә күзләренә тагын мөлдерәп яшь тула. Тынлаусыз тамчылар бит алмалары буйлап йөгерешә.

—Йә, бездә начармени сина?

Кыз "Юк!" дигәнне белдереп баш чайкый.

—Алайса ник бер дә көлмисен, шаярмыйсын? Песи белән дә уйнамыйсын? Артык түгел син безгә… Анла. Әтиен сине бик-бик ярата. Мин дә…

—Ә әни…

Йә, Раббым! Кешенен үз әнисе бар шул!

—Әниенне әтиен әлегә ял йортына илтте. Бераз савыккач, монда кайтыр.

—Чынмы?—Нәүмиз генә башын иеп утырган бала, кош кебек канатланып, Айзарәгә елышты.

—Тик елама, яме! Гел елагач, күзләреннен зәнгәрлеге унар. Синен бит әле үсәсен бар. Берәр егеткә гашыйк булырсын… Беләсенме, егет халкы зәп-зәнгәр күзле көләч кызларны ярата. Елмайса, кеше сөйкемле күренә.

—Елмаю килешә сина да. Син болай да бик чибәр!

—Әниен чибәррәктер!

Кыз, сөенеп, "Әйе" дип баш какты, ялгышын тизрәк төзәтергә ашыккандай: "Икегез дә матур!—дип куйды. Күнелендәгесен уйлап көрсенде. Йөзеннән күләгә йөгереп үтте.

Хәер, Айзарәнен дә күнел күген болыт сарырга өлгергән иде инде.

Мәнге шулай булыр бу… Уртак малны эт җыймас, диләр. Ә уртак ярны…

• • •

…Язның янгырлы бер иртәсендә Айзарә, авыру кеше кебек иләсләнеп, авыраеп уянып китте. Чәй эчеп карады, күнеле болганып, укшый башлады.

Ярамаган нәрсә ашаган, дисә... Агуланганмын, ахырысы, дип, хәвефкә батты. Аннан төшенде... Күптән көткән бәхет ишек шакый. Ниһаять, ул—авырлы бугай.

—Әллә авырыйсың инде?—Каян сизенгән диген, Зөлфия песи кебек шыпырт кына янына килеп сыенган да, иркә бармаклары белән маңгаен сыйпый.

—Юк, алтыным! Мин... Беләсеңме? Бик бәхетле бүген.

Кыз, нигә сөенгәнен ап-ачык төшенеп җитмәсә дә, шат елмаеп ана сыенды. Айзарә кызның арыш саламы төсле алтын-сары чәчләреннән сыйпый-сыйпый:

—Рәхмәте киң Раббыбызның,—дип кенә куйды.

Үзе дә сизмичә, көндәше сүзен кабатлый түгелме?!

Көндәш... "Ходаем, балама көндәш ачылары күрсәтә күрмә",—дип тели иде әнкәсе. Кыз көлә генә, янәсе, заманасы ул түгел, башка! Юкка баш ватма. Башкасын башка, әмма... "Курыкканга—куш, койрыгы белән бишь",—диләрме? Уйлаган алга килә, диюләре хак инде әллә?!

Зөлхия башка... Ул—Зөлфиянең әнисе. Әнкәсе! Димәк, көндәш туган-тумача саналыр көнгә килеп җитте ул да. Шулай икән шул. Зөлфияне—иренең бәгырь җимешен—үзенеке дип исәпләгәч, шулай булырга тиеш тә. Ире ягыннан туган икән ич ул Зөлхиягә! Әбәү, ычкына башлавы хак ахрысы. Хәер, ычкынырсың да... Ачы хыянәт җимеше түгелме соң бу кыз бала? Бала—бал сүзеннәнме? Әйе, бала—бал, әгәр чага дигәне өстәлмәсә! Балдай татлы булса да чага! Ә моны бөтенләй "бүре чагасы" дип тора берәүләр. Чү, әллә саташамы? Соң, сабыйның ни гаебе бар? Үзе сорап, кем әйтмешли, гариза-мазар язып килмәгән ич яп-якты дөньягызга. Дөньягыз караңгыланыр дип дә белмәгән. Ә Зөлхия?

* * *

Ниһаять, Назыйм, көннәрдән беркөнне, Зөлхияне хастаханәдән туры үзләренә алып кайтты.

"Болын кадәр коттедж, сыярбыз!"—Кем беләндер бәхәсләшкәндәй кычкырып әйтте. Югыйсә, Айзарә бәхәс куертырга җыенмый бугай. Ә Зөлфия бик ямансулый. Сагына әнкәсен. Берни эшләтә алмыйсың. Бүре баласын бишеккә салсаң да... Тьфу-тьфу, Назыймның үзе сыман киребеткән ич кызы да.

Үзалдына шулай сөйләнде. Һәм гаҗәпкә калды. Өзелеп ярату түгелдер бу, әмма, ничектер үз, якын ул. Димәк, кыздан Назыйм чалымнарын эзләве хак. Юкса... Әгәр, ир аяк тереп каршы торса, минеке түгел ул бала, кызганудан сыендырдым, теләсән, илт тә тапшыр балалар йортына, дисә дә булыр иде... Юк, барыбер илтеп тапшырмас иде нарасый сабыйны детдом дип яманаты чыккан йортка. Тамак тук, өсләре бөтен булса да, анда үскән бала икенче була бит ул, йә бик әрсез, тәрбиясез, йә артык кыюсыз, булдыксыз. Үз каны, үз тамырчасы икәнен белә торып, баласыннан ваз кичкән адәмнәр күпме җир йөзендә? Җир—мәрхәмәтле, күтәрә андыйларны да. Ә Айзарә, ул чакта... Кичерер идеме ирен? Элеккечә ярата алыр идеме икән? Кызык. Кеше күңеле—табышмак. Табышмак җавабын беләм дигәннәр мең кат ялгыша.

Кызыл "Жигули" ишегалдына кереп туктады. Айзарә каршы чыкмады, ак челтәр пәрдә артына качып, ишегалдын күзәтте. Назыйм, шушы өч ай эчендә ун еллык картайган шикелле. Әллә моңарчы текәлеп карамаганмы? Бөкресе чыккан сыман. "Шул кирәк сиңа!"—дип ысылдады эчтәге явыз елан. "Шома боздан шуа белгәнсең икән, җимерек чанаңны тауга үзең сөйрәп менә бел!"

Ишекне ачып, кулын сузып машинадагы кунагын чыгармакчы булды бугай, әмма тегесе һаман төшә алмый азаплана, аяк-куллары калтырый... Шулкадәр кипкән-корыган, как сөяккә калган авыру хатынны ир җинел генә күтәреп алды. Тегесе: "Әйдә, теләсәгез нишләтегез, тик баламнан гына аермагыз!"—дигәндәй, кулларын көчкә күтәреп, ирнең таза иңенә салды...

* * *

Авыру хатынны карарга Назыйм шәфкать туташы яллады. Танылган, атаклы табибларны консилиумга чакырды. Зөлфиясе бик кадерле, якын иде аңа. Ә кызның газиз кешесен аякка бастыру өчен җан да, мал да җәл түгел. Яшәсен генә. Кызы күз алдында булсын. Ә кеше сүзе... Бүген сөйләрләр, бәлки иртәгә... Ә берсекөнгә барыбер онытачаклар. Чөнки берәүнең дә касәсе буш түгел, язмыш атлы гаҗәеп серле зат һәркайсына мәшәкать-хәсрәтне өстәп кенә тора. Мөлдерәтеп! Кайгы—кайгыга охшамый, урыны бер дә бушамый, дип тиккә генә әйтмәгәннәр шул.

Тик менә карау-тәрбия көткән нәтиҗәне бирмәде, авыру тернәкләнеп китә алмады. Күз текәп торган атаклы табиб та баш кына чайкады. Соң инде, соң...

Ә Айзарәгә бу очрашу гомерлек сабак бирде!

Йөзенә зәгъфран сарысы иңгән Зөлхия, бер иртәне ничектер җиләнәп, яшәреп киткәндәй, Назыйм белән Айзарәне үз янына дәште.

Киң, иркен бүлмәгә тәрәзәдән күз камаштыргыч яктылык кереп тулган. Тышта кошлар сайрый. Мондый ямьле иртәдә якты дөнья белән саубуллашып, кара җир асларына кереп яту бик кыендыр шул... Әмма тәкъдир каләмнәре адәм кулында түгел шул, түгел! Газраилнең килер сәгатен генә белмисен.

Авыру терсәкләренә таянып, биек итеп өелгән ап-ак мендәрләргә сөялеп утырган. Шәфкать туташы—Гамилә тырыштырган, күрәсең. Ир белән хатын, кыенсынып кына анын каршысына чүмәште. Кипкән яфрак кебек калтыранган кулларын кая куярга белмәгәндәй, Зөлхия ак юрган тышын сыйпап юанды.

—Чигүле юрган тышы матур икән. Шундый ак юрганга кызыккан идем. Чигүле тышлысын ябынасым килеп хыялланган идем. Ни сорасам, шуны алдыма бастыра Ходай. Тик... Мин сорый гына белмәгәнмен,—дип куйды. Сүзне нидән башларга белми аптыравы идеме бу анын, нидер әйтәсе килүме...

—Мендәр каты, җайсыз түгелме?—дип сораштырасы итте Айзарә сүзне ялгап җибәрер өчен генә.—Йомшаграгы кирәкмиме?

—Рәхмәтләр яусын.—Ул беркавым тын торды. Керфекләренә яшь элпәсе сарылган иде.—Язмыш, диген... Кем уйлаган болай булырын.

—Рәнҗемә...—Назыйм телен көчкә кыймылдатып, авырлык белән әвәләп чыгарды бу тәкъбирне. Ләкин моны әйтү анын өчен бик мөһим. Әгәр рәнҗеп китсә, гомергә бәхет йөзе күрмәячәк ул да, гаиләсе дә...

—Рәнҗегән чаклар да булгандыр,—диде хатын узган эшләргә йомгак ясагандай көрсенеп.—Ә рәнҗергә ярамый икән. Безнен кулда түгел Тәкъдир каләмнәре. Үкенердәй эшләр булса да... киң рәхмәте белән Хак тәгалә кичерә күрсен. Язмышка үпкәләү—гөнаһ. Менә бит... Сездән яхшылык күрергә насыйп икән. Күрсәткән изгелегегез үзегезгә кире кайтсын! Хәер-догада мин. Зөлфиям сезнең янда кала. Кага күрмәгез. Юкса тыныч яталмам...

Ул авырлык белән үрелеп Айзарәнең кулын тотты. Сыйпап-сыпырып:

—Син—үзең дә ана булырсың... Ана хәлен ана гына аңлый,—дип куйды.

Аннан авыраеп киткәндәй күзен йомды. Йөз-кыяфәте тыныч, бик тыныч иде анын. Гүяки озак авыру белән тартышудан соң тынычлап йоклап китте...

Әнисен җирләгәч, Зөлфия бер мәл Айзарәдән ятсынгандай гел турсаеп

йөрде. Юк-барга да киреләнде, тупас сөйләште.

Хәтта ни сабыр Алмапа да берсендә түзмичә: "Бүре баласын бишеккә..."— дип сүз башлаган иде дә, Айзарә кырт кисеп туктатты.

—Ул түгел, мин үзем гаепле. Баштан ук төкле аягың белән, дип каршы алмагач соң... Шул чактагы үпкә галәмәтедер бусы! Һәр нәрсәгә түләү тиеш.

—Тәүбәгә килергә әле дә соң түгел,—дип әләктереп алды күңелендә усаллык саклый белми торган беркатлы, самими апасы.

* * *

Менә бүген иң зур сөенечен кызы белән уртаклашасы килеп кыбырсыпмы кыбырсый Айзарә. Сүзне нидән башларга гына белми йөди. Кызның калын чәчләрен тарап, тасма белән үргәч:

—Кызым, алтын кояшым минем!—дип, иркә итеп дәште. Тәмле теленә, кыздан бигрәк, үзе сөенде. Күңеленә тынычлык иңүе—олы куаныч ич. Сулышы иркенәеп китте. Басу-кырларны дымга туендырып, җылы яңгыр яуган чакта күңелгә шундый хөрлек-иминлек хисе тула.—Беләсеңме, сиңа сөйлисе серем...

—Нинди сер ул?

—Ялгызыңа күңелсез булмасын дип, сиңа энекәш алып кайтырга уйлап торам бит әле мин.

—Ур-ра! Чып-чын энекәшме?

—Энекәш дип инде... Ә елак кыз булса ярыймы?

—Елак кызларны мин бигрәк тә нык яратам. Юатуы күңелле аларны.

—Үскән кызымдыр ла минем! Юатырсың, яме! Үзең дә юанырсың!

—Мин аны бик-бик яратырмын, яме, әнием!

Әнием!

Арадагы бозның эрүен күрү, уртак кояшта җылынуга сөенү нинди рәхәт! Зөлфия, әнисен югалтканнан соң әле беренче тапкыр балкып-елмаеп Айзарәнең күкрәгенә башын куйды. Гүяки йөрәк тибешен анык белән тигезли-барлый иде ул.

**Редакциядән:**

***Киләсе айда язучы Роза Муллануровaның юбилее. Каләмдәшебезне ихластан тәбрик итәбез, сәламәтлек, иҗат уңышлары телибез.***



Нәҗибә
Сафина

## ЯШЕРЕН УЙЛАР

### Коллар арттыручы кол алар

**Дөньяларда тәртип юк, диләр дә,
Гел үзгәртеп кормак булалар:
Елгаларны хәтта—дөрес акмый,
Диеп, кире бормак булалар...**

**Кирәк чакта гына яумый диеп,
Болытларны "кыйнап" куалар...
Кылган гамәлләрен дөресләргә
Булмасын диеп шаһит-гуаһлар,
Әллә күпме ачык капкаларны...
Күзләрне дә ябып куялар...
Ә дөньяга, барыбер, тәртип керми!
Һәм керә дә алмый. Ни өчен?
...Берәү анә үзен хуҗа итеп
Танытырга куя бар көчен...**

**Чын кешенең аның бөеклеген
Исбатларга бер дә кирәкми:
Сез аңлагыз беркем фәрманына
Буйсынмаган керсез йөрәкне!**

**Яшәешнең бар кануны шундый,
Табигый ул, аңа тимәгез!
Шул канунны буйсындырмак булып,
Комга терәлде лә көймәгез...**

**Дөньяларда тәртип юк диләр дә,
Гел үзгәртеп кормак булалар.
Үзгәртәм дип җаннар кыючылар—
Коллар арттыручы... кол алар.**

Нәҗибә САФИНА — *шагыйрә, публицист; «Таң кошы», «Әгәр дә уйлаганда» һ.б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

## Ике ягы

Кешене—"җилбәзәк" диләр,—
хурлау сүзе.
Кешене, аһ, "җилле" диләр,—
зурлау сүзе..

Кешене—"тымызык" диләр,—
хурлау сүзе...
"Ләйсән булып тамса җанга"—
зурлау сүзе.

Кешене—"ул салкын" диләр,—
хурлау сүзе.
"Салкын акыллы ул", диләр—
зурлау сүзе.

Сүзләрнең дә була шулай—
ике ягы.
...Кешене тик Кеше итә—
сүзнең Хагы...

* * *

Дөнья безне кыйнады,
Язмышы—типкәләде...
Сирәк-мирәк мизгел генә
Бәхетле иткәләде.

Дөнья белеп кыйнаган,
Язмыш белеп тыймаган:
Шул бәхетле мизгелләрне
Без үзебез җыймаган...—

Үзебез таратканбыз...
Ә ничек яратканбыз!
Дөнья һаман дөнья килеш,
Без тоташ яра-канбыз.
Барыбер яратабыз...

## Йокысызлык

Карая да куркыта төн,
"Барыбер киләм!" диеп.
Таң кызара, чыга кояш:
"Барыбер көләм!"—диеп.

Җир буйлап томан тарала,
Җәяүләп йөри болыт.
Кояш нуры кагылуга
Чык тама энҗе булып.

Шундый якты күз яшьләре—
Кем уйлар: кара төннән...
Куркып елый төн көннән...
Әй, кемнәр курка—кемнән?!

* * *

Чыгып очкач аның җаны,
Калды "Иблис" дигән даны.
Әмма хата килеп чыкты:
Дәвам итә аның каны!

"Иблис китте!" дип сөенеп
Кычкырганнар—кычкыралар.
Шул табутны—бишек итеп
Тибрәтеп лә эш кыралар...

* * *

Берчак шулай катып кала
бар вөҗүдең,—
Әйтерсең лә, бу дөньяда син
бер үзең...
Ә югыйсә туктап калган
шушы бер чак—
"Пешмәгән" мәл дөнья белән
безнең "борчак"...

* * *

Атламаса аякларың үз-үзеннән,
Чигенә торган булып китсәң
син үзеңнән,
Югалып тор син бер мәлгә—
ил күзеннән:
Аңлар өчен киткәнеңне—
үз-үзеңнән...

* * *

Тула күңел, түгелә:
Күз яшьләре—тоз гына.
Тимә өшегән җанга,
Йә уалыр—боз гына.
Җан кителә, чәчелә.
Куна көмеш чәчеңә.
...Карамый да яшеңә!

## Бар әле...

Төшкә кердең,—
Һаман чакырасың.
Ә мин икеләнәм, шикләнәм.
Юкса инде гомер.... юк, әлегә
Ахырына килеп җитмәгән.

Җитмәгәндер,—
Күрешергә кирәк,—
Әйтер сүзләр калган телләрдә.
Болыннарга чыксам, тамчы-тамчы
Күз яшьләре икән гөлләрдә...

**Сагына ул,
Сагына ул, диләр.
Итәк очларымнан үбәләр...
Шул җилләрне булмый тик туктатып,
Гөлләремә сагыш түгәләр.**

**Гөлләремә...
Түгел гөлләр генә,
Сагыш төсләрендә—көннәрем.
Андый төсне әле дөнья белми—
Нинди төстә дисәң, төннәрем...**

**Ялгызлыкның
Төсен таныйм хәзер—
Аккош коткән күлгә карәле!
...Мәңге кайтмасын да белгән килеш
Котә белүчеләр бар әле...**

* * *

**Танымыйча да танмыйча
Булмас ахры шуны:
Торам-торам да кучерәм
Һаман сиңа уйны.**

**Күчерәм дип күчермим дә:
Уй уя үз юлын.
Уйлар—хәким, алар миндә
Таптылар үз колын.**

**Уйларның иге-чиге юк,—
Иярәм... уйларга....
Тагы сиңа алып бара,—
Белмим ни уйларга...**

**Уйламаска тырышсаң да
Уйлаталар уйлар.
Әле дә кычкырып уйланмыйм,—
Кешеләр ни уйлар?!**



Әлфия
Ситдыйкова

## МИН—БЕР ИНЕШ...

* * *

Минем дөньям чиксез галәм төсле:
Яши ятлар, яши якыннар.
Үз дөньямны шаулы бакча итеп
Яшәр өчен тулы хакым бар.

Якыннарга үзем ишек ачам,
Ятлар әрсез, керә сораусыз.
Өннәрем бар—күгем яктыртучы,
Төшләрем бар—калган юраусыз.

Назларым бар, якты язларым бар,
Шаулап чәчәк аткан аланым.
Чиксез бәхет: ишетәм һәр мизгел
Шат тавышын газиз баламның.

Сөюем бар җанны җылытырга,
Җырларым бар халык өчен дә.
Сыенам мин асыл хакыйкатькә,
Бар бәхетем яшәү көчендә.

### Күңел

Күңел сандыгымны ачтым сезгә,
Йөрәгемдә ничә яра бар?
Сез хөкемдар бүген барлыгыма,
Бер җылы сүз, бәлки, дәвалар.

Үткәннәрем бар да сезнең алда.
Мин—гөнаһлы гади бер кеше.
Үз-үземә язган шикаятьтә
Кайсыгызның күпме өлеше?

Әлфия СИТДЫЙКОВА—*яшь шагыйрә; журналыбызда беренче тапкыр басыла. Чаллыда яши.*

Үкенмим лә, бу бит минем язмыш,
Үпкәм дә юк минем үткәнгә.
Кем ялгышмый, кем хатадан хали
Сикәлтәле юллар үткәндә?

Мин ничек бар, шулай яратыгыз,
Һәр кешенең җирдә үз юлы.
Күңел—арфа. Киерелеп, чыңлап,
Өзелергә әзер һәр кылы.

* * *

Үз үземне табар өчен күпме
Сүткәнмен мин гомер йомгагын.
Үкенмәслек итеп яшәдемме
Артта калган яшьлек елларын?..

Инде таптым үз-үземне дигәч,
Язмыш куя алга зур сынау.
Мөмкинме соң узган мизгелләрне
Хәтерләрдә барлап юксынмау.

Мин үземне таныбырга түгел,
Таныр өчен яшим дөньяда.
Мин—бер инеш, сафлык өстәргә дип
Кушылучы олы елгага.

## Үпкә хисе

Үксез бала сыман күңел
И, елый үксеп-үксеп.
Әйтерсең лә чит ояга
Сыенган ятим көчек.

Җир түгәрәк. Әйләнә дә,
Кояш күренә күктә.
Юып алгандай югала
Шул чакта барлык үпкә.

* * *

Өннәремдә тоям, чынга аша
Һәр мизгеле күргән төшемнең.
Дөньялыкның кырыслыгы аша
Яшәү мәгънәсенә төшендем.

Дошманнарым сөенмәсен әле
Сыгылды дип барган юлында.
Мин иелеп җирдән бәхет кошын
Алдым бары кайнар кулыма.

* * *

Кызыктырып яна, дөрли учак,
Битарафлык җанга хас түгел.
Иеләм дә утлы күмер алам,
Алданасың нигә, әй күңел?!

Тагын сызлый уч төбендә яра,
Пешмәс дигән идем... пешергән:
Янмый гына чыгып буламы соң
Дөрләп янган учак эченнән.

Яши-яши төшендерде язмыш,
Янып яшәү—минем язмышым.
Утлы кузны җыям учларыма,
Тыңлый-тыңлый дөнья тавышын.

Xəter
Хәтер



Миркасыйм
Госманов

# БЕРЕНЧЕ РЕДАКТОРЫМ

*2004 елда "Милли китап" нәшриятында бер библиографик күрсәткеч чыккан иде. Ул тулысы белән диярлек минем исем белән басылган китаплар, эреле-ваклы мәкаләләр, әдәби тәрҗемәләр, интервью-әңгәмәләрнең һәм, ниһаять, минем тарафтан төзелгән яки редакциямдә дөньяга чыккан хезмәтләрнең исемлеген эченә алган. Җәүдәт Миңнуллин тарафыннан тупланган әлеге белешмәдә 2004 елга кадәр дөнья күргән биш йөзләп хезмәтнең исемлеге теркәлгән. Болар арасында махсус монографияләр, җыентыклар, күләмле мәкаләләр белән бергә, әлбәттә, кечерәк язмалар, вак-төяк нәрсәләр дә бар. Бәлки соңгылары күбрәктер дә. Ләкин нәкъ менә шул вак-төякләр арасындагы бер язманы үзем өчен аерата истәлекле дип әйтер идем.*

*Ул—минем Казанда дөнья күргән беренче әйберем—уч төбе кадәре кечкенә генә язма. Менә шул нәрсәнең ничек язылуына, дөньяга чыгуына, дөресрәге, аның барлыкка килүенә сәбәп булган бер очрашу, танышу, хәтта, өзек-өзек рәвештә булса да, нәтиҗәле генә дәвам иткән хезмәттәшлек хакында тәфсилләбрәк язу гыйбрәтле булыр иде дип уйлыйм.*

* * *

1958 елның җәендә Казанга килеп, университетка укырга кергәч, бушрак вакытларымда, моңарчы бер кат язганымча ("Аяз әкә сабаклары"нда), "Чаян" журналының "йомышчы малае" кебегрәк булып йөргән чакта булды әлеге очрашу һәм танышу. Бауман урамындагы Матбугат йортының икенче катында фойеда, Аяз Гыйләҗев яныннан чыгып килгәндә, чамалы гына буйлы, чандыр гәүдәле бер ыспай кеше исемемне атап, "Сез шулмы?"—дип дәште. Уңай җавап алуга ук, исәнләшер өчен кулын сузды:

—Мин "Азат хатын" журналының секретаре Рәшат Гайнанов булам,—диде ул, чак кына елмая төшеп.—Вакытыгыз мөмкинчелек бирсә, биш-ун минут сөйләшеп утырыр идек, сорашасы нәрсәләр бар.

Бер-ике секунд эчендә баштан төрле уйлар өере кичеп узды. Чит илдә туып-үскән, Казанга күптән түгел генә килгән кеше булганга, минем кемлегем, ни өчен бу якларда йөрүем хакында сорашулар болай да җитәрлек иде. Төрле имеш-мимешләр, кыю фаразлар белән мәгънәсез дип әйтерлек уйдырмалар да шактый таралган иде бугай. Бергә укый башлаган группадашларның кайберләре үземә дә ишеттереп торалар иде алар турында. Бигрәк тә шул вакытлардагы гадәт буенча "потенциаль антисоветчик" дип атарлык, хәзергечә әйткәндә, диссидент диярлек рухта булган бер олырак яшьтәге егет, Зыя Ситдыйков (бер ярсыган чакта үз-үзенә кул салган дуамал холыклы кеше) гаҗәпләнеп тә, хәтта беркадәре гарьләнеп тә әйтә иде андый имеш-мимешләр, шикләнүләр хакында.

Күпләр өчен ул вакытта минем СССРга, бигрәк тә Казанга кайтуым беркадәре табышмак та иде бугай. Паспорт-мазар эләктерүгә үк авыл яшьләренең иң әлек берәр

шәһәргә китәргә, хәтта шахталарга, яисә Урта Азия, Казакъстан яки Себер якларына ук ычкынырга тырышулары тәмам туктамаган чор иде бит әле. Өстәвенә, озак еллар дәвамында чит илләргә, чит ил кешеләренә карата ят караш, дошманлык, шикләнүчәнлек хисләре тәрбияләнгән, андый тәрбия әле бетмәгән шартларда... Ә син нәкъ шундый чорда Казанга кил, имеш... Житмәсә, чит илдә туып-үскән кеше, янәсе "ак эмигрант калдыгы"... "Сорашучылар күп булыр",—дигән иде бер көнне, икәү генә калгач, әлеге Зыя сабакташ һәм кисәтеп тә куйган иде:

—Сак бул, бездә бит шымчы өстенә шпион да утыра.

Моның шулай икәнлеген мин үзем дә сизә башлаган идем инде. Бер көнне, сентябрь ахырларында, ниндидер сәбәп белән мине Тарих, тел һәм әдәбият институтына чакырганнар иде. Башта телче галимнәрдән ике-өч кеше, җөмләдән, профессор Латыйф Җәләй дә, минем нинди мәктәптә укуым, татар теленә кайда өйрәнүем, Кытайдагы татарларның ниндирәк телдә сөйләшүләре хакында сорашкан булдылар, аннары әңгәмә өчен икенче бүлмәгә алып керделәр. Андагы "телче" исә сүз арасында ата-бабаларымның кем булулары, нинди эш белән шөгыльләнүләре, кайсысының кайчан, кайда үлүе хакында сорашып бетергәч, Бобинский (!) дигән берәү турында төпченә башлаган иде. Минем әлләни белмәвемне күргәч (ул чакта чынлап та күп нәрсәләр хакында җүнләп белми идем әле), үзе үк аңлатып бирде: "Ул—Русиянең, русларның кан дошманы булган атаклы панисламист, пантюркист, националистларның берсе. Моннан качып китеп, сез яшәгән Кульджада мәктәп ачып маташкан милләтче!" Шунда гына сүзнең Габдулла Буби хакында барганлыгын аңладым. (Соңрак ачыкланганча, жандармерия документларында мәгърифәтченең "фамилиясе" шулай Бобинский дигән вариантта да кулланылган икән.)

Бу "телчене", нигәдер, башка очратырга туры килмәде миңа...

"Казанга кайту" дигәннән, тагын бер "вакыйга" истә ныграк сакланып калган. Матбугат йортының ишеге алдында бәләкәй генә буйлы, зур күзлекле бер журналист ханым, ике-өч җөмлә белән ничек укый башлавым хакында белешкәч, турыдан ярып сорау да бирде: "Казанга ни өчен кайттыгыз соң?!"

Сорау ачуымны китерде шикелле. Шуңа күрә, әлеге "кыю фаразлар" белән имеш-мимешләрне "расларга" теләгән төсле, кырыс кына әйтеп куйдым: "Мин бит милләтче, шуның өчен кайтканмындыр!" Ханым күзләрен зуррак ачып карап алды да, артык бер сүз дә әйтмичә, читкә тайпылды. (Бары 90нчы еллар уртасында гына, Австралиядән кайткач, яныма килеп, интервью бирүемне сорады...)

Дөрес, әлеге сорауның икенче вариантын да ишетергә туры килгән иде миңа. Әле генә исеме аталган, үз язмышыннан һәм илдәге тормыш шартларыннан гел канәгать булмаган сабакташым Зыя Ситдыйков мәсьәләне бөтенләй башкача янгыраткан иде: "Ни пычагыма кайттыгыз бу җүнсез илгә?! Китәргә иде башка берәр җир төбенә! Адәм шикелле яшәр идегез, ичмасам..."

Әмма шуны да әйтергә кирәк, "төп ватанга", хәзергечә әйтсәк, "тарихи ватанга" кайтуны дөрес санаучылар, хуплаучылар да бар иде. Аз түгел иде андыйлар...

Кыскасы, Рәшат Гайнановның биш-ун минут сорашып утыру турындагы тәкъдимен ишетүгә, бер-ике секунд эчендә үк, әйткәнемчә, баштан шундый төрле уйлар, шик-шөбһәләр кичеп өлгергән иде. Шулай да, "монысы нәрсәләр турында төпченер икән әле" дигән кызыксыну белән сөйләшергә ризалыгымны биреп тә өлгергән идем.

Әлеге кечкенә фойедан сул якка борылып, тар коридор буенча дүрт-биш адым атлауга, беренче ишеккә—редакция бүлмәсенә кердек. Эш көненең ахыры булганга, бүлмәдә башка кеше юк иде.

Сөйләшүгә шик-шөбһәләр белән ризалык бирсәм дә, ул тиздән нормаль рәвештә аккан дустанә әңгәмә кыяфәтен алган иде. Менә, ихтимал, иң элек Рәшат Гайнановның үзе белән тәфсилләбрәк таныштыруы, үзен нәрсәләр кызыксындыруы хакында ачыграк әйтүе сәбәп булгандыр. Аның XX гасыр башы татар культурасы, әдәбияты тарихы белән кызыксынуы, Фатих Әмирхан иҗатын өйрәнүе дә (минем искә, кылт итеп, "Шыксыз үрдәк бәбкәсе" төште!), күрәсең, әңгәмәне җайлы юлга кертеп җибәргәндер. Шулай ук боларга, бәлкем, аның башкалар кебек Кытайга барып чыгуның социаль-иҗтимагый, сәяси сәбәпләренә кереп тормавы, "байлык-

ярлылык" хакында да кызыксынмавы, ниһаять, чит илдәге татарларга карата, кыеклап булса да, өстән карарга омтылмавы да өстәлгәндер. Ихтимал.

Рәшат агайны Голжадагы татарларның мәктәп-мәгариф мәсьәләләре күбрәк кызыксындыра иде. Мәсәлән, нинди язу кулланылу, укытучыларның кемнәр булуы, кайда белем алуы, нинди дәреслекләрдән файдалануы һ.б. Татар мәктәбе укытучылары, үземә дәрес биргәннәре арасында да Габдулла Бубыйдан укыган кешеләр булуын ишеткәч, ул елмаеп кына мине бүлдерде:

—Димәк, аның тырышлыгы бушка китмәгән икән!.. Тик бу хакта башкаларга сөйләмәгез; бездә хәзергә Бубыйга карата тискәре мөнәсәбәт хөкем сөрә... Ә дәреслекләр нинди иде соң?

Дәреслекләрнең нигездә совет чорында Казанда басылган булуын, өлешчә иске китаплар да укылуын әйткәч, ул, ни өчендер, "Монысы әйбәт икән" дип хуплап куйды. Аннары совет чоры татар язучыларыннан кемнәр күбрәк укылу хакында да сорады. Гомумән алганда, аның сораулары эшлекле дә, зыялыларга хас рәвештә әдәпле, төпле һәм конкрет та иде. Шулай ук революциягә кадәр чыккан газит-журналларда да Голжа татарлары хакында шактый материаллар булуын әйтеп, минем үземә дә кайбер мәгълүматларны бирде. Һәрхәлдә, аның күп мәсьәләләрдән хәбәрдар булуы, аларны тирәнрәк аңлавы сизелеп тора иде.

Шул рәвешчә сәгать ярым чамасы сөйләшеп утырудан соң, Рәшат Гайнанов конкрет тәкъдим дә ясады:

—Әйдәгез, Голжа татарлары хакында берәр материал әзерләгез әле. Тарихларын, соңгы чордагы хәлләрен дә яктыртып дигәндәй. Тик артык озын булмасын иде. Озын әйбер озаграк чыга.

Минем уйланыбрак торуымны күргәч, ул:

—Икеләнмәгез,—диде.—Сез язмасагыз, кем язарга тиеш аны? Безнең халыкның зур өлеше Татарстаннан читтә яши. Тик монда алар хакында аз беләбез. Ә белергә кирәк! Ике дә уйлап тормагыз—языгыз. Озакка гына сузмагыз...

Икенче көнне үк, уку залының читтәге бер өстәлендә, алдыма КПСС съездлары резолюцияләреннән торган калын томнарның берсен куеп, конспект дәфтәрен дә ачкан килеш, Голжа татарлары хакында уйлана-уйлана "кәгазь тырный" башладым. Сөйләве җиңел булса да, язуы ул кадәр үк ансат түгел икән. Яздым, сыздым, күчердем һәм тагын сыздым дигәндәй. Һәрхәлдә, бер атнадан соң текстны күтәреп, "Азат хатын" редакциясенә килдем.

Текст димәсәң, хәтере калыр: машинкадан соң хәреф хаталары төзәтелүдән тәмам чуарланып беткән ике-өч битле әйбер инде шунда. Татар теле һәм әдәбияты бүлегенең ул чактагы машинисткасы Асия апа—кечкенә генә буйлы, чандыр гәүдәле шадра әби—шулай өч-дүрт юлда биш-алты хата белән баса икән. Кем әйтмешли, "таудан тычкан туган" иде.

Ләкин Рәшат Гайнанов, якты чырай белән каршылап, олы бүләк кебек кулына алды әлеге текст кисәген: "Булган икән, булган икән, рәхмәт сезгә",—дип кабатлый-кабатлый урынына барып утырды.

Башта бер мәртәбә текстка гомум күз йөртеп чыкты. Аннары, кулына каләм алып, аны төзәтә дә башлады. "Әгәр каршы булмасагыз, болай үзгәртик әле", яки "Бу исемне әлегә атарга ярамастыр", "Монысы турында киләчәктә язырсыз әле" дип, кайбер сүзләрне алыштырып, икенчеләрен сызып ташлап, мин язганнарны ботарлый да башлады. Әлбәттә, кайсы исемне ни өчен телгә алырга ярамаганлыгын аңлатып та бара иде.

Тел чатаклылыклары да миндә шактый икән. Мәсәлән, Казакъстан һәм Урта Азия якларында "мин өчен, без өчен" кебегрәк сөйләсәк, әдәби телдә "минем өчен, безнең өчен" кирәк икән...

Шул рәвешчә, мин нәрсәләр, нинди исемнәр тыелган булуы хакында да беренче мәртәбә белә башладым шикелле. Шулай ук гадәти сүзләрнең дә нинлиләре ничегрәк кулланылуы, үз телемдәге аерым кытыршылыклар хакында да уйланырлык "азык" туплана башлады ул көнне.

Һәрхәлдә, аз гына вакыт эчендә дә, язу-сызу эшләренең кайбер "серләре" хакында сабак ала башладым дип әйтерлек булды. Дөрес, текстларны чын-чынлап

редакцияләү кәсебенә мин күбрәк Фәрваз Миңнуллиннан өйрәндем дип әйтер идем. Әмма Рәшат Гайнанов төзәтүләренең иң беренче адымнардан икәнлеген дә онытмыйм.

Аның бер исемне төзәтүе истән чыкмый. Мин безнең тарихтагы билгеле бер мәгърифәтче исемен, аннан бер җәй дәресләр тыңлаган әниебезнең сүзләре буенча, "Закирел Кадыйрый" дип язган идем. Рәшат агай исә аны "Закир әл-Кадыйрый" дип төзәтте һәм хатаның "серләрен" дә аңлатты.

Шул рәвешчә, үзем үк шактый чуарлап китергән текст кисәге тәмам "бизәкләнеп" беткән иде. Тырыша-тырыша язганнарымның бу кадәр сызгалануыннан кәефем ярыйсы гына кырылган иде бугай, моны сизгән редакторым мине юата да башлады:

—Борчылмагыз болай төзәтүгә, башкаларның әйберләрен дә шулай төзәткәлибез инде,—диде ул һәм өстәлдәге кульязмалардан шулай ук чуарланып беткән бер кәгазьне алып күрсәтте.—Без шуның өчен утырабыз инде монда, редакторларның бурычы шуннан гыйбарәт. Ә бу сезнең матбугат өчен беренче әйберегез, ялгышмасам. Әле шома язарга да өйрәнерсез. Һәрхәлдә, сезгә зур рәхмәт, вәгъдәдә торганыгыз өчен. Бастырырбыз монысын!

Шулай итеп, уку залында мин сызгалаган, бозган, Рәшат Гайнанов редакцияләгән-төзәткән беренче язмам, ягъни матбугатка текст әзерләүдә узган беренче тәҗрибәм һәм зурдан кубып "Голҗа татарлары" дип аталган әйберем ике-өч айдан соң дөньяга чыкты. "Азат хатын" журналының 1959 елгы икенче санында.

Ул язманы кем ничек укыгандыр, укып ни уйлагандыр, гомумән, укучы булгандырмы—анысын ул чакта белмәдем. Дөресрәге, берәр сүз әйтүчене хәтерләмим. Шулай да, бер нәрсә сизелгәндәй булды: тора-бара төрле примитив сораулар биру кими төшкәндәй итте. Ләкин мондый үзгәрүнең икенче сәбәпләре дә булуы ихтимал. Мәсәлән, "Кытай татары кайту" хәбәренең искерә баруы, күзләрнең дә "ят чырайга" күнегә төшүе...

Язмам шулай үз алдымда ук тиз генә редакцияләнеп, китәргә дә ярар дип хуплаша башлагач, редакторым тагын нәрсәләр язарга җыенуым, язылган әйберләрем дә булу-булмау турында сорашты. Шигырьләр язгалавым хакында әйткәч, аларны да китерергә кушты. (Минем Казанга 1958 елда ук килеп чыгуыма, бер әйткәнемчә, шулай шигырьләр язу белән дә мавыгуым сәбәп булган иде бит.) Китердем. Берничә тәрҗемә үрнәкләрен дә. Үз әйберләремнән ике-өчен сайлап алып, аларны да бастырырга ниятләвен белдерде Рәшат агай. Шунда ук аларның ике-өч сүзен төзәтеп тә куйды. Ләкин ни өчендер алар басылмыйча калды. Бары үзбәк шагыйрәсе Зөлфиянең шигырьләреннән эшләнгән әйберләрем шул ук 1959 елда басылып та чыккан иде.

Бу вакытта миндә кайбер эчке үзгәрешләр барлыкка килеп, гамәлдәге матур әдәбиятка, җөмләдән, шигърияткә карата да күңелдә әллә нинди аңлаешсыз мөнәсәбәт урнаша башлаган иде. Суыну хисе дип әйтимме шунда. Әллә мәнфәгатьләрнең икенчерәк юнәлешкә керүе сәбәп булуы микән. Бәлки, шагыйрьлек "жененең оеткысы" шуның кадәр генә булгандыр миндә. (Һәрхәлдә, бу вакытта мин тел белеме белән күбрәк кызыксына башлаган идем.) Шуна күрә махсус сорашып тормадым әлеге ике-өч әйберем хакында. Рәшат абый да алар турында, авызына су капкан кебек, башка сүз кузгатмады. Ягъни икебез дә бер-беребездән, үз-үзебездән "сер саклаган" төсле, әлеге билгесезлекне саклadык. Мин үзем исә ул чакта, хәзер дөресен әйткәндә, аларның чыкмауларын теләп йөргән кебегрәк халәттә идем.

Мондый "билгесезлекнең серләре" бик соң, кырык елдан соң гына ачылды. 90 нчы елларның ахырларында бер зур җыенда "Азат хатын" журналының элекке баш мөхәррире Асия ханым Хәсәнова (сугыш вакытында чыгудан туктаган, ягъни "үлгән" басманы янадан "тергезгән", ныклап аякка бастырган мөхтәрәм зат) белән очрашырга туры килгән иде. Исәнләшеп, хәл-әхвәл сорашкач, Асия ханым үз хәтереннән шәп икәнлеген раслаган төсле:

—Сезнең иң беренче әйберегез бездә басылган иде бит!—диде һәм сәер генә елмаеп өстәп куйды.—Ул мәкаләгез чыккач, беләсезме, мине Өлкә комитетына чакыртып алып, өстәл төя-төя: "Тапмадыгызмы бастырырга берәр башка нәрсә?!"—дип орышканнар иде...

Бу сүзләрне ишетүгә, кылт итеп дигәндәй, искә әлеге ике-өч шигырь кисәгенең серле язмышы килеп төште. Рәшат абыйның авызына су капкан кебек йөрүен дә аңладым шунда.

Әмма Асия ханымнан аны кемнәрнең шулай өстәл төеп орышуы, ягъни түбәнсетүе хакында сорашырга базмадым. Кайчандыр "серне йотуы" белән минем күңел тынычлыгын саклаган кешенең күңел ярасын янартып тоз салырга теләмәдем бугай. Ә Рәшат абый исән булган булса, ихтимал, анардан сораштырып карар идем.

Әлеге "Голжа татарлары" дигән язмадан соң ике ел узгач кына, минем Чыңгыз Айтматовның "Җәмилә" повестын тәрҗемә итеп йөрүемне ишеткән Р.Гайнанов, махсус чакыртып алып, аннан берәр өзек бирүемне сорады. Шул рәвешчә, 1961 елда "Азат хатын"да "Җәмилә" повестеннан "Җыр" дигән өзек басылып чыкты.

Дөрес, ул чакта әле киң танылып өлгермәгән Ч.Айтматов әсәреннән алынган өзеккә (ихтимал, тәрҗемәгә) карата редакциядә беркадәре шөбһә, бәхәс тә туган иде бугай. Рәшат абый мыгырданган кебек кенә, борчулы кыяфәт белән шуны сиздерде. Шул форсатны гына көтеп торган кебек мин портфелемнән атаклы француз әдибе, халыкара абруйлы коммунист Луи Арагонның "Җәмилә"гә багышланып, "Мәхәббәт хакында дөньядагы иң гүзәл бәян" ("Самая прекрасная на свете повесть о любви") дип аталган мәкаләсен чыгарып бирдем. Ана бер күз йөртеп чыгу белән Рәшат абыйның йөзләре яктырып китте: "Шәп булды бу!"—дип көлеп тә җибәрде. Хәзер уйлап карасам, әлеге бәхәскә кайчандыр "өстәл төя-төя" орышу да сәбәп булганга охшый...

Моннан соң күп елларга кадәр "Азат хатын" белән элемтәләр өзелеп торды диярлек. Бер кадәре вакыттан соң Рәшат Гайнанов та аннан киткән, минем әдәби-гыйльми мәнфәгатьләрем дә шактый үзгәргән иде. Шулай да, Рәшат абыйның үзе белән шәхсән самими мөнәсәбәтләр өзелмәде. Очрашкан чакта ихлас сөенеп кул кысыштык, әңгәмәләшеп тә алгалый идек. Шулай бер-беребезгә карата изге теләктә кала килдек. Шул ук вакытта безнең арада билгеле бер дистанция дә сакланды—яшь ягыннан аерма булуның нәтиҗәседер, күрәсең. Без артык якынлашмадык дип әйтүем.

Мине иң кызыксындырган, хәтта сокландырган нәрсә ул Рәшат Гайнановның XX гасыр башы—татарларның алтын чоры тарихы буенча гаҗәеп киң колачлы, искитәрлек тирән белеме иде. Р.Гайнанов тырышлыгы белән кайбер "онытылган", дөресрәге, махсус рәвештә оныттырылган исемнәрнең кайтарылуы, Газиз Гобәйдуллин, Нәҗип Думави иҗе күренекле әдипләрнең җыентыклары чыгарылу яңа чор әдәби фикеребезгә сизелерлек өлеш булды. Фатих Әмирхан иҗаты да аның тарафыннан эзлекле рәвештә өйрәнелә иде. Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимовларның гыйльми югарылыкта эшләнгән томнары чыгуда да аның өлеше зур икәнлеге һәммәбезгә мәгълүм иде. Хәтта моны танырга теләмәгән хөсет кешеләр өчен дә.

Мине бигрәк тә әлеге томнарга Рәшат Гайнанов тарафыннан шул чор өчен мөмкин булган күләмдә, киңлектә, тирәнлектә язылган искәрмәләр, аңлатмалар сокландыра иде. Алар белән җентекләп танышу XX йөз башы татар әдәбияты, татар мәдәнияте хакында шактый мул һәм конкрет белем тупларга мөмкинлек бирә иде. Шул чорда хөкем сөргән төссез, шәхессезләндерелгән рәсми тарих—печелгән, кысрыклапдырылган, ягъни нигездән саектырылган, бозылган совет чоры тарих "фәне" фонында бигрәк тә.

Шунысы да мәгълүм булсын, күпләр теге яки бу мәсьәлә буенча аңлаешсызлык килеп чыкса, Рәшат Гайнановка мөрәҗәгать итеп, анардан мөмкин кадәр тулы, төгәл җавап алалар иде. Үземнең дә берничә кат шул рәвешчә аның белеменнән файдаланганым бар. Шундыйлардан бер гыйбрәтле мисалга махсус тукталуны кирәк табам.

Кәгазьдәге "су билгеләренә" караганда, бу кулъязма 1822 елдан соң Казан артында күчерелгән икән. 1845 елда аны Көтек авылында "бер сум утыз тиен" хакына Бәләбәй өязе кешесе сатып ала. Аннары ул 1901 елда Орск якларында тагын "дүрт сум акча" исәбенә "Гыйрфан мулла Әхмәди угылы Ибраһимов" дигән кеше милкенә күчә. Моннан соң әлеге Казан арты кулъязмасы Кытай җирендәге Голжа шәһәренә барып чыга. 50нче елларның икенче яртысында татар язмышы

аны Алма-Атага китереп ташлый, шуннан соң ул, ниһаять, 70нче елларда Казанга әйләнеп кайта.

Менә шул "сәяхәтче" китапның тарихын өйрәнгән чакта, элек бер язганымча ("Каурый каләм" китабында), мин бер фараз белән мавыгып киттем. Ирексездән мәгълүм әдибебез Галимҗан Ибраһимовның әтисе Гыйрфан мулла искә төште. Ул да бит Оренбург, Троицк якларында йөргән. Гаҗәп, Гыйрфан мулланың атасы ни исемле булды икән? Әгәр шулай Әхмәди булган булса, ул чакта китапның соңгы бер битендәге бала кулы белән "Һәза китап сахибе (иясе, хуҗасы – М.Г.) Гыйрфан Әхмәди Ибраһимов" дигән язу Галимҗанның үзе, яки аның берәр туганы калдырган автограф булып чыга түгелме соң?!.

Бу фаразымның дөреслеген ачыклауны, дөресрәге, аның раслануын теләп дигәндәй, мин мавыгып эзләнә башладым. Тик Г.Ибраһимовка багышланган хезмәтләрнең берсендә дә Гыйрфан мулланың атасы кем икәнлеге күрсәтелмәгән икән. Сорауларыма төгәл җавап тапмаган саен Г.Ибраһимовның бабасы шулай Әхмәди дип аталгандыр дигән ышаныч, дөресрәге, өмет көчәя генә барды. Күрәсең, ышанычлы мәгълүматлар житеп бетмәү менә шундый ашыгыч нәтиҗәләргә этәрәдер дә инде.

Шулай бер нәтиҗәгә килә язган төсле, кызыклы ачыш буласы дип, үз-үземә ышанып бетә язган көннәрнең берсендә, Матбугат йорты тирәсендә, сугышта яраланган бер аягын урый төшеп атлаучы Рәшат Гайнановны очраттым. Саулык-сәламәтлек хакында сорашып, бер-беребезгә уңышлар теләшеп, китә башлагач, исемә әлеге Әхмәди мәсьәләсе килеп төште.

—Карале,—дидем,—Галимҗан Ибраһимовның бабасы ни исемле булды икән?

Рәшат абый бу юлы да миңа электән үк танышрак рәвештә җавап бирде:

—Хәзер хәтерләмим инде. Кичкә, картотекага карагач, үзеңә шалтыратып әйтермен әле.

Өйгә кайтып, икенче бер эш белән мавыгып, бу кичкә Әхмәдине дә, әлеге илгизәр китапны да онытып утырган чакта, телефон чылтырады:

—Рәшат абыең бу. "Йолдыз" гәзитенең 1913 ел, 16 апрелендә чыккан 970нче санында Гыйрфан Ибраһимовның вафаты турында хәбәр ителгән, ягъни кечкенә генә некролог басылган. Бәлки әдипнең бабасы шунда телгә алынадыр? Миндә некролог тәфсилләп язылмаган икән. Гәзитнең шул саны университет китапханәсендә бар. Хәзергә менә шулар гына.

Иртәгесен иртүк университет китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә идем. Менә "Йолдыз"ның 1913 елгы төпләме. Менә 970 нче сан. Менә әлеге тәгъзиянамә—некролог. Гыйрфан мулланың кайчан вафат булуы, кайчан дәфен ителүе һәм үзенең сәер холкы вә уңай гадәтләре. Ул Троицкида Зәйнулла ишанның хәлфәләреннән берсе булып торган икән. "Тик атасы *Нурмөхәммәд ахунд* вафат булганнан соң, халыкның теләве белән Солтанморадка кайтмыштыр."

Шулай итеп, элек бер язганымча, очты-китте Әхмәдием!

Шуның белән бергә әлеге "ачыш" хакындагы татлы хыяллар да...

"Йолдыз"ның төпләмен япкан чакта мин шулай кәнфит урынына кәгазен генә алып алданган малай шикелле хис итә идем үземне. Тик урамга чыгып, бер чәлем кабызып, аны тәмам суырып бетергәч, үз-үземнән көлеп, әллә-ничек сөенеп тә куйдым: ничек кенә булмасын, хакыйкать ачыкланды бит! Монысы да үзенә күрә бер табыш. Икенчедән, бу вакыйга очраткан мәгълүматларны Рәшат Гайнанов шикелле тәртипле рәвештә, иренмичә теркәп баруның да хикмәтен, әһәмиятен күрсәтте. Гәзитнең кайсы саны кайда саклануын да теркәп куйган бит бу Гайнанов!..

Моннан соң Рәшат Гайнановны бер очратканда, әлеге хикмәтле картотекасы хакында тәфсилләбрәк сораштым. Студентлык һәм аспирантурада укыган елларында ук ул элекке гәзит-журналларда мәдәният һәм әдәбият тарихына караган һәр материалны, кыскача гына эчтәлеген ачып, шулай аерым карточкага теркәп барган икән. Үзе эшли торган конкрет темага караганнарын да, карамаганнарын да. Ягъни сайлап кына түгел. Карточкалар тематик һәм алфавит тәртибендә сакла112налар икән. Шул рәвешчә киң колачлы белешмәлек барлыкка килгән.

Бер үк вакытта ул үзе укыган, үз күзләре белән күргән, яки башка кешеләрнең

хезмәтләреннән укып белгән татарча газит-журналларның исемнәрен дә аерым картотекага махсус теркәп, исемлек төзи башлаган икән.

—Гомерем житсә,—диде ул уйчан гына,—революциягә кадәр татар телендә чыккан барлык газит-журналларның тулы исемлеген төзергә дигән ниятем бар. Бер Казан-Оренбургларда түгел, ә бөтен Русия империясендә чыкканнарын. Һәм, беләсенме, коры исемлек кенә түгел, бәлки кайсы газит-журналның кайда күпме һәм нинди саннары саклангалыгын күрсәтә торган төгәл белешмә дә кирәк безгә!

Соңгы фикер мина аерата мөһим булып тоелды: андый белешмә эзләнүче галимнәрнең эшләрен бермә-бер жиңеләйтәчәк бит. Тизрәк ирешәсе иде шундый төгәл мәгълүматлы күрсәткечкә...

...Шактый еллар узып, ректораттагы тавык чүпләп бетермәс эшләргә күмелеп утырган көннәрнең берсендә "Рәшат Гайнановны эшеннән чыгарганнар икән, хәзер эшсез йөри диләр" дигән хәбәр килеп житте. Имештер, вакыт-вакыт эшкә рәтләп йөрмәве сәбәп булган. Бу хәбәр мине бик гажәпләндерде. XX гасыр башы татар әдәбияты, татар культурасы тарихы буенча энциклопедик белемгә ия дип әйтерлек, һаман ижади эшкә сәләтен саклаган шундый кешенең эшеннән чыгарылуы акылга сыймаслык хәл иде. Һәрхәлдә, минем акылга шулайрак тоела иде. Әгәр берәр кеше өчен урын кирәк булган булса, институтта көн саен эшкә тәртипле йөреп тә, соңгы ун-унбиш ел дәвамында файдалы бер эш тә башкармаган бәндәләр дә буа буарлык бит ләбаса! Һәм, уйлана торгач, миндә бер фикер дә борный башлады. Эш урыныма чакырттым үзен.

Артык көттермичә килде Рәшат абый. Бераз картая төшкән, йончылып та калган сыман тоелды үзе. Һәрхәлдә, элеккечә күнелле, ачык чырайлы түгел иде ул. Шул ук вакытта зарланып та утырмады. Пенсионерлык язмышының котылгысыз икәнлегенә аңына сеңеп өлгергән иде бугай. Тик бездәге пенсия акчасына яшәп булмавы да көн кебек ачык бит... Шуна күрә мин сүзне кыска тоттым: анар безгә, ягъни күптән түгел университетта оештырылган археографик лабораториягә, эшкә керергә тәкъдим иттем.

—Анда нишләрмен соң?—диде ул бераз гажәпсенгән төсле.—Мин бит кулъязмалар белгече түгел... Факультетта берәр эш кисәге булмасмы дип уйлаган идем, лаборант кына булса да...

Археографик лабораториянең эшчәнлегенә элекке иске язуыбыздагы газит-журналларга библиографик күрсәткечләр төзү эше дә керәчәген әйттем. Гыйльми хезмәткәр вазыйфасындагы аның үзенә исә, әгәр риза булса, революциягә кадәрге татар матбугаты хакындагы әлеге үзе төзи башлаган белешмәне тәмамлау бурычы йөкләнү мөмкинлеген белдердем. Соңгы фикерне ишеткәч, Рәшат абый жанлана төште:

—Монысы әйбәт булыр иде,—диде ул көррәк тавыш белән, ләкин шунда ук, төртелеп калган төсле, бераз уйланып торды һәм тагын сүлпәнләнә төшкән тавыш белән тезеп китте.—Анда эшлисе эшләр шактый әле, кайсы матбугат органының кайда күпме саклануы хакындагы мәгълүматларны яңабаштан тикшерергә, тулыландырырга кирәк. Аннары Ленинградка, Уфага, Алма-Ата белән Ташкентларга да барасы булыр. Миндә нәкъ шул өлешләре житеп бетми. Командировка өчен акча да кысылып бетте бит хәзер... Дөресен әйткәндә, ерак юлга чыгу да куркыта, аяк та, йөрәк тә... дигәндәй. Бурычны үги алмыйча оятка калмасмынмы соң?..

Мәсьәләнең бу яклары да беркадәре уйланылган иде миндә. Командировкаларга йөрү, жыелган материалларны эшкәртү ише "кара эшләрне" башкару өчен, әгәр үзе риза булса, ярдәмгә бер-ике егет тә билгеләнү мөмкинлеген әйттем. Ул чак кына сагайган кыяфәт белән сорап куйды:

—Кемнәр, мәсәлән, иске язуны укый алырлармы соң ул егетләр?

Раиф Мәрданов белән Фәрит Шәкүровларның исемнәрен ишеткәч, ул канәгать чырай белән башын иэде:

—Аларны беркадәре беләм. Аларга да эш житәрлек. Теләсәләр, соавтор да булырлар.

—Авторлашлык мәсьәләсен эш нәтижәсе күрсәтер,—дидем,—ә бүген принципта хәл итик. Ризамы соң?

Ул тагын сорап куйды:

—Күпме вакытка эшкә алырсыз икән?

—Монысы шарт түгел, бары әлеге тулы күрсәткечне тәмамлау төп шарт булырга тиеш. Аннан соң да, исән булсак, эш табылыр.

Шулай итеп, ул, ниһаять, эшкә керергә ризалыгын бирде, рәхмәтләрен әйтте. Аның мәсьәләгә шулай җаваплы каравы мине тагын бер кат сокландырды. Шуңа күрә янә бер кат аның күңелен җылытырга теләдем:

—Лаборатория кулъязмалар бүлеге янында гына. Тик ул кичке бишкә кадәр генә ачык була. Көн саен фәлән сәгатькә эшкә йөрү дә катгый шарт түгел бездә. Үз җаена карап йөрерсең шунда.

Шул рәвешчә, 1988 елның август аеннан башлап Рәшат Гайнанов Казан университетының татар халкы тарихы кафедрасы каршындагы фәнни-тикшеренү археографик лабораториясендә гыйльми хезмәткәр сыйфатында эшли башлады. Ярдәмгә тәкъдим ителгән егетләр белән дә бик тиз уртак тел тапты.

Эш турында махсус сөйләшү берәр атнадан соң булды. Рәшат абый ике бит кәгазьгә эшләнергә тиешле эшләрнең планын һәм, иң мөһиме, булачак күрсәткечнең концепциясен төзеп китерде. Аның төп идеяләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт иде.

1. Библиографик күрсәткеч татарча беренче басма сүз чыккан вакыттан, ягъни 1905 елдан алып 1918 елда совет хөкүмәте карары белән "буржуаз һәм контрреволюцион" газит-журналлар тыелганга кадәр төрле җирләрдә татарча нәшер ителгән барлык матбугат органнарын эченә алырга тиеш.

2. Гәзит-журналларга сәяси һәм идеологик күзлектән бернинди бәя бирелмәс, ягъни берьяклы тамга сугылмас, алар хакындагы мәгълүматлар бары хронологик тәртиптә урнаштырылган булыр.

3. Гәзит-журналларның исемнәре, тоткан юллары хакындагы белешмәигъланнары оригиналдагыча гарәп язулары белән, чыккан җирләре, нашир һәм редактор исемнәре татарча латин язуындагы транскрипциядә вә боларның барысы да русчага тәрҗемәдә бирелер. Ягъни күрсәткечкә икетеллек тәэмин ителер.

4. Мөмкин булган очракта һәр гәзит-журналның кайда күпме нөсхәләре һәм конкрет нинди саннары сакланылуы да күрсәтелер. Шул рәвешчә аларны эзләү һәм табу эше җинеләйтелер.

5. Төзүче үзе күрмәгән, шәхсән танышмаган, ләкин башка авторларның хезмәтләреннән укып белгәннәре хакында мәгълүматны шул чыганаклар нигезендә бирер, белешмәнең кайдан алынуын төгәл күрсәтер һ.б.

Принципләр белән килешмичә мөмкин түгел иде. Киләчәктә тагын кайбер аныклаулар, төгәлләүләр булыр әле дигән фикер белән бер карарга киленде. Минем үземә икенче пункттагы фикер аерата ошаган иде. 1967 елда Мөхәммәт Мәһдиев белән бергә язган бер мәкаләбездә бик зур саклык белән генә шундыйрак фикер уздырырга тырышуыбызның шактый көчле тәнкыйтькә очравы искә төште. Безне "бербөтен буржуаз агым" идеясенә ияртүдә гаепләделәр. Өлкә комитетының органы булган "Социалистик Татарстан" гәзитендә зур күләмле редакцион (дөрес булса, ультра сул тәнкыйтьче Хәсән Хәйри тарафыннан әзерләнгән) шактый "тешле" мәкалә басылып чыккан иде. Монысы аз дигәндәй, бер гыйльми конференциядә мәгълүм большевистик идеолог Камил Фәсиевнең зур күсәккә охшаган "саллы" докладлы да яңгыратылган иде... Аннан бирле егерме елга якын вакыт узган, заманалар үзгәргән—"үзгәртеп кору"ның айныткыч җилләре исә иде инде. Шулай да, нәрсә әйтер икән, дигән уй белән, Рәшат абыйдан сорап куйдым:

—Теге вакыттагы кебек таяк эләкмәсме соң?

—Безнең бурыч алдан ук бәя бирү түгел бит! Исмәгыйль Рәми белешмәсенең бер кимчелеге менә шуннан гыйбарәт. Без башкалар махсус өйрәнер өчен ярдәмлек әзерләүчеләр генә бит. Библиографиянең чын максаты менә шуннан гыйбарәт, минемчә!

Археографик лабораториядә Рәшат Гайнановның эшчәнлеге менә шулайрак башланып киткән иде. Берkадәр вакыт узгач ул, "киңәшәсе бар" дип, яңадан минем янга керде.

—Беләсеңме, планны бер кадәре үзгәртергә дигән фикергә килеп торам әле,—

диде ул уйчан гына.—Белешмәнең хронологик кысаларын киңәйтергә кирәк булыр дигән фикердәмен. Әйтик, 1918 ел белән генә чикләнмичә, 1925 елга кадәр, ягъни 1905-1924 елларны бергә алсак, дөресрәк булыр дигән нәтиҗәгә килдем. Чөнки 1918 елгы хөкүмәт карары белән генә мәсьәлә хәл ителеп бетми бит. Юашрак рәвештә булса да, матбугат һәм сүз иреге өчен көрәш 1923-1924 елларда да дәвам итә әле. Бары шуннан соң гына татар телендәге матбугат тәмам советлашу юлына баса. Аннары 1925 елдан алып латинга күчү процессы да башлана бит...

Дөресен әйткәндә, бу тәкъдим минем өчен күктән көткәнне җирдән табу кебек тоелды. Минем үземдә дә кайбер күренешләрне бик тиз "советлаштыруга" карата шикләнү хисе барлыкка килгән иде. Мәсәлән, 1917 елдан соң күп кенә рус һәм татар тарихчыларын "совет тарихчысы" дип характерлау белән килешеп җитмәү кебек. Гүяки элекке патша Русиясендә тәрбияләнгән, белем алган, дөньяга карашлары утырып җиткән кешеләр бер-ике ел эчендә генә шулай нигездән үзгәрә дә куя! Өстәвенә, Мирсәет Солтангалиевне эзәрлекләү белән татарлар арасындагы милли-азатлык хәрәкәтенә, милли бердәмлек идеясенә чик, киртә куела башлау да минем өчен артык зур сер түгел иде.

Әйе, тарихыбызда үзенә күрә иң кискен борылышның берсе, дөресрәге, якнактан кысылу, кысрыклану, асылда "советча" гарипләнү чоры шулай егерменче елларның урталарыннан башланган иде. Димәк, Рәшат Гайнанов та икенче төр чыганаклар (милли матбугат язмышы) мисалында шундый ук фикергә килгән икән. Кабул иттем, әлбәттә, әлеге тәкъдимне.

Шулай да:

—Күрсәткечнең тәмамлануына тәэсир итмәсме бу?—дип сорадым.

—Бераз тоткарланыр, күрәсең,—диде ул һәм өстәп куйды,—аның каруы күрсәткеч тулырак та, тарихи җәһәттән дөресрәк тә булыр иде.

Ул вакытта мин, хронологик кысаларның киңәюе күрсәткеч тәмамлануны берике елга кичектерер дип уйлаган идем. Ләкин чынбарлык тагын да катлаулырак булып чыкты. "Үзгәртеп кору"дан соң барлыкка килгән үзгәрешләр нәтиҗәсендә университетның, бигрәк тә гыйльми лабораторияләрнең финанс мөмкинлекләре кискен рәвештә начарлана башлады. Хезмәт хакына тиешле фондның университетта гел киселә баруы сәбәпле, хезмәткәрләр штатын да кыскарта барырга туры килде. Берара ун-унбер кешедән торган штат дүрт-биш кешегә калды...

Командировкалар өчен дә акча тәмам саегып бетте. Ерак шәһәрләргә сәфәрләр оештыру хакында уйларлык та түгел...

Өстәвенә, Рәшат агай да ешрак авыргалый башлады бугай, һәрхәлдә, сирәгрәк күренә иде. Ябыга төшкән хәлдә, йончыган кыяфәттә йөрде ул. Дөрес, бер дә зарланмый иде үзе. Вәзгыять авыраюның объектив сәбәпләрен үзе дә яхшы аңлый иде, күрәсең. Болай да тыйнак табигатьле кеше тагын да ныграк тыйнакланды шикелле. Шул рәвешчә, 1990 елның 9 октябрендә "тыныч кына" китеп тә барды ул. Үзенә 65 яшь туларга да нибары 20 көн генә калган килеш...

Шулай итеп, Рәшат Гайнановның идеясе вә тырышлыгы белән башланган зур күләмле һәм бик кирәкле күрсәткеч-белешмә төрле объектив сәбәпләр аркасында тәмамланып җитмәгән килеш калган иде. Ләкин дәвам итәрлек, тулыландырып җибәрерлек бай мая—булачак белешмәнең төп һәм, һичшиксез, зур нигезе калган иде мәрхүм Рәшат Гайнановтан соң.

90нчы елларда университеттагы барлык лабораторияләрнең хәлләре тагын да мөшкелләнә төште. Археографик лабораториянең үзен, *дөресрәге, аның идеясен* саклау өчен штатны һәм башка чыгымнарны да гел кыскарта бару мөмкинлеге генә калды. Хезмәткәрләр саны ике-өчкә "җитте"... Раиф Мәрданов Милли китапханәгә эшкә күчте. Фәрит Шәкүров Чаллы ягына ук китеп барды.

Шулай да, егетләр күрсәткеч өстендә эшләүләрен дәвам иттеләр. Элек тупланган мәгълүматларны яңабаштан тикшереп чыгу, өстәмә белешмәләр кертү, җыелган материалларны редакцияләү, дөресрәге, унификацияләү һәм башка эшләр. Милли китапханә ярдәме белән ерак шәһәрләргә ике-өч сәфәр оештыру мөмкинлеге дә туды. Ул яклардан элек исәпкә алынмаган өр-яңа материаллар кайтты.

Шул рәвешчә, XX гасырның 50нче елларында ук аспирант Рәшат Гайнанов

туплый башлаган, 80нче еллар ахырында "лаеклы ялдагы" кеше тарафыннан шактый тулыландырылган, 90нчы елларда исә аның яшь каләмдәшләре тырышлыгы белән төгәлләнеп, эшкәртелеп беткән күрсәткеч, ниһаять, 1999 һәм 2000 елларда, ягъни илле елдан соң(!) аерым китап булып басылып та чыкты. (Сынап карау өчен чыгарылган беренче басмасы 200 генә нөсхәдә булса, 2000 елдагы тулырак варианты 500 данәдә нәшер ителде.) Милли китапханә каршындагы "Милли китап" нәшриятында "Хезмәттәшлек" дигән сериядә.

Университеттан "Татар халкы тарихы кафедрасы"ның, китапханәдән исә анда яңа ачылган "Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге"нең уртак хезмәте сыйфатында чыкты әлеге белешмә.

Ул китап татарча **"XX йөз башы татар вакытлы матбугаты. Библиографик күрсәткеч"** һәм русча **"Татарская периодическая печать начала XX века. Библиографический указатель"** дип атала. Чөнки аңардан ике телдә дә файдаланып була. Икенче вариантта тагын төп мәгълүматлар латин транскрипциясендә дә бирелгән. Һәр ике очракта да хезмәт өч кешенең—Р.Р.Гайнанов, Р.М.Мәрданов, Ф.Н.Шәкүровларның авторлыгында басылган.

316 битле күрсәткечтә 1905-1924 елларда Россия империясенең һәм СССРның төрле шәһәрләрендә, төбәкләрендә татар телендә чыгып калган 310 исемдәге гәзит һәм 89 журнал хакындагы иң кирәкле белешмәләр тупланган. Китап шулай ук файдалану өчен кирәкле өстәмә белешмәләр—махсус таблицалар белән дә тәэмин ителгән.

Әлбәттә, киләчәктә бу хезмәткә керми калган берән-сәрән башка гәзит-журналларның да табылуы, яки кайбер белешмәләргә өстәмәләр, төзәтүләр бирелүе бик ихтимал. Чөнки XX гасырның беренче чирегендә—татар халкы тарихының гаҗәеп актив чорында барлыкка килгән күренешләрнең, яңалыкларның һәммәсен дә төгәл беләбез, исәпкә алып бетергәнбез дип әйтү артык кыюлык булыр иде.

Тулылыгы җәһәтеннән элегрәк чыккан башка күрсәткечләрдән шактый аерылып тора торган (шулай да аларның казанышларыннан актив файдаланган) бу хезмәтнең бер иң мөһим өстенлеге бар. Ул өстенлек анда теркәлгән күпчелек гәзит-журналларның кайда күпме нөсхәләре, конкрет саннары саклануы төгәл күрсәтелүдән гыйбарәт. Димәк, теге яки бу матбугат органын карарга, өйрәнергә теләгән кеше, элеккечә "капшанып" кына йөрмичә, кайда нәрсә барлыгын алдан белеп эш итәчәк. Рәшат Гайнанов тарафыннан фәнни культурабызга кертелгән иң әһәмиятле өлешләрнең берсе дип мин күрсәткечнең менә шушы сыйфатын атар идем.

Күрсәткечнең озак еллар дәвамында барлыкка килүе очраклы хәл түгел, бәлки үзенә күрә табигый, шунысы белән *гыйбрәтле* күренеш. Күпчелек өчен хезмәт итәргә тиешле фундаменталь фәнни хезмәтләр—махсус белешмәләр шулай озак эшләү, күмәк хезмәт нәтиҗәсендә барлыкка килүчән була...

Мәсьәләнең тагын бер гыйбрәтле ягы да бар: кайчандыр минем беренче басма әйберемә редактор булып аны дөньяга чыгарган кешенең соңгы зур хезмәтенә гыйльми редактор булу, махсус кереш мәкалә язу шәрәфе минем үземә насыйп булган икән. Шулай ук мин үзем азмы-күпме дәрәҗәдә аның шәкерте булган булсам, үз нәүбәтендә минем шәкертләрем дә күрсәткечнең чыгуына лаеклы өлеш керттеләр.

* * *

...Рәшат абый Гайнанов үзе исән булса, тулысынча канәгать калыр идеме икән бу күрсәткечтән—өздереп әйтүе мөмкин түгел, әлбәттә. Әмма бер нәрсәне тәгаен беләм: татар тарихы, аның мәдәнияте, катлаулы язмышка ия басма сүзе белән киләчәктәге кызыксынучыларның һәммәсе дә диярлек, иң элек, китапны кулларына алуга ук, "Р. Р. Гайнанов" дигән фамилияне укыячаклар.

Үзенә күрә истәлек, хәтта һәйкәл дә.

Ниһаять, форсаттан файдаланып, бу истәлекне барлыкка китерүгә, дөньяга чыгаруга өлеш керткән шәкертләремә рәхмәтләр әйтеп, әле генә телгә алынган гыйбрәтләргә—буыннар арасындагы хикмәтле, зарурый бәйләнешләргә тагын бер кат ишарәләп, сүзләремне тәмамлар идем.

*Июль, 2005, Нарат.ты.*



Әхәт
Мушинский

# ЯҢГЫРЛЫ ФИНЛЯНДИЯДӘ

Фин язучыларының, төгәлрәк әйткәндә—Фин ПЕН-үзәгенең чакыруы буенча мин узган елның ноябрь аенда бер атна Хельсинкида булып кайттым. Аңа кадәр августта, Казанның 1000 еллык юбилей тантаналарында Фин ПЕН-үзәге җитәкчеләренең берсе Юкка Маллинен башкалабызда кунак булып киткән иде. Ул совет чорыннан соңгы илләрнең Халыкара ПЕН-клубын әйдәп баручы да әле.

Кунагыбыз Казанны бик ошатты—Кремлебездә тату гына күршеләр булып мөселман ярым ае белән христианнар хачы кукраеп утыра, шунда ук Европадагы иң зур Кол Шәриф мәчете, сагышлы башын кыйшайта төшкән Сөембикә манарасы...

Юкка Татарстан Республикасының Дәүләт Советында, Казан университетында, Милли китапханәбездә, Татарстан Язучылар берлегендә булды, Салих Сәйдәшевкә һәйкәл ачу тантанасында катнашты. Атаклы Раифа монастырен да күреп кайтты, Казанның ташландык хәлдәге обсерваториясен күреп исе китеп әйтте:

—Астрономнар һәм аларның гаиләләренең каберләре генә азмы-күпме кеше күзенә күрсәтерлек икән...

Нишләмәк кирәк, ПЕН-клуб кешесе дөньяга алсу күзлек аша карамый шул, нинәрсәләребез бар—һәммәсен дә күрсәтергә туры килде.

Август көннәре кояшлы тора иде. Яңгырлы Суоми иленнән килгән кунагыбыз Займищедагы язучылар-журналистлар дачаларында язучылар белән аралашты. Идел өстендә кояш баеп килә иде, ул аны да хозурланып күзәтте. Аның белән әңгәмәләшкән татар әдипләре Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, Нур Әхмәдиев, Илфак Ибраһимов һәм башкалар Юкканың татар халкы, аның тарихы, мәдәнияте, дине, теле белән дә яхшы таныш булуын күрделәр. Карасана, телләребездә гаҗәеп уртаклык та бар икән! «Мин», «син», «мин сине яратам» кебек сүзләр һәм иялек килеше кушымчаларыбыз бөтенләй тәңгәл килә диярлек икән.

Без аңа ярым шаяртып «Юкка» исеме татарча өч мәгънәгә ия булуын искәрттек: «Юкка юкә юка түгелдер»,—дип көлештек.

• • •

Фин ПЕН-клубы белән без дустанә мөнәсәбәтләрдә яшибез. Моннан тугыз ел элек Мексикада безнең Татарстан Язучылар берлеген язучыларның бөтендөнья берләшмәсенә кабул иткәндә ул клуб безне тәкъдим итүчеләрнең берсе булды. Дуслыгыбыз елдан-ел ныгый-үсә бара. 1998 елда язучыларның Хельсинкида үткәрелгән Бөтендөнья конгрессында татарлар иң зур делегацияләрнең берсе булды—без унбер кеше идек.

Македония белән Норвегиядә Фин һәм Рус ПЕН-үзәкләре Россия хакимиятенә һәм хокук саклау оешмаларына татар язуын латин алфавитына күчерүне яклауларын сорап

---

Әхәт МУШИНСКИЙ (1951) – *прозаик; «Шейх и звездочет», «Алаш малай», «Бер тибүдә гол» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

язган мөрәҗәгатебезне һәм резолюцияне әзерләгәндә дә ярдәм иттеләр. Хәзер дә танышу-дуслашуларыбыз дәвам итә.

Хельсинкида кайларда буласым, кемнәр белән очрашасым алдан ук билгеләнгән иде—пресс-конференция, халыкара шигърият кичәсендә катнашу, Финляндиянең җәмгыять Йортында төрки-татар милли мәдәниятенең һәм дин эшлеклеләренең кайберләре белән аннары Финляндия Республикасының чит ил эшләре министры белән, очрашулар тәгаенләнгән иде... Ә шулай да мин ул чараларның шулай зурлап үтүләрен көтмәгән идем. Пресс-конференциягә матбугат чаралары вәкилләре бик күп җыелган иде. Әле пресса үзәгенә барып та җитмәдем, бер бик эре фин радиостанциясенә тулы әңгәмә бирергә туры килде. Пресс-конференциягә кереп барганда, Юкка белән икебезне фотохәбәрчеләр чарт та чорт фоторәсемгә төшерергә тотынды. Юккадан:

—Безне, башкалар белән буташтырмыйлар микән?—дип сорадым.

—Борчылма,—диде ул.—Шулай кирәк.—Аннары тиз генә журналистлар белән берике сүз алышты. Үзебезнең ничек аңлашу-аралашуларыбыз турында да әйтеп үтим әле. Юкка һәркайда минем белән йөрде. Ул үзе фин теленнән тыш рус, инглиз, немец, швед, карел һәм тагын бер-ике тел белә—алары исемдә калмаган.

Пресс-конференциядә мин үз чыгышымны 1552 елның октябрендә Казанны рус патшасы Явыз Иван яулап алган чордан, татар халкының ачы язмышлы тарихын бәян итүдән башладым. Халкыбызның дәүләтчелеген югалтуына тукталдым. Казан татарларының авылларга-бистәләргә куылуын сөйләдем. Татар мәдәнияте, әдәбияты, мәгарифе советлар заманында тагын да кысылды-чикләнде, дидем. Егерменче, гасырда Г.Тукай заманнарыннан ук үзаңыбыз уянган булса да, без бу четерекле мәсьәләләрне чишә алмадык. Хәзерге зыялы дөньяда да урта гасырлардан сөйрәлеп килә торган яман мирасыбыздан котыла алмадык.

Мәгариф ,мәдәният һәм матбугат чараларындагы хәлебезне тасвирлап, Россия халыклары арасында саны буенча икенче урында булган татарларның башкалабызда бер генә шагыйре дә тумаган, дидем—шуңа басым ясадым. Әдипләребез һәммәсе дә авылдан чыкканнар. Казанда татар балалары өчен балалар бакчалары, мәктәпләр, гимназияләр, югары уку йортлары җитәрлек булырга тиеш. Балачагыбызда Татарстан башкаласында бары тик берләнбер сигезьеллык татар мәктәбе бар иде. Мин боларны ачынып сөйләдем.

Татар ПЕН-үзәге хәлләренә кагылып, хәзер язучыларны төрмәләргә утыртмыйлар. Дөньядагы хокук яклаучылар аерым шәхесләрне яклауны бурыч итеп куйганда, безнең ПЕН-үзәкнең төп максаты барлык татарларның мәдәниятькә, туган теленә һәм үз алфавитына хокуклы булуын яклау, дидем. Бер кешене яклап кына мәктәп ачып булмый. Шул ук вакытта мәктәпләр булмаса, аерым кешенең белемгә, туган теленә хокукларын да яклый алмаячаксың. Без әллә нинди тормышка ашмас таләпләр куймыйбыз. Бары тик Россиядә башка халыклар белән тигез хокуклы булуыбызны гына телибез. Бу безнең идеалыбыз. Лев Толстой идеалны офыкка тиңләгән, аңа барып җитә алмыйсың, әмма шуңа омтылырга кирәк дигән. Аңлыйбыз: Россиядә барлык халыклар да закон нигезендә тигез саналсалар да, тормыш чынбарлыгы алай түгел—өлкән туган дигән милләт бар. Әмма без дә алар белән тигез яшәргә омтылабыз.

Мин сөйләгәннәрне Юкка төкми-чәчми тәрҗемә итеп, аңлата барды, без бик озак әңгәмәләшеп утырдык. Шуннан соң сораулар һәм җаваплар башланып китте. Сорауларның күбесе Татарстанда латин алфавиты кертү мәсьәләсенә кагыла иде. Без ул хакта да тәфсилләп сөйләдек. Шунысы кызык, Хельсинкида моны Россиягә, кайбер очракларда Татарстанга караганда да күбрәк аңлыйлар икән. Гомумән, финнар күршедәге Россиянең иҗтимагый-сәяси хәле белән бик кызыксыналар. Бу уңайдан Юкка үзенчә шаяртып:

—Финляндиядә хәл ителәсе мәсьәләләр калмады бит. Без аларны хәзер сездән эзлибез,—диде.

Хельсинкидагы беренче көнебез якшәмбегә туры килде. Дүшәмбедә булачак прессконференциягә кадәр үк без Финляндиянең төрки-татар милли мәдәнияте һәм дини җәмгыяте рәисе, Финляндия чит ил эшләре министрлыгы каршындагы Халыкара кеше хокуклары советы әгъзасы Окан әфәнде Таһир белән очрашкан идек. Ул үзен «әфәнде» дип тә, «абый» дип тә атамавыбызны үтенде. Гади генә итеп Окан дип йөртүебезне сорады. Бу безгә дә уңайлы иде, җиңел генә килештек.

Аңа кадәр, көндез Юкка мине музейларда йөртте, паромга утырып Свеаборг дигән утраудагы кирмәнне да карап килдек. Ул безнең Кронштадтка охшаган икән, андагы рәхимсез Балтыйк җилләре мин җәяүле татарны шактый туңдырды.

Бик үк модалы булмаган эшләпә кигән, озын итәкле җиләнен җилбәгәй җибәргән, бер кулына таяк-зонтик тоткан, икенчесенә газет кыстырган Окан Таһир безне алдан билгеләнгән урында көтеп тора иде инде. Аның ачык йөзле, киң күңелле кеше икәнлеге һәр хәрәкәтеннән сизелеп тора иде. Ул сәламләп кулларын җәеп җибәрде, йөз еллар күрешмәгән якын туганнар кебек кочаклашып күрештек.

Окан—Финляндиянең икенче буын гражданы. Аның әтисе—Гомәр Таһир Хельсинки университеты профессоры, төрки телләр галиме, юрист. Ул бирегә узган гасырның егерме икенче елында ук килеп төпләнгән икән. Окан белән исә мин 1998 елда язучыларның Хельсинкида үткәрелгән Бөтендөнья конгрессында танышкан идем. Ул вакытта зур делегация составында булсам, бу юлы бөтенләй башкача—күзгә-күз очрашып, якыннан таныштык. "Strindberq" ресторанында кичке аш ашадык. Берсе русча, икенчесе татарча, өченчесе финча аңлашкан өч кешенең әңгәмәләшеп утыруы кызык иде. Сөйләшү болай барды: Окан минем белән татарча сөйләшә, Юкка—русча, үзара алар фин телендә аралашалар. Шулай итеп җаен таптык тагын.

Юкка безгә бик матур төсле рәсемнәр бизәлгән фин журналы күрсәтте, анда аның Казанга килеп китүе турында мәкалә басылган икән. Фоторәсемнәрдә Казан Кремле, шәһәр күренешләре, сабан туенда түбәтәйле-калфаклы егетләр-кызлар сурәтләнгән иде. Мәкаләдә исә М. Шәймиев, Ф. Мөхәммәтшин, Т. Миңнуллин, Р. Вәлиев, Р. Хәкимов, Ф. Сафиуллин фикерләре дә китерелгән, шунда ук минем сүзләрем дә бар. Ул мәкаләне Юкка тотлыкмый-нитми генә рус теленә тәрҗемә итеп бирде. Димәк, безнең очрашуларыбыз файдалы, алар турында әнә ничек мактап язалар. Үз вакытында Юкка минем кайбер мәкаләләремне дә фин теленә тәрҗемә иткән иде, фин теленә безнең ПЕН-үзәкнең рус телендәге «Татарский путь: право народа и политкорректность» дигән китабын да тәкъдим итте.

Окан өстәлгә үз кулындагы газетны чыгарып салды. Бу фин татарларының татар телендә латин хәрефләре белән басылган «Мәхәллә хәбәрләре» дигән газеты икән. Битләрен ачып укый башлыйбыз. Беренче биттә изге Рамазан аена багышланган зур мәкалә, «Яңалыклар»да башка хәбәрләр янында Финляндия Президентының Татар җәмгыяте йортына килүе бирелгән. «Әдәбият» бүлегендә Г. Тукай, Г. Исхакый, М. Гафури, И. Юзеев әсәрләре басылган. Балалар өчен махсус биттә—татар халык әкиятләре, спорт сөючеләргә—«Йолдыз» спортклубының отчет-сайлау җыелышы турында хәбәр ителә. Болары санап кителгәннәре генә. Әлбәттә, барысын да санап бетереп булмый, газетлары бик бай эчтәлекле иде.

Сөйләшә торгач, татар язуында да латин хәрефләре кулланылган заманнарга күчәбез. Фин татарлары файдалана торган латин алфавитында «ә» хәрефе белән "х" хәрефе юк икән. "Ә" урынына «а» хәрефенең өстенә ике төртке төртеп, «а» итеп язалар ә "х" урынына "h" хәрефен кулланалар. Заманында Казанда татар латины дип «ә» хәрефе ,ә "h" урынына русларның «х» хәрефен алганнар—кыскасы, буталчыклык килеп чыккан.

Хельсинкидагы беренче кичебез шулай бәхәсләр-әңгәмәләрдә бик файдалы узды. Рус-татар-фин телендәге аерымлыклар да ничектер үзеннән-үзе онытылып торды, сизелми башлады.

* * *

Шигърият кичәсе бик матур култык буенда, текә-биек түбәле уңайлы йортта үтте. Язучылар йорты икән ул. Кичәне Фин ПЕН-үзәге президенты Элизабет Нордгрен алып барды. Ул инде пресс-конференциядә үк татарлар һәм финнар белән аралаша башлаган иде.

Диварларга Финляндия язучыларының фоторәсемнәре, әлеге кичәнең афишалары эленгән. Окан үз милләттәшләрен—Рәфыйк Шакир, Файзал Самархан, Раиф Низаметдиннарны да алып килгән. Мин алар белән Хельсинкига беренче килүемдә үк танышкан идем инде. Юкка Хельсинкида яши башлаган мордва шагыйре Сергей Завьялов янәшәсенә утырды—Сергей фин телен үзләштермәгән икән әле.

Элизабет Нордгрен беренче итеп сүзне миңа бирде. Без президиумда Юкка белән янәшә, ул минем чыгышымны тәрҗемә итә. Мин исә татарлар, аларның тарихы,

мәдәнияте, бүгенге көндәге мәсьәләләре турында сөйлим. Аннары Казанның Яңа бистәсендәге татар зираты турындагы озын гына шигыремне рус телендә укыйм. Аны Юкка тагын тәрҗемә итеп бирә, татарча укыган хикәямне исә иң яшь татар егете Раиф Низаметдин фин телендә үз сүзләре белән сөйләп чыга.

Кичә шулай матур гына дәвам итә. Сергей Завьялов үз шигырьләрен укый, фин егетенә кияүгә чыгып, Россиядән киткән мари кызы Лена Лау-лайнен сөйли... Ә мин куанып утырам: бу яңгырлы Суоми илендә татарга да, мордвинга да, мари кызына да бердәй рәхәт-иркен. Финнар безнең чыгышларыбызны кызыксынып тыңлыйлар.

Хельсинкида 7 ноябрь көнне пресс-үзәктә журналистлар өчен бәйрәм шикеллерәк кичә үткәрелгән иде—күңелдә шул уелып калган. Җыелган халыклар киемнәрендә, залдагы плакатларда урак-чүкеч рәсемнәре, лозунглар, К. Маркс, Ф. Энгельс, В. Ленин, И. Сталиннарның таныш йөзләре... Кызыл яулыклы кырыс хатын-кыз кычкырып сөйләшеп утырмаска куша, бер эшче үзенә сузган касәне читкә кага. Сәхнә кебегрәк күтәртелгән урынга гитарага кушылып кемнәрдер такмак әйтә, өстәлләр янында төркем-төркем утыручылар көлешә, кул чаба, кызып-кызып сөйләшә, кемдер сыра, кемнәрдер шәраб эчә...

Без ике өстәлне берләштереп утырыштык. Янәбызда—Элизабет, Юкка, Сергей, Хельсинкида швед телендә чыга торган «Башкала газетасы» шеф-редакторы Нелс-Эрик Фрис, тагын нинд ид ер итальян журналисты, анысы Че Геварага охшаган, тагын кемнәрдер, тагын... Рәхәтләнеп сөйләшеп утырабыз. Татарстан турында фин радиосы аша тапшырылган әңгәмәмне мактыйлар. Димәк, тиз тотканнар, без пресс-конференциядә чакта ук аны яңгыратып өлгергәннәр.

Нилс-Эрик Фрис миңа визиткасын суза, үз газетасы редакциясенә чакыра. Минем өчен Юкка ризалык бирә, чит ил эшләре министры янына бару өзеләчәген аңлата.

—Редакциядә кызык булырмы соң?—дип сорыйм.

—Һичшиксез,—ди Юкка. Аның башында—диңгезчеләр бәйрәмнәрдә генә кия торган ак кәпәч, миндә—түбәтәй. Юкка:—Болар кызык өчен генә инде,—дип, залны күзәтә.

—Һәр шаяртуда өлешчә дөреслек була,—дип искәртәм мин. Күңелемдә ни өчендер Россия Халык Комиссарлары Советының 1917 елда Финляндиягә милли бәйсезлек бирү турындагы карары яңара. Ул Ленин карары.

* * *

Хельсинки үзәгендәге Татар җәмгыяте йортының түбәсенә зур ярым ай куйганнар. Шуңа ишарә итеп, Юккага дәшәм:

—Тәэсир итәрлекме?

—Итәрлек,—ди Юкка, маңгаена бәреп чыккан тирләрен сөртеп. Казаннан китаплар төяп килгән авыр чемоданымны җиргә куя.

Ишек төбендә безне Окан каршы ала:

—Хуш килдегез!—дип татарча сәламли ул.

Иркен кунак бүлмәсендәге озын өстәл тирәсенә җыелып чәй эчәбез, шунда ук Казан кучтәнәче—зур чәк-чәк кояш кебек балкып утыра. Диварларга элентән фоторәсемнәрдән безгә батырлык күрсәткән фин татарлары карап тора. Аларның күбесе Финляндиянең бәйсезлеге өчен көрәштә башларын салганнар.

Юкка биредә беренче мәртәбә әле. Татар ПЕН-үзәге төрле милләттән булган фин гражданнарының үзара дуслыгын ныгыта. Аралашканда Юкка белән Окан—фин белән татар—озаклап сөйләшеп утырдылар. Икесе дә Финляндиянең чит ил эшләре министрлыгы каршындагы кеше хокукларын яклаучы Халыкара совет әгъзалары. Элизавет Нордгрен да Окан белән әңгәмә корды. Димәк, фин җирендә дә бергәләп хәл итәсе мәсьәләләр җитәрлек икән әле.

Мин татарча хикәя укыйм. Ул Казанның опера һәм балет театры сәхнәсе артында аунап үткән балачагым турында. Әнием шул театрда кырык елдан артык эшләгән иде. Ялгызымны өйдә калдырырга ярамаганга күрә, һәрвакыт аның янында була идем.

Кичәбезгә килгән фин татарлары артык күп түгел, байтагы миңа таныш, таныш булмаганнары—Хәмидә Чайдам, Фидан Хәйрулла, Тарик Насретдин. Алар белән дә танышам.

Хикәямне кызыксынып тыңлыйлар, кирәк урынында көлешеп тә куялар. Аннры

тыңлаучыларның сорауларына җавап бирәм: булган хәлме бу? Әниең ул театрда кайсы елларда җырлады?

Кичәнең азагында үзем алып килгән китапларны чыгарып салам. Безнең ПЕН-үзәкнең инглиз телендә нәшер иткән «Татар халык әкиятләре"н, Г. Тукайның "Шүрәле"сен, Р. Фәхретдиновның "Татар тарихы"н, хәзерге татар әдәбияты антологиясен сокланып карыйлар-актаралар. Мин "Мәгариф" нәшрияты бер тышлык астында татар, рус, инглиз телләрендә бастырган Туфан Миннуллинның "Әлдермештән Әлмәндәр" китабын да күрсәтәм. Окан төсле рәсемнәр белән бизәлгән «Шүрәле» китабын кабат-кабат актара, аерым юлларын укып та җибәрә:

—Тукай инглиз телендә—искиткеч бит бу!—ди ул.

Үз чиратыбызда без дә сораштырабыз. Хуҗалар үз Йортларының 80 еллык юбилее, анда М. Шәймиевне кабул итүләре, "Йолдыз" футбол командасының тәрекләр белән уйнаганнары турында сөйлиләр. Юкка иң атаклы фин футболчысы татар егете Исмаил булганлыгын искә ала. Казанның 1000 еллык бәйрәменә килгәч, Файзал Самархан безнең "Яңа гасыр" телевидениесе ярдәмендә ул бәйрәмне видеомагнитофонга төшереп алган икән. Аны Окан Таһирга да күрсәткән, видеотасмада Окан да сурәтләнгән булган.

Йортны карап йөрү Окан бүлмәсеннән башланды, анда аны бер төргәк бандерольләр, хатлар көтә иде. Окан иң өстә яткан пакетны алып:

—Әһә!—дип адресын күрсәтте, аны Разил Вәлиев җибәргән булып чыкты. Бандероль эчендә «Казан утлары», "Сөембикә" журналларының да яңа саннары бар иде.

—Әллә рус хәрефләрен дә укый беләсеңме?—дип сорадым Оканнан.

—Нишләмәк кирәк, Казанда һаман да латин алфавитына күчмиләр бит әле. Аннары, мин биредә Хельсинки университеты белән мәдәният институтында татар теле дә укытам,—диде ул.

Хельсинкидагы Татар җәмгыяте Йорты биш катлы зур бина, катлары да бездәге ише генә түгел—биекләр. Шунда ук китапханә, уку бүлмәләре, гыйбадәт кылу өчен иркен бер бүлмә.

Иң югары катта лифттан чыгабыз да, аяк киемнәребезне салып, гыйбадәт бүлмәсенең келәменә кереп басабыз. Җан тыныч, бер нәрсә дә борчымый. Үз милләттәшләребезнең Европа дәрәҗәсендәге тормышын, мәдәниятен, белемлелеген күреп рәхәтлек кичерәсең. Әйе, безнең халыкның мөмкинлекләре чиксез, аның киләчәге бар.

Түбәсендә ярым ай балкып утырган бу гүзәл йорттан чыккач, без әлеге җәмгыятьнең татар теле дәресләре җитәкчесе, Тампере шәһәре имамы кызы Хәмидә Чайдам эшләгән офиска юнәлдек. Ул миңа бер төргәк газеталар тоттырды, аларда безнең пресс-конференциябез турында хәбәрләр басылган икән.

Бу көннәремдә мин диңгез култыгы ярына ук урнашкан ике катлы агач йортта—язучылар кунакханәсендә яшәдем. Көннәр яңгырлы да, кояшлы да иде, әмма салкын торды. Иҗат итү өчен уңайлы көннәр булды ул. Шунлыктан, култыкта дулкыннар уйнавын яки ямь-яшел хәтфә үләнле тугайны күзәтә-күзәтә, әйбәт кенә язылды да, уйланды да. Чыршылардагы тиеннәр дә, кешеләргә игътибар итмәстән, агачтан-агачка сикерешәләр. Ә китәргә бер көн кала балконымнан куян да күреп алдым. Соры, кәр куян. Колакларын аркасына сылаган да яшел хәтфә үлән өстеннән сикергәләп узып китте. Бер биш минут та үтмәде, әкрен генә яңадан әйләнеп кайтты. Әйтерсең, кибеткә генә барып килде!

Мин дә йөреп керергә уйладым. Иртә иде әле, Юкка белән көн уртасында гына очрашырга сүз куешкан идек.

Мин тамаша кылып, күзәтеп йөрергә яратам. Иртәнге Хельсинкины карап, манзара кылып йөрисем килде. Бер йорт яныннан икенчесенә, бер урамнан икенчесенә, кечкенә бакчаларга кергәләп-чыккалап йөри торгач, кунакханәдән һаман ераклашканмын икән. Ә шәһәр таныш түгел. Үзәк урамнарын бераз чамаласам да, гонаһ шомлыгына каршы, адашканмын бит! Такси ялларга туры килде. Таксисты да аңлап бетермәде шикелле, уратып йөрде дә йөрде. Нәтиҗәдә шактый соңладым. Кайтып җиткәндә, кунакханә ишегe төбендә Юкка сукрангалап басып тора иде инде. Мине күреп алгач, куанып, кредит карточкасын тартып чыгарды, әлеге кара «Мерседес»ка чыгымнарымны түләмәкче була икән. Мин:

—Түләдем инде,—дидем.

—Күпме каерды соң?—дип кызыксынды ул.

—Егермене—дидем мин ваемсыз гына, күңелемнән евро акчаларын үзебезнең сумнарга күчерә-күчерә.

* * *

Менә без Хельсинки-Мәскәү юлында йөри торган «Лев Толстой» поезды янында. Мине Юкка белән Окан озата. Поездның исеменә ишарәләп, Юккага:

—Син беләсеңме икән, Лев Толстойның татар-славян каны фин каны белән дә катышкан булган,—дидем.

—Син моны хәзер генә уйлап чыгардыңмы?—диде ул, ышанмыйча.

—Юк. Ромен Роллан бөек язучының тормышы турындагы язмасында раслый моны.

—Алай икән. Поездның шундый исем йөртүе аңлашыла хәзер.

Вокзалга килгәнче, без аның белән «Башкала газетасы» редакциясендә булдык. Нилс-Эрик Фрис безне күптәнге дусларын очраткандай каршы алды. Чибәр баш редакторы белән дә таныштырды, икәүләп үз газеталарының үзенчәлекләрен сөйләделәр. Кайдандыр Элизабет Нордгрен килеп керде. Ул биредә сәнгать бүлеген җитәкли икән.

—Шведларны Финляндиядә бик хөрмәт итәләр,—дип сүз кыстырды Юкка.—Маннергейм да швед булган бит. Бездә дәүләт теле дә икәү—фин һәм швед телләре.

Швед журналистлары Татарстандагы журналистика хәлләре белән кызыксындылар, республикабыз матбугатында ике дәүләт теленең тәңгәллек дәрәҗәсе, Татарстанда һәм, гомумән, Россиядә сүз ирегенең булу-булмавы турында сораштылар.

Бу редакция чама белән спортзал чаклы бер зур бүлмәдә урнашкан, бөтен коллектив үз компьютерлары белән шунда утыра. Бүлек мөдирләре дә, башка җитәкчеләр дә бер-берсеннән пыяла белән генә аерылган бүлемнәргә кунаклаганнар. Барысы да ачык күренеп тора, шау-шу гына ишетелми.

Татар-фин делегациясе өчен Нилс-Эрик Фрис “Акылсыз әтәч” (“Hullukkuko”) ресторанында бай аш мәҗлесе оештырган иде.

—Финляндия—кунакчыл ил,—диган булдым мин, бик акыллы сүз әйткәндәй итеп.

Швед Нилс-Эрик елмаеп җавап бирде:

—Әйе, кунакчыл.

Бу кыйммәтчелек хөкем сөргән илгә (трамвайда да 2 евро түлисе) Мәскәүдән үк кыстырып килгән, аннары, кунакханәдә ашыйсың килүе бар, дигән булып, Юкка да нәрсәдер өстәгән коры паек тотылмый калды.

Перронда Окан Таһир миңа тагын кучтәнәчләр тутыра-тутыра сөйләнә:

—Татарстанга сәлам, Туфан белән Разилга да сәлам,—ди. Ә Юкка хушлашканда әйтеп куя:

—Син анда Казаныңда киләсе елда юбилей буласын онытма тагын, әзерләнеп тор, яме,—ди.

—Нинди юбилей?

—Туксан алтынчы елның ноябрендә Мексикада татар ПЕН-үзәгенең Халыкара ПЕН-клубка кабул ителгәнен хәтерлисеңдер ич.

—Ә-ә-ә, әйе шул...

Мин вагонга күтәреләм. «Лев Толстой» поезды кузгалып китә.

*Казан - Хельсинки - Казан.*

# Б

**БАЯН** (Баянов) Нур Галим улы (15.5.1905, Уфа губ., Минзәлә өязе Әнәк а. - 23.4.1945, Австрия), шагыйрь. Татар-башкорт хәрби мәктәбендә укый (1923-25). «Кызыл-лармеец» г-тасында әдәби хезмәткәр (1928), «Колхоз яшьләре» ж-лы сәркәтибе (1929-30), Чаллы район газетасы мөхәррире (1930-32) булып эшли. 1932-38 елларда ТАССР Язучылар берлеген оештыру комитетында инструктор, Татарстан китап нәшриятында өлкән мөхәррир. Беренче шигырь җыентыклары «Уракчы кызлар», «Җимерелгән окоплар» 1928 елда басылып чыга. Иҗатында Һ.Такташ шигъри традицияләре чагылыш таба. «Шлем кигәч», «Пост янында», «Әхмүшкә» кебек романтик рух, публицистик пафос б-н язылган шигырьләрендә Гражданнар сугышы, Кызыл Армия сугышчыларына дан җырлый. «Клеверлы кырлар» (1929), «Яңгырлы төн» (1933), «Гөләндәм» (1939), «Җимерелгән дворец янында» (1940) поэмалары авыл һәм шәһәр хезмәтчәннәренә багышланган. Б.ның Ватанны саклаучылар турындагы шигырьләре «Яшь сакчылар» (1934), «Ватан җыры» (1936), «Язгы төн» (1939) исемле җыентыкларга кертелгән. Б. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтка китә, полк партия оешмасын җитәкли, дивизия г-тасы мөхәррире, сәяси эшләр буенча полк командирының урынбасары була. Б.ның сугыш чоры поэзиясе патриотизм, совет халкының җиңүенә ышаныч б-н сугарылган (әсәрләренең бер өлеше югалган). Подполковник Б. Австрияне азат итү өчен барган сугышларның берсендә һәлак була. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1948; Шигырьләр, поэмалар. К., 1960.

Әд.: Хәйри Х. Шагыйрь Нур Баян // Әдәбият һәм тормыш. К., 1958; Юзиев Н. Тугры улың, халкым, мин сиңа // Сәнгатьчә матурлык һәм осталык. К., 1969.

З.М.Мәҗитов.

**БӘЙРӘМЕВА** Фәүзия Әүхәди кызы (5.12.1950, Саба р-ны Сабай а.), язучы, җәмәгать эшлеклесе. Казан театр уч-щесын (1971) һәм Казан ун-тын (1989) тәмамлый. 1973-75 елларда ТАССР МС каршындагы телевидение һәм радиотапшырулар комитетында режиссёр ярдәмчесе, 1987-90 да Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият бүлеге мөхәррире. 1980 елларның 2 нче яртысыннан публицистик язмалары республика газеталарында күренә башлый. «Болын» исемле беренче җыентыгы 1986 да басыла. Балаларга атап язылган, Идел буе Болгарстаны һәм татар халкы тарихын чагылдырган хикәяләр китабы («Сәнгать дөньясына сәяхәт», 1989), повесть һәм новеллалары тупланган «Моң» җыентыгы (1991), «Кара урман» романы (1997), «Безне онытмагыз» (1998) исемле пьесалар китабы, «Дәверләр кучешендә» (1998), «Хаҗ көндәлеге» (1999), «Заман. Милләт. Кеше» (2000), «Туфаннан таралган татарлар» (2004) дип аталган публицистик мәкаләләр җыентыклары, «Күкел карлыгачлары» (2000), «Соңгы намаз» (2000), «Ахырзаман афәте» (2002) повестьлары, Һ.Такташ иҗатына багышланган «Мишәрнең бөек улы» (2001) китабы, Магнитогорск шәһәренә сөрелгән татарлар язмышын чагылдырган "Кырык сырт" (2006) романы укучыларга билгеле. Б. әсәрләренең төп темасы – кеше һәм табигать, шәхес һәм коллектив, ныклы тормыш позициясе сайлау һәм характер формалашу, кеше күңелендәге үзгәрешләрне җентекләп күзәтү. 2003 елда "Михаил Худяков һәм татар халкы тарихы" дигән хезмәте дөнья күрде. Бөтентатар иҗтимагый үзәге лидерларыннан берсе (1988-91) һәм Иттифак партиясен оештыручы (1991 дән аның рәисе), Төрки халыклар ассамблеясе рәисе урынбасары (1991 дән), Милли мәҗлес рәисе (1994-97). 1990-95 тә ТР ЮС депутаты.

Әд.: Зөлкарнәй Ф. Яшәеш һәм иҗат // Чакма чакмый ут чыкмый. К., 1991; Рәшит Ә. Милләтнең сөеклесе // Заман. 2000. 15 дек.; Хәлим А. Гаделлек сагында // Мирас. 2000. N12.

А.Хәлим.

**БӘЙТ**, гарәп, фарсы һәм төрки телле поэзиядә ике юллы шигырь формасы. Җиде иҗекле шигырь юлларына ни-

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2005 ел, 4 саныннан басылып килә.*

гезләнгән шигъри форма, алар, аерым бер тәртиптә төркемләнеп, дүртешәр юллы строфа тәшкил итәләр. Шәрекъ классик поэзиясендә газәл, касыйдә, мәснәви, рөбагый һ.б. кайбер жанр төрләре шушы Б. нигезендә төзелгәннәр. Алар бер-берсеннән рифмалар системасы һәм Б.ләрнең санына карап аерылалар. Жанр үзенчәлегенә карап, Б.ләр рифмалы яки рифмасыз булырга мөмкин. Мәс., газәл һәм касыйдәдә беренче Б. рифмалы, шуннан соңгы Б.ләрдә исә икенче шигъри юл беренче Б.нең икенче юлы б-н рифмалаша бара (аа, ба, ва...).

Күрәсең, бу болыт берлә гомерлеккә кояш бергә;

Шулай бергә бугай шатлык та хәсрәт канлы яшь берлә.

Бу – Г.Тукайның «Шатлык вә хәсрәт» исемле 4 бәйтле шигыреннән ахыргы Б. Шигырь гаруз системасындагы һазаҗе мөсәммәне салим: мөфагыйлун, мөфагыйлун, мөфагыйлун, мөфагыйлун (v---v---v---v---) үлчәмендә язылган.

Әд.: Курбатов Х.Р. Иске татар поэзиясендә тел, стиль, метрика һәм строфика. К., 1984; Табризи В. Джам и мухтасар (Трактат о поэтике). М., 1959; Хамраев М.К. Основы тюркского стихосложения. Алма-Ата. 1963; Tassy M.K. Rhetorique et prosodie des langues de l'orient musulman. Paris. 1873; Weil G. Grundriss und Susten der altarabishen Metrum. Wiesbaden, 1956.

Х.Р.Курбатов.

**БӘКЕР** (Бакиров) Кәбир Кәрим улы (1885, Оренбург губ., Зобачи (Түбән Әзерки) а. - 1944, Куйбышев ш.), журналист, драматург, театр тәнкыйтьчесе. Гарәп, фарсы, төрек телләрен яхшы белгән. 1905 елдан «Нур» (С.-Петербург), аннан Казанда «Әлислах» г-таларында эшли. 1910 елдан 3 нче Дәүләт думасында мөселман депутатлар фракциясе секретаре. 1 нче Балкан сугышы вакытында (1912), С.-Петербургтан бер төркем шәфкать туташларын ияртеп, Төркиягә бара, яралы сугышчыларны тәрбия итүдә катнаша. 1913 тә Казанга кайта, аннан Оренбург шәһәренә китеп, «Вакыт» г-тасында эшли (1914-17). Февр. революциясеннән соң Ташкентта «Олугъ Төркестан» г-тасын оештыра; ул чыгудан туктагач «Правда Востока» г-тасында эшли. Төркестан мөселманнары корылтаенда катнаша. 1920 елларның 1 нче яртысында Төркестанда совет хакимиятен урнаштыруда катнашкан татар гаскәрләрендә хәрби мулла вазифасын башкара. Соңга таба Ташкентта сәүдә эше б-н шөгыльләнә, зәркән әйберләр кибете тота. 1926 да Себергә сөрелә. Сөргеннән туган якларына кайткач, янәдән кулга алына (1930) һәм үлем җәзасына хөкем ителә, ахырда җәзасы Соловки сәяси лагерына озатуга алыштырыла. Гомеренең соңгы елларын Куйбышев (хәзерге Самара) шәһәрендә яши һәм заводта эшли. «Чөн тамь, яхуд Татар мәдрәсәсендә атна кич» (1912), «Тарихи пьеса» (1912) пьесалары; «Ахун хәзрәтнең вафаты» (1912), «Кара тап» (1912), «Җанлы курчаклар» (1912) хикәяләре; «Тукай Петербургта» 1914) истәлеге, татар театры һәм әдәбиятына багышланган күп санлы тәнкыйди һәм публицистик мәкаләләр авторы.

Әсәр.: Мувәккать хөкүмәтнең тәдбирләре. Оренбург, 1917.

Әд.: Кәбир Бәкер тууына 100 ел // Казан утлары. 1980, N 8; Батулла. Татар акылы төштән соң (Онытыла язган Кәбир Бәкер турында уйланулар) // Ватаным Татарстан. 1994. 5 авг.; шул ук. Яралы бүре. Кыйсса // Идел. 1996. N 5,6.

Р.М.Батулла.

**БӘРКӘ ФӘКЫЙҺ** (тулы исеме Бәркә бине Бәрәкыйз бине Кандуз бине Идеге әл-Кыпчакый) (14 йөзнең 2 нче яртысы), төрки-татар шагыйре, фәкыйһ, хаттат. Чыгышы б-н Идел буеннан. Яшьлегендә хуҗасы Алтынбуга б-н мәмлүкләр Мисырына күчеп китә, Искәндәрия шәһәрендә укый. 1383 елда Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын күчереп язып, күчермәсенең ахырына 51 бәйттән (икеюллыктан) торган һәм үзенең чит җирдә яшәгәндә кичергән авыр тормышын тасвирлаган шигырен урнаштыра. Б.Ф. билгесез бер авторның шәригать кануннарына, фикъһ мәсьәләләренә багышланган «Иршаделмөлүк вәс-сәлятыйн» («Патша һәм солтаннарны хак юлга өндәү», Искәндәрия, 1387) исемле хезмәтен гарәп теленнән төрки телгә тәрҗемә итә. Тәрҗемәнең кульязма нөсхәсе хәзер Истанбул шәһәрендәге Айя Суфия мәчете китапханәсендә саклана. 1992 дә тәрҗемә төрек галиме Р.Топарлы кереш сүзе б-н Әнкарада аерым китап булып басылып чыга.

Әсәр.: Котб. Хөсрәү-Ширин хикәяте: Ике кисәктә. К., 1969; Irsadul-Muluk ves-Selatin // Hazirlayan: R. Toparli. Ankara, 1992.

Әд.: Миңнегулов Х. Котб иҗаты. К., 1976; Исламов Р.Ф. Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры: язма мирас, мәдәни багланышлар. К., 1998.

Х.Й.Миңнегулов.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Камил
Кәримов

# ТАТАР КАЙЧАН КӨЛГӘН яки МӘКӘРҖӘ СИНДРОМЫ

Татар сатирасының шәҗәрәсен күзаллап утырам...

Әлбәттә, юмордан яралган сатира жанрының метрикәсен рәсмиләштерер өчен кимендә мең еллык әдәбият тарихын: телдән-телгә күчеп чарланган халык авыз иҗатын, дастаннарны; күчереп яза торгач, дәүләтара таралып, безнең көннәргә кадәр исән-имин килеп җиткән кульязма китапларны, әдәби чыганакларны уртага салып сөйләшү кирәктер. Төрки халыкларның уртак мирасына әверелгән әсәрләрне өстән-өстән генә санап үтсәк тә сәхифәбездә урын җитмәс... Мең ел элек, "Диване лөгатет—төрек"ендә, борынгы заман фольклор үрнәкләрен туплый алган Мәхмүд Кашгари, үзеннән соң килгәннәрне сатирик әсәрләргә рухландырырлык "Җөмҗөмә солтан" дастаны калдырган шагыйрь Хисам Кятиб, күпкырлы иҗаты белән Казан ханлыгының иң күренекле вәкиленә әверелгән Мөхәммәдьяр, моннан йөз илле ел элек язылып сатирик шигырьләре бүгенге татар эстрадасында да яши алган Габделҗаббар Кандалый, үткен шигырьләре һәм фельетоннары белән егерменче гасыр әдәбиятына килеп кергән Шәехзадә Бабич һәм тагын күп, бик күп шагыйрьләрне, язучыларны, галимнәрне берләштерә ул сатира.

Шакир Мөхәммәдев, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан...

Бүгенге көннәргә нык аваздаш булган XX йөзнең гасыр капкасыннан кереп, биографияләре өйрәнелгән, киштәдәге әсәрләренең авторлыгы исбатланган, исемнәре дәреслекләрдә калган төгәл адреслы сатирикларыбызның өчесенә аерым тукталырга телим.

Укырга ансат, сюжеты төзек, эчтәлеге аңлаешлы, үтә дә халыкчан "Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай" повесты (1905) белән генә дәреслекләргә кергән Шакир Мөхәммәдев ошбу мактаулы әсәреннән һич кайтыш булмаган "Яфрак асты яки Мәкәрҗә ярминкәсе" дигән сатирик хикәясе белән 1901 елда ук танылып өлгергән. Хикәядә XX йөз башында татар сәүдә буржуазиясенә бик хас булган тискәре күренеш—ялган юллар белән акча үзләштереп, аны төрле бозык эшләргә туздырганнан соң, банкротлыкка чыгу—тормышчан типик вакыйгалар фонында сурәтләнә. Банкрот булып Мәкәрҗәдән яшерен качкан байларны язучы, "яфрак астына керү"челәр дип үрти. Августның 25 нче көнендә Мәкәрҗә ярминкәсенең ахыргы, кыяматнең беренче көнедер, ди Ш. Мөхәммәдев.

Йөз ел вакыт үткән...

Ә банкротлыкка чыгу бүген дә мал үзләштерүнең иң популяр ысулы. Хәрби заводлар, автогигантлар, химия комбинатлары, банклар, финанс пирамидаларының бер-бер артлы банкротлануы—генеральный эшмәкәрләрнең "яфрак астына керү"е белән төгәлләнмәдеме?! Автор әйткән августның 25 нче көне дә һәркайсыбызга мәгълүм—1998 елның август ахыры—Мәкәрҗәгә кушылган яңа Рәсәйнең банкротлыкка чыгу көненә аваздаш түгелме? Дөрес, базар мөнәсәбәтен Советлар иленә көчләп таккан океан арты илләренең күңеле булсын өчен, без аны *дефолт* дип атадык.

Апрельдә 1 апрель бар, апрельдә 26 апрель бар.

Татар поэтик сатирасының юлбашчысы Габдулла Тукайның беренче һәҗүви шигырьләре 1905 елда языла. Билгеле сәбәпләр аркасында бер елга соңрак басылып чыкса да Г. Тукайның "Хәзерге хәлебезгә карата" дигән шигъри юллары темабызга туры килә:

*Көнчелек, үчлек белән тулган татарлык,*
*................................................*
*................................................*
*Каләм иясенең каләмгә хөрмәте юк,*
*Болар каршында тәкәббернең хөрмәте күп.*

Әлеге шигырьне, тулысынча алып, һәр язучының ишек өстенә шамаил итеп эләргә була.

Сатира—Г. Тукай иҗатының буеннан-буена дөрләп бара. Көлү—аның иҗат рәвеше һәм көрәш коралы. Шагыйрь арсеналы бу коралга бик бай. Мәгәр, алдан ук кисәтеп үткәнемчә, Г. Тукай иҗатына анализ ясау ише глобаль эшкә алынмадым, һич юк. Мин бары тик татар сатирасының чишмә башын гына эзлим.

Шагыйрь әйтмешли: "татар үлгәнме, әллә йоклый гынамы", дигәндәй... 1909 елда Фатих Әмирхан мәрткә киткән "Фәтхулла хәзрәт"не озын-озак йокысыннан уятып татар әдәбиятын уйга калдыра. Повестьта искелек белән яналык, кичәге белән бүгенге, әтиләр белән балалар (отцы и дети) чәкәләшә. Рус әдәбиятында тамыр җәйгән критик реализм ниһаять татар әдәбиятына янарыш булып килеп керә.

Повесть йөз елдан соң тагын да актуальрәк була бара. Без—җитмеш ел буе якты киләчәккә өметләнеп таяк атка атланып калган бүгенге өлкән һәм урта буын вәкилләре—үзебез дә Фәтхулла хәзрәт хәлендә бугай инде. Ә колак тишекләрен нәни "наушник"лар белән томалаган, урам уеннарын компьютерга алыштырган, күлмәк киюдән бөтенләйгә ваз кичкән чалбарлы, кендекләренә йөзек кашы теккән чибәркәйләр, унбиш ел укып "Клево", "Кайф", "Круто", "Вау", "Бухать", "Секс" дигән сүзләр тезмәсеннән гайрене әйтә белмәгән балаларыбыз "Фәтхулла хәзрәт"нең Әхмәт илә Ләйләләре роленә килгәндер. Безне дә теге гасырның 70 елларында сугыштан соң туган "иркә буын" итеп—"стиляга"лар дип сүгәләр иде. Кай арада акыл утыртып, тормыш йөген үз җилкәбезгә алып, бүгенге "крутой"ларга дәгъва белдерердәй, басынкы буынга әверелдек соң әле без?!. Бу мөнәсәбәттә бүгенгеләрнең үз киләчәкләре өчен дә, шулай ук дәвам өчен дә борчылу гаме. Һәм бу коллизияләр фәлсәфи спираль нигезендә һәрдаим кабатланып торачак. Ф. Әмирханның әүлиялыгы да шунда. Димәк без әле янарыш сатирасының бәйрәмен 2009 елда да зурлап үткәрә алабыз.



*Шакир Мөхәммәдев.*

Шакир Мөхәммәдев, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан...

Һөҗүви жанрда сатирик повесть, үткен шигырь, фельетон һәм памфлет төрләренә юнәлеш бирүче өч корифей... Өч кеше, өч төрле шәхес. Өчесе өч якта тусалар да бер-берсенә күзгә күренмәс җеп белән бәйләнгән өч язмыш. Өчесе дә мулла малайлары, шуна да карамастан, өчесе дә антиклерикализм тарафдарлары—тәнкыйтьләгәндә күп кенә дин әһелләрен золымлы байлар белән бер якка куеп көләрләр. Өчесе дә мөхәррир, өчесе дә үпкә авыруыннан үлә...

Иҗат итү чорлары, кичергән вакыйгалары, күргән-аралашкан кешеләре, прототиплары берүк яссылыкта булгач, һәр өчесенең дә сөексез персонажлары уртача буйлы, юан корсаклы, кара сакаллы, кысык күзле, кылыч борынлы—портретлары карикатурага тартым, үзләре комсыз, саран һәм тотнаксыз затлар.

Мәдрәсәләрдә хәлфәләр тарафыннан бердәнбер дәреслек итеп кулланыла торган массовый тиражлы дини-дидактик "Бәдәвам" белән "Кисекбаш" китапларына

протест йөзеннән Ш. Мөхәммәдев 1903 елда "Яна бәдәвам китабы"н, ә Г. Тукай 1908 елда "Печән базары, яхуд Яна Кисекбаш" поэмасын төгәлли.

Фатих Әмирхан (ул чакта әле яшь тәнкыйтьче) "...Яна Кисекбаш"ка багышланган рецензиясендә: "Тукаевны галәмнең иң оста юмористы диясем килә башлады"—дип язып чыга. Әгәр сонрак бәяләгән булса, ул Тукайны һичшиксез галәмнең иң оста сатиригы дияр иде. Чөнки юмор ул көлдерү чарасы гына, ә сатира фаш итә!

Ш. Мөхәммәдевнең тууына узган ел 140 тулды. Г. Тукай белән Ф. Әмирхан яшьтәшләр—быел аларның икесенә дә 120. Әйе, Г. Тукай иҗатына сокланып Ф. Әмирхан үзе дә үсә. Соклану-бәяләү димәктән, безнең көннәргә чаклы дүрт томлык мирасы килеп житкән зур язучының исеме гадәттә Г. Тукай күләгәсендә калып бара. Икесе дә бер елда тугач, юбилейларын үткәргән саен, без бер Бөек шагыйрь исеме белән артык мавыгып, икенче бер Бөек язучыга сүрелә төшәбез һәм пьедесталда икесен ике урынга аерабыз.

Сатира жанры, үзалдына өлгереп, жимшәненнән төшәр өчен 1905 елгы Беренче рус революциясен көтеп яткан. Сугышларның да тарихи әһәмияте булган кебек—тәхетен югалтудан шүрләгән патша Россиясе Манифест чыгарып демократия уены уйнап ала. Капитализм изүеннән мал-мөлкәтсез калган эшчеләр язмышына 1905 елгы чуалышлар беркадәр хөррият алып килә. Иң мөһиме—матбугат иреге, димәк ки: тел, сүз, каләм иреге, фикер төрлелеге!

1906 елда Оренбургта "Вакыт" газетасы ачылу унаеннан Шакир Мөхәммәдев "Аз булса да алга барабыз"[1] дигән мәкалә белән чыга.

***"...ничә йөз еллардан бирле беркетелгән авызларыбыздагы йозаклар, кулыбыздагы зынжырлар, аякларыбыздагы богаулар, калепләребездәге кайгы-хәсрәтләр... һәркемгә тигез иркенлек, ихтыярлык игълан кылынды, теләгәнчә сөйләргә, теләгәнчә язарга рөхсәт булды"***—дип яза ул.




*"Яшен" журналының тышлыгы.*

Татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә 1905 елдан башлап жиде төрле исемдәге көлке газетасы вә журналы ачыла.

Хәленнән килгән һәр татар зыялысы үз матбагасын булдырырга, шәхси редакция ачарга тырышкан.

Сатира жанры чын мәгънәсендә янарыш чорына керә: Уральскида—Камил Мотыйгыйның "Әлгасрел жәдит" һәм "Уклар" журналы; Оренбургта—Хөсәен Ямашевның "Урал" һәм Фатыйх Кәриминең "Вакыт" газеталары, Шакир Мөхәммәдевнең "Карчыга" журналы бар; Казанда—"Әльислах"ны Фатих Әмирхан житәкли, Галиәсгар Камал белән Габдулла Тукай берләшеп, әвәл "Яшен", аннары "Ялт-йолт" журналлары чыгара. Саный китсәң, шөкер, бик күп алар, цензура укып өлгерерлек түгел, күпчелек фельетоннар автор кулыннан төшкән килеш басылган. Мөхәррирләре дә гаярь егетләр, яшьләре егерме белән утыз тирәсендә.

Беренче рус революциясеннән соң йөз ел үткәч, социализм жирлегендә шытып чыккан, бүгенгәчә исән-имин яшәп калган сатирик журналыбыз һаман да шул бер "Чаян" дәфтәре генә. Аның каравы, сатира һәм юмор һәр тарафка таралды, коммунистлардан калган башка матбагаларның хәтта беренче битенә (!) үк үтеп керде. Әйе, цензура бүген бөтенләй үк бетте кебек, ләкин социалистик диктатура үзенең варислары итеп һәр редакция саен өлкән пенсионерларын калдырды. Алар

[1] Ш. Мөхәммәдев. Сайланма әсәрләр. ТКН. 1958 ел. (Алга таба да өзекләр шушы китаптан алынды. Ред.)

барында цензураның бөтенләй керәге юк. "Ум, честь и совесть народа" сагында үзләре торырдай хәлдә. Тукайчарак әйтсәк: аларга алмашка килердәй яшьләр үлгәнме, әллә йоклыйлар гынамы, дигән сорау туа.

Йөз ел элек...

Өчесе өч тарафта яшәгән әдипләрнең, сүз куешкандай берләшеп, ныгып житкән Рәсәй капитализмына каршы бер үк вакытта күтәрелүе һич кенә дә очраклы хәл түгел. Рәсәйнең кайсы төбәген алма—халык бертөрле изелеп яши, илдәге закон кораллы реакция кулына күчә, ризасызлык һәм көрәш рухы әкренләп югары даирәләргә дә үтеп керә.

Капитализм бишеге булган шәһәр жирлегендә үткен каләм өчен негатив күренешләр чиктән ашкан. Гади халыкның наданлыгыннан файдаланып баеган чиновниклар башбаштаклыгы, бюрократиянең чәчәк атуы, завод-фабрикаларда уникешәр сәгатькә сузылган эш көне, яшәү шартларының мескенлегеннән таралган саусызлык вә төрле эпидемияләр—болар барысы да шәһәрдән килә.

Казан да шул шәһәрләрнең берсе.

Ф. Әмирхан Казанда туып үсә. Кечкенәдән Кушлавычтан чыгып киткән Тукай да, Жаек буйларында бәхет эзләп аргач, 1907 елның көзеннән Казанда яши башлый. Ул торган "Болгар" номерларының тәрәзәсеннән "Печән базары" күренеп тора. "Уклар" һәм "Фикер" аша шигырьләре белән танылып өлгергән шагыйрь өчен "Печән базары" чын мәгънәсендә табышлы урын була. Ә "Печән базары"ннан ерак Оренбург жирендә яшәгән Ш. Мөхәммәдевкә һөжү куәсе каян килгән?

Ул, өяз шәһәре Буада туып, шунда ундүрт яшенә кадәр үскән. Ә Буа ягының милли составы күп кырлы. Жирле халыкның яртысы татар булса, калган яртысын чуашлар белән руслар тәшкил итә, чыраенда вә холкында өч милләтнең колориты берьюлы чагылган кешеләре дә житәрлек. Төрле милләт вәкилләре күбәеп, телләр кисешкән төбәктә диалект искиткеч бай, фольклор усал, бер-беренне үртәүдән килеп чыккан сүз бозулар, каламбур, мәзәкләр, аеруча жетеләнә. Үсмер чагына тиклем Буа сутында туенып үскән Ш. Мөхәммәдевкә прототиплар сайлавы кыен булмагандыр. Соңгы йөз еллык тарихын жентекләсәң, Буа ягында иҗат кешеләренең күплегә сокландыра. Сынлы сәнгатебезгә нигез салучы Б. Урманче, әдәбият галиме һәм фольклорчы Г. Толымбай, прозаик һәм тәнкыйтьче Г. Гали, драматург Ш. Хөсәенов, шагыйрьләр Т. Камалиев, Р. Харис, Ә. Рәшит, Р. Рахмани, Л. Газизова, чуаш язучылары А. Калган, Н. Дедушкин, А. Назул, В. Урдаш һ. б. Шушы кадәр лирик шәхес арасында бер сатирик язучы—Ш. Мөхәммәдев очраклы рәвештә булса да туарга тиеш булган инде.

Чиле-пешле революциянең каршылыклы елларында яшәп иҗат иткән сатира атлантларының үзара мөнәсәбәте ни дәрәҗәдә булган соң?

Уральскидан "Жиктереп пар ат Казанга" кайткач, Г. Тукай чын мәгънәсендә мәркәзебезнең мәгърифәт, гыйрфан һәм нур дингезенә чума. Сонрак ул бу турыда Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатында (1911) ярымшаяртып болай ди:

"Көндез Галиәсгар Камал, Галимжан Ибраһимов вә Фатих Әмирхан вә башка интеллегентлар белән катышам. Кич белән күрше мәйханәгә кереп, тиречеләр, итчеләр, извозчиклар, жуликлар белән катышам."[1]

Казан—әдәби процессны үстерүче, бәя бирүче, мирасны туплаучы үзәккә әверелә. Гомер буе Оренбургта яшәгән, ә Казанны хатлар аша гына белгән Ш. Мөхәммәдевнең Г. Тукай белән бер-берсенә карашын ни дәрәҗәдә аныклый алабыз?

Г. Тукайны Оренбургка эшкә чакыралар. Ш. Камал, Ж. Вәлиди, Я. Сүнчәләйләр тартып барган "Вакыт" газетасына һәм яна гына ачылган "Шура" журналына (Дәрдмәнд янына) өстәмә көч кирәк була. Г. Тукай "отказ" җавабын нәшир Ф. Кәримигә түгел, ә Газизә апасына яза: "...мин хәзергә анда бара алмыйм. Оренбург язучылары илә гәзитә аркылы бераз чәкәләшеп алган идек".[2]

Оренбург илә чәкәләшеп алуның нигезе шактый четерекле. Г. Тукай "Әлгасрел

---

[1] Г. Тукай. Әсәрләр. V том. ТКН. 1986. 99 бит.

[2] Шунда ук V том. ТКН. 1986. 84 бит.

җәдит" журналында (1907) "Мөтәшагыйрьгә" (шигырь язып маташучыга) дигән шигырь бастыра.

*Тырышма нафилә җиргә в а к т ы гаҗзеңне икърарга:*
*Сиңа соң сандугачча сайрамак мөмкинме, и карга!*[1]

Әлеге журналда в а к ы т сүзе куштырнакларга алынган була. Һәм Оренбургның "Вакыт" газетасында хезмәттәшлек иткән кырык сигез яшьлек шагыйрь Дәрдмәнд әлеге мыскыллауны үзенә ала. Җавап озак көттерми. Дәрдмәнд Тукайга җавап бирә:

*Ничөн бу хиддәт (ачу), и шагыйрь,*
*Нәдер бу ярганың ярма?*
*Эчеңдә бармы йә бер чир,*
*Вә йә синдә күңел тарма?*[2]

Калганы нәкъ мәзәктәгечә: ул мина көрәк белән бәрде, мин ана балта түтәсе белән ордым... шуннан сугышып киттек инде, дигәндәй... Оренбург белән Казан арасында әдәби "разборкалар" башлана. Дәрдмәнд белән Тукайны каршыңа утыртып үгетләсәң дә татуландырырлык хәл түгел. Хәерченен теле әче, дигән борынгылар. Сәүдәгәр гаиләсендә туып үскәне, миллионер булганы өчен өнәмәгәнме ул Дәрдмәндне—Закир Рәмиевне?! Әллә "Вакыт"ның үзендәме хикмәт? Чөнки аны либераль татар капиталистлары—Рәмиевләрнең алтыны матди яктан тәэмин итә, бәлки шагыйрьләре дә "ун" белән "сул" арасында бәргәләнеп йөрүчеләр булып, шигырьләре байлар поэзиясе булып тоелгандыр Тукайга?!

Татарда шагыйрьнең шагыйрьдән көлүе Тукайлардан килә.

Бу очрактан, Тукайлы, Ф. Әмирханлы "Әльислах"ның Оренбургтагы көлке журналы "Чүкеч" белән озаклап талашуы да мәгълүм.




Г. Тукай илә Оренбург мөнәсәбәтенә тагын бер таш атабыз. Оренбургта Дәрдмәндтән алты гына яшькә кече Шакир Мөхәммәдев тә бар бит әле.

Яңа матбагалар ачылу унаеннан, 1906 елның октябрь аенда Г. Тукай "Фикер" газетасында кыска хәбәрләр бирә.

***"Оренбургта берничә милли хикәяләр язуы илә мәшһүр Шакир Мөхәммәдев җәнаблары тарафыннан атналык "Карчыга" исемле бер журнал чыга башлады..."***[3]

Әлеге хәбәрнең беренче юлыннан ук сарказм бөркелә. Җөмләнең мәгънәсенә игътибар итегез: "Оренбургта яшәп хикәяләр язуы белән мәшһүр" димәгән. Туган телне тудырган, татар җөмләсенең стилен, фикер конструкциясен төгәл белгән Тукай "яшәп" дигән сүзне төшереп калдыра да хикәяләр язуы илә Оренбургта (гына) мәшһүр мәгънәсен бирә, дорфалыкның нәзакәтле алымына ирешә. "Яфрак асты яки Мәкәрҗә ярминкәсе", "Япон сугышы яки доброволец Батыргали агай", "Хан кызы", "Яңа бәдәвам" китаплары, сиксәнләп сатирик шигырь-фельетоннары, памфлетлары белән татар дөньясына танылган кырык бер яшьлек Шакир абыйсы Мөхәммәдевне бер сүз белән провинциаль язучы итә дә куя.

Алай гына да түгел...

---

[1] Г.Т. Әсәрләр. I том. ТКН. 1986. 157 бит.
[2] Дәрдмәнд. Исә җилләр. ТКН. 1980. 31 бит.
[3] Ш.М. 218 бит.

Реакция еллары башлангач, яңалыкка ыргылып ачылган газета-журналлар берәм-берәм ябыла башлый. Ш. Мөхәммәдевнең "Карчыга" журналы да тугыз айдан соң ябыла. "Актык сүзләр"не Г. Тукай әйтә, фельетонның исем астына җәя ачып: (Үлгәннәрегезне яхшылык белән телгә алыгыз) дип куя. Аның: "Карчыга" журналы куык булып шартлады",—дигәнендә каләмдәш дуслары өчен борчылу түгел, киресенчә мыскыллап көлүе сизелә.

Шакир Мөхәммәдевнең: ***"Урыслар белән еврейләр, юк суманы бар кылып, компания булалар; ә безнең татарлар бар суманы юк кылырга, корылган эшне бетерергә, корытырга юл эзлиләр. Алланың каһәре төшкән милләт бу татар халкы!"***[1]—дип сукрануы искә төшеп, һәр очрак саен оялып куясың. Г. Тукай Уральски, Казан, Әстерхан, Өчиле, Уфа, Троицки белән унике ел буе хат алышкан, ә егерме меңнән артык татар кешесе яшәгән Оренбург каласына кемгә дә булса хат язарлык бер генә сәбәп тә тапмаган. Ш. Мөхәммәдевнең иҗатын бөтенләй белмәгәнме шагыйрь? Белгән. Моннан бер гасыр элек татар язучыларының саны бүгенгечә өч йөзгә җитмәгән, ә бәлки кушучлап санарлык кына булган. Алар арасында кемнең ничек язганын чамалавы һич кыен булмагандыр.

Шуна өстәп, Ш. Мөхәммәдев "Карчыга"ның һәр санын Г. Камалга күпләп җибәреп торган. Ә Казанга кайткач Г. Тукай Г. Камал белән бергәләп төрле редакцияләрдә хезмәттәшлек итә, элек тә хатлар алышкан. Ш. Мөхәммәдев хакында үзара сүз кузгалмагандыр дип һич ышанасы килми.

Казан Тукайны Камаллар, Әмирханнар белән каршы ала. Матбагачы, сатирик, булачак халык драматургы (рәсми төстә бу исем әле Г. Камалга 1926 елда гына бирелә), беренче татар театрына нигез салучының исеме шагыйрьгә яна мохиттә иҗат интеллигенциясе арасында зур таяну ноктасы булган. Егерме бер яшендә паралич сугып аяксыз калган Ф. Әмирхан белән саулыкка туенмаган Тукай арасындагы дуслыкның да бик күп тигезлек билгеләре булгандыр.

Йорт кошлары сайрый белмәгән кебек, рәхәттә үскән кеше дә сатира яза алмастыр.

Ә Шакир Мөхәммәдевкә килгәндә...

Өяз шәһәре Буаның ярлы тормышыннан качып, ундүрт яшьлек Шакир эш эзләп чыгып китә. Оренбургка барып бер байга самавырчы малай булып керә. Соңыннан приказчикларга булышып йөри. Үзлегеннән русча укырга-язарга өйрәнә. 12-14 сәгать эшләүдән курыкмаган егет, ниһаять, приказчик булып кала. Либераль бай Хөсәенов конторында хисапчылык итә. Мәскәүгә китеп, рус сәүдәгәренең конторасына урнаша, бухгалтерия курсларына йөри, шул сәүдәгәр фатихасы белән Харбин шәһәренә барып урнаша һәм хикәяләр яза башлый. Оренбургка кайтып, гаиләсе ишле булу сәбәбе белән, гел шунда төпләнеп кала. Ш. Мөхәммәдев җәмәгате Суфия белән дүрт малай үстерә. Бу—XX йөз башында мәйданга килгән әдипләр арасында батырлык саналган.

Тукайның сәүдәгәрләргә, приказчикларга карата антагонистик мөнәсәбәте бәхәссез. Ләкин Ш. Мөхәммәдев Тукай сөймәслек бай булганмы соң?

Ш. Мөхәммәдев үзенең китапларын һәм "Карчыга" журналын сатуда ярдәм иткән Г. Камалга хат язып зур үтенеч куя: ***"шул сатылган китапларның акчасын җибәреп торырсыз. Чөнки без байда, жалованиегә генә хезмәт итүче адәм".***[1]

Харбинга, З. Гобәйдуллинга язылган хатта да шуны күрәбез: ***"Карчыга"ны очырсак та, акчасын җыйнавы кыен, китапчылар акча җибәрми күбесе. Еллык подписчик күп юк. 150 ләп кенә. Болай вольный сатыладыр Казанда, Уфада, Троицкида..."***[2]

Оренбургтагы бәяләрне искә төшерик. 1905 елның җәенә сыер ите 12 тиен булып, язучы түлисе фатир хакы 15 сумга килә. Ә инде 1907 елда Столыпинның аграр реформасы крестьян хуҗалыкларны бөлгенлеккә төшерә, эшсезләр шәһәргә агыла, азык-төлек бәяләре котырып үсә, ит хакы килосына 4 сум 50 тиенгә җитә. Бодай оны 2 сум, май 7 сум 50 тиен, фатир хакы ике тапкырга күтәрелә. (Г. Тукайны Оренбургка 40 сум жалуние белән чакыралар.—К. К.)

---

[1] Ш. М. 218 бит.

[2] Ш. М. 359 бит.

Күрәсез, алты кешелек гаиләсе булган хисапчы—язучы Ш. Мөхәммәдевнең яшәү шартлары, "Болгар" номерында көн күргән ялгыз Тукайның хәерчелегеннән әлләни аерылмагандыр.

Ш. Мөхәммәдев Харбиндагы дусты Зарифтан йөз патроны белән маузерский револьвер сорап язган икән—бу корал байлык саклау өчен түгел, ә каләм көлкесенә эләккән сәүдәгәрләрнең, "фальшивый Батыргали" агайларның реаль янавыннан сакланыр өчен, илдәге реакцион киеренкелектә мескен булып йөрмәс өчен кирәк булган.

Ш. Мөхәммәдевнең фельетоннары усал һәм дә озын гомерле. Бу сүзләр язучы исеменә мактау булып яңгыраса, икенче яктан бик тә аяныч хәл булып кала—димәк нинди генә кискен үзгәрешләр ясасак та авыру федератив империябез һаман савыкмаган, чирләре шул ук... "Зур кешеләр" дигән фельетонында ***...Иң яхшы, иң гадел вә иң мәрхәмәтле булырга тиешле зур түрәләребезнең күкрәкләре тышкы яктан: "Фәләнчә хезмәте өчен дип язылган асмалы знаклар, кәлерле медальләр белән тулган булса да, эчке ягында (калебендә) һичнәрсә юклыгы, әллә ничә төрле хыянәтчеләр, әллә нинди явызлыклар, мәрхәмәтсезлекләр белән тулганы күренде...***[1] дип бәян итә ул. Сүз ачыктан-ачык, исемен атап, Рус-япон сугышында җиңелүебезгә сәбәп булган патша генералы Куропаткинның сугыш кирәк-яракларына дип алынган 2 миллион 600 мең сум казна акчасын урлавы турында бара (Тагын дүрт айдан соң, 1906 елның июнендә, Г. Тукай да бу турыда "Уклар" журналында язып чыга.).

Шуңа охшаш юллар "Яңа бәдәвам китабы"нда да бар. Ш. Мөхәммәдев шагыйрь дә бит әле:

*Мәскәүгә довериегә кергәчтән, салалар таш домнарны,*
*Биш-ун ел үткәч, ни күрәсең: йоткан ул йөз мең сумнарны!*

Ш. Мөхәммәдев китабының түренә кереп, ***бетерелсә иде Бохарада укыган бәгъзе мәллаларның авызына әфиун кабуы*** дигән юлларны укыйсын да, ***гаҗәп безнең татар халкы: дөньядагы барлык ләззәтне, рәхәтне ахрысы шул төн буенча трактирларда, фәхешханәләрдә ашап-эчеп исереп, галәмгә рисвай булып йөрүдә генә диеп белә торгандыр***, дигәннәренә артык игътибар итмәстән, ***Мәхмүт бай да Казандагы барлык майны бер кулга кертеп, потына өч сум хак арттырып, аннан башка да ачлыктан үләргә җиткән ярлы халыкны кычкыртып талый башлады*** дигән хәбәргә килеп төртеләсең дә ирексездән икеләнеп каласың: чынлап та 1905 елларда ук язылды микән болар, әллә безнең көннәрдә микән?! Йөз ел үтсә дә элеккеге чирләрнең терминнары, жаргоннары, атамалары һәм дә хуҗалары гына алышынган, ә гади халыкның хәле һаман шул ук. Негатив сурәтләребезне позитивлаштыру өчен бер гасыр буе көрәшү дә аз икән.

Шакир Мөхәммәдев, без урыслардан артта калмадыкмы, дигән риторик сорауга төгәл җавап тапкан: татар алдан йөри, дигән ул, бик яхшы ат җиккән бер бай урысның кучерына күрсәтеп...

Тукай белән Мөхәммәдев арасында һәрдаим биш-алты йөз чакрымлы юл яткан. Бу ара елның көйле фасылларына карап җылына алыр иде бәлки, ник дигәндә, аларны борчыган проблемалар уртак, максатлары бер, вәзгыять шул ук. Алар бер үк биеклеккә икесе ике яктан килә. Сәясәтнең икътисадка корылганын бик яхшы белгән Ш. Мөхәммәдев Рәсәйдәге кризисның төп сәбәбен югары даирәдәге чиновниклар арасыннан эзли, илдәге финанс тотрыксызлыгының механизмнарын Мәкәрҗә ярминкәсе, банклар һәм сәүдә аша ачып сала, ирония һәм гиперболалар аша фаш итә. Г. Тукай исә татар милләте һәм туган тел язмышы өчен борчыла, ярлы халыкны яклауга кучә, шәһәр байларын сүгә.

"Сәүдәгәр" Шакир Мөхәммәдевнең фельетоннарында Рәсәйнең ефәк юлына әверелгән зур сәүдә каласы Мәкәрҗә ничә тапкыр кабатланса, "шәкерт" Габдулла Тукайның шигырьләрендә Печән базары да шулхәтлек телгә алына. Һәм ошбу бүленешне Дума белән Шура, биржа белән Кәфер почмагы, мәхкәмә белән казый,

[1] Ш. М. 351 бит.

депутат белән приказчик, банк белән кесә төбе аермасы дип тә әйтеп булыр иде.

Тәнкыйтьләү масштабы, карикатура форматлары төрлечә дисәк тә әүлиялыклары белән тиннәр алар. Ләкин... 1917 елгы Октябрь революциясен бик куанып каршылаган, Совет учреждениеләрендә эшләгән, Оренбургта Приказчик-конторщиклар профсоюзын оештыруда башлап йөргән сатирик Шакир Мөхәммәдев язучыларның 1986 елгы (ТКН) библиографик белешмәсенә кертелмәгән. Аның исеме чордашлары Ш. Бабич, Ж. Вәлиди, Дәрдмәнд, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Ф. Кәримиләрдән аерылып калган.

XX йөз башында әдәбиятка килгән талантларыбызның иң зур трагедиясе шунда ки—алар иҗатына “күпчелек исеменнән” пролетариат диктатурасы һәм Коммунистлар партиясе бәя биргән. Ш. Мөхәммәдевнең “Мәкәрҗә синдромын” югары бәяләү ул социалистик җәмгыятьнең тамырдан дөрес корылмаганлыгын тану булыр иде. Яңа экономик политика (НЭП) елларында ук аңлаган идек бит инде—бер генә җәмгыять тә сыйфат ярышыннан, ягъни базар мөнәсәбәтләреннән качып, ялгызы гына үсә алмый! Печән базары гына түгел, Мәкәрҗә хакында сүз бара монда.

Татар әдәбиятында Шакир Мөхәммәдев дигән зур сатирикның булуы бәхәссез. Коръәнебездә “Шагыйрь” сүрәсе бар, ә чиновниклар сүрәсе юк. Димәк, иҗат Ходайдан килә дә халыкка кала. Ә шагыйрьләргә бәя бирүче түрәләр килә дә китә, килә дә китә.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

Шамил
Маннапов

# ИҖАТТА ТАБЫЛГАН БӘХЕТ

Мин аны бик күптәннән, бала чагымнан ук беләм кебек. Шагыйрь абый белән беренче тапкыр аның "Янадан сафка" исемле юка гына китабы аша танышкан идем. Шигырьләреннән мин аның бик яшьли ут эченә—Ватан сугышына—киткәнен, шунда авыр яраланып кайтканын укып белдем. Үземнең дә әти белән зур абыем фронт юлларындагы сират күперләрен кичеп кайткангамы, китапта язылганнар миңа ничектер бик тә якын һәм аңлаешлы, мавыктыргыч һәм ышандырырлык иделәр. Авыр яраланган шагыйрь абыйның:

*Инде нишлим,*
*Әллә йөрәгемне*
*Басар өчен җиргә куймимме?*
*Әллә җирне үзенә буйсындырган*
*Бу кешеләр өчен түзимме?*—дигән соравына:

"Түз, абый, түз!"—диясем килде. Ул шуны сизгәндәй:

*Һәм мин түзәм...*—диде.

Үзенең янадан сафка кайтасына өмет-ышаныч, җанда җыелган рухи көч һәм сабырлык сизелә иде бу сүзләрдә.

*Язмыш, сиңа һич тә үпкәләмим:*
*Җәлләп-нитеп мине тормадың,*
*Япь-яшь чактук, әллә чыныксын дип,*
*Ташкын белән мине чорнадың.*
*Йөзеп чыкса ярга—яшәр, дидең,*
*Чыгалмаса, үзенә үпкәләр...*
*Йөзеп чыктым, ярга аңсыз аудым,*
*Әй, яшисе килде шулкадәр!..*

Солдатта хезмәтемне тәмамлап, Казан дәүләт университеты студенты булу бәхетенә ирешкәч, шагыйрь Хисам абыйның үзе белән дә якыннан танышу насыйп булды. Шагыйрь булырга хыялланып йөргән вакытлар бит. Солдатта әдәби мөхитне күзәткәләп, үзеңә рухи таяныч, остаз булырлык шәхесләрне эзләштергән чаклар. Лениногорскида чыга торган "Ильич васыятьләре" газетендә эшләп, андагы каләм тибрәтүче яшьләрне үз тирәсенә туплаган Шамил абый Бикчурин белән солдатта вакытта ук хатлар алышып, шигырьләремне җибәреп тордым. Аларның күбесе шәһәр газетендә басылып та чыктылар. Хәтта Татарстанның кайсыдыр юбилеена багышлап уздырылган конкурста җинүче дә иткәннәр иде үземне. Әнә шул Шамил абый Казанга килеп, минем белән очрашу вакытында киңәш бирде:

—Син шигырьләреңне Хисам Камаловка күрсәтеп кара. Ул да солдатлар темасына яза, синең дә шул темага кулың ятып тора. Хисам сине яхшырак аңлар, акыллы киңәшләрен дә бирер, иншалла...—диде. Хисам абыйның адресын әйтте.

Минем балачактан ук Шагыйрь абыйны якын иткәнемне белгән диярсең. Ихтимал, бу турыда үзем дә әйткән булганмындыр...

Хисам абый яшәгән йорт Матбугат йортыннан берничә адымда гына — Островский урамында гына икән ләбаса. Мин аны ишек алдында һава сулап йөргән вакытында очраттым. Култык таяклы абыйны шундук таныдым, билгеле. Таныштык. Шундагы эскәмиягә утырып, әңгәмә корып җибәрдек. Ул мине игътибар белән тыңлады. Кайсы районнан булуым белән кызыксынды. "Әлкидән",—дигәч, "Безнең нефтьле якларда да Әлкәй авылы бар, әллә син шуннанмы?"—дип сорады...

Аның тавышы табибларныкы сыман тыныч-басынкы, хәер-хаһлы тоелды. Бу тавыш аның тыйнак холкын, дөньяның ачысын-төчесен күп татыган ихлас җанын сиздереп тора иде шикелле...

Хисам абый шигырьләремне алып калды. Соңыннан мин аңардан университеттан тыш, әдәбият белеменнән бик күп файдалы киңәшләр, тормыш дәресләре алдым. Шуны да әйтәм, беренче мөстәкыйль шигъри китабым да ("Хәят көндәлеге", 1970) Хисам Камаловның кереш сүзе белән, аның җәмәгать эше тәртибендә редакцияләве нәтиҗәсендә дөнья күрде.



*Хисам Камаловка 75 яшь. Котларга килүче дуслары арасында. Сулдан уңга: (беренче рәттә) Кыям Миңлебаев, Әхсән Баян, Хисам Камалов, Мөсәгыйт Хәбибуллин; (икенче рәттә): Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Галимҗан Гыйльманов.*

Бу елларны язып утырганда күңелгә үзеннән-үзе моңдый уй килә: ә бит безне — шигърият мәйданына алтмышынчы елларда килгәннәрне—бәхетле буын диярга мөмкин. Безгә фронт мәхшәреннән әйләнеп кайта алган Сибгат Хәким, Зыя Мансур, Әнвәр Давыдов, Нури Арсланов, Шәрәф Мөдәррис, Гали Хуҗи, Нәби Дәүли, Әдип Маликов кебек, лагерь-зинданнар аша узып исән калган Хәсән Туфан кебек олпат әдипләрнең җылы карашын тоеп, фатихаларын алырга насыйп булды.

Хисам Камалов та әнә шул якты шәхесләр, үзенчәлекле әдипләр йолдызлыгыннан. Әлмәт районының Кама-Исмәгыйль авылында туып-үскән егетне унсигез яше тулар-тулмас килеш, 1943 елның көзендә сугышка алалар. Икенче Балтыйк буе фронты гаскәрләре составында фашистлар белән якага-яка килә. Яраланып, ике айга якын госпитальдә дәваланганнан соң, янадан алгы сызыкта ул. Артиллерия полкы элемтәчесе буларак, Латвия җирләрен азат итешә. 1945 елның февраль азагында (Җиңү көннәренә дә ерак калмаган бер вакытта бит!) яңадан бик каты яралана. Төрле госпитальләрдә дәвалана. Мәгәр яшь егетнең бер аягын төптән үк кисеп алырга туры килә. Әле юньләп кызлар кочарга да өлгермәгән авыл егетенең бу вакытлардагы рухи газапларын, әрнүләрен күз алдына да китерү коточкыч лабаса! Шулай да язмыш сынауларына дучар ителгән солдат Ходайдан сабырлыклар сорап, түзәргә, яшәү өчен көрәшне дәвам итәргә карар кыла. Фронттан кайтып, Бөгелмә педагогия училищесын уңышлы тәмамлый. 1950—1954 елларда Казан дәүләт педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Шул елларда Хисам Камалов белән бер курста укыган Илдар Юзеев аның турында соңыннан болай язды:

"Нишләптер ул кешеләр белән аралашудан кача торган авыр табигатьле кеше булып күренә иде. Без, яңа гына мәктәп парталарыннан килгән яшь-җилкенчәк, шаулыйбыз, көләбез, ә ул, бернигә дә игътибар итмичә, башын куллары белән

тотып, китап укып утыра. Аның авыр еллар узган катлаулы биографиясен без соныннан гына белдек... Әмма ул үзе бу турыда сөйләми иде. Үтенеп сорасаң:

—Нәрсәсен сөйлисең аның?—дип кул селти дә башын аска иеп атлавын дәвам итә иде.

Ниһаять, ул барысын да сөйләп бирде. Безгә генә түгел, күпсанлы укучыларга шигырь теле белән сөйләп бирде..." (Илдар Юзеев. "Шагыйрь турында берничә сүз. Хисам Камаловның "Тормыш дулкыннары" (Казан, 1968) китабына язган кереш мәкаләдән).

Әйе, аның язмышы—әсәрләрендә. Каләмдәш дусты Гариф Ахунов бәяләгәнчә, ул "татар әдәбиятына тормышчан поэзия, солдат поэзиясе, хезмәтне һәм батырлыкны данлаучы поэзия алып килде". Ул заманда бик күпләр тормышның да, узган сугышның да кайбер "кытыршы" якларын шомартыбрак, бизәбрәк тасвирлаган мәлдә, Хисам Камалов үзе кичергәннәрне ялгансыз, бөтен ачы хакыйкате белән, шул ук вакытта югары сәнгатьле итеп бирү юлын сайлады. Шуның белән укучылар күңеленә юлны да тиз тапты. 1955 елда дөнья күргән "Янадан сафка" исемле беренче мөстәкыйль җыентыгыннан соң, бер-бер артлы нәшер ителгән "Чияле тау" (1956), "Зәй буенда" (1963), "Тормыш дулкыннары" (1968), "Каен суы" (1972), "Тойгылар" (1984), "Күңел" (1976) һ. б. шигырь һәм поэмалар китаплары укучылар кулына барып ирешә. Китаптан-китапка шагыйрьнең таланты ачыла, колачы киңәя, сулышы иркенәя барды. Аның тормыштан алган сабаклары, тойгы-хисләре, әйтер сүзе—фәлсәфи фикерләре шигырь юлларына гына сыймый, киңрәк мәйданга—поэмаларга, чәчмә әсәрләргә омтыла иде. Нәтиҗәдә, "Һәркемнең гомере бер генә." (1975), "Бердәнбер ул" (1982), "Безне өйдә көтәләр" (1986), "Үлгәннән соң яздым" (1989), "Түләнмәгән күз яше" (1997) дигән роман һәм повестьлары дөньяга чыкты. Китапларның нәшер ителү вакытларына күз салсак, без аларның арасы нибары биш-алты ел чамасы гына икәнен күрербез. Ә бит аларны иҗат итүче ярлы аягын урындыкка ничегрәк куярга белмичә, намазлыкка янтайган килеш эшли, контузиядән калган сызлауларын басу өчен башын, Сабан туендагы җайдак кебек, яулык белән кысып бәйләгән килеш яза... Моны фронтовик әдипнең икенче батырлыгы—иҗаттагы каһарманлыгы—димичә ни дисең!

Хисам Камаловның иҗаты, табигый ки, күп вакыт солдат поэзиясе, Ватан сугышы гарасатларын гади солдат күзлегеннән карап бөтен чынлыгы белән тасвирлаган романнар остасы буларак телгә алына. Ә бит ул, гәрчә фронтта алган тәэсирләре, гыйбрәтләре үз гомеренә җитәрлек булса да, болар белән—узганнар белән генә—чикләнеп калмады. Ул заман белән бергә атлап, тормышны, шул тормыштагы кешеләр язмышын туктаусыз өйрәнде. Әледән-әле туган якларына кайтып, үзе язганча, зур "океан кораблары үзләренә ябышкан төрле әкәм-төкәмнәрдән чистарыр өчен төче-саф суларга кергән кебек", хисләрен яңартып, язарына азык алып килергә җай тапты. Шуларның бәрәкәтле нәтиҗәсе буларак, "Эскизлар" (1964), "Әнкәй истәлеге" (1955—1964) һәм башка поэмалары дөньяга чыкты.

КамАЗ төзелә башлаган житмешенче елларда ул Чаллыга ашкынды. Миңа аның юлдашы булырга, бер атна дәвамында кунакханәдә бергә торырга, төзелеш, кешеләр, җитәкчеләр белән бергә-бергә танышып йөрергә туры килде. Шунда мин Хисам абыйның солдатларга хас тәртип яратуын, үзенең эш көнен бик төгәл оештыра белүен, иртүк торып үз планы буенча хәрәкәт итүен, бер генә минутын да бушка уздырмавын күреп сокландым. Ул кайберәүләр кебек үзен махсус машинага утыртып, озатып йөрүләрен таләп итмәде, култык таякларына таянган килеш, гигант төзелешне аркылыга-буйга йөреп чыкты. Үзенең булачак әсәр геройларын машина тәрәзәсеннән генә күзәтмәде, ә бәлки алар белән эш урыннарында очрашып сөйләште, кунакханәдә утырып та әңгәмә корды, алар язмышын үз күңеле, үз йөрәге аша үткәрде.

Хисам абыйның КамАЗ төзелешендә булган көннәрендә язарына нинди азык алганлыгын мин тиздән матбугатта дөнья күргән "Язмыш елмаюы" (1973) дигән поэмасыннан һәм шигырьләр шәлкеменнән укып белдем. Болар КамАЗ төзүчеләргә багышланган, аларның язмышларын, уй-хисләрен, шатлык-кайгыларын тасвирлаган беренче карлыгачлар иде. Бу әсәрләрендә дә шагыйрьнең кеше күңелен тирәнтен

аңлавы, нинди генә кыен шартларда да кешелек сыйфатларын югалтмавы, гаделлек тарафдарлары ягында булуы белән очрашабыз. Сугыш гарасатларыннан авырлык белән котылган, ярты гәүдәсен фашист аждаһасы умырып алган солдат тыныч тормышның кадерен белә, халкыбызның фидакарь хезмәтенә ихлас соклана:

*Бу ташларда кемнең кул җылысы,*
*Кем тирләре аккан бу төштә?*
*Тәрәзләрдә кемнең елмаюы*
*Балкып китә һаман нур төшсә?*
*Ул төзүче үзе ничек икән,*
*Тапты микән бәхет бу эштән?..*
("Эскизлар" поэмасыннан)

"Мәхәббәт хакы" поэмасында шагыйрь уй-фикерләрен бер фокуска туплап, фәлсәфи нәтиҗә ясый:

*Ирек кадере беленә томкынлыкта,*
*Яшәү кадере—абынып егылгач,*
*Ипи кадере беленә ач вакытта,*
*Кеше кадере—аннан айрылгач...*

Хисам Камалов үзенең беренче әсәрләрендә сугышта алган яралары өчен сызланса да, кабат сафка кайтуына сөенгән нык ихтыярлы фронтовик образын тудырды. Соңга таба ул тыныч хезмәт кешесенең фидакарьлеген, тирә-юнендәгеләр белән үзара мөнәсәбәтен, кешеләр аңындагы искелек белән яналыкның—көрәшен, замана барышындагы чишелмәгән сораулар ятьмәсендә чәбәләнүләрне зуррак полотнода тудыруга ирешә. Әлеге поэзия һәм проза әсәрләрендә үз уйлары, үз кичерешләре, миһербан идеалы тормышның киң мәйданында тагын да тулырак чагыла. Без геройларны хезмәттә, шәхси тормышларында, мәхәббәт сынауларында күрәбез. Әсәрдән-әсәргә күңелдәге образ зурая, тулырак ачыла бара. "Мәхәббәт хакы" поэмасында "бүлмәләргә көлүедәй матур парчалардан бизәк төшерүче Зилә", "Эскизлар"дагы "күнелем акка көнем ак минем" диюче эшче Харис, "Әнкәй истәлеге" әсәрендәге лирик герой, "Язмыш елмаюы"ндагы илнен төрле төбәкләреннән җыелган катлаулы язмышлы Нур Хәлкин, Илфәт, Дилфә, Руфа, Вовкалар—барысы бергә замандашыбыз образын калку итеп күз алдына китерәләр.

Инде житмешле барьерны алганнан соң, Хисам абый янә бер батырлык, иҗади каһарманлык күрсәтте: нефть чыккан туган җирендә авыл хуҗалыгы эшчәннәре тормышын чагылдырган яна романын язып тәмамлады. Мин бу вакытта "Казан утлары" журналының проза бүлеге мөхәррире идем. "Югалган бәхет" дип аталган бу әсәрне редакцияләп, журналга бирү миңа насыйп булды. (Ул журналда "Үксезләр" исеме белән, бераз кыскартылган вариантта басылып чыкты).

Роман тормышчан низагларга һәм гыйбрәтле язмышларга бай булуы белән кызыклы. Әлегә кадәр әдәбиятта нефтьне гел кара алтынга тиң байлык булуына соклану рухында тасвирласалар, Хисам Камалов бу алтынның "кара" ягына күбрәк игътибарын юнәлтә. Ул шуның белән янача. Хәер, бу уй-фикерләре белән ул безне шигырьләрендә кисәткән иде бит инде. Әле ул вакытта Татарстан нефтенең фонтан булып аткан, куәт алган вакытлары иде. Күпләребез моңа сөенеп, Әлмәт, Лениногорски яклары күгең дөрләп янган газ факеллары яктыртуын Җирдәге йолдызларга тиңләп, сокланып язган бер вакытта Хисам Камалов болай дип оран салды:

*Хет яманла мине, начар диген,*
*Күңелем акка көнем ак минем!..*
*Туган җирнең һәр нәрсәсен җәллим,*
*Бар ла шундый начар як минем!..*
*...Харис—ятты, ә мин төнгә чыктым.*

*Факел хоры яна тауларда:*
*Факел тотып гүя туземецлар*
*Чыккансыман филләр ауларга...*

Автор бу сүзләрне фронтовик дусты Харис авызыннан әйттерә. 1964 елда ук язылган "Эскизлар" поэмасыннан бу. Халык байлыгы булган җиребез маен түгепчәчеп алуларга, әрәм-шәрәм итүләргә, шамдәй матур каеннарны бульдозерлар белән изеп, трасса яруларга шагыйрьнең йөрәге әрни. Чын хуҗалар болай эшләргә тиеш түгелләр, ди кебек ул. Бу юллар ул еллардагы "Обллит" дигән цензура аша ничек узгандыр, гаҗәп! Ә соңрак нәшер ителгән "Тойгылар" китабына бу поэма "Туган җирдә" исеме белән кертелгән. Биредә әлеге әсәргә аваздаш "Табигать" дигән шигырь кешелекне кисәтә:

*Мәрхәмәтле ана ул Табигать!—*
*Иркәли, тик салма казага!*
*Иркәләгән кулы белән кайчак*
*Бирә белә бик шәп җәза да!*

Кызганыч ки, шагыйрьнең бу йөрәк әрнүе белән бәргәләнүләрен үткен күзле тәнкыйтьчеләребез дә күрми уздырдылар. Ә бит бу фикерләрне күтәреп алып, матбугатта шаулап чыкканда, авторга да рухи таяныч, халыкка да файдалы гамәл буласы иде ләбаса.

Бераз читкә кителде бугай. Сүзем "Югалган бәхет" ("Үксезләр") романы турында иде бит әле. Романда "кара алтын"ның нефть төбәге экологиясенә салган зарары, тереклек чыганагы—чишмәләрнең Кәримуллин кәҗәсе дә эчә алмаслык дәрәҗәдә тозлануы, җир-анабызның уныш бирү куәте зәгыйфьләнүе турында. Шуңа да карамастан, тоталитар режимның "давай-давай!"га корылган мәрхәмәтсез алымнары әлеге әсәрдә авыл эшчәннәренең тормышчан образлары аша тасвир ителгән. Мине аеруча агроном Вәзыйх Надыйров язмышы тетрәндерде. Хәлбуки, аның йөзендә мин шул ук "торгынлык" елларында Түбән Кама якларында агроном булып эшләгән Кадыйр абыемны күргәндәй булдым. Ул да бит Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаганнан соң, җирдән мул уңышлар алырга хыялланган иде. Хыялланып кына калмады, бөтен көчен, җан җегәрен куеп, үзе яраткан эшкә ябышты ул. Ләкин эрлевакллы түрәләр ана алган белемен үзе теләгәнчә файдаланырга ирек бирмәделәр, белербелмәс эшенә тыкшындылар. Шушы гамәлләре аркасында җирдән уныш аз чыкса, бөтен гаепне агрономга сылтап, җәза чәпәделәр. Ә уңыш шәп елларда шөһрәте түрәләргә булды. Күп кыерсытулар күрү аркасында төрле авыруларга дучар булып, нибары кырык җиде яшендә җир куенына керде. Ә бит ул яшьтән үк төп кебек таза, Сабан туйларында көрәшеп йөргән егет иде... Аның миндә бик күп зарлы хатлары саклана. "Их, шул еллардагы гаделсезлекләр турында бер әсәр язасы иде", дигән теләк йөри күңелдә... Ә олуг әдибебез нәкъ кенә шушы теләкне белгәндәй, сәнгатьчә югары кимәлдә роман иҗат иткән. Шул заманның чирләрен оста хирург кебек, кисеп-кисеп алган ул!

Дөрес, романда алынган проблемаларның кайберләре бүген инде хәл ителгән, кайсыбер конфликтлар чишелгән булырга да мөмкин. Хәлбуки, заман проблемаларның яңаларын куя тора, ә аларны хәл итү өчен узганнардан гыйбрәтсабак алу зарур.

"Югалган бәхет" ("Үксезләр") романында тагы шунысы игътибарга лаек: андагы геройларның гадиләре дә, түрәләре дә үз бәхетләрен таба алмый. Барысы да диярлек иртәме-соңмы, һәлакәткә дучар була. Хәтта район түрәләренең үзенә "Социалистик Хезмәт Герое исеме бирәбез", дигән вәгъдәләренә ымсынып, тиресеннән чыгардай булып тырышкан колхоз рәисе Вил Садриевич та соңыннан рухи бөлгенлеккә төшеп, гомерен җүләрләр йортында чикли... Романдагы гаилә, мәхәббәт мәсьәләләре дә гаять тормышчан хакыйкатьне чагылдыра.

Әдипнең авыл хуҗалыгы темасына роман язганлыгын ишеткән берәү, әле аны юньләп укымаган да килеш: "Аның конегы—Ватан сугышы бит инде, нишләп авылга сугылды икән?.."—дип ышанмаучылык белдерде, икенче берәү: "Романда татар

әдәбиятына яңалык алып килмәде..."—дип башкаларны ышандырырга тырышты. Әмма һәр әсәргә гадел бәя бирүче укучы бар бит әле. Роман "Казан утлары" журналында басылып чыккач, укучылар аны яратып кабул иттеләр, язучыны яңа уңышы белән котлаулар күп булды. Бу әсәр аның биш томлыгына да кертелде...

Авыл темасы шагыйрь өчен нишләп ят булсын икән?! Ул бит авыл чирәмендә аунап үскән, колхоз кырларында башак җыйган, атлар көткән... Кара алтын чыккан якларның хәл-әхвәлен чагылдырган әсәрне нәкъ менә шул якта туып-үскән әдип иҗат итәргә тиеш иде. Хисам Камалов кайсы гына темага алынмасын, "уртада барыбер авыл. Авыл кешеләре рухы. Бала чактан ук канына авыл рухы сеңгән шагыйрьнең хисләре ул әсәрләрдә...—дип язган иде Сибгат ага Хәким үзенең бер мәкаләсендә. ("Халык язмышы—шагыйрь язмышы". Тат. кит. нәшр. 1979.) Хак сүзләр.

Инде без беләбез: зур бәхетсезлекләргә юлыккан, тәмам үз-үзенә кул салырга җиткән адәмнәр хәзерге вакытта берданбер котылу чарасы—дингә мөрәҗәгать итә. Иманга кайта, мәчеткә йөз тота. "Югалган бәхет" романында бу кайту юлы әлегә күрсәтелмәгән. Күрәсең, бу Хисам абыйның киләчәк иҗат эшедер...

Без теге яки бу әдип турында "исән вакытында тиешенчә бәяләмәделәр, кадерен белмәделәр"...—дияргә яратабыз. Мәгәр бу очракта алай зар кылу дөрес үк булмастыр. Хисам Камалов иҗаты укучылар тарафыннан да, югары даирәләр тарафыннан да кыерсытылмады, яклау тапты, аның иҗаты соңлап булса да һаман тиешле бәясен ала килде. Очрашып сөйләшкән вакытларда үзе әйтмәсә дә, мин аның I дәрәҗә Ватан сугышы ордены кавалеры булуын да, "Һәркемнең гомере бер генә" һәм "Безне өйдә көтәләр" романнары өчен республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнүен дә беләм. Әле менә шушы елларда гына аңа Татарстан Президенты указы белән Татарстанның халык язучысы дигән мактаулы исем бирелде, Татарстан китап нәшриятында 5 томда Сайланма әсәрләре басылып чыкты. Шушы гомер эчендә татарча һәм рус телендә егерме сигез китабы дөнья күргән.

"Димәк, бүгенге еллар биеклегеннән торып караганда, язучы буларак гомерем бушка узмаган икән дип әйтә алам,—ди әдип үзе.—Аннары мин үз укучымны таптым дип әйтә алам, язучы өчен моннан да татлырак кичерешнең булуы мөмкин түгел. ...Мин бар булган сәләтемне биреп, ихлас күңелемнән халкым өчен—татар укучысы өчен яздым һәм халкым язучысы була алуым белән чиксез бәхетлемен..."

Әдип үзе әйткәнчә, ул көндәлек тормышта да алдашуны яратмый һәм иҗатында да алдашмаска тырыша. Бу—аның яшәешкә һәм үз иҗатына карашы, төп кыйбласы, җан таләбе. "Кырыс Хакыйкать—ялган-матур бизәкләргә караганда бик күпкә саваплырак гамәл, минемчә",—ди Ил агасы.

Дөрестән дә, аның әсәрләрен укыганда үзеңне аңлый торган җан дустың белән сөйләшеп утыргандай бер рәхәтлек тоясың, рухың сафлана, кешеләргә, дөньяга ышанычың арта, яшәү мәгънәсен яхшырак аңлагандай буласың, дөньядагы барлык җан ияләренә мәрхәмәт хисләре канат кага... Син, үзең дә сизмәстән, бик матур тәрбия дәресләре аласың, дога укыгандагы сыман җан тынычлыгы табасың. Ә бит динне санга сукмаган дәһри заманда безнең күңелләрдәге Иман нурын нәкъ менә ихлас әдипләрнең игелеккә өндәгән әсәрләре саклап калды. Борынгы байтак язучыларыбызның мулла нәселеннән, кайберләренең үзләре дә дин әһеле булулары юкка түгелдер. Пәйгамбәрләр язмышын үзәккә алып, мәңгелек "Кыйссаи Йосыф" әсәрен язган Кол Гали, кешене бу дөньяда күбрәк игелек кылырга өндәгән шигырьләр һәм поэмалар иҗат иткән Котб, Хисам Кятиб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф, Мәүлә Колый кебек борынгы шагыйрьләрне аласыңмы, Әбелмәних Каргалый, Габделҗаббар Кандалый, Габделрәхим Утыз Имәни, Акмулла, Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич шикелле яңа дәвер поэзиясе вәкилләрен яд итәсеңме, совет чоры әдипләренең күренеклеләрен барлыйсыңмы—барысының да иманлы-ниязлы гаиләдән икәнен күрәбез.

Менә шулай тоела: Хисам Камалов үз әсәрләрен язарга утырганда Кол Гали кебек, "Күкрәгемдә ярдәм итү шәмен яндыр,—Күңелемне нурың белән яктырт имди... Минем алда ач син уңыш капкаларын,—Гакылым саф, телем нәфис булсын имди..."—дип Ходайга сыенгандыр, мөгаен. Шулайдыр, хәлбуки, ул бит балачакта әнисенең намаз укуларын күреп үскән, аның өйрәткән догаларын фронтта

"разведкага барган чакларында гел укыган", авыр чакта Илен генә түгел, җанындагы Иман нурын да саклап кала алган... һәм ул шул Нурны әсәрләре аша бүгенге һәм киләр буыннарга тапшыра.

Мәкаләм-уйлануларымның башында мин Хисам абыйны бала чагымнан ук беләм кебек, дигән идем. Мәгәр дөньяны күп күргән саен аны азрак белгәнлегеңне аңлаган шикелле, шагыйрьне дә илаһи-уптым белү-аңлау мөмкин түгел икән. Яшең, тормыш тәҗрибәң арткан саен теге яки бу әсәрне аңлау дәрәҗәң дә арта-тирәнәя бара икән ул. Аннары әдип тә үз иҗатында бер урында гына таптанып тормый бит, ул әсәрдән-әсәргә һаман үсә, камилләшә, яңа яклары белән ачыла бара. Элегрәк, мәсәлән, Хисам абыйның поэмаларында интонациянең ихласлыгына,эпик-сөйләм алымының фәлсәфи гомумиләштерүләр белән чиратлашып баруына сокланган хәлдә, фикерне артык сузу, укучыга "чәйнәп каптыру"ларның булуын тәнкыйтьләп чыкканым да бар. ("Социалистик Татарстан", 11 май, 1969 ел. "Тормышның үзеннән" мәкаләсе.) Бара-тора, теоретик яктан хаклы булсам да, әлеге "артык юлларның" поэмаларда хис дулкыны эзлеклелеге, эмоциональ накалны арттыру хасиятләре барлыгын аңладым. Шигырьләренең агымы-ритмы вакыт-вакыт "шигырь теориясен" санга сукмыйча, салулап-салулап китүе, теге яки бу фикергә укучы игътибар итсен, дигәндәй аны "абындырып" алгалавы да соңра шагыйрьнең бер үзенчәлеге, тормышны шигырьгә мөмкин кадәр реальрәк, ничек бар—шулай тасвирлау өчен кулланган алымы булып тоела башлады. Соңыннан Хисам Камалов бу алымнарын прозада дәвам итеп, менә дигән шигъри кимәлдәге хикәяләр, повестьлар, романнар иҗат итте. Чәчмә әсәрләрдә аның таланты аеруча бер балку белән ачылып китте. Иҗатының буеннан-буена бер генә ягы "үзгәрешсез" булып калды: ул һәр әсәренә утны-суны кичкән солдат, ялпи нужа тарткан авыл баласы, тормышның якты якларын күрергә, Яхшылыкның Явызлыкны авызлыклый алачагына, яхшы кешеләрнең начарларына караганда күбрәк булуына ышанган лирик геройлары белән килде. Кешеләргә карата әнисе васыять иткәнчә, "түзем булу, сабыр булу", тормыш сынауларыннан Кеше булып чыга алу, киләчәккә өмет белән яшәү—менә аның үзгәрмәс, ныклы тормыш кыйбласы. Аның язмыш кыйнауларыннан, иҗат газапларыннан соң яулап алынган бәхете шуна күрә кадерле дә. Ул биртелеп булса да, сугыш мәхшәреннән исән кайтты, фронтта ятып калган иптәшләренең уй-хыялларын, газапларын үз иҗаты аша халкыбызга җиткерә алды. Шулар үзләре генә дә олуг бәхет түгелмени?!

*Ил яшь иде сугыш башланганда,*
*Ил яшенә куштым яшьлегем.*
*Вөҗүдем дә илнеке иде инде,*
*Булмады бер нәрсәм яшерен.*
*Максатына куштым максатымны,*
*Теләгенә куштым теләгем.*
*Хыялына куштым хыялымны,*
*Кирәгенә куштым кирәгем.*

.........................................

*Бәхетем дә, бәхетсезлегем дә*
*Илдән генә торды һәрдаим...*
*Юк, ахыры, булып булмады инде*
*Карый торган фәкать үз җаен...*

.........................................

*Хәзер ансат, җиңдек, дию. Анда:*
*Гомер белән түләү, кандыру...*
*Газапларын алар әйталмады...*
*Гүя китте миңа калдырып...*

Әйе, Татарстанның халык язучысы, Ил улы, шагыйрь һәм прозаик Хисам Камалов фронтовик дусларының үзенә сүзсез күз карашлары белән тапшырып киткән әманәтен үтәүдә бүген дә сафта әле. Үз постында әле. Иҗат постында.

# ӘТИ САГЫНЫП СӨЙЛИ ИДЕ

Габдулла Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф, безнең бабай Әхмәтҗан, тау ягы кешесе Мотыйгулла абзый Төхфәтуллин Кышкар мәдрәсәсендә сабакташ булганнар. Менә шушы хәл Тукай белән әтинең бер-берсенә ихтирам белән каравы, якынаюы өчен сәбәп булгандыр дип уйлыйм. Тагы мөһим нәрсә— алар якташлар да бит әле. Әти шулай ук Тукайның туып-үскән якларын бик сагынып сөйләвен, аңарда җирсу тойгысы көчле булуын әйтә иде. Чынлап та, аның "Пар ат", "Туган җирем" дигән ул инде Җаектан кайткач язылгандыр, дип уйларлык шигырьләре, ул анда чакта, аның Казанга кайтуыннан шактый алда язылган. Күрәсең, ул Казанга, туган якка кайтырга алдан ук ашкынып торган. Ул гына да түгел, әти кечкенәдән су буендагы яшьләр уеннарын күзәтеп, егет-кызларның андагы җырларын, шаян такмакларын бик күп белгән. Үзе гармунчы булгач, аларны уйнап-җырлап та күрсәтә алган, күрәсең, ә Тукай халык иҗаты белән бик кызыксынучан була. Бу фактор да аларның якынаюы өчен бер сәбәп булгандыр, дип уйлыйм. Әти Тукайдан биш яшькә олы булса да, бу аларның якынаюы өчен киртә булмый. Әти олыгайган көндә дә балалык сыйфатларын җуймаган, ихластан шаяра, шаяртa, көлке сүзләр сөйли белә иде. Шуның өстенә, әти гармунчы буларак, ә туганыбыз Нәҗиб абый җырчы буларак бик яхшы ансамбль тәшкил итәләр. Инде соңрак, олыгайган көннәрендә дә әти гармун уйнап, Нәҗиб абый җырлап, кунаклар соравы буенча "Карурман"ны башкаралар иде. Алар аны гаҗәп үзенчәлекле итеп, "Карурманны чыккан чакта, атым китте" дигән сүзләрдә көйнең сузынкы ритмын үзгәртеп, кызулатып, ат юырткан чактагы кебек ритмик борылыш ясап куялар, җыр көтмәгәндә ниндидер оптимистик төсмер ала, шуннан соң гына "Күл буйлап" дигән җирдә яңадан "Карурман"ның гадәттәге сузынкы ритмикасына кайтып төшәләр. Ә инде "мин саргайдым сезне уйлап" дигән төштә салмак дулкындай тирбәлеш белән киң моң дәрьясына чыгалар иде. Бу тыңлаучыларны хәйран итә иде. Бу да әти белән Тукайның якынаюына бер сәбәп булгандыр дип уйлыйм.

Тукай чатнама суыкта да юка җилән киеп йөри иде, дип сөйли иде әти. Гыйният абый белән бергә икесе Тукайга: "Габдулла, менә без сиңа бик йомшак тиредән җинел генә тун тектереп бирмәкче булабыз, синең болай юка киемнән йөрүеңә эчебез поша" дигәч, Тукай моңа теше-тырнагы белән дигәндәй каршы килә: "Тире дигән нәрсәне исемә дә төшермәгез. Җаекка килгәндә кара тире толыпка төрделәр дә, чак тончыгып үлмәдем", дип җавап бирә. Әти Тукайның гәүдәгә арык булуын, әмма үзенең туры әйтә торган кыю кеше булуын әйтә торган иде.

Әтинең Җаектан авылга кайтуы кайсы елда булганын төгәл белмим. Тукайдан берничә ай алдарак булгандыр дип уйлыйм. Һәрхәлдә 1908 нче елда аны өйләндергәннәр. "Өйләндергәннәр", чөнки бу эш яшьләр ихтыярында булмаган. Ике бабай—"Кеби" Әхмәтҗаны белән Бәрәзәнең "Чеби" Сабирҗаны икесе килешү, кодалашу житкән. Гаиләдәге беренче бала, өлкән апабыз Фәрзәнә 1909 нчы елгы иде.

1907 нче елның көзендә Тукай Уральскидан кайткач, Әтнәгә волость

управасына солдат хезмәтенә каралырга килә. Шунда алар (әти анда ат белән үзебезнең авыл рекрутларын китергән булса кирәк) якын туганнардай очрашалар. Барсы да дулкынланып управа комиссиясенең карарын көтә. Тукайны солдат хезмәтенә саулыгы буенча яраксыз дип табалар. Шунда әти аны Бәрәскәгә кунакка чакыра. Тукай Каенсардагы апасы Сажидәне күрәсе килүен әйтеп, бераз уйда торгач, Нигъмәтжан:

—Карале, Габдулла, безнең әтиләр сабакташ-шәрикләр булган, минем әти Әхмәтжан мәрхүм Мөхәммәтгариф хәзрәтнең улы Габдулла мәхдүмне күрергә бик шат булыр иде, бер-ике көн кунгач Каенсарга, Сажидә янына сине үзем илтеп куям дигәч, ризалаша. Тукай безнең авылга—Бәрәскәгә килә. Алар шул безнең авыл рекрутлары белән бергә кайталар. Солдатка алынган рекрут егетләр башта армия хезмәтеннән котылып калган Тукайга кырын карыйлар, әмма әти аның мулла улы, ятим калып үскән мәхдүм икәнен әйткәч, аңа ихтирам белән карый башлыйлар. Тукайның үзе өчен дә әтисе белән бергә укыган кешене күрү, аңардан чын әтисе турында сораштыру кызык булгандыр. Аңа сабый чагында берничә кешегә “әти” дип дәшәргә туры килә—башта, әнисе икенче тапкыр кияүгә чыккан Сасна мулласына, аннан Казанның Яңа Бистәсендәге Габдулланы балалыкка алган һөнәрче Мөхәммәтвәли абзыйга, Кырлайдагы Сәгъди абзыйга. Ә монда аның үз әтисен яхшы белгән, аның белән озак вакыт бергә мәдрәсәдә яшәгән абзыйны күрү, сораштыру үзе бер дөнья булгандыр. Мәшһүр язучыбыз, галим Ибраһим Нуруллин үзенең “Тукай” китабында “Ул Әтнәдән 8 чакрымдагы Олы Мәңгәргә, анда яшәгән Жаектагы танышына барып 3 көн тора”, дип язган. Әмма Тукай шулай ук 8 чакрымдагы Бәрәскә авылына, ягъни безнең әти өенә кунакка килә. Шунда күпмедер кунак була. Бәлки ул соңыннан Мәңгәрдә дә булгандыр, кем белә. Әмма аның Жаектагы танышы безнең әти була бит. Әти аны апасы Сажидәгә (Каенсарга буладыр инде) илтеп куя. Тукай әтигә үзенең буйга төшкән фоторәсемен ядкарь итеп бирә. Әти аны кадер белән башка туганнарының сурәтләре куелган уртак зур рам эченә урнаштыра.

Тукайның үлеме халык өчен, милләт өчен чын фаҗига була. Бу хакта без Айрат Арслан белән бергә Гаяз Исхакыйның Тукай үлеменә бер ел тулганда язган нәкъ менә “Милли фаҗига” дигән мәрсиясе буенча тапшыру эшләгән идек. Әти сөйләгәннәр шунда искә төште. Икебезнең дә күзләр яшьле булды.

**Госман ӘХМӘТҖАНОВ,**
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***САБАН***— Гомумтөрки "сабан" сүзе "сабан; сука; игеннәр, иген кыры, басу" мәгънәләренә ия. "Древнетюркский словарь" белешмәсендә аның "җир сөрү коралларын тартып бару өчен парлап җигелгән үгезләр" һәм "җир сөрү" мәгънәләре теркәлгән. Хәзерге татар телендә: **1**.Җир сөрү коралы, камилләштерелгән сука. Русларда сабан ике тәгәрмәчле, ике тоткалы, түбәнге башларына сука тимере беркетелгән ике "аяклы" булган (Вл.Даль. Толковый словарь живого русского языка). **2**.Сөрү, сукалау.

Сабан — чуаш, мари, удмурт телләренә дә кергән сүз. Аларда ул агач кисү өчен җайланма, аскуйма, кузла мәгънәсендә дә кулланыла. Р.Әхмәтьянов "сабан" сүзен фарсы телендәге *сапанд* (арбалет, катапульта-мәнҗәникъ) сүзе белән бәйли. Чыннан да "элекке төрки гаскәрләрдә авыр чана сыман станлы мәнҗәникъларны җирдән сөйрәтеп күчереп йөрткәннәр".

Тагын кара: ***МӘНҖӘНИКЪ.***

***САБЫН*** *г.* — Сабын сүзе безгә гарәптән яки фарсыдан кергән. Төрки телләрдә — *самын, сабун*, монгол телендә — *сабан*. Сабын сүзенең латинча яңгырашы да охшашлы дияргә мөмкин: sapa, sapon. Чуаш, мари һәм мордва телләрендә дә шул ук мәгънәдәге охшаш сүзләр булуы игътибарга лаек: димәк, гигиена культурасы аларга болгар-татар аша кергән булып чыга.

"Урта Азиядә, Иранда, Һиндстанда элек-электән сабын урынына шундагы бер үсемлекнең күбекләнүчән тамырын кулланганнар Бу тамыр фарсыларда *соибун*— югыч тамыр дип атала" (Р.Әхмәтьянов). Безнең якларда да *нугай сабыны, сабын күбеге, кыр сабыны* (мыльнянка лекарственная) дигән үсемлек үсә. Ул йон һәм ефәк материяләрне юуу өчен дә кулланылган.

Шулай да безнең бабаларыбыз сабын белән гарәпләр аркылы танышканнар дияргә мөмкин. Бу, ихтимал, X-XI гасырларга — пакьлекне таләп итә торган Исламның безнең төбәктә ныклап таралу чорына туры киләдер. Элек татар хатыннары чәчләрен *әче катык* яки *эркет суы* (кызыл эремчек суы) белән юа торган булганнар. Урта гасырларда Багдад мунчаларында сабын урынына *ногыт оны* кулланганнар. Ә Русьта Новгород халкының мунчада *куас* белән юынганлыгы тарихи язмалардан билгеле.

Гален дигән табиб II гасырда римлыларның кер уу һәм, гомумән, юыну өчен сабын ясауларын әйтә. Борынгы Римда кер уу өчен көл, поташ, балчык һәм бәвел кулланганнар.

X гасыр. Византиядә Константинополь шәһәре башлыгы христиан уразасы көннәрендә терлек маеннан сабын кайнатуны тыя, бу көннәрдә аны зәйтүн маеннан эшләгәннәр.

XI гасыр. Киевкә Константинопольдән сабын кайтарта торган булганнар.

Новгородта безнең көннәрдә җир астыннан табылган XIV гасырга нисбәтле тузга мондый сүзләр язылган: "...китән тукыманы агартырга, агарту өчен *болгар сабыны* алырга." Димәк, ул заманнарда новгородлылар сабынны Идел буе болгарларыннан алганнар дип уйларга була.

1714 елда Казанда беренче сабын кайнату остаханәсе барлыкка килә.

1741 елда француз Жюльен Луи Жоффруа каты сабын җитештерә.

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санынан басылып килә.*

XIX гасыр урталарында Казанда эшкуар Крестовников стеарин һәм сабын кайнату заводы ачкан. Күп тә үтми, бу төшемле эш белән татарлар да шөгыльләнә башлыйлар. Мәс., узган гасырда Ибраһим Юнысов энесе белән сабын заводы тоткан. Хәер, XVIII гасырның 90-елларына ук инде Казанда 30 сабын кайнату сәнагәсеннән 19 ы татарлар кулында, 11 е руслар кулында булган. Сонрак Галикәев Мөхәммәтсафа исемле сәүдәгәр дә сабын җитештерү белән шөгыльләнгән, М.К.Борнаев үзе җитештергән сабын белән сәүдә иткән. Казанда *Сабынчы урамы* дигән урам да булган. Элекке Казанда "Гөлҗиһан сабыны" исемле исле сабын чыгарылуы билгеле.

Иске әдәбиятта *"сабын пешерү"* гыйбарәсе очрый.

***САДА*** *г.* — Тавыш, аваз; кайтаваз, эхо. / / *"Сада" көе* — 1905-1907 еллардагы революция вакытында мәдрәсә реформасын даулаган шәкертләр тарафыннан чыгарылган көй. Авторы билгесез. *"Беренче сада"* — шәкертләр марсельезасы. Беренче тапкыр Казанда "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә җилем басмада яшерен рәвештә чыккан "Әльислах" газитендә басыла һәм Россиядәге бөтен татар мәдрәсәләренә тарала. 1907 елда аны Оренбургта "Шәкерт садалары" исемле китапка кертеп басалар. Ләкин Оренбург жандармериясе бу китапны басылу белән үк конфискацияли. "Беренче сада" һәм "Икенче сада" тыелган җырлар исемлегенә кертелсәләр дә, шәкертләр арасында кулъязма хәлендә йөриләр. "Икенче сада" русча "Хазбулат удалой" көенә башкарылган. *Сада салу* — тавыш салу, хәбәр җибәрү. *Садаи шәрык* — Шәрык авазы, Көнчыгыш авазы.

***САДАК*** *тар.* — Ук-җәя сала торган, билгә тагылмалы күн савыт, калчан, кыны. Телдә *сагадак, сайдак, сагайдак* вариантлары да булган. Мәхмүд Кашгарый сүзлегенә "садак" мәгънәсендәге борынгы төрки *ясык* сүзе теркәлгән. Сугышка барганда яугирләргә үзләре белән берничә дистә ук алырга кушылган. Н.Гумилев фикеренчә, сагайдак — "итек", чөнки атлы сугышчылыр укны күнитек кунычына тыгып йөрткәннәр. "Татарча-русча сүзлек"тә (1966) садак — ук һәм җәя савыты дип аңлатылган, ләкин Вл.Даль үзенең сүзлегендә "сайдак" һәм "сагайдак"ның фәкать *җәя кынысы* мәгънәсен генә терки, ә Г.Саттаровның "Татар исемнәре сүзлеге" *сагайдак* һәм *садак* сүзләрен борынгы төркичә "ук" мәгънәсендә (?) дип аңлата.

***САДАКА, СӘДАКА*** *г.* — Савап; әҗер өчен бирелә торган ярдәм, хәер. Коръәндә (3:92/86): "Ий мөселманнар, үзегезгә сөекле нәрсәләрдән мохтаҗ мөселманнарга бирмичә торып, Аллаһудан биреләчәк нигъмәтләргә ирешә алмассыз. Бит Аллаһ сезнең нинди нәрсәләрдән садака биргәнегезне беләдер," — диелгән. Коръәндә садакага нисбәтле аятьләр байтак, мәсәлән, 2:195/191; 162/264-263/265, 270/273, 276-277/277; 4:114;9:58, 60, 79/80, 103/104-104/105; 58:12/13-13/14.

Адәмнәргә явызлык тидерүдән саклан, бу эш синнән садака булыр.

Садаканың иң саваплысы үзең сәламәт чакта һәм дә фәкыйрьлектән курыккан, байлыкка омтылган вакытта биргән садакадыр.

Яшерен садака бирү — бөтен өмидне Аллаһы Тәгаләгә баглауга, җазаны аңардан гына күрүне һәрнәрсәдән алда тотуга дәлил. Р.Фәхреддин.

Байлыгы булган һәм дә әгъзалары сәламәт булып кәсеп кылырга көче җитәрлек кешеләрнең садака соравы хәләл түгел. Хәдис.

Өстәге кул астагы кулдан хәерлерәк (садака бирүче кул турында).

Әбү Һөрәйрә риваять кылган: "Рәсүлуллаһ (с.г.с.) янына бер кеше килеп: "Йә Рәсүлуллаһ, нинди садаканың савабы олуграктыр?" — дип сораган. Рәсүлуллаһ: "Ярлы булып калмактан куркып һәм бай булмакны өмет итеп садака кылсаң, әнә шул садаканың савабы олуграктыр. Җаның күкрәгеңә килгәнче садака биреп кал. Соңыннан "Фәләнгә бу кадәр, тегеңә шул кадәр бирәсе булган икән," — дисәң дә соң булыр, барча мал-дөньяң мирас хурга (мирас ашаучыга) калыр," — дигән."

Садака биргәндә аның Шәригать максудына муафыйк булуы шарт. Моның өчен исә садакаларның әһел кешеләр кулына төшүен тәэмин итәргә кирәк, садака тиешсез адәмнәр кулына кермәсен. Мәетләр өчен багышланачак садакалар җәмгыяте хәйрия кебек оешмалар аркылы өләшенсә, ул садака каргаларына вә комсызларга эләкмәс, бәлки әһел кулларга төшәр иде.

Хәдисләрдә һәм фикъһе буенча әдәбиятта садака термины зәкят мәгънәсендә кулланыла. Чыннан да башта садака белән зәкят бер үк төшенчәне белдергәннәр һәм садака алу хокукына ия кешеләр белән зәкят малына хокуклы кешеләр бер үк сыйныфка караган. Мәҗбүри зәкяттән аеру өчен *ихтыяри (ирекле) садака* дигән термин да кулланылган.

Садаканың азы-күбе юк һәм садаканы азсынып алучылар гөнаһлы булырлар. Кешеләрдән хәер-садака алып яшәүгә җайлашкан кешене *садака кошы* дип атаганнар.

// *Садака кылу.*

***САКЫЙ*** *г.* — Тустаганчы, аякчы, шәрабдар, шәраб биреп торучы (мәйханәләрдә). Ләкин бу сүзнең төп мәгънәсе *су таратучы, су өләшүче* булган. Мәс., *сакый-и Кәүсәр*-Кәүсәр суын мөэминнәргә өләшүче. Электә авыл чишмәсеннән су алып кайтып халыкка таратучы кеше төркиләрдә дә *"сака"* дип аталган. // *Сакыя* — су өләшү вазыйфасы.

Бекташия тарикатендә сакый мөһим урын тота. Тарикатькә керү тантанасы ахырында сакый шәрабны тарикать шәехеннән башлап өләшә, аннары һәркем алдына килеп, шәраб эчкәндә символик мәгънәле сүзләр әйтә.

// *Сакый-Кәүсәр* — "Кәүсәр шәрабы"н өләшүче мәгънәсендә, хәзрәти Галинең ләкабе. Җәннәттәге Кәүсәр суын мөселманнарга имам Гали өләшәчәк дигән фикер таралган.

***САЛАВАТ КҮПЕРЕ*** — Аллаһны "данлыклау, рәхмәт уку күпере" мәгънәсендә дигән фикер яши. Бу сүз башкорт телендә дә бар. Чуашта — *саламат (салават) кепере*. Ләкин В.Г.Егоров чуаш телендәге *самават кепере* вариантына игътибар итә һәм аны "күк(ләр) күпере" дип аңлата (гарәп телендә *сәма* — күк, *сәмават* — күкләр). Бу фараз игътибарга лаек шикелле. Салават күперен *сират күпере* дип атау да очрый (мишәр-чагатайларда), чуаш телендәге тагын бер варианты — *сурәт күпере*, тик бу очракта "сурәт" сүзе "сират" урынына кулланылган дип уйларга була. Мордва-каратайларда салават күпере-*д'эшел д'әйәсе, д'эшел җәймәсе* (*д'эшел* — җылдырым, яшен).

Тагын кара: ***КАВӘСЕ КОЗӘХ.***

***САЛЫМ*** *тар.* — "Аңлатмалы сүзлек" буенча "Дәүләткә халык яки хуҗалык оешмалары түли торган мәҗбүри җыем; налог". Хан заманнарында *ясак* дип йөртелгән, ә рус кенәзләре һәм патша чорында *дань, подать* терминнары булган.

Идел буе Болгар дәүләтендә гошер, хәраҗ, җизья, зәкят кебек салымнарга Алтын Урда ханнары тамга, калан, сабан салымнары һ.б.ны өстәгәннәр. Казан ханлыгында да шундый ук салымнар (ясак) гамәлдә булган дип уйларга кирәк.

Рәсәйдә патша чорында һәм аннан соң да күпсанлы салым-җыемнар уйлап чыгарганнар. Мәс., Петр патшаның өзлексез сугыш чыгымнарын каплау максатында мунчалар өчен, хәтта мунчада себерке белән чабынган өчен дә салым салганнар. Ә салым җыючы эмиссарлар моннан да арттырып җибәргәннәр. Мәс., Петр патшаның 1704 елгы указы буенча Идел-Урал төбәгендә салым җыю буенча патша эмиссарлары А.Жихарев һәм М.Дохов дигән бәндәләр указда булмаган уннарча салым уйлап тапканнар: һәр морҗа өчен (төтен өчен), базарга яисә мәчеткә барган өчен, мәет өстендә җеназа укыган өчен, камыт башыннан, дуга башыннан, бәкеләр, тәрәзәләр, нәүрәп-базлар, капкалар саныннан салым таләп иткәннәр. Хәтта күзнең төсе өчен дә налог түләткәннәр: соры күзлеләрдән алтышар тиен, кара күзлеләрдән сигез тиен алганнар. Санкт-Петербург аксарайлары менә шул акчалар хисабына торгызылган.

Совет чоры да дистәләгән салым төрләре белән характерлы. Авылда салымнарын түләп бетерә алмаганнарның өйләренә кереп, әүвәлгедәге кебек, әйберләрен язып чыгалар яки алып китәләр. Икенче бөтендөнья сугышы елларында Карабаш-Бөгелмә юлындагы телеграф баганасына үлгән тавык асып куйганнар һәм шунда ук:

"Бер тавыктан бер йөз күкәй
асылынам, түтекәй," — дигән язу элгәннәр иде.

СССР да дәүләт чыгарган заем облигацияләрен халык арасында "урнаштыру" салымның өстәмә бер төре була. 1957 елга кадәр ел саен бер айлык хезмәт хакын

дәүләткә "бурычка биреп тору" кампаниясе уздырыла һәм тора-бара халык монысын да котылгысыз бер афәт дип кабул итә башлап, бил каешын тагы да тартыбрак буып куя. Заемга язылу кампаниясе фаҗигале төстә үтсә дә, агитаторлар бу эш барышында көлкеле фактларны да искә алалар. Татарстан АССР ның Сарман районы Сарайлы авылында, мәсәлән, бер ялгыз апа (күрәсең, тол солдатка булгандыр) капка төбендә заемга яздыручы агитаторлар (гадәттә авыл мәктәбе укытучылары) күренүгә, матчасына кагылган чөйгә бозау мунчагы бәйләп куеп, урындыкка баскан килеш, муенын элмәккә тыгып көтеп тора. Агитаторлар ишектән керәләр дә, бер сүз әйтми генә, башларын чайкыйлар, уфтанган булалар, аннары мыштым гына чыгып китәләр. Капкага килеп җиткәнче үк артларыннан теге апа йөгереп чыга да: "Ярар инде алайса, быел йөз сумга язылырмын инде, хәердән булыр", — дия-дия, бөгәрләнеп беткән соңгы акчасын суза...

***САНАЙ*** *тар.* — Җәянең бер төре. Гыйсъянчы Батырша үзенең бер хатында язган сүзләргә караганда, "санай йәйә" кырыгар-иллешәр тиен генә торган, ләкин "йалан башкортларының" унар-егермешәр сумлык "әдернә йәйәләреннән артыктыр." "Ботакка кунган тиенне, сусарны атканда ботагы берлә өзеп төшерәдер". Себер татарлары телендә "санай"-җәя ("йагы"), аларда *санай-ук* яки *ук-санай* дигән сүз дә бар. Шул ук Себер татарларының бер тарихи җырында Карьят батырның иңенә "ике батман санай" угы асканлыгы әйтелә.

***САНАР ТАКТА*** *бор.төр.* — "Санар такта" сүзе "Кодекс куманикус"та очрый (1303 ел). Абак, исәп-хисап җайланмасы, русча — *счеты*. Функциясе ягыннан асылда *дисбегә* һәм *рәмел тактасына* тәңгәл. "Санар такта" атамасы хәзерге терминологиядә "калькулятор" сүзен алмаштыра алыр иде. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китик, бүгенге терминологлардан кайберәүләрнең "компьютер" сүзе урынына "санак" сүзе тәкъдим итүе телне баету түгел, чөнки төрки телдә аның белән тамырдаш "санар" сүзе күп гасырлар элек төгәл мәгънәдә кулланылган инде. Ә компьютерның функциясе санау белән хисаплаудан күпкә катлаулырак һәм югарырак, "фәһемлерәк" һәм "дәрәҗәлерәк".

Тагын кара: ***САҢАК; КАЛЕНДАРЬЛАР.***

***САНӘМ*** *г.* — Сын, пот, сурәт, табындык (мәҗүсиләрнең табынган нәрсәсе), кумир. *Сыным* язылышы очрый, ләкин ул *сын* сүзе белән бутаудан гына килә.

Сөнгатулла Бикбулатның "Хәзрәт Мөхәммәд" китабында җаһилият дәверендә гарәпләр табынган санәмнәр санап чыгыла. Китаптагы язылышны беразүзгәртеп, шул исемлектәге потларны күрсәтик: 1) *Вәд* — кәлб кабиләсенең поты; 2) *Сувагъ* — һузәил кабиләсенең поты; 3) *Йәгус*-Йәмәндә мәзхәҗ һәм кайбер башка кабиләләрнең поты; 4) *Йәгук* — һәмәдән гарәпләре табынган пот; 5) *Нәсер* — Йәмәндә хәмириләр табынган пот; 6) *Мәнат* — әүс һәм хәзрәҗ кабиләләренең поты; 7) *Лут* — сәкыйф кабиләсенең поты; 8) *Гоззә* — көрәйш һәм бәни Кәнәнә кабиләләре табынган пот. Гарәпләр соңгы өч санәмне Алла кызлары дип ышанганнар, аларның ире Һубәл булган; 9) *Һубәл* — көрәйш кабиләсенең бер поты; 10-11) *Исаф* һәм *Наилә* — Исаф бер егет, ә Наилә бер кыз булган, алар Кәгъбә эчендә зина кылганнары өчен ташка әйләнгәннәр имеш; 12) *Фулъс* — тай кабиләсе табынган пот.

Бу пот-санәмнәрнең баштагы бишесе "Нух сүрәсе"нең 23 нче аятендә телгә алына.

*Санәм*-нең күплек саны шәкеле-*әснам*.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## РУБРИКАГА КЕРЕШ СҮЗ

*Бөек әдибебез Галимҗан Ибраһимовның Кырымда дәваланган чагы. Бер кичне ул юлдашы белән тауга менә. Аста — меңләгән утларын җемелдәткән Ялта. Порттан аклы-кызыллы-яшелле фонарьларын яндырган катер чыгып бара, йөзләрчә утларын кабызган зур "Абхазия" пароходы портка кереп килә. Күктән тулы ай карый, аның нурларыннан диңгез гаҗәеп төсләргә кереп уйный. Ошбу манзарадан күзен ала алмыйча озак кына карап торганнан соң, әдип болай ди: "Бу матурлыкны тел белән, сүз белән яисә буяулар белән тасвирлый ала торган художник бармы икән? Юктыр. Чынбарлык сәнгатькә караганда бик күп, бик күп көчлерәк, баерак, мулрак". (Б. Гозәеров истәлеге.)*

*Монысы исә — Лев Толстой сүзләре: "Киләчәктә әдәби әсәрләр уйлап чыгарудан туктарлардыр. Язучылар, иҗат итмичә, тормышта үзләре күргән мөһим һәм кызык хәлләрне генә тасвирларлар".*

*Бу, бәлки, бәхәсле фикерләрдер. Әмма дөньяда иң бай фантазиягә ия язучыларны да көнләштерерлек вакыйгаларның булгалап торуы хак бит. Яңа сәхифәдә урын шуларга биреләчәк тә инде.*

*Шунысын да искәртик: "Казан утлары" — язучылар журналы гына түгел. Тиешле кимәлдә язылган мәкаләләр, фикерләре, хатлары белән анда һәркем катнаша ала... "Тормыш язган хикәяләр" дигән рубрикада бирелгән беренче язманың авторы да — гади авыл агае.*

# ӘМӘЙГЕЛ ӘБИ

Әтием Гайфетдиннең әнисе ул Әмәйгел әби. "Әни*, син кайсы авылда туып үскәнсең?—дигән соравыма әбиебез: "Улым, мин менә шушы җәберләнгән Җәнгилдедә туып үскәнмен",—дип җавап бирер иде. Минем сорауларымның исә иге-чиге юк. "Ни өчен җәберләнгән Янгилде?"—дип кызыксынам. Бер мәлгә аның карашын сагыш баса, аннан соң, йөзе яктыра төшеп, эчке горурлык хисе белән сөйләп китә: "Җәнгилдене, улым, җәберләү генә түгел, чукындырып җәфалаганнар, җәзалаганнар. Аның халкын православие динендә тоту өчен куркытып та, алдап та, җайлап та караганнар. Тик Җәнгилде җинелмәгән, беренчеләрдән булып яңадан Мөхәммәт диненә кайткан. Шул борынгы, батыр авылда туып-үскәнмен мин",—ди иде.

Әмәйгел әбиебезнең әтисе Вәлиулла бабай яшүсмер чагында 1834 елгы чукындыру гарасатын үз башыннан кичерә. Шуннан соң Коланга побы Виктор Охотин, мөселман исемен юкка чыгарып, "Герасим" исеме кушып, бабабызны Зөя өязе исправнигы тарафына җибәрә. Вәлиулланы армия хезмәтенә алалар һәм, кулына озын мылтык тоттырып, Россия изүенә каршы баш күтәргән Кавказ "инородецларын" бастырырга озаталар. Вәлиулла солдатны дин кардәшләренә каршы атарга да мәҗбүр итәләр—ул Россия регуляр армиясе составында төрекләргә каршы сугыша.

"Әтием Вәлиулланы авыл халкы Вәлуч дип йөртә иде. Ул, бик ярлы булганга, хәрби хезмәттән калу өчен түләнергә тиешле зур сумманы туплый алмый. Исемен көчләп үзгәртсәләр дә, армиядә дә үз динен ташламый,—дип сөйли торган иде әбием.—Бервакыт әтинең куаклар арасына кереп намаз укыганын урыс офицеры күреп ала да, бу хакта полк командиры исеменә рапорт яза. Полк командиры мөселманнарны үлеп яратмый торган, бик явыз бәндә була. Ул әтигә патша армиясендә кулланылган, иң рәхимсез җәзалардан саналган "через строй" җәзасын билгели. Ротадагы барлык солдатларны бер-берсенә каратып ике рәткә тезәләр. Һәрберсенә берәр тал чыбыгы тоттыралар. Куелган шарт буенча һәр солдат әтинең шәрә аркасына берәр мәртәбә сугарга тиеш була. Сукмаган солдатка үзен саф аша үткәрү яный. Аның югалткач кына әтине стройдан сөйрәп чыгаралар һәм хәрби лазаретка салалар. Бәхетенә күрә, лазаретта санитар булып бер татар солдаты хезмәт итә икән. Шул солдат әтине үлемнән алып калган".

*Без, аның унҗиде оныгы, аңа "әни" дип, үзебезнең әниләребезгә "нәнә" дип эндәшә идек.

Россия армиясендә 28 ел хезмәт иткәннән соң, Вәлиулла бабай Янгилдесенә кайта һәм Ләйли исемле тол хатынга йортка керә. Ләйли әбинең яшьли вафат булган иреннән Миңлегази исемле улы кала. Бабай аны уллыкка ала. Яңа корылган гаилә матур гына яши башлый. Вәлиулла солдаттан Ләйли әби алты бала таба. Беренче булып Әсәдулла дөньяга килә. Аннан соң туган Хәйрулла үлеп китә. Өченче булып җиһанга аваз салган улларына аның исемен кушалар. Шуннан соң бер-бер артлы өч кызлары туа.

Армиягә алынганчы Вәлиулла бабай Әмәйгел исемле кызны яратып йөри. Кыз егетнең 28 ел буе хезмәт иткәнен көтми, башка кешегә тормышка чыга. Ләкин Вәлиулла солдат аны оныта алмый, икенче кызы тугач, хатынына: "Ләйли, бу кызыбызга Әмәйгел исеме кушыйк әле",—ди. Ләйли әби шатланып риза була. Шул рәвешле, әбиебез әтисенең беренче мәхәббәте исемен ала.

1873 елның июнендә Вәлиулла солдат гаиләсенә икенче мәртәбә ачы хәсрәт килә. Ул бөтен авылны тетрәндерә. Гомерендә кыенлыкларны күп күргән, аерым хуҗалык һәм колхоз чорларында авыр эшләрне җигелеп тарткан, шуның нәтиҗәсендә бармаклары кәкрәеп каткан Әмәйгел әби бу фаҗигане искә алганда, аның гәүдәсе тагын да кечерәеп кала, битләрендәге җыерчыклар да күбәя, тирәнәя, эчкә баткан күзләреннән яшьләр бәреп чыга иде. Аны тыңлаганда мин дә кушылып елый торган идем.

Көннәрдән бер көнне Ләйли Вәлиулла белән буй җиткән уллары Әсәдулла һәм Хәйрулланы ышна кырына, пар җирен сөрергә җибәрә. Үзе исә Бурышлы тавындагы ясмык җирен чүп басмадымы икән дип карап кайтырга җыена. Өч яшьлек төпчеге Гөлнисаны аннан нибары ике генә яшькә олырак кызы Әмәйгелгә ышанып тапшырып, сеңлесенә күз-колак булырга кирәклеген кат-кат искәрткәннән соң, юлга кузгала.

Ике кызчык өйдә кала. Бераздан, иске-москылар салып, Әмәйгел сеңлесен өйалдында йоклата. Озакламый, гөнаһ шомлыгына каршы, үзе дә изрәп йокыга тала. Гөлниса апасыннан иртәрәк уяна һәм, капка астыннан шуышып, урамга чыгып китә...

Әмәйгел өй каршына җыелган халык тавышына уяна. Урамга чыкса—чирәм өстендә йоклап яткан сеңлесен күрә һәм аптырап кала. Кире өйалдына кереп корама юрган алып чыга һәм аны Гөлниса өстенә яба. Башта ул ни өчен сеңлесенең һаман да уянмавын, күлмәгенең нилектән юеш булуын, җыелган кешеләрнең нигә зар елавын аңламыйча тора...

Бу вакытта Ләйли, "Озаграк йөрдем, ахры" дип, урамнан агучы чишмә буйлап тиз-тиз аска таба атлый. Гаҗәеп матур табигатьле Янгилдегә Кошман авылыннан килен булып төшүеннән соң шактый еллар узса да, авылның ике урамыннан аккан чишмәләргә һаман да сокланып туя алмый ул. Аларның бишек җырыдай челтерәп агуы ару-талуны белмәгән бала-чагага да, көне буе кояш астында кырларда тир түккән өлкәннәргә дә җан рәхәтлеге бирә, алҗу-талчыгуларны оныттыра.

Чишмәләр тормыш көтүдә, хуҗалык итүдә дә ярдәмнәреннән ташламыйлар. Яшелчә үстерүчеләргә чиләк-көянтәләп коелардан су ташып мәшәкатьләнәсе дә калмый—алар, эрганаклар ерып, суны бакчаларына ук кертәләр. Каз-үрдәк асраучылар исә үз өйләре каршында кечкенә генә буалар буып куялар. Аларны ел саен чистартып, агач улакларны яңартып торалар. Буалар яңгын афәтеннән дә саклыйлар. Чишмә буйларында йөзәр яшьлек өянкеләр үсә. Өянкеләрнең ботаклары-яфраклары арасына меңәрләгән кошлар оя корып, бала чыгаралар. Язларда авыл кошлар тавышына күмелә.

Чишмәләрнең зыян салган чаклары да булгалый: кышкы көннәрдә су урамнар буйлап җәелә, язлар җиткәч, ул идән асларына юл сала, җәйләрдә исә күпләрнең тавык-чебиләре буага төшеп үлә...

Бу ни хәл?! Аларның өе каршында халык җыелган. Каршы очраган авылдашлары, бер сүз дә дәшмичә, читкә карап узалар.

Өе янына килеп җиткәч, Ләйли кызы Әмәйгелнең өзгәләнеп елавын, өч яшьлек Гөлнисаның яшел чирәм өстендә яткан җансыз гәүдәсен күреп ала. Аның йөзе агарына, күз аллары караңгылана, тезләре тотмас хәлгә килә һәм һушын җуйган ана үле кызы янына ава.

Авылда мәет булуы, кызчыкның әтисе чистарткан буада батып үлүе турындагы хәбәрне куштаннары Колангы чиркәве побы Охотинга җиткерәләр. Тиз арада үзе белән ике дьячок—бертуганнар Алексей һәм Александр Петровларны ияртеп, поп килеп тә җитә. Ул авыл старостасы (Янгилде авылы урысы) Алексей Ивановны да чакырта. Алар җәберләнгән Янгилде халкына кечкенә Гөлнисаның җәсәден мөселман зиратына җирләргә мөмкинлек бирмиләр, кәфенләнгән бала мәетен өйдән чыгармаска тырышалар. Янгилде зиратында мөселман агайлар казыган кабер көтеп тора. Поп исә Колангы чиркәвенә алып барып, служба үткәреп, чиркәү янындагы зиратка җирләргә куша. Гөлнисаның әтисе Вәлиулла солдатта алган Георгий тәресен (тәре булганга күрә, ул аны бервакытта да түшенә такмаган) күрсәтеп карый, ләкин моның файдасы тими.

Тышта җылы июнь ае, ә сабый мәете өч көн буе җирләнмичә ята, ул исләнә башлый. Ләйли исә нык тора, попны якын да җибәрми: “Исләнсен, үзем иснәрмен. Ләкин чукындырырга бирмәм!”—ди. “Отпавшие от православия” дип йөртелгән, әмма мөселманнар буларак рәсми рәвештә теркәлеп өлгермәгән яшьләр Ләйли апаларының өе каршына җыелалар. Алар поп һәм аның яраннарының башларына таш яудыру белән яныйлар. Поп кул селтәргә мәҗбүр була һәм дьячоклары белән арбага утырып, Колангыга кайтып китә. Гөлнисаның җәсәден, барлык мөселман йолаларын үтәп, авыл зиратында җирлиләр. Әмәйгел әби исә гомере буе судан куркып яши. Әби: “Улым, мин аның каты итеп кычкырганын ишеттем, тик йокы аралаш берни дә аңламадым, кабат йоклап киткәнмен”,—дип өзгәләнә иде.

Гөлниса фаҗигасе бәгыренда уелып калган әбием мине Имәлле буена җибәрмәскә тырыша, өйдән чыгып шылган вакытымда эзләргә чыга иде. Әмма балачак шуклыклардан гыйбарәт. Әби мине эзләгән вакытта малайлар арасына кереп, йә суга чумып, аның күрер-күрмәс күзләреннән качып котыла идем. Тик әби үзенекен итә—мине эзләп тапмыйча өйгә кайтмый. Ул чакларда минем өчен иң яманы шул—кояшта каш өстенә кулын куеп: “Бәбкәм, кайт. Кайт, Тәптил (Тәфкил) бәбкәм, кайт, улым, суга батарсың”,—дип кычкырып торыр иде. Зуррак малайлар арасыннан әче телләләр табыла. Алар “Тәптил, кайт бәбкәм, суга батарсың”,—дип үртәп теңкәгә тияләр, рәхәтләнеп көлешәләр. Бу хәл исә миңа бер дә ошамый, әбине ачулана идем.

Әмәйгел әбиебез дөньяның ачысын күп татыса да, без аның гаҗәеп сыйфатларына сокланып яшәдек. Шул сыйфатларның берсе—тормышта очраган кыенлыкларны да кызыкка әйләндереп сөйли белүе, төрле мәзәкләр уйлап чыгаруы, уен-көлке яратуы. Минемчә, мондый сыйфат нык рухлы, чиста күңелле кешегә генә хас була. Бу җәһәттән балачагымдагы бер вакыйганы бәян итмәкчемен.

Без үскәндә Берләш егермеләп йорттан торган, берничә милләт кешеләре яшәгән авыл иде. Әбиебез еш кына шунда—кызы Мәрьям (без аны Берләш апа дип тә атап йөрттек) янына барырга ярата иде. Ул анда атналар буе, күңеле булганчы яши. Мин дә әбидән калмыйм, җиде чакрымлык араны ана ияреп теркелдим. Берләшкә барганда Шыгай авылы аша чыгабыз. Шыгайда әбинең танышлары бар, ул алар белән очрашып, туйганчы сөйләшә, авыл зираты янына тукталып бер сәгать чамасы догалар укый. Шулай итеп, Янгилде белән Берләш арасын биш-алты сәгатьләп барырга туры килә иде.

Берләш апаның биш улы бар. Бишесе дә—гармунчылар. Мин дә алар кебек уйнарга хыялландым. Улларының дүртесе миннән олыраклар. Аларга Гашыйк абый, Хамиз абый, Хәмзә абый, Рәшит абый дип эндәшә идем. Берләш апаның төпчек улы Фәһим исемле, ул миннән өч яшькә кечерәк. Без аның белән көн дәвамында Зөя буеннан кайтып кермибез. Кыш көннәрендә безне Янгилдегә Рәшит абый илтеп куя.

1944 елның декабре. Тышта 20-25 градус салкын. Күк йөзе чалт аяз. Җигелгән чанага Рәшит абый печән салды да әбине толыпка төреп утыртты. Берләшне чыгып, бер чакрым чамасы үткәч, мин 40-50 метр биеклектә кызыл төстәге зур булмаган һава шары очып килүен күреп алдым. Тиздән аны Рәшит абый да күрде һәм, атын туктатып, әбигә күрсәтте. Шарга 5-6 метр озынлыктагы нечкә трос белән китап рәвешендәге тартмачык эленгән, аның астында 4 канатлы пропеллер әйләнеп тора. Шарны күргәч, әби белгәннәрен укырга кереште. Бераздан тартмачыкның

пропеллеры йомшак карга төшеп калалды, шар исә тукталып, баш очыбызда эленеп калды.

Рәшит абыйга унбиш яшь, дүртенче сыйныфны тәмамлавына ике генә ел. Кыскасы, безгә караганда ул белемлерәк. Аның кичләрен каравыл өенә тәмәке тартырга, сөйләшеп утырырга килгән агайлардан немец шпионнары турында да ишеткәне бар. Бер мәлгә ул югалып калды, пропеллерлы тартма янына барырга шүрли иде: "Немецлар жибәргән шартлаткыч түгел микән?"—диде ул. Уйлаша торгач, тәвәккәллек жинде—Рәшит абый балтасын алып, тросны кисте дә, шарны тәртәгә бәйләп куйды. Ярый инде карт алаша күпне күргән, шардан өрекмәде. Тора-бара Рәшит абый батыраеп китте, шаяртырга ук кереште, тартмачык янына килде дә, әбигә: "Әни (әби), сиңа Мөхәммәт галәйһис-сәлам персональ Коръән жибәргән",—диде. Әби ышана калды: "Алай булса, якын бармагыз",—дип, толыбыннан әкрен генә чыкты да тартма янына чүмәшеп утырды. Догасын тәмамлаганнан соң тартманы ике кулы белән алып чанага салды, "Өйгә кайткач ачарбыз",—диде. Безне якын да жибәрмәде.

Без, тәртәгә бәйләнгән шарны һавада йөздереп, өч чакрым жир үтеп, Шыгайга килеп кердек. Безне күргән авыл этләренең барчасы койрыкларын кысып ояларына шылдылар; шардан өреккән жигүле атлар, хужаларын тыңламыйча, дулап абзарга таба чапты.

Шыгайда әби Миңлебәян апаларга кереп чыгарга булды. Өй янында тукталгач, ул әкрен генә толып эченнән чыкты да серле аппаратны күтәреп капкага юнәлде. Өйгә кергәч, тартманы ачарга маташты, ләкин ача алмады. Шуннан соң күрше Әмәнулла абзый өенә чыгып өтергә алып керде һәм аппаратны ачты. Серле тоелган тартма эчендә, дүрт данә батареядан һәм ниндидер яздыру приборыннан гайре, берни дә юк иде. Сугыштан гарипләнеп, аксап кайткан Газимжан абзый: "Шарны очырып жибәрергә кирәк. Моның өчен аны башта жылытмыйча булмый",—диде. Гыйлажетдин абзыйның армия яшенә житкән улы Рәфикъ абый да аның сүзен куәтләде: "Әгәр дә шарны очырып жибәрмәсәк, аны ваянныйлар эзләп киләчәк. Чөнки аларга бу серле язу приборын табарга кирәк,—диде ул.

Салкын һавада кечерәйгән шарны ишек аша өйгә тартып кертү әлләни кыен булмады. Өй эче жылы, өстәл өстендә сары самавыр жырлап утыра. Әби кайда—мин шунда, бигрәк тә кунакка баргач. Без аның белән тәмләп чәй эчәбез.

Өйгә кергәч, шар зурая башлады. Моны күреп аны тиз генә тышка чыгармакчы булдылар. Тик кая ул чыгару! Шар инде түшәмгә үк терәлде, өйдәгеләрне кысрыклый башлады, сәкедә утырган Газимжан абзый белән Рәшит абыйны диварга китереп кысты. Без әби белән өстәл астына чумарга өлгердек. Өйдә ыгы-зыгы купты. Почмакта нидер белән мәшгуль булган Миңлебәян апаның иминлегенә генә әлегә берни дә янамый иде. Газимжан абзый бар көченә кычкырып жибәрде: "Миңлебәян, тиш пычак белән, тизрәк!" Хужа хатын шундук агач саплы чалгы пычагын шарга батырды. Пышылдап нидер чыга башлады, без һава дип уйлаган нәрсәнең газ булуы ачыкланды. Эшнең нәрсәдә икәнен аңлаган Миңлебәян апа шарны ярып ук жибәрде. Без тончыга-тончыга тышка атылдык. Өлкәннәр әбине өстәл астыннан тартып алдылар да толыбына төреп чанага чыгарып салдылар. Котылуыбызга багышлап, ул белгәннәрен укыды.

Тәмам коты алынса да әбинең безгә хәтере калмады, фәкать үз-үзен генә тиргәде. Карчыклар жыелган мәжлесләрдә ул бу вакыйганы кызык итеп сөйли торган иде. Рәшит абыйның "Сиңа Мөхәммәт галәйһис-сәлам персональ Коръән жибәргән" диюенә дә үпкәләмәде, бары тик "И рәхмәт яугырлары, әбиегезне шулай алдавыгыз өчен сезгә атагызның бил каешы кирәк иде дә, юк шул, сугыш сезне аннан да мәхрүм итте",—дип көрсенеп куя һәм яу кырыннан кайтмаган улын—Гайфетдинен исенә төшереп елап жибәрә иде. Шарның кабыгын әби беркемгә дә бирмәде, "Ваянныйлар килеп, сез яшьләрдән табып алса, сезне төрмәгә утыртырлар, ә мина, бөрешкән карчыкка берни дә булмас", дип, резинны иске француз яулыгына төйнәп, тимер белән тышланган зур сандыгына салып куйды. Серле аппаратка да шул ук сандыкта урын табылды. Сугыш тәмамланганнан соң әби резинны хатын-кызларга таратты, аппаратны Рәшит абыйга бирде, Рәшит абый исә безгә аны каләнә кадәр сүтеп күрсәтте.

Әби сеңлесе Гөлнисаның тетрәндергеч фаҗигасе турында сөйләгәннән соң күп дигәндә ай ярым вакыт узгандыр, аның үзе белән дә яман хәл булды. Иң аянычы шул—бу вакыйгада минем дә катнашым бар иде.

Сугыштан соңгы беренче авыр еллар. Колхоз рәисе әнине кабат Кече Урсак авылына урман кисәргә җибәрде. Мин Сатмыш җидееллык мәктәбендә бишенче сыйныфта укый башладым, миңа инде 12 яшь. Әни урман эшенә җибәрелгәч, мал-туар, кош-корт карау, өй эчендәге мәшәкатьләр аягына көчкә генә басып йөргән 78 яшьлек әби өстенә калды. Сыер асрап та азапланабыз әле. Мал-туар абзарын мин чистартам.

1947 елның ноябре. Якшәмбе көн. Мәктәптә бүген укулар юк. Без сеңлем Фәнзилә белән өйдә калдык. Иртән үк торып ишегалдына чыктым да сабы коргаксыган балта белән ботаклы агач яркасының кырыйларын китеп алырга керештем. Әби инде күптән торган. Сыер саварга әзерләнеп йөри. Сөт чиләген алып сыер астына кереп утырды да, тыңламас бармаклары белән сыер имчәген тарткаларга керешге. Чиләк төбенә шылтырап төшкән сөт агымы тавышы ишетелде. Чиләк төбе күмелгәч, тавыш үзгәрде, аннан соң бөтенләй ишетелмәс булды. “Ah!” дигән тавышка борылып карасам—сөт чиләге тәгәрәгән, әби исә яна гына салынган “сыер бәлеше”ндә ята. Сыер кузгалмаган, сауган җирендә басып тора. Мин, берни дә аңламыйча, рәхәтләнеп көләргә керештем. Әбинең битенә текәлгәч, тынып калдым: йөзе дә үзгәргән, авызы сулга кыйшайган, үзе бер сүз дә әйтә алмый. Әбине пычрак киемнәре белән өйгә сөйрәп кердем. Аннан соң тиз генә Зәйнәп туганый апаны алып килдем. Күрше апалар да керделәр. Сатмыштагы фельдшерлык пунктына хәбәр иттек. Олылар “Әмәйгел астайның сул ягын паралич суккан”,—диделәр. Без Рифат белән җиде чакрымлык арадагы Берләш авылына—әбинең олы кызы Мәрьям апага әйтергә йөгердек. Фәнзилә белән Әлфинә Сатмышка—икенче кызы Хәбирә апага хәбәр иттеләр.

Әбиебезнең сул ягы тоймас булды. Ул урыныннан кузгала алмады, хаҗәтләре—астында. Өч кызы булса да, аларга илттермәде. Әбине кече килене—әнием Бәдерхәят карады, кирәк икән, күтәреп тә йөртте. Хәер, Берләш апа аны 1946 елның җәендә алып киткән иде дә, көзгә таба “уфалла” арбасы белән кайтарып куйдылар.

Дөнья мәшәкатьләре белән бергә өебез дә тузуның соңгы чигенә җитте—түшәм такталары берәм-берәм төшә башлады, өйнең бурасы череп, тәмам таркалып бара иде. Әни Шыгай авылына барып, сугыштан исән-имин кайткан өч балта остасы белән сөйләште. Ул аларны булачак бәрәнге уңышыннан өлеш чыгару, тиенләп җыелган 3 мең сумны түләү, әтинең бер пар костюм-чалбарын бирү һәм осталарны көнгә өч мәртәбә ашату шарты белән күндерде.

Аллага тапшырып, өйне һәм келәтне бер көн эчендә сүтеп ташладылар. Икесеннән бер буралык нигезләрне, агачларын сайлап алдылар.

Әбине үзенең ризалыгы белән бездән биш йорт аша гына яшәүче олы улы Гыйльфанетдин өенә—туган нигезенә илтеп куйдык. Аны Зәйнәп туганый апа карарга булды.

Әни, барлык көчен туплап, үзе әйтмешли, торырлык өй “әмәлләргә” кереште. Анда чапты—монда йөгерде, бурычка керде, көн-төн булачак өй янында кайнашты. Минем бер кулыма—тукмак, икенчесенә калак тоттырып, нигезләр арасындагы мүкне төяргә кушты. Фәнзилә осталар артыннан йомычка җыйды. Әни җинеп чыкты. 1949 елның апрелендә өйнең эшен төгәлләделәр, мич тә чыгарылды, кереп яши башладык. Ләкин әбиебезне гомер иткән нигезенә кайтару насыйп булмады. Шул ук апрель аенда ул дөнья куйды. Аны югалтуны мин бик авыр кичердем. Әби мине 12 яшемә кадәр гел үзе белән алып йөрде, кая гына барса да, мин аннан калмадым. Ул миңа авылыбыз һәм гаиләбез тарихына кагылышлы күп мәгълүмат бирде, гаҗәеп кызыклы хатирәләр сөйләде, күңелем түрендә якты эз калдырды.

**Тәфкил ВАФИН,**
*Лаеш районы.*

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2006 елның беренче яртысы өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. «Казан утлары»ның индексы—**73210**, ярты елга язылу бәясе **150 сум**.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан быел да абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар журналга «Горпечать» киоскларында язылა алалар. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була. Фатирыгызда почта әрҗәсе бик үк ышанычлы булмаса, сезгә моннан да кулай ысул юк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ** на ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

*Казан утлары* (наименование издания) — Количество комплектов:

на **2006** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|
| | | |

на ~~газету~~ журнал — 73210 (индекс издания)

*Казан утлары* (наименование издания)

| | | | |
|---|---|---|---|
| Стоимость | подписки | ___ руб. ___ коп. | Количество комплектов |
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | |

на **2006** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)



*Драматург Нәкый Исәнбәтнең 60 яшьлек уңаеннан Казан университеты студентлары "Муса Җәлил" трагедиясен сәхнәләштерәләр. Спектакльдән соң төшерелгән рәсем. Беренче рәттә, сулдан уңга—Рейн Ганиев, Рәшидә Җиһаншина, Нәкый Исәнбәт, Рим Кәримов; икенче рәттә—Равил Сәйфетдинов, Кояш Тимбикова, Илдар Әүһәдиев, Фарук Нәфиев, Равил Низамов, Мөнир Абдуллин. 1959 ел.*



*Балалар язучысы Җәүдәт Дәрзаман. 1995 ел.*



*Язучылар Ләбибә Ихсанова һәм Хәсән Сарьян. 1973 ел.*



*Габдрахман Әпсәләмов Татарстан Язучылар берлеге хезмәткәрләре белән. Үткән гасырның 70 нче еллары.*



*Америкада яшәп иҗат итүче шагыйрә Нурия Измайлова. 80 нче еллар.*



*Композитор Фасил Әхмәтов һәм баянчы-музыкант Әхмәт Кәримов. 80 нче еллар.*

Рәдиф
СӘГЪДИ

# СИХЕРЧЕ ВИКТОРИЯ

Гомере буе эчсә-эчмәсә дә, хезмәт хакы алуга хатыны белән ике баласына һәрвакыт бүләкләр күтәреп өенә туры кайтырга яраткан токарь Нургаш иллегә якынлашып килгәндә, бөтен күрше-тирәне дә шаккатырып, кинәт кенә үзгәрде дә куйды. Мавыгып китте ул, әллә нинди Виктория белән...

Тир түгеп, авыр хезмәт белән тапкан сәмәннәре гаиләсенә тулысынча кайтмый башлады. Соңгы айларда исә гомумән, бусагада сукыр бер тиенсез пәйда була торган иде, ул. Хатыны Лимония дә иренең югалып торуларына түзде-түзде дә, тормыш иптәше белән усал гына итеп аңлашып карарга булды.

—Кызың икенче курста укый, улың Лимонад унберенчене бетерә, инде әллә ничә ай буена сукыр бер тиен алып кайтып биргәнең юк. Бу нәрсә дигән сүз инде, апаем,—диде ул күзләрен алартып. "Апаем"—дип әйтмәс тә иде ул, чөнки чыгышы Актаныштан.—Эчеп кайтсаң, кайт инде син "апаем", тик элеккечә гаиләң барын да онытма, без синең кебек гап-гади районнан чыкмаган, президентыбыз, туган төбәктән без, Аллага шөкер!—дип тә нотык укыды Лимония.

—Беләм, беләм кайсы җирдән чыкканыгызны, тәки колакны тондырдыгыз инде, президент та президент, имеш. Бүтән горурланыр әйберегез булмагач!—Аңа калса Аллага шөкер, иң беренче безнең районда сыер дагалый башлаганнар!—диеп башына иң беренче ни сукса, шуны чәпәде.

Лимония бер мәлгә аптырап сүзсез калды, шушы яшенә житеп, аның әле сыер дагалаганнарын күргәне дә, ишеткәне дә юк иде. "Нишләп авыл җирендә үссәм дә, бу хәлне белмим соң әле мин дип уйлады ул. Бу вакытта, ире Нургаш, утыз яшьлегенә бүләк ителгән егерме еллык "Спартак" ботинкаларын киеп чыгып китәргә маташа иде. Хатыны аның артыннан:

—Әгәр бүген дә шул Викториян янына барсаң, өйгә аяк басасы булма! Шундук аерылышырга гариза язам, белеп тор шуны,—диеп кычкырып калды.

Әйе, жинел түгел иде, сыер дагалап үскән Нургашка. Улы Лимонад белән кызы Литфониясенә хәтле әтиләре белән сөйләшми башлады хәзер. Үзенә дә уңайсыз иде аның. "Юк, житте, бүген Алла боерса, акча алуга туп-туры өйгә кайтам". Тик бәхетсезлеккә каршы, бүген дә ул эштән соң янадан сихерче Викториясе янына юнәлде. Әлбәттә, Виктория жанашы янына үзе генә түгел, тагын дистәләгән, бәлкем әле йөзләгән ир-атның йөргәнен белә иде Нургаш. Үпкәләмәде дә, көнләшмәде дә ул нишләптер алардан. Киресенчә, бу хәл аның күз алдында Викториянең бәясен генә күтәрә иде. Ә үпкәләргә, рәнжергә хакы бар идеме соң аның? Юк, әлбәттә! Чөнки Викториясе аны чакырып китермәде, шулай ук куып та җибәрмәде. Хатыны Лимония кебек әшәке сүзләр әйтеп тәмсезләнмәде... Килсәң ни иде дә аңа, килмәсәң ни... Иң мөһиме кесәңдә акчаң гына булсын.

Нургаш соңгы вакытта, бигрәк тә яз, җәй, көз айларында ял көннәре килеп житүгә, өендәге гаугадан туеп, туган авылы Мөкбәштә ялгыз гына

яшәп ятучы әнисе янына чаба торган булып китте. Ана кеше ана инде ул, кая барсын, пенсиясенең соңгы тиеннәренә хәтле җыеп, газиз улының юлына биреп җибәрә торган иде. Бу вакытта күчтәнәчкә диеп җибәрелгән казүрдәкләргә хәтле өйгә кайтмый башлаган иде инде. Хәл ачыклангач, әнисе үксеп-үксеп, рәнҗеп елады. Улының күптән юылмаган чәчләреннән сыйпап:

—Улым, алма кебек балаларың, тупылдап торган хатының Лимониян бар, каян таптың син шул Виктория дигән нәмәстәне? Нәселебездә булмаганны, җитте балам, акылыңа кил, җитте. Вакытсыз гүргә кертмә инде мине күз нурым,—дип үтенде ул.

—Яхшы әнкәй, яхшы! Менә күрерсең барысы да җайланачак,—дип җавап бирер иде Нургаш. Ләкин, эш кенә җайланмады, киресенчә гел түбәнгә генә тәгәрәде. Виктория белән танышканнарына ике ел дигәндә, хатынының сабырлыгы сынып, алар аерылыштылар. Үзенчә ирен фатирсыз да калдырмады ул, иртәме-соңмы барыбер балаларга булачак, диеп, өч бүлмәне икелегә алыштырып, Нургашка да бер "гостинка" алып бирде. Ләкин, иренең "гостинка"да кунак булып яшәве озакка бармады. Аны сатып җибәргәнен сизми дә калды ул. Озакламый мал бүлгәндә, "өлешенә тигән көмеше" дигәндәй, иске жигулиның да китүе ачыкланды...

Улының фатирсыз, машинасыз, эшсез калганын ишеткән ана гына бөтен эшен ташлап, туган авылыннан көне-сәгате белән шундук шәһәргә килеп җитте. Оныгы Лимонад белән Нургаш улын эзләргә тотынды ул. Нарасыен әле бер ай элек, үзе кидереп җибәргән иске джемпрыннан танып алды.

—Улым, Нургалием, җанкисәгем нишләп биредә аунап ятасың соң син,—диеп өзгәләнде ана. Ир кеше дә җанына кадерле, ягымлы тавыш ишетеп селкенеп куйды. Соңыннан күзләрен ачып, "нихәл әнкәй",—диеп мескен генә елмайгандай итте.

—Менә әнкәй, Виктория җибәрми бит үзеннән, сихерләде ул мине.

Ана кеше улы төртеп күрсәткән нәмәстәгә күз салды. Каршысында "Виктория" дип язылган уен автоматы басып тора иде.

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

## Ибраһим Биектаулы

**(Ибраһим Нәфыйков)**



Нәфыйков Ибраһим Шәйдулла улы Татарстанның Балык Бистәсе районындагы Биектау авылында 1937 елны туган. 1954 елны Котлы Бөкәш урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казанда техник училищеда укып электромонтаж һөнәрен үзләштерә. 1956 елны армиягә алына, очучылык буенча хәрби мәктәп тәмамлый, укчы-радист сыйфатында Ерак Көнчыгышта хезмәт итә. Демобилизациядән соң, 1959 елның ахырында туган якларына кайтып төрле эшләрдә эшли, өч ел буе Юлсубино (Балтач) авылы мәктәбендә укытучы була. 1970 елда Казан авиация институтын тәмамлап, Ижевск шәһәренә эшкә китә, хәзергә кадәр шунда яши, эшли, иҗат итә. Хезмәт гомеренең төп өлешен белгечлек эшенә—электрон радиоаппаратлары инженерлыгына багышласа да, Ибраһим Биектаулы мәктәп елларыннан башлап иҗат эшеннән аерылмады. 90 еллардан башлап шигърият өлкәсендә аерым игътибар биреп, профессиональләрчә шөгыльләнә башлады. Иҗатында кыска формаларны үз итә, остазлары итеп Тукай, Дәрдмәнд, Такташ, Равил Фәйзуллинны саный.

Ибраһим Биектаулының шигырьләре, публицистик мәкаләләре Татарстан ("Казан утлары", "Ватаным Татарстан", "Мәдәни җомга", "Шәһри Казан", "Татар иле" һ. б.) һәм Удмуртия ("Яңарыш", "Удмуртская правда" һ. б.) матбугатында еш басыла. Соңгы елларда басылып чыккан "Җирдән җиде җиһанга", "Галәм серләре" китаплары аны ил-халык язмышы турында җитди уйланучы шагыйрь итеп танытты.

Ибраһим Биектаулы, милләт җанлы кеше буларак, иҗтимагый тормышта да актив катнаша. Ул—Удмуртия Татар иҗтимагый үзәгенең президиум әгъзасы, "Яңарыш" газетасының актив язучысы.

Шагыйрь җыр өлкәсендә дә актив эшли. Аның байтак шигырьләре көйгә салынган.

Язучылар берлеге идарәсе утырышы Ибраһим Биектаулыны Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул итте.

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ЭШЛЕКЛЕ СӨЙЛӘШҮЛӘР, БӘЙРӘМИ МИЗГЕЛЛӘР

Президент Минтимер Шәймиев Киров өлкәсендә Татарстан мәдәнияте көннәрендә катнашты. "Татарстан-Нократ: без—бердәм Россия" дип аталган бу тантаналар Нократ Аланы (Вятские Поляны) шәһәрендә үтте.

Әлеге чаралар кысаларында Татарстанның Балтач, Арча, Кукмара районы иҗат коллективлары Киров өлкәсенең Килмәз, Малмыж һәм Нократ Аланы районнарында, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле Киров шәһәрендә чыгыш ясады. Президент Минтимер Шәймиев һәм Киров өлкәсе губернаторы Николай Шаклеин "Бердәм Россия" партиясенең җирле бүлекләре җитәкчелеге белән очрашты. М. Шәймиев бу өлкәдә яшәүчеләрнең Татарстан өчен һәрвакыт игелекле күрше булуына аеруча басым ясады. Татарстан Президенты үз чыгышында Киров өлкәсен бай төбәк дип атады, соңгы вакытта мондагы социаль-икътисадый тармакта унай үзгәрешләрнең аеруча күзәтелүен әйтте.

Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева белән Киров өлкәсе мәдәният һәм сәнгать департаменты башлыгы Владимир Микрюков Нократ Аланында ике төбәк арасында мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүгә кул куйды. Үзенең сәламләү сүзендә Зилә Вәлиева татар халкы тарихында Михаил Худяковның мөһим роль уйнавына басым ясады, мәшһүр рус тарихчысына Киров өлкәсендә яки Татарстанда һәйкәл кую турында сөйләшүләр алып барылуын әйтте. 2006 елның Татарстанда Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителүен билгеләп үтте. ТР Мәдәният министрлыгы җирле китапханәгә 150дән артык китап бүләк итте. Алар арасында Муса Җәлилнең "Моабит дәфтәре", татар классиклары әсәрләре бар.

Киров өлкәсендә Татарстан мәдәнияте көннәрен үткәрүдә Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты һәм Киров шәһәре татарларының милли-мәдәни автономиясе актив катнашты. Татарстан делегациясе составында Нократ Аланына күренекле әдипләребез Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Бөтендөнья татар конгрессы рәисе Ринат Закиров, "Бердәм Россия" партиясенең Татарстан төбәк бүлеге башкарма комитеты рәисе Виктор Бударин һ. б. килгән иде. Бәйрәм концертында Татарстанның һәм Киров өлкәсенең күренекле сәнгать осталары белән бергә безнең шагыйрьләребез дә чыгыш ясады.

## ИЛСУР МЕТШИН—КАЗАН МЭРЫ

Казан шәһәр Думасы утырышында шәһәр муниципаль берәмлегенең яңа җитәкчесе сайланды.

Сессиядә катнашкан 46 депутатның 45 е Илсур Метшинны (ул 12 мартта узган сайлауларда, Ваһапов сайлау округы буенча җиңеп, депутат булган иде) яклап тавыш бирде. Монарчы Илсур Метшин Казан муниципаль берәмлегенең башкарма комитетына җитәкчелек итте.

Казанның яңа сайлап куелган мэры Илсур Метшин ант кабул итте, шуннан соң Казан муниципалитетының сайлау комиссиясе рәисе Валерий Дашин аңа шәһәр мэры билгесен, муниципаль берәмлекнең иң югары дәрәҗәдәге вазыйфаи заты символын тапшырды.

Муниципалитет җитәкчесенең беренче урынбасары Рафис Борһанов, Илсур Метшинны әлеге вазыйфага сайлануы уңаеннан котлап, уңышлы эшләр теләде.

## ҮТКӘН ЕЛГА БЕР ХИСАП

Республика гаммәви мәгълүмат чараларының төп бурычы—Татарстанда, шулай ук Россиядә үткәрелеп килә торган икътисадый һәм социаль реформаларны югары һөнәри дәрәҗәдә яктырту.

Премьер-министр Р. Миңнеханов "Татмедиа" агентлыгы киңәшмәсендә (анда узган елга йомгак ясалып, агымдагы елга бурычлар билгеләнде) әнә шулай дип белдерде. Ул, киңәшмәдә катнашучылар алдында чыгыш ясап, агентлыкның оештыру-хокукый формасы иң әһәмиятле дәүләти һәм муниципаль бурычларны хәл кылу мөмкинлеге бирә, диде. Премьер-министр фикеренчә, республикадагы электрон, шулай ук басма мәгълүмат чараларының төп бурычы—бер яктан, өстәмә средстволар җәлеп итү, реклама урнаштыру, басмаларны кызыклы-

рак итү булса, икенче яктан, чыгымнарны оптимальләштерү.

Кайбер гаммәви мәгълүмат чараларын бердәм комплекска берләштерү техник базадан нәтиҗәлерәк файдалану, шулай ук эштә финанс чыгымнарын киметү мөмкинлеге бирер иде, дигән фикер әйтте Р. Миннеханов. Ә инде Татарстанның гаммәви мәгълүмат чараларын финанслау (бу юлы ул 500 миллион сум чамасы тәшкил итәчәк) турында сөйләгәндә, Премьер-министр грантлар системасын үстерүнең мөһимлеген әйтте.

Р. Миннеханов үз чыгышында Татарстан журналистларының һөнәри әзерлек мәсьәләсенә дә кагылып үтте. Аның әйтүенчә, журналист билгеле бер тема буенча югары дәрәҗәдәге белгеч кебек яза алырга тиеш.

Киңәшмәдә "Татмедиа" агентлыгы генераль директоры М. Моратов чыгыш ясады. Фикер алышуда Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова һәм башкалар катнашты.

### ӘДӘБИЯТЕБЕЗ БИЕКЛЕГЕН БАРЛАУ

К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында классик язучы, драматург, публицист, әдәби тәнкыйтьче, мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирханның тууына 120 ел тулуга багышланган "Чәчәкләр китерегез миңа" дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды. Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов ачып җибәрде. Аннары әдипнең иҗаты турында филология фәннәре докторы, Фоат Галимуллин сөйләде. Кичәнең икенче өлешендә театрлаштырылган тамаша тәкъдим ителде. Рольләрне К. Тинчурин театры артистлары, ә аерым номерларны җырчы һәм биючеләр башкарды.

Юбилей кичәсендә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, Мәдәният министрлыгының беренче урынбасары Рафаэль Вәлиев, Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев катнашты.

### ШАЛЯПИН ФЕСТИВАЛЕ

М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында Ф. И. Шаляпин исемендәге XXIV халыкара опера фестивале булып узды. Быел фестивальгә Австрия, Бөек Британия, Италия, Германия, Чехия, Украина, Казахстан һәм Россиядән 30дан артык җырчы җыелды. Мондый составның фестиваль тарихында әле булганы юк иде. Шаляпин фестивале премьера—Моцартның "Тылсымлы флейта"сы белән ачылды. Фестиваль көннәрендә музыка сөючеләр опера һәм балет театрында "Аида" (Дж. Верди), "Борис Годунов" (М. Мусоргский), "Травиата" (Дж. Верди), "Тоска" (Дж. Пуччини) кебек үлемсез сәнгать әсәрләрен карадылар.

### ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕН ЙӨРТКӘН ЛАУРЕАТЛАР

Республика яшүсмерләр китапханәсендә каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 100 ел тулу уңае белән әдәбият өлкәсендә Җәлил исемендәге республика бүләге иярәренең портретлар галереясе ачылды.

Аны ачу тантанасында Җәлил премиясе лауреатлары: Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллин, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, шагыйрь Разил Вәлиев, әдәбият белгече, тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, драматург Ризван Хәмид, "Татарстан" журналының баш мөхәррире Рифат Фәттахов, "Мәгариф" нәшрияте директоры Мөдәррис Вәлиев, шулай ук Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов катнашты.

Кичә барышында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Зөһрә Шакирҗан башкаруында Муса Җәлилнең шигырьләре яңгырады, лауреатлар иҗатын чагылдырган китап күргәзмәсе тәкъдим ителде.

Гамәлгә куелган көннән алып Муса Җәлил исемендәге бүләккә барлыгы 78 яшь иҗатчы һәм хезмәт коллективы лаек булган. Шул исәптән әдәбият өлкәсендә—15, сәнгать өлкәсендә—38 шәхес һәм иҗади коллектив Муса Җәлил исемендәге бүләк иясе дигән мәртәбәле исемне йөртә.

### ҖӘЛИЛ ӘСӘРЛӘРЕ МУЛЬТФИЛЬМДА

Муса Җәлил иҗатына нигезләнеп эшләнгән "Ана бәйрәме" дип аталган мультфильмның презентациясе булды. Каһарман шагыйрьнең "Ана бәйрәме", "Кызыл ромашка", "Чишмә һәм сандугач" шигырьләре буенча төшерелгән анимацион фильм 17 минут бара. Ул 3D технологиясе белән, ягъни әзер рәсемнәргә тирә-як мохитне тудыручы махсус 3 үлчәүле сурәтләр кушылып ясалган. Фильмда композитор Нәҗип Җиһанов көйләре файдаланылган. Аны Татарстанның халык артисты Рамил Төхвәтуллин җитәкләгән "Татарстан—Синема" иҗат берләшмәсе җиде ай эчендә төшергән. Аларга республиканың Кино сәнгатен үстерү фонды һәм РФ Пенсия фондының Татарстан идарәсе ярдәм иткән. Мультфильмның режиссеры—Рамил Төхвәтуллин. Рәсемнәрне компьютер графикасында Казан дәүләт техника университеты студентлары ясаган. Текстларны Г. Камал театры артистлары укый. Тиздән мультфильм DVD-дискларда сатуга чыгар, рус һәм инглиз телләренә тәрҗемә ителер дип тә көтелә.

### ТАРИХ ДӨРЕС ЯЗЫЛСЫН

ТР Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында үткән елдагы эш нәтиҗәләренә һәм перспективаларына багышланган киңәйтелгән гыйльми со-

вет утырышы узды. Гыйльми совет эшендә ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

"Без, тарихчылар, дәреслекне ни өчендер һәрвакыт ерактан эзлибез,—диде Дәүләт Советы Рәисе үз чыгышында.—Мина калса, бүгенге тарихчылар, соңыннан тирәнгә төшеп казымас өчен, бүгенге тарихны дөрес итеп язарга тиешләр. Моннан тыш, Россиядә тарихка кагылышлы уку дәреслекләрен бернинди контрольсез бастырып чыгару борчу тудыра. Мона һич тә юл куярга ярамый".

"Хәзергә мәктәптә тарихны укытуга үзгәрешләр кертү бик авыр,—дип аңлатма бирде ТР мәгариф һәм фән министры Рәис Шәйхелисламов.—Хәтта Татарстан мәктәпләрендә дә теге яки бу фактларны аңлатуда житди каршылыклар очрый. Шуна күрә дә без бүгенге көндә лицензия үтеп һәм тигез хокукларда мәгариф базарында Россиянекеләр белән көндәшлек итәрдәй тарих дәреслекләрен төзү өчен Тарих институты белән сөйләшүләр алып барабыз. Бәлки әле, тарихта татарларның ролен исәпкә алып һәм тарихи юлда безгә объектив бәя биреп төзелгән бердәм, килештерелгән тарих дәреслегенә дә күчә алырбыз".

## ТАТАРЛАР ТУРЫНДА ФИЛЬМНАР

Төркия дәүләт телеканалының "Чикләр кисешкәндә" программасы кысаларында Румыния татарлары тормышы турында фильм күрсәтелде. Тапшыруда элек Румыния татарларыннан парламент депутаты булган, хәзер исә андагы татар җәмгыяте житәкчеләренең берсе буларак татар дөньясында танылган Нәжип Сали катнашты.

Узган елның декабрь уртасында ТРТның II каналы исә Кырым һәм кырым татарлары турында фильм тәкъдим итте. Анда кырым татарларының сугышка кадәр, сугыштан соң һәм хәзерге тормышы турында 6 серияле фильм күрсәтү планлаштырылган. Серияләрнең берсе сугыш вакытында Германиягә барып эләккән төрек мөселман хатын-кызларының аянычлы язмышына багышланган.

## АЗНАКАЙДА ӘДӘБИЯТ БӘЙРӘМЕ

Азнакай районында үткәрелгән татар әдәбияты көннәренең үзенчәлекле ягы шунда: әлеге төбәктә яшәп иҗат итүче күренекле шагыйрь Илдус Гыйләжевкә 60 яшь тулу бу бәйрәмнең үзәген тәшкил итте, һәм ике көн дәвам иткән тантаналар Әдәбият һәм сәнгать елының югары дәрәҗәдә оештырылган күркәм бер чарасына әверелде.

Әдәбият бәйрәмендә Казаннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, шагыйрьләр М. Әгъләмов, Ф. Гыйззәтуллина, М. Галиев, З. Мансуров, Ф. Сафин, Р. Юныс, Р. Ягъфәров, Ж. Дәрзаман, Н. Сафина, Г. Морат, Р. Зәйдулла, Л. Лерон, Р. Корбан, Р. Рахман, драматург Д. Салихов, Казан дәүләт университеты профессоры Ф. Сафиуллина, Татарстанның халык артисты Ә. Шакиров, композитор Р. Гатауллин, Әлмәттән Язучылар оешмасы житәкчесе З. Дәүләтов, шагыйрьләр К. Булатова, Н. Әхмәдиев, Л. Кәшфи, язучы Ә. Сәлах, Чаллыдан Язучылар оешмасы житәкчесе В. Имамов, шагыйрь Р. Бәшир, Мөслимнән язучы Ф. Садриев, шагыйрь Мөҗәһит, Лениногорскидан язучы А. Хәсәнов һ. б.лар катнашты.

Шәһәр мәдәният сараенда үткәрелгән юбилей кичәсендә Азнакай район муниципаль берәмлеге башлыгы М. Хәйретдинов шагыйрь И. Гыйләҗевне ихлас тәбрикләп, аңа татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Президентының Рәхмәт хатын тапшырды. И. Ибраһимов үзенең котлау чыгышында юбилярга 2006 ел өчен Язучылар берлегенең Һ. Такташ исемендәге әдәби бүләк бирелү турында игълан итте.

Икенче көнне әдәбият бәйрәмендә катнашучы каләм әһелләре район үзәк китапханәсендә, шәһәр балалар китапханәсендә, туган якны өйрәнү музеенда, картиналар галереясында, "Дельфин" су-сәламәтләндерү комплексында, "Алтын алка" боз сараенда булдылар, татар гимназиясендә һәм 2, 5, 7 нче урта мәктәпләрдә укучылар белән очраштылар. Кичен алар, дүрт төркемгә бүленеп, шагыйрь И. Гыйләҗевнең туган авылы Урсайда, шулай ук Уразай, Әсәй, Тымытык авылларында үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәләрдә катнаштылар.

## "ЯРА" БҮЛӘК АЛА

Драматург Мансур Гыйләжев Мәскәүдән бүләк алып кайтты.

Мансур Гыйләжев—Мәскәүдә нәшер ителә торган "Хәзерге заман драматургиясе" журналының даими авторы. Әлеге журнал редакциясе драма әсәрләренә конкурс игълан иткән булган. "Бурыч, намус, дәрәҗә" дип аталган бу бәйгедә 130лап пьеса катнашкан. Жюри сайлап алган иң яхшы 7 әсәр арасына Мансур Гыйләжевнең "Яра" драмасы да кергән.

## ӘДӘБИ ПРЕМИЯЛӘР ЛАУРЕАТЛАРЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышында 2006 ел өчен әдәби премия лауреатлары игълан ителде. Идарә әгъзалары Г. Исхакый исемендәге әдәби премиягә "Һаваларда ялгыз торна" хикәяләр һәм повестьлар җыентыгы, соңгы еллардагы публицистика һәм актив иҗади эшчәнлеге өчен Зәки Зәйнуллинны, "Казан утлары" журналында чыгып килә торган "Миллият сүзлеге" өчен Адлер Тимергалинны лаек дип тапты.

Шулай ук ТР Язучылар берлегенең Ф. Хөсни исемендәге әдәби премиясенә "Чыктым аркылы күпер" әсәре өчен Л. Лерон, Һ. Такташ премиясенә "Яратканга күрә" китабы өчен Азнакайда яшәп иҗат итүче әдип Илдус Гыйләжев, Ж. Валиди

исемендәге әдәби премиягә "Казан утлары" һәм "Мирас" журналларында басылып чыккан әдәби тәнкыйть мәкаләләре өчен Казан дәүләт университеты галиме Дания Заһидуллина лаек дип табылды.

### ЯҢА ӘГЪЗАЛАР

Татарстан Язучылар берлегенең чираттагы утырышында берлеккә яңа әгъзалар кабул ителде. Алар арасында "Көмеш балдак" хикәяләр җыентыгы авторы, яшь прозаик Нурзилә (Нурзидә Нотфуллина), филология фәннәре докторы, әдәби тәнкыйтьче Фәрит Бәширов бар.

Шулай ук Төркиядә яшәп иҗат итүче шагыйрә, әдәбият белгече Чулпан Зариф та Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булды.

### ЕРАКТАГЫ ЯКЫН МӘСГҮДӘ

Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева Американың Сиэтл шәһәрендә яшәп иҗат итүче Мәсгүдә Шәмсетдинованың 50 яшьлегенә багышланган кичәсендә аны "Татарның тынгысыз җаны" дип атады. Һәм: "Мәсгүдә, бер яктан, татар традицион музыкасын саклаучы, икенчедән, үзенең иҗаты белән яңалыклар алып килә торган композитор. Ул татар халкының җанын, моңын тоеп зур әсәрләр дә яза, татар режиссерлары, артистлары белән дә эшли, фән белән дә шөгыльләнә... Мәсгүдә кайда гына торса да, кайда гына эшләсә дә ул татар сулышы белән халыкны таныштып яши",—диде юбилярны котлап.

С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында уздырылган юбилей кичәсендә М. Шәмсетдинованың танылган дирижер Фуат Мансуров җитәкчелегендә Татарстан дәүләт симфоник оркестры, "Хыял" камера хоры башкаруында "Чыңгызхан" симфониясенең өченче өлеше, "Дәрвиш" симфоник поэмасы, "Мәүлид-нәби" суфи әсәрләре яңгырады. Казанда беренче тапкыр башкарылган бу әсәрләр милли, дини тәсмерләргә бай, күңел кылларына тиярдәй, кичерешләрне уятырдай тирән мәгънәле. "Мөхәммәд пәйгамбәр туу" әсәре турында автор үзе: "Мин моны үзем өчен генә түгел, татар халкының нинди булуы турында күрсәтергә теләп эшләдем. Фольклор экспедицияләренә йөргәндә шуны аңладым: татарлар күркәм мәүлиднәби шигырьләрен тудырганнар. Әсәрне иҗат иткәндә аларны һәм Сөләйман Чәләби, Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури шигырьләрен файдаландым",—диде.

Кичәдә композиторның мөнәҗәт рухындагы әсәрләрен танылган җырчыларыбыз Зөһрә Сәхәбиева, Гөлзада Сафиуллиналар башкарды.

### ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЯКЛАДЫ

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт киңәшчесе Рафаил Хәкимов җитәкчелегендә эшләп килүче Тарих институты соңгы елларда татар тарихын фундаменталь өйрәнү буенча шактый гына нәтиҗәле эшләр башкарды. Бигрәк тә аспирантура ачылу, анда яшь галимнәрне туплау, татар һәм Татарстан тарихына багышланган фәнни монографияләр әзерләү һәм нәшер итү, мөһим тарихи мәсьәләләр буенча халыкара һәм Россия күләмендәге конференцияләр үткәрү эшләре җайга салынды. Хәзер инде биредә докторлык диссертацияләре яклау советы да ачылды.

Шушы яңа ачылган гыйльми советның беренче утырышында танылган тарихчылар Равил Фәхретдинов, Фаяз Хуҗин, Рәшит Галләмовларның ике шәкерте—авыл мәктәпләре укытучылары Рафыйк Насыйров белән Нурулла Гариф беренче диссертацияләрен якладылар. Мөгаллим Нурулла Гариф үзенең "Казан ханлыгында Чаллы олысы (Алтын Урдадан соң төрки-татар дәүләтләрендә феодал-вассаллык мөнәсәбәтләрен өйрәнү тәҗрибәсе)" дигән темага багышланган диссертациясен татар телендә язды һәм яклады.

### АВТОРЛЫК ХОКУКЛАРЫН БЕЛӘБЕЗМЕ?

Нәрсә ул интеллектуаль мөлкәт? Авторлык хокукларының асылы нинләрдән гыйбарәт? Мөгаен, бу сорауларга әле танылган язучылар, композиторлар, рәссамнар, галимнәр үзләре дә тулысынча һәм төгәл генә җавап биреп бетерә алмыйдыр.

Язучыларның Тукай клубында узган очрашу-семинарда сүз әнә шул хакта барды. Татар ПЕН-үзәгенең Мәскәүдәге вәкиле, юридик фәннәр кандидаты Борис Пантелеев нәкъ менә шул хакта лекция сөйләде, авторлык хокуклары һәм интеллектуаль мөлкәткә бәйле законнар, соңгы елларда бу мәсьәләдә Россия һәм Татарстан җирлегендә булган кайбер гыйбрәтле хәлләр белән таныштырды, шулай ук авторлык хокукын плагиатлыктан, һәртөрле үзләштерүләрдән яклау юлларын да искә алды.

Татар Пен-үзәге президенты, күренекле драматург Туфан Миңнуллин очрашуда күтәрелгән теманың бик мөһимлеген, мондый хокукый "ликбез"нең иҗат кешеләре өчен кирәкле булуын билгеләп үтте.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Тукай шигырьләре». Рәссам **Ә. Фәтхетдинов** эше.

# ЯҢА КИТАПЛАР




Равил Әмирхан. **Әмирханнар. Тәфсилле шәҗәрә.** — Казан: "Мәгариф" нәшр., 2005. —223 б. Тиражы—1000 данә.

Китапның керешендә тарихчы галим Марсель Әхмәтҗанов болай дип язган: "Милләтебез эчендә, сирәк булса да, бөтен нәселенең тарихын, тәфсилле шәҗәрәсен төзү юлына керешкән затлар да күренә башлады. Аерым алганда, Шиһабетдин Мәрҗани, бертуган Шәрәфләр һәм Әмирханнар варисларының эшчәнлеген бәяләп үтәргә була". Бу китап, чыннан да, галим раслаганча, татар халкының иҗтимагый, рухи һәм мәдәни тормышында гасырлар дәвамында күренекле роль уйнап килгән Әмирханнар нәселенә багышланган. Автор—Равил Әмирхан бу атаклы нәселнең бер варисы, тарих фәннәре докторы—ырунын XVI—XX гасырлардагы киң эшчәнлеген яктыртa, аның ин калку шәхесләре үрнәгендә иҗтимагый хәрәкәт, мәгърифәт, рухият өлкәсендәге казанышларын күрсәтә.

Китапның мөхәррире—Илсөяр Кадыйрова, бизәлеш рәссаме—Рәисә Сәйфуллина.




Рауль Мирхәйдәров. **Кара аксөякләр**: роман, повесть, әңгәмә. —Казан: "Рухият" нәшр., 2005. —472 б. Тиражы—1000 данә.

"Кара аксөякләр"—шул исемдәге сериягә караган романнарның берсе. Әлеге сериягә шулай ук "Җәяүле сәйран", "Кытай императорының сынары", "Мин хөкем итәм", "Һәрнәрсәгә—акчалата" романнары да керә. Алар һәркайсы дистәләрчә басма нәшер ителеп, хәзерге көндә гомуми тиражлары берничә миллион данә тәшкил итә.

Бу детектив романнар безнең тормышыбызга, хакимиятнең югары эшелоннары, спецслужбалары турында бинидһая күләмле фактик материалга нигезләнеп язылганнар.

Романның русчадан тәрҗемәчесе һәм мөхәррире Флүс Латыйфи, бизәлеш рәссамы—Ринат Хәсәншин.



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)